


# КАЗАН УТЛАРЫ

7
ИЮЛЬ
1979

# КАЗАН УТЛАРЫ

АЙЛЫК ӘДӘБИ ҺӘМ ИҖТИМАГЫЙ-ПОЛИТИК ЖУРНАЛ
ТАТАРСТАН ЯЗУЧЫЛАРЫ СОЮЗЫ ОРГАНЫ

1922 елның май аеннан башлап чыга

**7**
ИЮЛЬ
1979

## Бу санда

ТАТАРСТАННЫҢ 60 ЕЛЛЫГЫНА

**М. МӨХӘРРӘМОВ. Ленин декретлары белән** . . . 3
**А. РАСИХ. Сынау.** Роман . . . . . . . . . . . 10
**Н. ДӘҮЛИ. Хатлар килә миңа...** Шигырьләр . . 82
**М. ЮНЫС. Табу һәм югалту.** Повесть . . . . . 85

ДУСЛАР ҖЫРЫ

**Ә. ӘХМӘТХУҖИН. Алсу кош турында.** Шигырь . 116
**А. ХӘЛИМ. Гарсиа Лорка авазы.** Шигырь . . . 117
**Г. ДӘҮЛӘТОВ. Туган моңнар.** Шигырь . . . . 118

ЯШЬЛӘР ИҖАТЫ

**М. ГАЛИЕВ. Атлантида.** Шигырьләр . . . . . 119
**Ә. ГАДЕЛ. Кызыма.** Шигырьләр . . . . . . . 121
**Н. ӘХМӘДИЕВ. Мин — җирнеке!** Шигырьләр . . 123
**Р. РӘКЫЙПОВ. Диңгезче дәфтәреннән.** Шигырьләр . . . . . . . . . . . . . . . . . . 125
**Р. ЗӘЙДУЛЛИН. Алмагач.** Шигырьләр . . . . 127
**Л. ЗӨЛКАРНӘЕВ. Бәй өченмени ат — бәйге өчен.** Шигырьләр . . . . . . . . . . . . . . . 130

**М. ХУҖИН. Көрәшче.** Хикәя . . . . . . . . 132

ОЧЕРКЛАР

**М. ЗАРИПОВ. Яңа эш — киң колач** . . . . . . 138

ӘДӘБИ ТӘНКЫЙТЬ

**Р. МОСТАФИН. Каләм очында — КамАЗ** . . . . 152
**И. НИЗАМОВ. Публицистикага — кыюлык һәм осталык** . . . . . . . . . . . . . . . . . 160

ӘДӘБИЯТ ТАРИХЫНА МАТЕРИАЛЛАР

**Р. ХӘКИМОВ. Әдәбиятыбызда интернационализм идеяләре** . 168

КПССның
ТАТАРСТАН
ӨЛКӘ
КОМИТЕТЫНЫҢ
ГАЗЕТА ҺӘМ
ЖУРНАЛЛАР
НӘШРИЯТЫ
КАЗАН

КИТАП КҮЗӘТҮ

**Ф. ӘГЪЗӘМОВ.** Сүздән һәйкәл . . . . . . . . 175
**С. ПОВАРИСОВ.** Яшерен касса . . . . . . . . 179

Укучылар сүзе . . . . . . . . . . . . . . . 181

ЕЛМАЕП ТА, КӨЛЕП ТӘ...

**В. МОНАСЫЙПОВ.** Исеме булсын сәүдәгәр . . . 184
**Х. БАСЫЙРОВ.** Больницага эләктем . . . . . 186
**Ф. САБИРОВ.** Тапшыру . . . . . . . . . . . 187

Әдәбият һәм сәнгать яңалыклары . . . . . . 189



Редакциянең адресы. Казань, 420066, ул. Декабристов, 2.

Телефоннар: Баш редактор — 3-07-60, баш редактор урынбасары — 3-07-69, җаваплы секретарь — 3-07-09, проза бүлеге — 3-07-69, поэзия бүлеге — 3-07-69, тәнкыйть бүлеге — 3-07-63, сәнгать бүлеге — 3-07-63, очерклар бүлеге — 3-07-61, хатлар бүлеге — 3-07-61, корректорлар — 3-07-65, техник редактор — 3-07-65, машинисткалар — 3-07-60.



Баш редактор: **Зәки Нури**

Редколлегия: **Әхсән Баянов** (баш редактор урынбасары), **Шәүкәт Галиев, Аяз Гыйләҗев, Ләбибә Ихсанова, Шәйхи Маннур, Туфан Миңнуллин, Рәфыйк Нәфиков, Атилла Расих, Гали Халит, Сибгат Хәким, Нил Юзиев, Мирсәй Әмир.**



Техник редакторы *Р. Нәбиуллина*
Корректорлары *Р. Сөләйманова, Ф. Кадыйрова*

Производствога бирелде 22/III-1979 ел. Басарга кул куелды 7/VI-1979 ел. ПФ 07114. Кәгазь форматы 70×108 1/16. Учетн-изд. табак 14,2. Басма табак 12(16,8). Тираж 83349 экз.
Заказ Ц-113. Бәясе 50 тиен.

КПССның Татарстан өлкә комитеты нәшрияты типографиясе.
Казан, Декабристлар урамы, 2.



© «Казан утлары», 1979 ел.




**Мидхәт Мөхәррәмов,**
тарих фәннәре докторы

# ЛЕНИН ДЕКРЕТЫ БЕЛӘН

Кешелек дөньясы тарихында яңа сәхифә ачкан Бөек Октябрь социалистик революциясе җир йөзендә капитализмның таркалу, социализм һәм коммунизмның тантана итү чорын башлап җибәрде.

Революция ленинчы-большевиклар партиясе җитәкчелегендә әзерләнде һәм җиңеп чыкты. Социалистик революциянең төп проблемалары, стратегиясе һәм тактикасы партия һәм халыкның бөек юлбашчысы В. И. Ленин тарафыннан билгеләнде, партия документларында ныгытылды.

Халыклар төрмәсе булган царизм җимерелгәннән соң, большевиклар партиясенең политик һәм экономик платформасы В. И. Ленинның Апрель тезисларында һәм партиянең VII (Апрель) Бөтенроссия конференциясендә һәрьяклап яктыртылды, аныклачдырылды.

«Россиядә хәзерге моментның үзенчәлеге, — дип язды В. И. Ленин, — пролетариатның аңлылыгы һәм оешканлыгы җитәрлек булмау аркасында, революциянең властьны буржуазиягә биргән беренче этабыннан, аның властьны пролетариат һәм ярлы катлау крестьяннар кулына бирергә тиеш булган икенче этабына **күчүдән** гыйбарәт».

РСДРП(б) Үзәк Комитеты тарафыннан җибәрелгән күренекле революционер-ленинчы Виктор Александрович Тихомирнов җитәкчелегендә Казан большевиклар оешмасы яңадан аякка бастырыла. Күрәштә революцион тәҗрибә туплап һәм массаларны җитәкләү осталыгын үзләштереп, Казан большевиклар оешмасы тиз арада РСДРП(б)-ның иң оешкан, бердәм һәм сугышчан отрядына әверелә.

Партиянең VII (Апрель) Бөтенроссия конференциясендә сөйләгән речендә В. И. Ленин «Казандагы иптәшләр турыдан-туры социалистик революция мәсьәләләренә киләләр» дип белдерде.

Казандагы партия оешмасы сан ягыннан үсә, сыйнфый көрәш утларында чыныгып, сыйфат ягыннан ныгый. Башында В. А. Тихомирнов, И. Волков, Г. Ольkенецкий торган шәһәр коммунистлары, район оешмалары активистлары завод-фабрикаларда, Казан гарнизоны солдатлары арасында революцион агитацияне көннән-көн киңрәк җәелдереп, массаларга Ленин идеяләрен аңлаталар. Казанда чыгарылган «Рабочий» газетасы большевистик басмалар арасында иң яхшы, иң сугышчаннардан санала. Чистай, Бондюг һәм башка шәһәрләрдә һәм эшчеләр поселокларында да большевиклар нәтиҗәле эш алып бара. Бондюгта һәм Алабугада эшчеләрнең революцион хәрәкәтенә партиянең турылыклы көрәшчеләре Л. Я. Карпов һәм С. Н. Гассар җитәкчелек итә.

Татар большевиклары Камил Якубов, Миңнулла Вахитов, Якуб Чанышев, Садыйк Әхтәмов, Ногман Гайсин, Мөхәммәтҗан Мөхәммәтшин һәм башкалар — Казанда, Гаяз Гыйләҗетдинов — Алабугада, Ади Мәликов Тәтеш өязендә татар хезмәт ияләре арасында киеренке революцион эш алып баралар. Чистайда В. М. Бажанов, Г. И. Корнилов, И. Н. Гуськов, Н. И. Барышев, Ф. И. Миксин кебек революционерлар белән кулга-кул тотышып татар большевиклары Абдулла Исламов, Вәлиулла Рәхмәтуллин, Мөхлис Белялов һәм башкалар социалистик революциянең җиңүе хакына көрәшә.

Җирле шартларда революцион көчләрне туплауда Казандагы фабрика-завод эшчеләре хәлиткеч роль уйный. Промышленность предприятиеләре цехларында, эшче бистәләрендә коммунистлар партия идеяләрен, революцион максатларны аңлату һәм массаларны көрәшкә туплау эшчәнлеген даими алып баралар, эшчеләрнең фабрика-завод комитетлары һәм профсоюз оешмаларына берләшүен тәэмин итәләр.

Алафузов предприятиеләрендә эшчеләрнең революцион рухын Иван Яковлевич Гладилов, Семен Матвеевич Калин, Миңнулла Вахитов кебек сыналган җитәкчеләр чыныктыра. Алар 1905 елгы революция утларын кичкән, Столыпин реакциясе елларында да революцион рухны сүрелдермичсаклаган, яшерен шартларда массалар белән эшләү әмәлен белгән оста көрәшчеләр иде. 1917 елның март ахырында Алафузов фабрикасында эшчеләр комитетының үзәген Александр Антропович Константинов, Яков Лаврентьевич Хериков, Семен Алексеевич Протодъяконов, Сибгат Әхмәдуллин, Тәхау Сәйфетдинов, Ситдыйк Хөснетдинов, Ибраһим Зәйнетдинов кебек ялкынлы көрәшчеләр тәшкил итә.

Ә авыл җирләрендә революция җиңүе хакына бердәм булып рус, татар, чуваш, мари крестьяннары күтәрелә. Революцион хәрәкәт Спасс өязендә аеруча көчле була. Анда большевик Григорий Степанович Гордеев зур оештыру эше алып бара, крестьяннар хәрәкәтенә җитәкчелек итә. Казан гарнизонында исә солдатларны революцион рухта Николай Ершовның ялкынлы эшчәнлеге тәрбияли.

Большевиклар партиясе көчле революцион агымнарны — сыйнфый көрәш авангарды булган эшчеләр массасының социалистик хәрәкәтен, крестьяннарның революцион үзгәрешләргә омтылышын, халыкларның милли-азатлык хәрәкәтен һәм тынычлык өчен көрәшен уртак бер ташкынга берләштерде һәм бу ташкынның көче Россиядә капитализмның язмышын хәл кылды.

1917 елда, мәсәлән, татар халкының милли-азатлык хәрәкәте көнләп түгел, сәгатьләп үсте, көчәйде. Һәм бу хәрәкәттә ике капма-каршы лагерь — милли-азатлык өчен көрәш һәм буржуаз милләтчелек агымнары барлыкка килде һәм алар арасында тирән упкын хасил булды.

Татар эшчеләре һәм крестьяннары арасында революцион эш алып баруда татар большевикларына Мөселман социалистлар комитеты зур булышлык күрсәтте. Ул комитет 1917 елның мартында оештырылган иде. Аңа ялкынлы революционер Мулланур Вахитов белән берлектә Хөсәен Ямашевның көрәштәше, күренекле большевик Галимҗан Сәйфетдинов җитәкчелек иттеләр.

Мөселман социалистлар комитеты татар хезмәт ияләренең милли-азатлык хәрәкәтенә юнәлеш бирүче булды. Комитет тарафыннан чыгарылган «Кызыл байрак» газетасы татарлар яши торган иң ерак төбәкләргә дә барып җитә һәм аны укыйлар иде. Комитет составында большевиклар — Камил Якубов, Миңнулла Вахитов, Ибраһим Зәйнетдинов, Шәһит Әхмәдиев, Хасият Гайнуллин, Ибраһим Кулиев, Каюм Саттаров, Фатыйх Мөхәммәдъяров, Ситдыйк Хөснетдинов, Шиһаб Габидуллин, Вәли Шәфигуллин һәм башкалар тупланган иде.

Татар милли интеллигенциясенең прогрессив карашлы вәкилләре бу комитетның членнары булып та торды, күбесе, рәсми рәвештә комитет әгъзасы булмаса да, ул үткәрә торган политик линияне яклады, аңа теләктәшлек белдерде, иҗаты белән булышты. Тел галиме Гыймад Ногайбәк, драматург Галиәсгар Камал, актер, режиссер һәм драматург Кәрим Тинчурин, сәхнә остасы Габдулла Кариев Мөселман социалистлар комитетының таянычлары булдылар.

Күренекле революционер Шәһид Әхмәдиев приказчикларның демократик җәмгыятен оештырып, «Аваз» газетасын чыгаруны юлга салды. Бу басма үз укучыларына прогрессив карашларны үтемле итеп җиткерде.

Мулланур Вахитов, Шәһид Әхмәдиев һәм башка татар большевиклары милли-буржуаз оешмаларга каршы кискен, килешмәүчән көрәш алып бардылар, аларның контрреволюцион йөзен, халыкка каршы юнәлтелгән эшләрен фаш итеп тордылар. Милләтчеләрнең башлыгы булган Ф. Туктаров, С. Максуди, Ә. Цаликов, армиясез калган генераллар кебек, милли политика чытырманында буталып калды.

Партиянең тарихи VI съезды директивалары нигезендә Казан большевиклары кораллы восстаниене уңышлы әзерләде һәм аның җиңүен тәэмин итте.

Бөек Октябрь социалистик революциясе социаль һәм милли изүнең барлык формаларын юкка чыгарды, элекке Россия империясендәге бөтен халыкларга тигез хокуклар бирде.

Моның тарихи әһәмиятен билгеләп, үзенең «Бөек Октябрь һәм кешелек дөньясының прогрессы» дигән докладында КПСС Үзәк Комитетының Генеральный секретаре һәм СССР Верховный Советы Президиумы Председателе Л. И. Брежнев: «Милли мәсьәләне — кешелек җәмгыяте тарихында иң четерекле, иң драматик мәсьәләне хәл итү Октябрь казанышлары арасында аерым урын тота», дип белдерде.

Пролетариат диктатурасы урнаштырылуның беренче көннәреннән үк большевиклар партиясенең милли политикасы бөтен дәүләт күләмендә тормышка ашырыла башлады. Аны илебездәге барлык милләтләр һәм халыклар «ленинчыл милли политика» дип олылады.

Крестьянга — җир, эшчеләргә — завод һәм фабрикаларны, халыкларга тигез хокук биргән, тышкы политика нигезе халыкара тынычлык өчен көрәш булачак дип тантаналы төстә белдергән Совет властен барлык милләтләр дә гадел халык власте итеп таныды.

В. И. Ленин 1917 елның ахырында инде бик хаклы рәвештә: «Россиядәге халыкларның күпчелеге, барыннан да элек барлык милләт хезмәт иясе массаларының Совет властен тануы барысы өчен дә билгеле факт», — дип язды.

Буржуаз милләтчеләр, «үз» халыкларының ихтыярын һәм политик мәнфәгатьләрен санга сукмыйча, «сары шайтан» ялчыларына әверелеп, Халык Комиссарлары Советын — яңа властьны танудан баш тартуга барып җиттеләр. Менә бер мисал. 1917 елның 1 декабрендә Милләтләр Халык Комиссары И. В. Сталин Смольныйда Бөтенроссия мөселманнары советының рәисе Әхмәт Цаликовны кабул итә. Үзара әңгәмәдә сүз Совет власте һәм Россиядәге мөселман оешмаларының аңа мөнәсәбәтләре турында бара. Ә. Цаликов яңа власть органнары белән аралашу-аңлашуның барлык формаларыннан баш тарта.

Мондый шартларда, Совет властеның тарихи декретлары нигезендә милли политиканы тормышка ашыру, мөселман эшчеләр һәм крестьяннар арасында планлы һәм максатка юнәлтелгән эш алып бару өчен Үзәк Мөселман комиссариаты оештырыла. Аңа Мулланур Вахитов, Галимҗан Ибраһимов һәм Шәрәф Манатов җитәкчелек итәләр. Губерна һәм өязләрдә бу комиссариатның җирле органнары оештырыла. В. И. Ленин Мөселман Комиссариатының эше белән һәр вакыт кызыксынып, аның җитәкчеләренә даими булышлык итеп тора.

Мөселман комиссариатларының төп бурычлары итеп Совет властен ныгытуга юнәлтелгән чараларны тормышка ашыру, Совет дәүләте һәм большевиклар партиясенең политикасын пропагандалау һәм аңлату, милли-буржуаз оешмаларга һәм аларның агулы идеологиясенә каршы көрәш алып бару билгеләнә.

1918 елда Милләтләр Халык комиссариаты (Наркомнац) Татар-Башкорт республикасы оештыру турында «Положение» игълан итә. Чорның конкрет шартларында бу проектның политик әһәмияте зур булды, чөнки ул **совет проекты** иде.

Уфа шәһәрендә 1917 елның 20 ноябрендә Эчке Россия һәм Себер мөселманнарының Милли мәҗлесе ачыла. Түр башында С. Максуди һәм Б. Әхтәмов кебек милләтчеләр утырган әлеге «мәҗлес» «Идел — Урал штаты» дигән республика оештырырга карар итә. Бу инде милли дәүләтчелек төзелешендә **буржуаз проект** иде. һәм татар, һәм башкорт хезмәт ияләре халыктан аерылган «җилкәнсезләрнең» проектына каршы чыкты.

Үзәк Мөселман комиссариаты татарлар һәм башкортлар яши торган төбәкләрдә культура төзелешенә җитәкчелек итте. Татар телендә беренче совет газетасы булып тарихка кергән «Чулпан» газетасын комиссариат шул чакта чыгара башлый.

Советлар Россиясендә яшәүче барлык милләтләрнең интернациональ бердәмлеге гражданнар сугышының утлы-давыллы елларында аеруча ачык күренде.

Татарстан хәзер биләгән җирләрдән 1918—1919 елларда ике тапкыр сугыш давылы узды. В. И. Ленин чакыруына җавап итеп, Мәскәү, Петроград, Тула, Иваново-Вознесенск эшчеләреннән тупланган пролетар полклар Көнчыгыш фронтка ярдәмгә ашыкты. Алар Идел һәм Урал буйларында акгвардияче интервентларны тар-мар итүдә хәлиткеч роль уйнады. Гражданнар сугышында батырлык күрсәткән Владимир Азин, Николай Маркин, Ян Юдин исемнәре Татарстан тарихына алтын хәрефләр белән язылган, татар халкы күңелендә саклана.

Татар халкының батыр уллары һәм кызлары да Бөек Октябрь казанышларын, Совет властен саклап калу өчен, Тукай әйтмешли, сугышта арсланнан көчле булдылар, тынычта аттан артык эшләделәр. Беренче татар укчы бригадасы узган данлы юл әле дә булса җырларда җырлана.

Милли хәрби частьлар оештыруда, сугышчыларны шул чорның революцион рухында тәрбияләүдә һәм аларны командование куйган сугышчан бурычларны намус белән үтәргә әзерләүдә татар большевиклары зур эш башкарды. Мулланур Вахитов, Камил Якубов, Хөсәен Мәүлетов, Хәсән Урманов, Бәкер Белоусов, Шамил Усманов, Ади Мәликов, Якуб Чанышев, Гали Касыймов, Абдулла Рәҗәпов, Хаҗи Габидуллин, Бәдри Җиһаншин, Зөһрә Баимбетова, Зәки Кутлин, Юсыф Ибраһимов, Мәхмүт Шаһиәхмәтов, Нигъмәт Еникеев, Мөхәммәтсафа Корбанов, Нәбиулла Вахитов, Гомәр Әльмөхәммәтов, Мөхәммәт-Якуб Ильясов, Мөдәррис Вәлиәхмәтов, Хатыйп Алишев, Әхтәм Бахтизин һәм башка көрәшче-большевиклар, Кызыл Армиянең татарлардан торган частьларена җитәкчелек итеп, Совет властен яклау өчен барган көрәшләрдә дан казандылар.

В. И. Ленинның «чын-чыннан җитди һәм тирән политик мәсьәләдә группировкалар милләтләр буенча түгел, бәлки сыйныфлар буенча оеша» дигән сүзләре гражданнар сугышы чорында тулысынча расланды.

Татар буржуаз милләтчеләренең башлыклары Фуад Туктаров, Гаяз Исхаков, Бари Баттал, Гомәр Терегулов, Ильяс Алкин, акгвардияче бандалар белән элемтәгә кереп, үзләренең нинди «милләткә» һәм ничек хезмәт итүләрен күрсәттеләр. 1918 елның җәендә Казанга акчехлар кергәч, алар «Корылтай» дигән газета чыгара башлады. Аның һәр сәхифәсе, һәр юлы революцион халыкка каршы юнәлдерелгән иде.

Акгвардиячеләргә һәм чит ил интервентларына каршы сугышлар барган киеренке һәм авыр чакта да партия халык хуҗалыгын үзгәртеп коруга, милли культура мәсьәләләренә игътибар итәргә мөмкинлек тапты. Ленин һәм большевиклар партиясе милли политика һәм милли дәүләтчелек төзелеше проблемалары белән даим кызыксынып тордылар, аны хәл итүнең юлларын билгеләделәр.

Көнчыгыш халыклары арасында Коммунистлар партиясенең милли политикасын тормышка ашыруның дөрес юлын билгеләүдә мөселман-коммунистларның Мәскәүдә 1918 елның 4—12 ноябрендә үткәрелгән I Бөтенроссия съезды әһәмиятле роль уйнады. Оештыру мәсьәләләрен тикшергәндә, делегатларның күпчелеге М. Х. Солтангалиев һәм И. К. Фирдәвеснең «мөселманнарга мөстәкыйль компартия кирәк» дигән ялгыш карашларына отпор бирде. Съезд мөселман-коммунистларның оешмалары бердәм РКП(б)ның аерылгысыз өлеше булырга тиешләр, дип карар итте. Шунда ук Үзәк Мөселман Комиссариатының эшчәнлеге турында да карар кабул ителде һәм аның эшен яхшыртырга кирәклеге күрсәтелде. Съезд мөселман-коммунистлар оешмаларының Үзәк бюросын сайлады. Аның составына члennар итеп Камил Якубов, Буниат

Сардаров һ. б., кандидатлар итеп Нурулла Яруллин, Минһаж Конов, Мәхмүт Дулат-Али, Буниатзаде Дадашев, Исхак Рәхмәтуллин сайланды.

Съезддан соң партиянең Казан губерна комитеты һәм РКП(б)ның өяз комитетлары составында да мөселман бюролары оештырылды. Алар татар хезмәт ияләре арасында партия-тәрбия эшен туган телдә алып бардылар. РКП(б)ның Казан губкомында шулай ук чуваш һәм мари коммунистларының бюролары да оештырылды.

Татар һәм башкорт хезмәт ияләре арасында партия-политик эшне көчәйтү политиканың иң катлаулы проблемаларыннан берсе булган милли социалистик республикалар оештыру мәсьәләсен хәл итүгә юл ачты.

1919 елның март аенда Башкортстан автономия алды. Татар халкының милли дәүләтен булдыру өчен дә уңай шартлар туды. Революцион авангард — эшчеләр сыйныфы белән хезмәтчел крестьяннар союзы ныгыды. Авыр көрәшләрдә халыкларның ленинчыл дуслыгы чыныкты. Татарстан җирләре интервентлардан һәм акгвардиячә бандалардан азат ителде. Халык хуҗалыгын торгызырга керешкән территориядә партия, совет аппараты һәм хәрби белгеч кадрлар үсеп чыкты.

1919 елның 12—13 октябрендә Казан шәһәрендә җаваплы постларда эшләүче татар партия работникларының җыелышы булды. Анда мөстәкыйль Татарстан республикасы оештырырга кирәк, бу тарихи зарурлык дигән карар кабул ителде. Татар коммунистларының Казан губерна конференциясенең карары да шундый ук иде.

Татар һәм башкортлар өчен социалистик дәүләтчелек булдыру мәсьәләсе Көнчыгыш халыклары коммунистик оешмаларының 1919 елның 22 ноябрь — 3 декабрендә үткәрелгән II Бөтенроссия съездында җентекләп тикшерелде.

Бу вакытта В. И. Ленин, Мәскәүгә ыргылган Деникин армияләрен тар-мар итүне оештыру буенча гадәттән тыш киеренке эш алып баруга да карамастан, партиянең милли политикасын тормышка ашыру мәсьәләләренә дә игътибар итеп тора. Ул 1919 елның 21 ноябрендә Көнчыгыш халыклары коммунистик оешмаларының II Бөтенроссия съездында делегат булып катнашкан татар һәм башкорт вәкилләрен Кремльдә кабул итә. Әңгәмәдә РКП(б) Үзәк Комитетының кайбер члennары да катнаша. Съезд делегатларыннан монда Шәймәрдән Ибраһимов, Халик Садриев, Кәрим Хәкимов, Кадыйр Абдрахманов һәм башкалар була. Татар һәм башкорт коммунистларының чыгышларын зур игътибар белән тыңлаганнан соң, В. И. Ленин делегатларга съездның көн тәртибенә куела торган мәсьәләләр турында һәрьяклап уйланылган, нигезле күрсәтмәләр бирә. Татар һәм башкорт автономиясе мәсьәләсен хәл иткәндә, ул халыкларның үз ихтыярын, үз теләкләрен искә алырга кирәклеген әйтә.

Съездда мәгълүм булганча, Татар-Башкорт республикасы турындагы мәсьәлә һәм бу хакта 1918 елда ук игълан ителгән «Положение» тикшерелә. Милли хисләр агымыннан чыга алмаган татар делегатлары М. Х. Солтангалиев, М. Ю. Бурундуков, И. К. Фирдәвес съездда өстенлек алалар. Тавышларның бик аз өстенлеге белән алар берләштерелгән Татар-Башкорт республикасын оештыру эшен дәвам иттерергә дигән карар кабул иттерүгә ирешәләр. Тавышларның шулай икегә бүленүе нәтиҗәсендә, мәсьәләне хәл итү РКП(б) Үзәк Комитетына тапшырыла.

1919 елның 13 декабрендә РКП(б) Үзәк Комитеты Политбюросы Милләтләр Халык Комиссариатының Татар-Башкорт Совет республикасы оештыру турындагы 1918 ел, 22 март декретын гамәлдән чыккан дип карар итә, чөнки мөстәкыйль Башкортстан республикасы төзелгәннән соң инде әлеге декрет тормыш таләпләренә җавап бирә алмый. РКП(б) Үзәк Комитеты Политбюросының бу карары 1920 елның 6 гыйнварында Казан губерна комитеты утырышында, ә аннан соң, губком тәкъдиме белән, Мөселман бюросында тикшерелә. Шулай итеп, көн тәртибенә берләштерелгән Татар-Башкорт республикасы оештыру түгел, ә мөстәкыйль Татарстан автономиясе турындагы мәсьәлә килеп баса.

1920 елның 26 гыйнварында РКП(б) Үзәк Комитеты Политбюросы Татарстан АССРны оештыру мәсьәләсен карый һәм уңай хәл итә.

Шул ук елның 2 февралендә В. И. Ленин VII чакырылыш Бөтенроссия Үзәк Башкарма Комитетының беренче сессиясендә Комитет һәм Совнарком эше турындагы докладында: «Без Башкорт республикасына автономия бирдек. Без автономияле Татарстан республикасын оештырырга тиешбез һәм шундый ук политиканы Көнчыгышның башка барлык халыкларына мөнәсәбәттә дәвам иттерәбез», диде.

Партиянең милли политикасына кагылышлы мөһим проблемаларның күбесе, шул исәптән милли автономияләр мәсьәләсе дә, РКП(б) Үзәк Комитетының 1920 елның 21 февралендә игълан ителгән «Көнчыгыш халыклары арасында эшләүгә карата» дигән циркуляр хатында бик ачык чагылыш тапты. Бу хатта Үзәк Комитет мөселман массаларының совет строе шартларында милли үзбилгеләнүгә омтылышын коммунистлар дөрес аңларга, аңа теләктәшлек күрсәтергә тиеш, дип күрсәтте.

1920 елның 22 мартында В. И. Ленин РКП(б) Үзәк Комитеты каршындагы Көнчыгыш халыклары коммунистик оешмаларының Үзәк Бюросы җитәкчеләреннән С. Сәедгалиев, Б. Мансуров һәм башкаларны Кремльдә кабул итеп, алар белән Татарстан республикасын оештыру турында сөйләште. Үзәк Бюроның кайбер вәкилләре, бигрәк тә М. Солтангалиев, иске әләмгә ябыштылар — берләштерелгән Татар-Башкорт республикасы оештыруны яклап чыктылар. В. И. Ленин бу позициянең ялгыш һәм зарарлы булуын бик ышандырырлык итеп аңлатты. Бу урында шунысын да әйтеп үтик, ул вакытта партиянең Казан губкомында һәм губерна башкарма комитетындагы җитәкче работникларның кайберләре Татарстан республикасын оештыруның әһәмиятен тәгәл һәм ачык аңлап җитә алмадылар.

Мәскәүдә партиянең IX съезды барган көннәрдә шул съезд делегатларыннан Казан губерна башкарма комитеты председателе И. И. Ходоровский, РКП(б)ның Казан губкомы секретаре Г. С. Гордеев, губерна профсоветы председателе А. И. Догадов В. И. Ленин белән очрашалар һәм аңа Татарстан республикасы оештыруның файдасыз булуын нигезләргә тырышалар. Ходоровский, мәсәлән, татарлар арасында республикага җитәкчелек итәргә әзерлеге булган кешеләр юк, дип расларга тели. Җәй уртасында губернаның идарә органнарын үзгәртеп кору мәшәкатьләренең ашлык әзерләү буенча дәүләт планын өзүгә китерүе ихтимал дигән фикер дә белдерә. В. И. Ленин мондый фикерләрнең нигезсезлеген шундук ачып сала, аларның ялгышуларын күрсәтә. В. И. Ленин белән очрашудан соң Ходоровский һәм башкалар барысы да республика оештыруга карата ялгыш караштә торуларын бик яхшы аңлыйлар һәм соңыннан Татарстан АССРны төзүдә актив эшчәнлек күрсәтәләр.

РКП(б) Үзәк Комитеты һәм В. И. Ленин җитәкчелегендә башкарылган зур хәзерлек эшләре тәмамлаганнан соң, 1920 елның 4 маенда РСФСР Халык Комиссарлары Советы Татарстан автономияле республикасын оештыру турындагы декрет проектын әзерләү өчен комиссия төзи. Аның председателе итеп И. В. Сталин раслана, членнары С. Сәедгалиев, М. Владимирский һ. б. була. Шушы комиссия тарафыннан эшләнгән декрет проекты 1920 елның 25 маенда Халык Комиссарлары Советында тикшерелә һәм хуплана.

1920 елның 27 маенда В. И. Ленин һәм М. И. Калинин Татарстан Автономияле Совет Социалистик Республикасын оештыру турындагы декретка кул куялар.

Республика оештыру турындагы декрет Татарстан шәһәрләрендә һәм авылларында зур политик күтәренкелек тудыра. Һәркайда митинглар, җыелышлар уза, аларда катнашучы хезмәт ияләре — руслар һәм татарлар, чувашлар һәм марилар — барысы да Коммунистлар партиясенә, Совет хөкүмәтенә, бөек юлбашчы Ленинга рәхмәт белдерәләр.

Партиясез татар эшчеләренең Казанда үткәрелгән конференциясе, халыкның уртак фикерен чагылдырып, 1920 елның 12 июлендә III Коммунистик Интернационалның II Конгрессына телеграмма җибәрә. «Бары тик эшче-крестьяннарның Совет власте генә сыйнфый һәм милли изүне бетерә, нинди милләттән булуларына карамастан, хезмәт ияләренең тормышын яхшырту турында кайгырта. Татарстан Автономияле Совет Социалистик Республикасы игълан ителү — шуның ачык чагылышы», дип яза партиясез татар эшчеләре конференциясенең делегатлары.

1920 елның 8 июнендә РКП(б) Үзәк Комитеты Политбюросының утырышы була. Ленин председательлек иткән бу утырышта М. И. Калинин, М. Владимирский, С. Сәедгалиев, И. Ходоровский һәм башкалар катнаша. Монда Татарстанда партия һәм совет төзелешенә кагылышлы бик күп мәсьәләләр хәл ителә. Политбюро карары нигезендә, ТАССРда партиянең югары органы итеп РКП(б)ның өлкә комитеты билгеләнә, аның Татарстан республика партия конференциясендә сайланырга тиешлеге зарур итеп куела. Өлкә Комитеты оештырылганчы, аның функцияләрен РКП(б)ның Казан губкомы башкара. Политбюроның шул ук утырышында ТАССР Вакытлы революцион комитеты

(ВРК) составы да тикшерелә, соңыннан ул Бөтенроссия Үзәк Башкарма Комитеты тарафыннан 1920 елның 10 июнендә раслана. ВРК председателе итеп С. Сәедгалиев, членнары И. Казаков, К. Хәкимов, И. Ходоровский, А. Бочков һәм башка җитәкче кадрлар раслана. Политбюроның 1920 елгы 6 июнь карарында Казан шәһәр советын төзү дә хәл ителә. Аңарчы бөтен эшләрне губерна башкарма комитеты үтәп килгән була.

1920 елның 25 июнендә, тантаналы җыелышта, Казан губерна башкарма комитеты үз вәкаләтләрен Татарстан АССРның Вакытлы революцион комитетына тапшыра. Шул дата Татарстан АССР төзелгән көн булып тарихка керде.

РКП(б)ның I Татарстан өлкә конференциясе 1920 елның 23 августында ачыла. Анда губком секретаре К. Машкинның докладлы тыңлана һәм өлкә партия оешмасының агымдагы эшләре — фронтка ярдәмне көчәйтү, халык хуҗалыгын торгызу, идеологик эшне яхшырту бурычлары билгеләнә. Конференциядә партиянең Татарстан өлкә комитеты сайлана. Аның составына А. И. Бочков, С. Сәедгалиев, Н. А. Ванькова, А. П. Таняев, И. И. Ходоровский, Б. Гольдберг, Н. И. Барышев, И. Е. Табейкин, И. А. Дерунов, Х. З. Гайнуллин һәм башкалар кертелә.

Тагын бер айдан, 1920 елның 26—27 сентябрендә Татарстан АССР Советларының I Учредительный съезды була. Аның делегатлары — татар, рус, чуваш, мари, башкорт халыкларының вәкилләре Татарстан АССР төзелүне Коммунистлар партиясенең зирәк милли политикасының тарихи казанышы дип бәялиләр һәм беренче рәхмәт хисләрен большевиклар партиясенә нигез салган, Совет дәүләтен оештырган бөек Ленинга юллыйлар. Съезд Россия Федерациясенең Үзәк Башкарма Комитетына котлау телеграммасы җибәрә, илебез халыкларына социалистик дәүләт төзүдә зур булышлык иткән Россия эшчеләр сыйныфына рәхмәт белдерә.

Съездда Татарстан Советларының Үзәк Башкарма Комитетына 59 кеше сайлана. Алар арасында элекке Вакытлы революцион комитетының җитәкчеләре Сәхибгәрәй Сәедгалиев, Борһан Мансуров, революцион эшчәнлеген Мөселман социалистлар комитетында башлаган Хасият Гайнуллин, профсоюз эшлеклесе Александр Иванович Догадов, партия работнигы Александр Петрович Таняев, РКП(б)ның элекке Казан губкомы каршындагы Мөселман бюросы җитәкчесе Исхак Казаков, Минзәлә өязе укытучысы, соңыннан республиканың беренче халык мәгарифе комиссары булган Хәсән Шаһисолтанович Солтанов, РКП(б) Үзәк Комитеты каршындагы Көнчыгыш халыклары коммунистик оешмалары Үзәк Бюросы членлыгына кандидат Нурулла Яруллин, 1918 елда Мулланур Вахитов белән бергә Мөселман Комиссариатында эшләгән Минһаҗ Гайнетдинович Конов, 1907 елдан партия члены Абдрахман Юсупович Измайлов, татар хатын-кызлары арасында актив эш алып барган Зөһрә Әхтәмовна Баимбетова һәм башкалар бар.

Татарстан Үзәк Башкарма Комитетының председателе итеп Борһан Мансуров сайлана. Беренче утырышта ук республика хөкүмәте — Татарстан АССР Халык Комиссарлары Советы оештырыла, аның председателе итеп күренекле революционер Сәхибгәрәй Сәедгалиев сайлана.

Бөек Октябрь социалистик революциясенең җиңүе һәм коммунистлар партиясенең ленинчыл милли политикасы нәтиҗәсендә татар хезмәт ияләренең социалистик дәүләте барлыкка килде. Татар халкының тормыш офыклары киңәйде, аңа политик, экономик һәм культура үсешенә ирешү өчен киң мөмкинлекләр ачылды.

Ленин декреты белән туган Татарстан республикасы, тугандаш халыкларның тату семьясында, тиңнәр арасында тиң булып яши, иҗат итә, тормышның һәр өлкәсендә яңадан-яңа үрләр яулый.

## Атилла Расих

# СЫНАУ

РОМАН

### БЕРЕНЧЕ БҮЛЕК

### 1



Саргылт чәчле нәни кыз бала диван-караватта йомарланып яткан килеш зур бүлмәдә бер үзе тынычсызланып йоклый иде. Юрганы идәнгә төшеп киткәнгә, ул бик туңгандыр, ахры, куллары белән кечкенә тар күкрәген кочкан, тезчекләрен шәрә тәненә кыскан, ара-тирә тартышып куя.

Буй-буй зәңгәрсу төстәге пижама кигән зур башлы, төз гәүдәле карт кеше бүлмәгә кереп, бала янына килде, сак кына хәрәкәтләр белән аның өстенә юрганын япты, шыпырт кына, яратып:

— Сары чебием минем, — дип пышылдады, — тагы кайтмады бит, җүнсез...

Карт бары үзенең йөрүен генә белгән түгәрәк циферблатлы стена сәгатенә карап алды. Көн яктырып килә иде инде. Бишенче ярты. Баланың йөзен каплаган тузгак, йомшак чәчен дә сыпырып куймакчы иде ул. Тик әллә ни тагы уятырмын дип, бу уеннан кире кайтты, иелгән җиреннән турайды, борчымаска булып, әйбәт җиһазландырылган иркен бүлмәдә оныгын тагы япа-ялгыз калдырган хәлдә, үз бүлмәсенә таба юнәлде.

Ул күршедәге тар гына бүлмәгә керде. Монда электр лампасы кабызылган, бик якты иде. Ишектән кергәч тә сул якта затлы агач карават, карават каршында, уңда, көзгедәй ялтырап торган эш өстәле, аның ике ягында түшәмгә кадәр күтәрелгән китап киштәләре. Бу — аның йокы һәм эш бүлмәсе. Агай күптән уянган иде инде. Ә, дөресрәге, йоклады микән әле ул бүген? Авыр хәсрәт чигеп, куертыбрак әйткәндә, җан газаплары кичереп яши иде бу олы яшьтәге кеше. Барысына да сәбәп кызы Сафура белән уртак тел тапмау булды. Моннан бер ел элек Сафура, әнисе Мәгъмүрә үлгәч, Казанга кайтты. Чит шәһәрдә, Ростовта, яшәде моңарчы. Бер яшь лейтенантка кияүгә чыгып, шунда киткән иде. Күрәсең, ире белән тату яшәмәгәннәрдер. Их-

тимал, энисенең үлүе һәм атасының япа-ялгыз килеш өч бүлмәле квартирада калуы да сәбәп булгандыр, ул озын-озак уйлап тормыйча, ирен ташлап, баласы Лиана белән этисе янына бөтенләйгә Казанга кайтты. Кайткач, алар бер ай чамасы тату гына ата белән кызга хас мөнәсәбәтләргә ригая саклап яшәделәр. Ләкин, кызганычка каршы, бу хәл бер ай гына дәвам итте. Дәгъва Сафураның хезмәт иткән урынына карата башланды. Атасы, аңа яхшылык эшлим дип, аны үзенчә бик әйбәт, тырышканда үсү мөмкинлекләре күренеп торган эшкә, фәнни-тикшеренү институтларының берсенә, урнаштырган иде. Янәсе, тырышып эшләсә, диссертация дә язар, гыйльми дәрәҗә дә алыр.

Тик ул көткәнчә булмады. Карт юкка гына абруен саткан икән. Сафура бер атна чамасы эшләгәч тә юньлерәк эшкә урнаштырмауда, бердәнбер кызын кеше мәсхәрәсе итеп гади лаборантлык хезмәтенә тыгуда этисен гаепләп үпкә белдерде. Аһ, ата кеше кызының үсеп буйга җитү белән аның үзен санламый башлавын, үзен генә түгел, хәтта мәрхүмә әнисен дә еш-еш кимсетүен яхшы белә иде бит! Үзгәргәндер, үзен сөеп, иркәләп, булганның берсен дә кызганмыйча үстергән кызы хәзер үзгәргәндер, аны дөнья күрү, кияүдә булу, үзенең дә ана сыйфатында кызы Лиананы тәрбияләве үзгәрткәндер дип уйлаган иде. Күрәсең, ул кызының артык эгоистлыгын, артык үзсүзлелеген онытып җибәргән...

Менә шуннан китте. Сафура институтны ташлап икенче эшкә күчте, анысын да ошатмады, өченче урынга китте. Ниһаять, үзенә хуш килгән ниндидер дуслары киңәшен тотып, ул, югары белемле булуына карамастан, бер министрлыкка секретарь-машинистка булып урнашты. Әмма Сафура бу соңгы хезмәтеннән дә разый түгел иде. Хәзер эшендә килеп чыккан һәрбер уңайсызлык өчен, үзен кимсетү булып тоелган һәр сүз өчен, этисен гаепли башлады. Ул бераздан пенсионер этисен гомумән исеменә, дәрәҗәсенә лаек бер кешегә дә санамас булды. Сафураның фикеренчә, карт ашын ашаган, яшен яшәгән, хәзер инде фани дөнья белән араны кисәргә тиеш, бары бердәнбер эш белән шөгыльләнергә, ул да булса, кызын һәм оныгын карарга, аларга хезмәт итәргә тиеш дип карый иде. Сафура Лиананың барлык мәшәкатьләрен бабасына йөкләде. Ул аны бакчага илтергә, бакчадан алып кайтырга, вакытында ашатырга, уйнатырга, күңелен ачарга, циркка, курчак театрына алып барырга һәм башка эшләрне башкарырга тиеш.

Юк, хәзер бабакай кызының рөхсәтеннән тыш өйдән чыгарга да хаклы түгел иде. Хәтта шулай: әгәр өй эшен карт үзе башкармаса, беркем дә моны эшләмәячәк. Әгәр карт кибеттән азык-төлек алып кайтмаса, беркем дә анда бармаячак. Алай гына да түгел, ачык ярага тоз сипкәндәгедәй, күңелне сыкрата торган хәкарәтләү сүзләре явачак әле картка. Ничек инде оялмый ул! Пенсионер бит! Бер эше дә юк! Аның кызы министр приемныенда ат урынына эшли, капризлы начальникларның теләсә нинди йомышларын үтәп интегә. Бу кадәр дә намуссыз, рәхимсез кеше булыр икән безнең эти!

Менә шулай. Хәер, Сафура ике атнага бер идән юа, дөресрәге, юган булып маташа. Чөнки көяз, купшы кулы белән идән чүпрәген чеметеп тота һәм идәнне бары бер кулы белән ышкый.

Булдыра алмый икән, анысы инде, әйдә ярар, һәркем һәрнәрсәне булдыра ала димәгән. Бәла бары шунда: ул бит булдырырга да теләми. Менә ничек! Инде тормыш иткәндә беренче ихтыяҗ булып алга баскан эшләрне өйрәнү, булдыра алмасаң, булдырырга тырышу, ул бит, җаным, көн итүнең беренче бисмилласы.

Еш-еш Сафура үзенә тиң дип тапкан дусларын өйгә алып кайта. Алар төнге берләргә кадәр шаулашып олы бүлмәдә утыралар. Вино

эчәләр — бары сухойны, марочныйны! Радиолада модалы көнбатыш музыкасын үкертәләр, кул-аякларын, күкрәкләрен, арт саннарын оятсыз чалыш-чолыш уйнатып, муеннарын паралитикларча алга-артка котсыз селкетеп биилэр. Анысы да ярый, әйдә, теләсә нишләсеннәр, модасы шул икән, аны кемдер үзгәртә алмый, әлбәттә. Ләкин ни өчен алар пычратканнан соң савыт-сабаны үзләре юып китми? Ни өчен моны Сафураның картайган этисе эшләргә тиеш? Әйтсәң, син бит буш кеше, ни эшең бар, шуны да эшләмәгәч, диелә. Син борынгы карашларыңда кристаллашып, катып калгансың, эти. Син һаман үзеңнең феодал законнарыңны миңа такмакчы буласың! Барып чыкмас! Кеше бул. Син эти икәнлегеңне онытма!

Ичмаса, пенсиягә китмәгән булсачы! Әйттеләр дуслар. Юкка дуамалланасың, диделәр. Тыңламады. Янәсе, принципиаль кеше ул. Китте. Һәм нәрсә? Хатыны белән соңгы картлык көннәрен тыныч кына уздырырбыз, моңарчы вакыт булмау аркасында һаман киләчәккә калдырып килентән үзебез теләгән эшләрне рәхәтләнеп эшләрбез дигәндә, менә хәзер кызыңның, ахмак һәм кешелексез кызыңның, колы, хезмәтчесе булып яшә!

Менә шундый шартларда ул инде бер елдан бирле көн итә иде. Ләкин артык мөмкин түгел. Ул бүген үк китәргә карар кылды. Бу өйне ташлап, тинтәк Сафураны калдырып, үз иркенә куеп, әйдә, миннән башка гына яшәп карасын әле, бәлки кадеремне белер, дип...

Ул Әлфия янына китәчәк. Әлфия исә шулай ук аның кызы, ләкин үзенеке түгел, асрамага алынган кызы. Әмма үз кызыннан да якынрак, мәрхәмәтле, хәлим, кешегә хөрмәт күрсәтә белә торган кыз ул.

Карт, бүлмәсенә керү белән, кабаланып язу өстәленең уң яктагы өске тартмасын ачты. Барлык документлары шунда саклана аның. Исәбе шуларны иртәдән үк барлап, киткәндә алырга тиешлеләрен аерып кую иде. Кичкенә өстәл тартмасы документлар һәм башка кадерле истәлекле әйберләр белән шыплап тутырылган. Карт аларны күзләрне чагылдырып ялтыраган өстәл өстенә берәм-берәм, ашыкмыйча гына куя башлады. Кулына полиэтилин капка пөхтәләп салынган каты, кызыл тышлы дипломнары эләккәч, ул ирексездән тукталып калды. Баштагы максатын беразга онытып, үзе дә сәбәбен аңламастан, шул катыргы документларны шытырдавык кабыннан тартып чыгарды. Карт хәзер, күзләре белән генә елмайган хәлдә, дипломнарын актарып, күңел түрендә сакланган җылы истәлекләренә чумды. Дипломнар дүртәү иде. Аларның берсендә Галиәкбәр Хафиз улы Максудовның мең тугыз йөз илленче елның июнендә уңышлы рәвештә диссертация яклап, авыл хуҗалыгы фәннәре кандидаты дигән гыйльми дәрәҗә алганлыгы расланган. Икенче диплом исә аңа доцент дигән исем бирелү турында. Кандидатлык дәрәҗәсен яклаганнан соң сигез ел узмады, Галиәкбәр абзаң докторлык диссертациясен дә әзерләп өлгерде. Ә мең тугыз йөз алтмыш беренче елның язында ВАК[1] аңа бирелгән профессор исемен раслады. Галиәкбәр бу кадерле, истәлекле документларын тәмам онытылып, беренче тапкыр күргәндәй ләззәтләнеп, тәмләп тикшереп укырга керешге.

Бар иде дәртле, янып эшләгән чаклар. Барысы да, барысы да гыйльми эш башкаруга бирелде ул вакыт. Мәрхүмә Мәгъмүрә аңа барлык шартларны тудырырга тырышты, иренең эшендәге һәрбер омтылышы аның өчен дә бик-бик кадерле иде.

Галиәкбәр, күзләрен кыса төшеп, үзенең язу өстәле түренә куелган Мәгъмүрә портретына карап торды. Путалы калын пыяла кыса аша

---

[1] ВАК — (русча) югары аттестация комиссиясе.

хәзер инде бөтенләй картайган иренә мөлаем бер караш белән текәлгән иде хатын.

Иң күркәм чагында, әле кырык яше дә тулмаган вакытта, алдырган иде бит ул бу рәсемне. Хас иренең үтенүе буенча, истәлек итеп, һәр вакыт кесәдә, бумажникта йөртү өчен...

Түгәрәк йөз, озын керфекле нурлы күзләр. Арттан өеп, шомартып таралган чәч. Мәрхүмәнең портреты аша узган көннәрен еpoints күргәндәй, Галиәкбәр үзенең кандидатлык диссертациясен яклавын хәтерләде. Оппонентларның берсе диссертант остазының дошманы иде. Ул хезмәтне юкка чыгарырга бар көченә тырышты, юк-барга бәйләнеп маташты. Тирләп-пешеп чыкты. Пенсне күзлеген әле киде, әле салды. Мәгәр әллә ни майтара алмады. Чөнки эш методик яктан да, башкару җәһәтеннән дә бик камил. Әйе, оппонент, хәзер инде мәрхүм профессор, гыйльми совет членнарын ышандыра алмады, һәм ахырда бары бер үзе генә аңа каршы шар салучы булып калды. Ул җиңелде. Галиәкбәр, ул чагында тырыш — тапкыр аспирант, тантана итте. Ләкин бу тантана арзанга төшмәде. Каны җитәрлек бозылды аның бу гыйльми совет утырышында. Ә өйдә, өйдә? Мәгъмүрә аны ут йотып көткән иде бит. Галиәкбәр, диссертациясен уңышлы яклап, бу хәбәрне телефоннан әйткәч, ул, һич тыела алмастан, шатлыгыннан кычкырып елап җибәрде.

Ә докторлык диссертациясен Галиәкбәр Мәскәүдә үзе укыган институтта яклады. Бусы өчен дә аның Мәгъмүрәсе аз янмады, аз көймәде.

Әмма шулай да шатлыклы, бәхетле чаклар иде бу. Кайтарасы иде шул көннәрне!

Галиәкбәр өстәл тартмасыннан кызыл төстәге катыргы тартмалар чыгара башлады. Алар икәү иде. Ачып карамый булдырмады. Тартмаларда аның орденнары, медальләре саклана. Аларның күбесе әле өр-яңа, күз явыңны алып алтын һәм кызыл эмальләрен елкылдатып торалар, кайберләре исә, фронтта алынганнары, инде шактый тоныкланган, аларның муар тасмалары искерә төшкән. Галиәкбәргә Өченче Дәрәҗәдәге Дан һәм Кызыл Йолдыз орденнары, Батырлык һәм Германияне Җиңү медальләре биргәннәр иде. Ул аларның һәрберсен учына салып карап утырды. Уйлары аны моннан инде күп еллар элек булып узган, ә бер караганда әле кичә генә кичерелгәндәй хәтердә нык саклаңган көннәргә алып китте. Ул тагы онытылды. Әйе, сугышта ул үзенең иң гүзәл, иң матур яшьлек елларын калдырып кайткан иде. Каһәр суккан сугыш, илнең, кешенең нинди гүзәл омтылышларын җимермәде ул. Сугыш, дуамалланып, тәнгә генә түгел, күңелгә, калебкә тирән канлы яралар ясап узгач та, әле һаман артында гына посып торган карачкыдай күңелне шомландырып интектерде бит. Галиәкбәр ачы кычкырып атакага ташлануларын төшләрендә күреп ничә ел азапланмады?! Ничә ел буена аны бастырылулар, саташып уянулар эзәрлекләмәде шул сугыш аркасында!

Тартмаларның икенчесендәге орден-медальләрне Галиәкбәргә сугыштан соң, инде гыйльми хезмәткәр булып шактый эш күрсәткәч бирделәр. Анда ике Хезмәт Кызыл Байрагы ордены һәм медальләрнең Ленинның йөз еллыгына чыкканы, аннары әле моннан ике ел элек кенә тапшырылганы — пенсиягә киткәндә бирелә торганы иде. Галиәкбәр шул урак-чүкеч сурәте төшерелгән һәм «Хезмәт ветераны» дип язылган көмеш медальгә озак карап утырды. Бу — институт белән, үзе яратып, бирелеп җигелгән авыр, ләкин татлы хезмәте белән мәңгегә саубуллашу, аерылышу билгесе. Галиәкбәр аксыл кашларын җыерып, күңелсезләнеп утыра башлады. Ул кайта-кайта шул медальгә карап уйланды. Авыр көннәрнең билгесе иде бу. Бөтен гомереңнең төп максаты булган куанычлар чыганагы белән аерылышу билгесе.

Ниһаять, күңелсез тойгыларын җиңде карт, аңарда хәтта бер наян теләк туды: ул булган барлык орден-медальләрен күкрәгенә тагып карарга булды. Юри, кызык итеп, бәйрәм көннәрен искә төшереп... Җәһәт кенә урыныннан торды, пижамасын салып ташлады, караватянындагы шифоньердан пинжәген алды һәм шунда икеләнеп тукталып калды. Ничектер оялта иде, кемдер карап торыр һәм Галиәкбәрнең балалануыннан мыскыллап көләр сыман иде. Ләкин теләк шул кадәр көчле иде ки, Галиәкбәр, һич тә тыела алмастан, кеше күрмиме дигәндәй ишеккә карап алды да, пинжәген киеп, орденнарын күкрәгенә тага башлады.

Барысы да тагылып беткәч, ул шифоньер ишегенә беркетелгән бөтен буй-сынны күрсәтмәле көзге алдына килеп басты. Картның каршында хәзерябык чырайлы, агара башлаган куе кашлы һәм апак кыска мыеклы, сирәк чәчле, җәенкерәк борынлы, буйчан, ябык бер олы кеше басып тора иде. Күкрәген бизәгән купшы орден-медальләргә һич тәңгәл түгел иде кебек көзгедә күренгән картның кыяфәте. Төссезләнгән күзләрендә рәнҗү, төшенкелек, буй-сынында мескенлек чагыла иде аның.

— Һи-и,— дип куйды Галиәкбәр,— килешмәгәнне!

Ул гәүдәсен турайта төште, тәртипсез чуалган чәчләрен сыпырып куйды, үзен елмаерга мәҗбүр итеп:

— Ю-у-к, аллам сакласын, китәм дигәч китәм,— диде.— Ахмак, юләр! Сафура капризларына буйсынып торырга әллә теге мин! Тапкан бичара корбан тәкәсен.— Ул орден-медальләрен чыңлатып нык адымнар белән бүлмәне бер әйләнде дә, бүләкләрен тартмаларга ашыга-ашыга кире тутыра башлады. Алып китәсе документларын бумажнигына салды. Инде пинжәген элеп кую өчен шифоньерга таба атларга өлгермәде — күрше бүлмәдән яңгыравык бер тавыш ишетелде. Лиана: «Давати, давати»,— дип кычкыра иде. Ул «дәү әти» диясен шулай бозып әйтә. Галиәкбәрнең кинәт күзләре йомылды, йөзенә татлы, җыерчыклы елмаю билгеләре чыкты. Пинжәген караватына куйды да:

— Әү, минем сары песнәгем, әү, күгәрченем,— дип сөйләнеп олы бүлмәгә таба атлады. Анда Лиана уянган, үзе йоклаган җыелмалы диван-караватка торып баскан, кыскара төшкән ал чәчәкле фланель пижамадан, ак нәни трусиктан корсагын киергән килеш кулларын сузган хәлдә бабасының үзен күтәреп алуын көтеп тора иде.

— Давати, кушать хочу,— диде ул, әле йокысы качмаган соры күзләрен кыскалап, авызын очландырып. Аннары нәни авызын ачып, иснәп куйды. Ана телен белми иде бала. Сафура өйрәтмәгән, барыбер бетә, кирәксез нәрсә ул дип санаган. Казанда баланың бу житешсезлеген бабасы төзәтергә тырышты. Мәгәр ирешкәне шул: «давати» дигән сүздән ары китмәде. Галиәкбәр бу кадәресенә дә, әлбәттә, шат иде.

Ул баланы күтәреп алды:

— Бигрәк иртә уяндың, кызым, әле йокың туймагандыр ич? — диде.

— Я кушать хочу,— дип кабатлады Лиана, тагы нәни авызын очландырып.

Алар кухняга чыктылар. Бераз тамак ялгап алгач, Лиана әле яңа гына уянып киткәндәй бик житди рәвештә:

— Мама вернулась? — дип сорады. Галиәкбәр йөрәгенең чәнчешеп авырта башлавын тойды. Онықны күкрәгенә тагы да ныграк кысты. Һәм кинәт шул чак әле генә орденнарын тагып китәргә сүз бирүе исенә төште. «Я, хода, рәхимсез Сафурага ачудан бу гөнаһсыз сабыйны ничек ташлап китәргә була?!»-дип куйды.

# 2

Теге көнне Галиәкбәр нәни онык-кызчыгы аркасында беркая да китә алмады. Һәм, бик ихтимал, көтелмәгән хәл килеп чыкмаса, ул беркайчан да теләгенә ирешмәс иде. Ләкин уйламаганда-сизмәгәндә балалар бакчасында Лиананың кулына кадалган пирке пробасы туберкулезга уңай реакция күрсәтте. Тиз генә чарасына керергә кушылды. Озакка сузмастан, шундый балалар өчен оештырылган санаторий тибындагы махсус балалар бакчасына путевка бирделәр. Ул бакча Казаннан читтә, Мәскәү юлы өстендә, матур нарат урманында. Лиана шунда урнаштырылды. Хәзер аны якшәмбе көннәрендә генә барып күрергә мөмкин, чөнки башка көннәрдә ата-аналарыннан аерылган балаларны борчып йөрергә рөхсәт юк.

Бу хәл Сафураны гына түгел, Галиәкбәрне дә бәйдән ычкындырды. Сафура хәзер бөтенләй туарылды. Күрәсең, ни генә әйтмә, нәни кызчык ана үзе теләгәнчә кыйланырга ирек бирмәгән булса кирәк. Лиана Займищега киткәч, Сафураның читтә кунып калулары һәм өйдә мәҗлес уздырулары тагы да ешайды. Инде этисен бар дип тә белми сыман. Галиәкбәргә исә хәзер күптәнге ниятен гамәлгә ашырырга мөмкинлек туды. Ул, кызына язу гына калдырып, самолетта Әлфия янына, Татарстанның төньяк-көнчыгышына очты.

Язуында ул Сафурага болай мөрәҗәгать иткән иде: «Кызым, мин Әлфия янына барып кайтам. Өйне яхшы кара, әниеннең төсе буларак саклана торган бик кадерле әйберләрне-ватма-кыйратма. Савыт-сабаны үзенә юарга туры киләчәк. Акча калдыра алмыйм. Үз тапканыңа торып кара әле. Мине борчыма, үз вакытым белән кайтырмын».

Юлда ул Әлфия турында уйланып барды. Галиәкбәр өчен, дөресен генә әйткәндә, хәзер Әлфиядән дә якынрак кеше юк иде.

Мәрхүмә хатыны белән алар Әлфияне икәүләп бер яшьлек вакытыннан алып тәрбияләделәр. Мәгъмүрә Сафураны зур газаплар кичереп тапканнан соң, бала табу шәрәфеннән мәхрүм бер хатын булып калды. Әле монысыннан исән калуыңа шатлан, икенчесен таба алмассың, үләрсең, диделәр. Ләкин бер бала баламыни ул?! Кимендә икәү кирәк дип уйлаштылар яшьләр. Һәм тормыш көйләнә төшеп бер әзгә баскач, алар бәбиләр йортыннан ташландык бала — бер яшьлек Әлфияне алып кайттылар. Әлфия җиде класс бетергәнгә кадәр Галиәкбәр белән Мәгъмүрәнең үз эти-әнисе булмавын белмичә үсте. Ләкин безне капчыкта яшереп буламы соң?! Нииндидер үзара ызгыш чыккан да серне ничектер белеп алган Сафура, сеңелен кимсетү максаты белән, аңа барын да әйтеп салган. Шуннан соң инде Әлфиянең кемлеген яшереп торуның кирәге дә, мөмкинлеге дә калмады.

Авыр кичерде кыз бала эти-әнисен бер мизгелдә югалтуын. Тик аның эти-әнисенә хөрмәте, хәтта мәхәббәте шул көенчә сакланды. Әйе, бик акыллы иде шул Әлфия ул вакытта ук. Акыллылыгы аның яхшылыкны начарлыктан аера алуда, яхшылыкның кадерен белүдә иде.

Уку, фәннәрне үзләштерү җәһәтеннән Сафура кебек ярылып яткан сәләт иясе түгел иде Әлфия. Ләкин аның көчле ягы үзен эшкә җигә белү булды. Бу исә, Галиәкбәр фикеренчә, яшь кеше өчен барыннан да кадерлерәк үзенчәлек иде. Хәтта ул сәләтнең бер төре, һәм хәтта сирәгрәк очрый торганыдыр әле. Әлфия урта мәктәпне дә, институтны да уңышлы тәмамлады.

Ул үзе теләп Галиәкбәр юлыннан китәргә булды. Сафураның авыл хуҗалыгы фәнен гомумән фәнгә санамавына, җае чыккан саен этисенең белгечлеген кимсетүенә карамастан, ул терлекчелек институтын бетерде һәм менә дүрт ел инде районда, соңгы вакытта кошчылык фабрикасында лаборатория мөдире булып эшли. Хатлар язып тора.

һәр вакыт чакыра, кучтәнәч җибәрергә дә онытмый. Әйе, тагы барыннан да кадерлерәге шул, «әти» дип якын күреп дәшә, аһ итеп тора.

Галиәкбәр Сафура белән үзенең арасында булган котсыз, ата-баба белмәгән мәгънәсез мөнәсәбәтне Әлфиядән яшерергә мәҗбүр. Ничектер уңайсыз, ничектер үз каныңны хурлау кебек килеп чыга. Ләкин Әлфия кебек нечкә калебле кешеләр бу авыр күренешне сизмимени соң?! Сизенә, тәгаен сизенә Әлфия, тик сер сынатмый, әтисен борчырга теләми, шуңа күрә белмәмешкә салыша.

Мәгъмүрәне җирләргә баручы кешеләр арасында беркем дә бу югалтуны Әлфиядәй авыр кичермәгәндер. Ни өчен шулай? Бер үк тәрбия алып үскән балалар лабаса. Сафура бу кайгылы көннәрдә әнисен югалту газаплары белән әз генә дә җәфаланмады, еласа да — Галиәкбәрнең күзенә бу бик ачык чалынды — кеше елый дип, уңайсызланып кына елады. Ә Әлфия исә, у!

Галиәкбәр самолетта бер сәгать очканда шулар турында уйланды һәм тизрәк үзен якын иткән кадерле кызы янына барып җитәргә ашыкты. Ул ярты сәгать автобуста барды һәм Кама буена, куе урман арасына урнашкан кош фабрикасына якынлашты.

Көн аяз, матур иде. Епшетергә чамалый, ак кар катлавы күгелҗем төс алган. Әйе, март башы үзен сиздерә, язгы уяну шатлыгы күңелдә гүзәл көй булып яңгырый. Авыр киеренкелектән котылып, тынычлык бишегенә эләккәннән соң гына була торган күңел көрлегенә табигать гүзәллеге өстәлгәч, Галиәкбәр яшәреп, җиңеләеп киткәндәй булды. Ул автобустан кай турыда төшеп калырга кирәклеген Әлфия язган хатлардан белә иде. Тиешле урында төште, күкрәп торган нарат урманы аша сузылган юл буйлап җил-җил атлап алга китте. Бераздан урман артындагы поселок та күренде.

Фабриканың ике катлы ак таш торак биналары нарат урманы эчендә үк икән. Алар артындагы вак корылмалардан ук куе агачлык башлана. Галиәкбәр таш өйләрнең кыяфәтеннән аларның әле күптән түгел генә салынганлыгын һәм бик бай оешманың химаясендә эшләнгәнлеген чамалады. Йортлар әйбәт, байсымак, бөтен җире камил җитешлектә иде. Тротуарлар, урам юллары әле хәзергә кар астында булсалар да, сизелә, асфальт белән түшәлгән. Өй ишекләренә кадәр фасонлы. Аларның өлгеләренә калын фигуралы пыялалар куелган. Ә тышкы баскычлар исә нык, ясалма мәрмәрдән, хәтта баскыч мәйданчыкларының идәннәре дә матур бизәкле плиталардан ясалган. Кыскасы, биредә Татарстанның гына түгел, бөтен илнең горурлыгы булган Кама автомобильләр заводының ярдәме, ә, дөресрәге, шуның кулы, стиле ачык тоела иде.

Кош фабрикасы моннан ярты ел элек кенә эшли башлады. Бу өйләр салынганга да елдан артмастыр, ә Әлфиянең Бөгелмә кош фабрикасыннан бирегә күчеп килүенә сигез ай гына әле. Галиәкбәр бу фабрика эшли башлаганда институттан киткән иде инде. Шуңа күрә ул аның өчен бөтенләй ят, яңа нәрсә. Галиәкбәр чаттан икенче таш өйнең шома таянсасына тотына-тотына өске катка менгәндә: «Әле эштән кайтуын кайтмагандыр да, ярый инде, берәр яры китеп бармаган булса»,— дип уйланды. Ул телеграмма сукмавына бераз үкенә төште, тик шунда ук үзен тынычландырды. Тәгаен биредә, шушындый зур кош фабрикасында, үзенең берәр шәкерте бардыр әле. Булмый калмас дигән ышаныч, аңа, Әлфия читкә китеп барган хәлдә дә, кунып чыгарга урын, сыйланырга ризык вәгъдә итә иде. Ул хәзер хөрмәткә, игътибарга мохтаҗ. Аны Сафураның түбәнсетүләре, хәкарәтләүләре бөтенләй кешелектән чыгарды, әз генә булса да элеккедәй хөрмәткә ашкыну аның күңелендә дөрләп кабынмаса да, көйрәп тора иде хәзер.

Икенче кат белән беренче кат арасындагы баскыч мәйданчыгында тукталып, күкрәк кесәсеннән блокнотын чыгарды карт, болай да хәтерендә булуына карамастан, тагы бер тапкыр квартир номерын ачыклады һәм шактый житез адымнар белән, уфылдап, тирән-тирән сулаган хәлдә, өскә менеп китте.

Галиәкбәрне Әлфия үзе каршы алды. Эштән әле яңа гына кайтып кереше икән. Әтисен ишек төбендә күрү белән аның коңгырт нурлы күзләре зур булып ачылды. Ул әтисен шатлык белән муеныннан кинәт кочып алды. Галиәкбәр кызының бик якын, үз булып беткән тавышын ишетте, хуш ис, яшьлек, арулык исе аңкыткан тыгыз тәнен, шулай ук күптән таныш гөнаһсыз, кайнар, йомшак иреннәрен тойды. Кыз шатлыгыннан онытылып чыркылдап көлә: «Әтием, бәгырем»,— дип Галиәкбәрнең битен, чигәсен өзлексез үбә иде. Картның күзләрен яшь элпәсе каплады. Ул куанычтан елмая биреп, буш кулы белән Әлфиянең аркасын сыйпап торды.

— И, эти-и! — диде Әлфия алсуланып киткән йөзен күтәреп, үз күзләренә үзе ышанмагандай.— Нинди әйбәт иткәнсең киле-еп!

Галиәкбәр кулындагы торт тартмасын Әлфиягә сузды.

— Монда, авыл жирендә, юктыр бәлки. Хас синең өчен заказ биреп эшләттем. «Казан» торты,— диде карлыгып киткән тавыш белән. Ул кергәч тә ишек янына куйган чемоданына күрсәтте.

— Монда минем үз кирәк-яракларым, кирәк жиргә урнаштыр, кызым.

Әлфия чемоданны һәм зур ак тартмадагы тортны кулларында тоткан килеш сорады:

— Исән-саулыкмы соң? Апа, Лиана нишләп калдылар?..

— Гомумән бары да тәртиптә. Әле ул турыда сөйләшербез, кызым.— Карт пальтосын салып чөйгә элде, ишек янындагы табуреткага утырып ботинкаларын сала башлады.

— Салмасаң да ярый, идән юылмаган,— диде Әлфия ашыгып.

Галиәкбәр аның сүзенә карамады.

— Салыйм әле. Аякларым ял итсен. Син, кызым, минем чемоданнан чүәкләр алып бирче.

Карт постау чүәкләрен киеп аякка басты һәм авыр атлап уң яктагы олы бүлмәгә узды.

Квартира бер бүлмәле генә булса да, бик иркен һәм жайлы иде. Галиәкбәр зәвык белән жыештырылган бүлмәгә кергәч, кулларын баш-та аерып, аннан кушырып:

— Сине бик зурлаганнар икән, кызы-ым,— диде.

— Нигә, эти? — диде Әлфия, урманга караган зур тәрәзәнең шторасын тартып.

— Нигә ди, бик шикарный квартира биргәннәр, диюем.

— И,— диде Әлфия, «алай гына нәрсә ул» дигәндәй кул селтәп.

Кухня якка чыгып кергәч, ул тагы әтисе янына ук килде. Галиәкбәр йомшак диванда утыра иде инде.

— Әти, әйт дөресен, син ачыктыңмы?

— Юк. Юлга чыгар алдыннан гына аэропорт ресторанында бик ныклап ашадым.

— Ярый, алайса. Чәй генә эчәрбез хәзергә.

Чыннан да, артык берни дә кирәкми иде Галиәкбәргә. Ул бүлмәдә ялгызы озак утыра алмады, кул юарга дип, Әлфия янына кухняга чыкты. Әлфия газ плитәсендә нәрсәдер пешереп маташа иде. «Шәһәрдән бер жире дә ким түгел: газ, жылы батареялар» дип уйлап алды Галиәкбәр. Плитә жылысында йөзе кызарып киткән Әлфия үзенең якты елмаюы белән әтисенә карады.

— Әй, вакытын белеп кенә килгәнсең дә, эти. Син миңа бик, бик кирәк идең.

— Нәрсә, эшеңдә бер-бер нәрсә булдымы әллә?

— Юк, юк, әйтермен әле. Үзем белеп, вакыты житкәч, әйтермен.

Кухнядагы чисталыкка күз төшерү белән игътибар итте карт. Нинди тәртип! Хәер, аның салынып кешесе юк шул. Ул үз квартирасындагы тәртипсезлекне, Галиәкбәр җыймаса, беркайчан да җыелмый яткан урын-җирләрне, карт этисе юмаса, атналар буе юылмый яткан савыт-сабаны күз алдына китерде. Әйе, әйе, соңгы тапкыр кисәтеп әйткәч нинди җавап бирде әле Сафура? «Мин синең прислугаң түгел, тик ятасың, ю, җыештыр үзең»,— диде.

Бераздан Әлфия бик матур итеп табын әзерләде. Өстәлгә парлар бөркеп торган никель чәйнеген, табасында әле генә куырылган колбасалы тәбәсен китерде. Чәй ясап, чынаякны этисе алдына куйгач, нидер исенә төшереп:

— Эти, аракы эчәсеңме? — дип сорады. Галиәкбәр бераз сәерсенде. Чөнки ул Әлфиянең өендә аракы сакланыр дип һич уйлаганы юк иде.

— Юк, кызым,— диде. Аның инде аракы эчмәгәненә елга якын иде. Узган ел Җиңү бәйрәмендә үзе кебек ветераннар арасында ул ничектер юләрләнеп бер нык кына эчкән иде. Шунда бер атна авырып, йөрәк, бавыр белән газап чиккәннән соң, авызына алмас булды.

— Юк, кызым, андый нәрсәләрне хәзер...— ул тынып калды. Күрәсең, интонациясеннәндер, я булмаса күз карашыннанмы, Әлфия этисенең икеләнеебрәк җавап бирүен тойгач:

— Бәлки бераз кабарсың, минем бар,— диде. Галиәкбәр кул селтәде дә елмая төшеп: — Ярый, алайса, бары бер стопка гына, күңел көр булгач, йөрәк аны гына бәлки күтәрер әле,— диде.

Әлфия җыйнак кына куе көрән төстәге көзгеле һәм полировкалы сервантган этикеткасына «Петровская водка» дип алтын хәрефләр белән язылган, башланган ярты литрлы аракы шешәсен китереп куйды. Тагы бер сәерсендергән нәрсә аракының башланган булуы иде. Хәер, дип тынычланды карт, кунак-фәлән җыйгандыр. Әлфия бит инде үсмер түгел. Мин генә аңа һаман элекке нәни Әлфиягә караган кебек карыйм.

Кыз закускага дип тозлы кәбестә дә китереп куйды. Этисенә аракыны стопкага салды, үзенә салмады.

Эчеп тәмләп ашый башлагач, Галиәкбәргә бөтенләй күңелле булып китте. Күптән инде аның мондый рәхәт тынычлыкны татыганы юк иде.

— Молодец, кызым,— диде ул, аракының җиле бераз башка менә башлагач,— этиеңне бик әйбәт каршы алдың. Матур гына тормыш та коргансың икән. Инде мин синең әйбәт кенә егет табып, гаилә корып җибәрүеңне генә теләр идем.

— Рәхмәт, эти, үз вакыты белән барысы да булыр әле.

Галиәкбәр Әлфиянең ничектер хәйләле елмаюына игътибар итте. Ләкин сиздермәде.

— Гомер ул, кызым, искән җилдәй, уза да китә. Җимешнең өлгергәч өзелгәне яхшы,— диде.

— Булыр, булыр,— диде Әлфия, тагы матур очкынлы күзләре белән генә елмаеп.

— Тик апаңныкы кебек ямьсез чыкмасын инде, Әлфия.

— Ничек?

— Ничек ди, чыкты, дүрт ел торды, аннан баласын ятим калдырып, кайтып керде. Бу әйбәт түгел.

— Каян беләсең соң аны ничек булып бетәсен, эти. Бу инде бәхет эше.

— Шулай, бәхет эше. Тик тормыш иткәндә кайчак түзә белергә дә, гафу итә белергә дә кирәк.

Бераз дәшми-тынмый ашагач, сүзне икенчегә борып Галиәкбәр яңадан башлады.

— Бик әйбәт итеп тормышыңны коргансың, кызым. Әйе, әйбәт. Минем бернинди ярдәмемнән тыш, үзең...

Ул күңелсезләнә төшеп тынып калды. Барлык игътибарны һәм ярдәмне башлыча Сафурага күрсәткәнлеген хәтерләде. Ләкин Әлфия әшлекле генә түгел, артык нечкә калебле, үтә сизгер, акыллы кыз да иде.

— Сез мине мәрхүмә әни белән кеше иттердегез, әти,— диде ул.— Моннан да зур ярдәм була аламы дөньяда? Мин сезгә рәхмәтләремне беркайчан да әйтеп бетерә алмам, ахры, әти.

Галиәкбәрнең борыны йомшарып китте. Күзләрен тагы яшь элпәсе каплады. Ул бары: әй, кызы-ым! — дип кенә сузып әйтә алды. Кемнендер ишектә звонок шалтыратканы ишетелде.

Әлфия урыныннан сикереп торды һәм, серле көлемсерәп, әтисенә:

— Хәзер мин сине бер кеше белән таныштырам,— диде.

«Таныштырам» дигән кеше ишектән бик шаулап килеп керсә дә, Әлфия аңа әтисе килгәнлеген әйтте булса кирәк, кинәт тынып калды. Аның кыз белән ни турыдадыр шыпырт кына сөйләшкәне колакка чалынды. Аннан соң ул Галиәкбәр янына керде һәм шул вакыт кына егетнең кыяфәт-килбәтенә карт игътибар итте. Ул җыйнак гәүдәле, кояшта янган көрән йөзле утызлар тирәсендәге бер егет иде.

Коридордагы пышылдашудан ук Галиәкбәр нидер сизенгән иде. Ул шунда ук, шул үзе, аның язмышы түгелме икән, дип уйлап алган иде. Инде егет бүлмәгә кереп, җитез хәрәкәтләр белән картның кулын кыскач, һәм үзен «Фәрит» дип таныткач, Галиәкбәр аңа аерата дикъкать белән текәлде. Чибәр, күпереп, дулкынланып торган куе чәч, киң маңгай, чигәдән колак йомшагына хәтле төшкән бакенбардлар...

— Бик әйбәт,— диде карт. Әлфиягә мәгънәле генә итеп карап алды.— Кызым, синең таныштырам дигән кешең бит инде? Шул үземе?

— Әйе, әти. Безнең фабриканың баш белгече була. Фәрит Еникеев. Әлфия бүлмәдән чыгып китте.

— Яхшы, яхшы,— дип куйды Галиәкбәр, артык әйтер сүз таба алмыйча, дулкынлана төшеп. Аның йөзен күзәтеп егеткә карата туган тойгыны хәзер һич чамаларга мөмкин түгел иде. Хәер, ул үзе дә анык белми иде әле. Тик акылга буйсынмый торган бер сәер хис туганын гына чамалады ул. Шул икән аның сөйгән егете дигән уй картның күңелендә нинди дер килбәтсез бер бушлык тудырды.

— Әйдәгез табынга, рәхим итегез,— диде Галиәкбәр егеткә, әлеге ямьсез хисне томаларга тырышкандай ашыгып.

— Рәхмәт,— диде егет яңгыравык ягымлы тавыш белән. Ул өстәл янындагы утыргычны читкәрәк куеп утырды.

Ишектән савыт-саба, чәнечке-кашык күтәреп Әлфия килеп керде. Егетенә:

— Әйдә, Фәрит, якынрак утыр,— диде җылы бер караш ташлап, үз итеп. Егет алдына кирәк-яраклар куйды һәм Фәрит утыргычын яңадан өстәлгә якынрак тартып җайлап утыргач, чәй ясарга керешге. Тагы якын итеп, нурлы күзләре белән егетнең йөзен сыйпап алды. «И, боларның эшләр бик тирәнгә киткән, ахры,— дип уйлап алды карт,— хәерле булсын».

— Таныштырырга теләгән кешем менә шул була, әти,— диде Әлфия, бер тапкыр әйтелгәнне тагы кабатлап.— Минем сезне бик күрештерәсем килгән иде.

— Әйе, аңладык,— диде карт бик мәгънәле елмаеп.— Чибәр белгеч кул астында эшлисең икән. Мин бик риза.

Яшьләр уңайсызлыкны атлап узу өчен көлешеп куйдылар. Сүзне Фәрит башлады. Ул Галиәкбәрне ишетеп тә, профессорның хезмәтләрен укып та белгәнлеген, аның турында Әлфиянең күп тапкыр сөйләгәнлеген хәбәр итте. Сез озак еллар буе Казан терлекчелек институтында укыткансыз икән диде, үзенең Оренбургта укыганлыгын әйтте.

— Әйе, булды андый хәл,— диде карт артык туарылмыйча.

Әлфия сүзгә кушылды:

— Фәрит Зарипович ул Башкортстан егете, эти.

— Бакалыдан, Татарстан белән чиктәш районнан,— дип өстәде Фәрит.

— Институтны күптән тәмамлаган идегезме?

— Шактый инде,— диде егет.— Монда килгәнче Оренбург өлкәсендә биш ел эшләдем.

— Кошчылык буенчадыр инде?

— Әйе, кошчылык буенча.

— Мин дә соңгы елларда гел шул өлкә белән кызыксындым.

— Беләм, беләм. Мин сезнең белән танышуыма бик-бик шат, гомумән таныш булуым өчен дә шат, эшкә файдалы киңәшләр алып калырмын дигән өмет аркасында да шат.

Галиәкбәр кул селтәп куйды.

— Юк, мин хәзер пенсиядәге кеше. Ике елдан бирле инде кулыма гыйльми хезмәт тотканым юк. Хәтта оппонент итеп институтка чакырсалар да бармас булдым.

— Сезнең кафедрада ниндидер күңелсезлекләр булган, ахры? — Егет, шундый сорау бирү әдәпсезлек булмасмы дигәндәй, Әлфиягә карап куйды.

Әлфия үзгәрешсез калды. Бары аның ашарга кыставы гына сүзне икенче темага борырга кирәк дигәнне аңлата иде.

Әлфия егеткә дә, этисенә дә аракы салды.

— Юк, мин артык эчә алмыйм,— диде карт кырт кисеп. Егет тә кулында бераз әйләндергәннән соң стопкасын өстәлгә куйды.

— Бәлки безнең танышу хөрмәтенә, ә? — диде ул кара күзләре белән генә елмаеп. Аннан тагын үтенеч белдереп, Әлфиягә күз ташлады.— Мин синең дә бераз авыз итүеңне теләр идем, Әлфия.— Хәер, минем эти боларның берсен дә өнәми, безнең халык өчен хас түгел, ди. Тик шулай да...

Әлфия егетнең сүзен тыңлап сервантган әле бөтенләй ачылмаган яхшы маркалы кызыл вино чыгарды:

— Мә, алайса, үзең ачып бир,— диде.

Фәрит шешәне ачты да Әлфия куйган рюмкага чия суыдай кызыл, ләкин саф, үтәли күренмәле вино салды.

— Инде менә, Галиәкбәр Хафизович, мондый хәлдә баш тартып булмый, минемчә.

— Әйе, китереп кыстыгыз сез мине,— диде карт мыек астыннан гына елмаеп.— Тик иртәгә көне буе авырып ятсам, үзегез җавап бирерсез.

— Бирәбез,— диде Фәрит,— безнең монда һава әйбәт, берни дә булмас.

— Ә нәрсә өчен эчәбез соң,— дип сорады Әлфия бик беркатлыланып.

Аның этисеннән «сезнең бергә булуыгыз өчен, сезнең гүзәл киләчәгегез, бәхетле тормышыгыз өчен» дигән сүзләрне әйттерәсе килгән иде. Ләкин карт алай ук димәде: — Сезнең өчен,— диде,— сезнең дөрес атлап, сөртенми-егылмыйча гына гомер юлын кичүегез өчен.

Әлфия моны үзенчә уңай яктан аңлады. Күзләрен уйнатып, йөзен юрамалы чытты да эчеп җибәрде. Галиәкбәр әле үзенә салганны эчмәгән иде. Ул стопканы кулында тоткан килеш ирексездән Әлфия-

нең Фәрит килеп кергәч үзгәрүе турында уйлап алды. Кыз хәзер балаларча шат көләргә, елмаерга гына тора иде кебек. Шунда кызының бизәнә башлавына да, кашларының нечкәртеп, төзәтелгән булуына да, хәтта модасын саклап өске кабакларына чак сизелерлек зәңгәр буяу йөгерткәнлегенә дә игътибар итте карт. Шулай инде, мәхәббәт кешене үзгәртә, ул кешене үзе белмәгән, хәтта теләмәгән нәрсәләрне дә эшләтә ала, дип куйды. Эчеп алып бераз ашаганнан соң алар тагы сүзгә керештеләр.

— Миңа Әлфия хатлары аша да, болай да билгеле,— диде Галиәкбәр.— Монда яңа бройлер фабрикасы сафка баскан икән. Ничек соң, эш мантыймы?

Әлфия эченнән генә: «Кара, эти бу эштән бөтенләй киттем дисә дә, бөтенләй үк оныта алмый икән әле», дип уйлап куйды.

— Әйе, бөтен хикмәт тә шунда. Бройлер! Йомырка салыр өчен тавыкны асрау бездә ярыйсы көйләнгән, тик менә бройлер чебиләре симертү шактый тырышлык сорый торган, авыррак өлкә әле.

— Ә КамАЗга ит кирәк, тавык ите,— диде Галиәкбәр хәйләкәр генә көлемсерәп.

Фәрит, әйтәсе сүзенең бик мөһим икәнлеген аңлатырга теләгәндәй, чәнечкесен тәлинкә кырына төяп куйды да еллык планның нинди күләмдә икәнен, фабриканың аена ничә тонна кош ите тапшырырга тиешлеген сөйли башлады.

— Әле без производствоны тулысынча үзләштермәдек. Хәтта төзелеш тә бетмәгән,— диде.— Һәм менә шундый шартларда эшләргә туры килә.

— Бик табигый,— диде Галиәкбәр.— Һәр җирдә шундый хәл, урбанизация, гигант төзелешләр...

Ул яңа ясалган чәенә шикәр салды да, егетне тыңлый-тыңлый, чәен балкашыгы белән бик озак болгатып утырды. Аннан бер паузадан файдаланып сорап куйды.

— Ничек үстерәсез чебешләрне?

— Хәзергә идәндә асрап.

— Нигә «хәзергә»? Әллә читлеккә күчү ниятегез дә бармы?

Егет, теше сызлап киткәндәй, бер яңагын җыерып башын чайкап куйды:

— Бар шул. Бер корпуста ике рәткә батареялар урнаштырылды. Менә киләсе атна башында инкубациядән чыккан гибридларның бер өлешен шул читлекләргә утыртабыз. Ә фәнни һәм популяр әдәбияттан башка бернинди җитәкчел материал юк.

— Инструкцияләр бардыр бит?

Фәрит елмаеп кул селтәде.

— Анысы җитәрлек.

— Алдынгы бройлер фабрикасына барып эшнең технологиясе белән танышырга мөмкинлек булмадымыни?

— Булды. Мин үзем Кырымда бер ай булдым. Минем белән тагы бер оператор да барды. Таныштык.

— Соң?

— Сезгә сөйләп торуның кирәге юк инде, Галиәкбәр Хафизович, үзегез белгеч,— диде Фәрит күңелсезләнеп.— Безнең эштә бит һәр яңа урын үзенчәлекле ысуллар куллануны сорый.

— Анысына ышанам,— диде профессор килешеп. Ул нидер әйтмәкче иде, ахры. Ләкин Фәритнең сүзе бетмәгән, аның иң кызып дәлилләр чагы иде.

— Менә гибридлар мәсьәләсен генә алыгыз. Анда ул, Кырымда, көйләнгән мәгълүм кросс, мәгълүм линия. Ә бездәге гибрид читлектә

асраганда шундый ук нәтиҗә бирәме? Әле идәндә үстереп тә артык күп азык ашатабыз, ә артым тиешенчә түгел. Аннан, азык дигәннән, тегендәге комбикорм рецептларга тиешенчә туры китерелеп эшләнә. Ә бездә? Әле аксым тулы бәяле түгел, әле микроэлементлар тиешле дозадан ким, я булмаса тигез таратылмаган, бер карасаң витаминнары җитешми. Ә бит бу эштә миллиграмнар, ювелир төгәллек хәл итә.

Әлфия, күрәсең, артык җитдиләнеп киткән әңгәмәгә бераз җиңеллек кертү өчен:

— Тирпанхолникпербифо,— дип куйды.

Галиәкбәр көлемсерәде, Фәрит аптырап сорау белән Әлфиягә текәлде.

— Студентка чагымда әтигә витамин исемнәре истә калмый дип бер зарлангач, ул миңа ятлау ысулын өйрәтте,— диде Әлфия Фәриткә генә карап.— Тирпанхолникпербифо ул: тиамин, рибофлавин, пантотеновая кислота, холин, никотиновая кислота, перидоксин, фолиевая...— Әлфия, сүзен әйтеп бетерә алмыйча, рәхәтләнеп көлә башлады. Ирексездән тегеләр дә көләргә тотынды.

— Менә шулай, Галиәкбәр Хафизович,— диде Фәрит бераздан, тагы җитдиләнеп,— тоеп торам — авыр булачак.

— Авыр гынамы? Сезнең шартларда реальмы соң әле ул?

— Тырышырга кушалар.

— Ничек инде «кушалар», булмастай эш икән, ни пычагыма андый волюнтаризмга барырга, баш тартырга кирәк, трестка аңлатма, нигезләнгән аңлатма язарга... Төшенерләр.

— Соң инде.

— Фәрит трестта бу эшне булдырам дип сүз биреп кайткан,— дип шәрехләде Әлфия.

— Бу нинди эш инде! — диде Галиәкбәр ризасызлыгын белдереп.

— Шулай килеп чыкты шул. Минем башка чарам юк иде,— диде Фәрит.

Карт төшенмичә җилкәләрен күтәргәләп куйды. Байтак вакыт тынып тордылар. Аннан Әлфия башлап җибәргән сүз Казан вакыйгаларына, өйдәге хәлләргә, Сафурага, күбрәк Лианага кагылып, шулар турында куертылды да, яңадан кош фабрикасы, андагы эшләргә әйләнеп кайтты.

Китәр алдыннан Фәрит Галиәкбәрдән тагы бер тапкыр үтенеп карады.

— Мин шулай да сезнең ярдәм итүегезне теләр идем,— диде.— Сезнең киңәшләрегез безнең өчен эшне башлап җибәргәндә бик кирәк булачак. Безнең фабрика өчен читлектә асрауга күчү җитди сынау ул.

— Юк,— диде профессор кырт кисеп,— мин бирегә бөтенләй башка максат белән килдем. Аннан, әйткәнемчә, мин бу эштән артка да калдым инде.— Ул бөтенләй күңелсезләнеп өстәде: — Яшьләр булышсын иде сезгә. Әгәр телисез икән, мин институтка хат яза алам. Бәлки ректоратның сезгә консультант җибәрүенә ирешеп булыр...

Фәрит кирәкми дигәндәй өметсезләнеп кул селтәде. Саубуллашып чыгып китте.

— Бу егет кеше микән, кызым? — диде Галиәкбәр Фәрит чыгып китү белән.

Әлфия көлеп куйды.

— Бу шул дәрәҗәдә мөһиммени, әти?

— Ничек инде, кызым,— диде карт аптырый төшеп.

Әлфия дәшмәде, эчтән генә уйлап куйды: «Кызык бу олыларның карашы. Ахыр чиктә мәхәббәтнең, бары саф мәхәббәтнең хәл итүен аңламыйлар».

3

Фәрит үзенең егетме, ирме икәнлеге турында Әлфиягә, чыннан да, моңарчы дөресен сөйләмәде. Хәзер исә аның барлык фажигасе, кичерешләре шуның аркасында. Оренбург өлкәсендә ул хатынын һәм ике баласын ташлап китәргә мәҗбүр иде. Монда килеп урнашкач кәтмәгәндә-уйламаганда Әлфияне очратып, аңа гашыйк булды.

Галиәкбәр белән танышканда ул ике ут арасында янып яшәүче бер кеше иде. Чөнки эшләр артык тирәнгә китте, чөнки хәзер Әлфия белән үзе арасында булган мөнәсәбәт гади бер мавыгу гына түгел, ә көннән-көн артып, куерып бара торган, моңарчы әле Фәрит татымаган чын мәхәббәт иде.

Башта Фәрит үзенең өйләнгән кеше булуын Әлфия белән якыннанрак танышу максаты белән әйтмәде. Ә аннан соң инде Әлфияне югалтудан куркып яшерде.

Ул үзенең Әлфия каршында бик зур җинаять эшләвен тиз аңлады. Ләкин үзен бетеп сөйгән, шул мәхәббәте аркасында олы бәхеткә ирешкән шат, гүзәл кызны хәсрәт дәрьяларына ташлаудан куркып ачылмый яши бирде. Мәгәр эшләр зурга киткән саен бу җәрәхәт тә тирәнәйде. Хәзер инде бу яшеренү, хаиннәрчә алдашу аны буганнан-буа барды һәм көннән-көн катлауланган газаплы бер чиргә әйләнде.

Фәрит ташлап качкан хатынына яратмыйча өйләнгәнлеген бик соң аңлады. Аңлагач, үзенең яратмаган кеше белән гомер итүен зур ханҗалык санап, яшьлек тәҗрибәсезлеге аркасында эшләнгән бу ахмаклыгын төзәтү юлларын эзләргә кереште. Балалар җәл диде. Алар ата химаясенә мохтаҗ иде. Әлбәттә, Фәрит балаларына ярдәм итеп торачак. Әйе, монысы таш яуса да, җир тетрәсә дә шулай булыр, башы сау чагында балаларын ташламас, ул аларны ярата. Ләкин балалар дип, бөтенләй читләшкән, үзе тупас, үзе ни тән, ни җан җылысыннан мәхрүм ят, салкын хатын белән газап чигү табигать законнарына каршы килә торган бер нәрсә түгелмени?! Ни өчен ул гомерен җәфаланып, үзен газаплап уздырырга тиеш?

Ни хикмәттер, яши башлауларының икенче елында ук Фәһимәнең табигатендә көтелмәгән үзгәрешләр күренә башлады. Аның элекке чаялыгы, үткенлеге усаллыкка әйләнде, Фәритне һич нигезсез рәвештә үзенә хыянәт итүдә, өстәвенә, булдыксызлыкта, хуҗасызлыкта, жилкуарлыкта гаепләп, үзәгенә үтә башлады. Ул хәзер төннәрен, Фәрит йоклады дип уйлап, иренең кесәләрен, бумажникларын актара, дус-иш, туган-тумачаларыннан килгән хатларын рөхсәтсез укый, үзенең вакчыллыгы, нидәндер сырхау шикләнүләре белән ирен рәнҗетә иде.

Юк, юк, Фәһимә уенча, Фәрит мөстәкыйль яшәүгә сәләтле кеше түгел. Ул бүтән кеше ирләренә әз генә дә охшамаган, ул бары Фәһимә җитәкчелегендә генә ирләр рәтеннән йөрсә йөри алыр. Фәрит һәр адымын хатыны рөхсәте белән генә атларга тиеш. Айлык эш хакы соңгы тиененә кадәр Фәһимәгә тапшырылсын, Фәрит берәр читтән килгән якын кешесен өйгә чакырырга уйласа, башта хатыны белән киңәшсен.

Көннән-көн ямьсезрәк төс ала барган шундый кимсетүләр Фәритне башта куркулы аптырашка төшерде, тора-бара төзәлмәс ярадай аның үзәкләренә үтеп авырттырды. Соңыннан кискен авырту узды, тонык кына сызлау аша ул хатынына карата бик тирәндә көйрәп торган нәфрәт күмеренә әйләнде.

Бу хәлдән котылу юлларын чамалый һәм Фәһимә кебек каты бәгырьле кеше була алмады Фәрит. Кискен чарага баруда иң мөһим киртә, ни әйтсәң дә, үзе бик ярата торган нәниләре иде. Әтиләре өчен берсеннән-берсе матур, газиз, дөньядагы барлык кешедән дә якынрак

иде алар. Шулар бәхете-шатлыгы өчен барысына да түзәргә әзер ул.

Әйе, Фәритнең шундый бала җанлы кеше икәнлеген Фәһимә тиз сизде һәм муенчагын тагы да ныграк кысты. Ә Фәрит исә тешләрен кысып булса да балалар хакына түзде. Бик озак түзде, биш ел түзде. Әле моңарчы аның беркайчан да бу хәлдә мәсхәрәләнгәне юк иде. Аның ирлек горурлыгы, кешелек горурлыгы бу дәрәҗәдә беркем тарафыннан да бу кадәр үк тапталмады моңарчы.

Фәрит хатынына күп тапкырлар иплəп, дусларча аңлатырга, мондый тормышның нормаль булмавын, алар я аерым яши башларга яки Фәһимә үзгәрергә тиешлелеген төшенерергә тырышты. Тик мондый сөйләшүләр гадәттә тиргәшү, хурлау һәм истерика белән генә бетә иде.

«Ах, син мине ике бала белән ташлап китмәк булдыңмыни әле? Миннән яшьрәкне таптыңмыни? Юк, барып чыкмас, мин сиңа бары-бер көн бирмәячәкмен. Бөтен тамырыңны корытам мин синең, оятсыз».

Булмады! Фәритнең ярсуы соңгы ноктасына җитте. Ә көннәрдән бер көнне күңелдә нәрсәдер чатнап сынгандай булды, яңа паспорт алуыннан һәм ул паспортта кайбер мәгълүматларның язылмый калуыннан файдаланып, ул, үзе дә тоймастан, чемоданын эләктерде дә, хатыныннан качып, беренче поезд белән читкә китеп барды.

Поезд Казанга җиткәндә Фәрит үз акылында иде инде. Ул вокзалда «нишләргә миңа?» дип озак кына уйланып торды. Көче җитте, кире китмәде.

Казанда Фәритнең бер шәп дусты — птицепром трестының башлыкларыннан берсе яши иде. Алар Оренбургта бергә укыдылар, бер бүлмәдә яшәделәр. Якын дус белән Фәрит сирәк кенә булса да — башлыча бәйрәм открыткалары аша — соңгы көннәргәчә хәбәрләшеп, хат алышып тора иде әле. Казанда шуны эзләп тапкач, Фәрит аңа барысын да ачыктан-ачык сөйләп бирде. Дуслар арасында бүтәнчә була да алмый!

— Ярый, мин сиңа булдыра алганча ярдәм итәрмен,— диде дусты.— Уйлашырбыз, җае чыгар, тик син башта миндә кунак бул әле.

Фәритнең исә әле Казанда беренче тапкыр булуы иде. Ул барысы белән дә кызыксынды, республика башкаласының барлык күңелгә хуш килерлек урыннарын гизде. Кремльдә дә, университетта да, циркта да, академия һәм опера театрларында да булды. Идел буйларына төштеләр алар. Ослан таулары күренеп торган аргы якның бөдрә яшеллекләренә, җәйрәп яткан бөек елга дулкыннарына карап хозурландылар. Алай гына да түгел, дусты Закирҗановның Идел буендагы бәләкәй дачасына барып моторкада су өсләрендә гизделәр, балык тоттылар.

Инде килүенә бер атна үткәч, Закирҗанов иплe хәбәр белән кайтты.

— Кама буенда, КамАЗдан түбәнрәк бройлер фабрикасы эшли башлаячак,— диде ул,— шунда бер белгеч кирәк. Алынасыңмы? Син бит институт бетергәннән бирле кошчылык буенча эшлисең?

Фәрит озын-озак уйланып тормастан: «Алынам»,— диде. Фабриканың продукция күләме, эшнең куелышы белән кызыксынды. Зур, бик зур перспективалы иде бу фабрика. Мондый предприятиеләрдә әле эшләгәне булмаса да, үз көченә ышанды, хәер, сайланып маташырга аның мөмкинлеге дә юк иде, кабатлап «алынам» диде.

— Тик бер шарты бар,— диде Закирҗанов хәйләкәр генә көлемсерәп.— Андагы белгеч консерватор булып чыкты, чебешләрне идәндә асрап үстерүне генә мөмкин дип таба. Шуңа күрә без аны эшеннән азат итәргә тиешбез.

— Димәк?

— Димәк, шул: син бройлерларны читлектә үстерү технологиясен

әкренләп кертергә тиеш буласың. Чөнки фабриканың проект куәте шуңа исәпләнгән.

Фәрит уйланып торырга мәҗбүр булды. Чөнки бу ысулның торак мәйданны экономияләү һәм житештерүчәнлекне арттыру күзлегеннән караганда бик шәп ысул икәнлеген белү белән бергә, аның четерекле булып, бик зур төгәллек һәм белем таләп итүен дә яхшы аңлый иде. Бармы соң андый мөмкинлек әле яңа аякка басып килә торган фабрикада? Закиржанов көлеп куйды.

— Нәрсә, шүрләдеңме?

— Юк, шүрләвен шүрләмәдем, тик ни өчен теге белгеч баш тарта, шуны аңламыйм.

— Консерватор, курка. Гибридлар сыйфатлы булмас, азык мәсьәләсе, зоогигиена шартлары тиешенчә хәл ителмәс дип шүрли. Юкса, биналар автоматлаштырылган. Фәннең соңгы сүзе буенча дип әйтергә була.

Закиржанов яшькелт-сары күзләрен сорау белән Фәриткә текәде.

— Лаборатория шәп җиһазландырылганмы? Югары квалификацияле кешеләр җитәрлекме? — дип сорады Фәрит.

— Беренче класслы,— диде дусты, елмаеп баш бармагын тырпайтып куйды.— Во, менә дигән кешеләр. Тик аларны өйрәтергә кирәк. Анысы синең эш.

Фәрит ирексездән йөзен чытты.

— Алай булгач, ай-хай ла...

— Бер дә алай түгел, агайне. Менә барсаң, күрерсең.

— Ну, ярар,— диде Фәрит җитдиләнеп,— тиешле ярдәмне вәгъдә итәсеңме, Шәйхи дус?

— Борчылма, бары да булыр. Монысын эшләгәнне башкасын эшләмимме соң синең өчен.

— Булды, алайса, мин риза,— диде Фәрит, чигәсен кашыштырып.

— Әмма кара аны, мине уңайсыз хәлдә калдырма. Мин башлыкка «ручаюсь!» дидем. Белдеңме?

Фәрит шул ук көнне самолетта бройлер фабрикасына очты. Һәм шул ук көнне ул Әлфияне күреп аның кыяфәт-чыраен күңеленә теркәде. Ап-ак йөзле, коңгырт зур күзле, зифа, җитез кыз икән ул Фәрит танышып чыгу өчен кергән лаборатория мөдире. Була бит шундый якты чырайлы, беренче күрүдә үк игътибарны үзләренә тарта торган кешеләр. Менә шундыйлардан иде бу кыз. Әйе, шуннан инде фабриканы элекке белгечтән кабул итеп алгач, Фәрит Әлфия белән якыннанрак эш арасында танышты. Холкы, табигате дә һич Фәрит көтмәгәнчә әйбәт иде аның. Профессор кызы. Әйтүе генә ансат. Фәрит аны капризлы аристократкадыр дип уйлаган иде. Ялгышкан. Ифрат тыйнак һәм беркайчан да кешеләрне этеп-төртеп үзен күрсәтергә акшынучылардан түгел. Ләкин шулай да кызый үзенең бәясен белә. Һич чытлыкланмый. Артык якын җибәрми. Әйе, нәкъ менә Фәритнең күңел түрендә сакланган идеал.

Алар бер-ике айдан соң бөтенләй дуслаштылар, ә тагы бераздан алар арасында, һич сиздермәстән, көтелмәгән мәхәббәт шатлыгы балыкты. Очар кошлар канат яргач нинди җиңеллек тойса, болар да хәзер шуңа охшаш тойгылар рәхәтен кичереп, мәхәббәт ләззәтен татып яши башладылар. Мондый бәхетне Фәритнең дә, Әлфиянең дә әле беркайчан татыганы юк иде. Алар бәхетле иде. Тик Фәрит кенә мәхәббәт исереклегеннән айныган араларда үзенең сөйгәненә дөреслекне әйтә алмавына сыкрана, вөҗдан газаплары кичерә иде.

Шулай, бүгенге шактый җаваплы көн дә килеп җитте: инкубатор бүлегеннән чебешләрнең дөнья бетереп чиелдаулары, күкәй кабыгын тишеп, якты дөньяга чыккан меңләгән сап-сары, йом-йомшак җан ияләренең яшәү хокукларын даулаулары ишетелде. Сай, агач тартма-

ларга тутырып аларны инкубатор эшчеләре батареялар куелган бүлеккә ашыга-ашыга ташый башладылар. Өч көн эчендә чебиләр берсе өстенә берсе куелган тимер читлекләргә тутырылды.

## 4

Фәрит лабораториягә килеп кергәндә Әлфия бик бирелеп аналитик үлчәүдә капкачлы уймактай кечкенә пыяла стаканнар үлчи иде. Фәритнең ашыгып килеп керүен күргәч, кыз башын күтәрде. Әллә берләр хәл булдымы, дип шомланып, баш белгечкә таба борылды.

— Чебешләрне утыртып бетердек, корпуста һава режимы да, дым да, яктылык та нормаль,— диде Фәрит дәртле күтәренкелек белән.— Эш хәзер азыкның югары сыйфатлы булуында. Әгәр бары да җиренә җиткерелеп, артым башта ук тиешенчә булса, эш барып чыгачак.

— Эремчек пробалары тикшерелде. Стандартча. Комбикорм да җибәрелгән составына караганда югарырак сыйфатлы,— диде Әлфия. Ул урыныннан торды да җитез адымнар белән ишек янындагы үзенең язу өстәленә таба юнәлде. Кәгазьләр өеменнән берничәсен алып, Фәриткә китереп бирде.

— Менә кара.

Фәритнең куе кара кашлары җыерылды. Ул җитди бер кыяфәт белән кәгазьдә язылганнар белән таныша башлады.

Әле укып чыкканчы ук кәгазьдән аерылып:

— Аңламыйм мин ул кешеләрне, — дип куйды көрсенеп.—Вәгъдәләрендә тормыйлар. Кичә кич белән генә килде бит азык. Чеби, вакыты җиткәч тә, күкәй эченнән чыкмыйча, аларны көтеп утыра дип уйлыйлар, ахры.

— Ярый әле, шулай да өлгерде. Тагын соңгарса да берни эшли алмас идең.

Фәрит тагы күзләрен кәгазьдән аерды. Хәйләкәр генә елмаеп:

— Анысы шашып калмас идек инде калуын,— диде. Әлфия бу сүзләрнең мәгънәсен аңлый иде, әлбәттә. Фәрит һәр ихтималга каршы дип калдырылган азык турында сүз алып бара иде. Ул запас азыкны алар башта ук лабораториядә тикшерделәр, тиешеннән азрак булган витаминнарны һәм микроэлементлар өстәделәр. Алай-болай азык заводтан вакытында килеп җитмәсә, шуны файдаланырга җыендылар. Ләкин завод, бераз соңгарып булса да, азыкны җибәргән иде. Күрәсең, югарыдан да тикшерәләрдер. Инде хәзер азыкның тиешле микъдарын бункерларга вакытында сала барырга кирәк иде. Ә чебиләргә ул автоматик рәвештә улак буйлап агачак. Фәрит кәгазеннән аерылып:

— Сынап карыйк, чебешләр ни әйтер,— дип куйды. Әлфия, үлчәү тоткаларыннан аерылмаган хәлдә, эшен дәвам иттереп:

— Органолептик[1] анализ әйбәт, юкса,— диде.

— Эх, ул безнең тою әгъзалары! Барын да сизеп бетермиләр шул. Менә хәзер үк иснәп карау белән әйтеп булсын иде ул: җитәрлекме бу азыкта лизин, глицин, кобальт, марганец, тиамин...

Фәрит әйләнмәле, кирәгендә биегәйтеп һәм түбәнәйтеп була торган винтлы ак утыргычта утырган килеш, һаман әле пыяла читлек эчендәге аналитик үлчәүдә бьюкслар үлчәп маташкан Әлфиягә мут ялтыраган күзләрен текәде. Бик ихтимал, лабораториядә эшләүче кыз якында гына басып тормаса, ул үрелеп Әлфиянең ап-ак матур муеныннан үбеп тә алыр иде. Тик болай да Фәрит килеп керү белән лаборантка кызның йөзеннән шикле хәйләкәр бер елмаю узды. Әллә Фәриткә генә шулай күрендеме? Һәр хәлдә, эш вакыты бит, ярамый, яхшы түгел.

[1] Органолептик — тою әгъзалары ярдәмендә бәяләү.

Фәрит лабораториядә озак тоткарланмады. Әлфиягә анализлар әзер булгач та телефоннан хәбәр итәргә кушты да, каударланып, тар баскычтан азык әзерләү цехына төшеп китте.

Ул, баш белгеч буларак, барлык корпус-кетәкләр өчен җаваплы. Кайбер абыну-сөртенүләр булгаласа да, әлеге идәндә үстерелә торган чебиләр хәле дә ярыйсы иде. Чебиләрне батареяларда үстерү эшен булдырам дип, Закирҗановка сүз биргәч, Фәрит бу эшне кемгәдер башка кешегә йөкләргә җөрьәт итмәде, аны өстәмә бер эш итеп үз кулына алды. Инде ул көйләнеп китсә, ул эшнең барышын күзәтүне бүтән берәр белгечкә тапшырырга булыр.

Фәрит бүген корпусларның үзе керергә тиешлеләрендә булмаган иде әле. Таш коймалы ишегалдындагы, тезеп куйган шырпы тартмаларыдай, кирпечтән салынган корпуслар арасына кереп китте ул. Пинҗәк өстеннән халат кына кигән иде, алай да суык тоелмады аңа. Яз сулышын сизенгән тавыкларның җырлавы маточниклар корпусының ишегеннән аңа бик ачык булып ишетелде. Ул да булмады, шунда ук бер-бер артлы өч этәч тә кычкырып алды. Ни өчендер бала чак, җәйге көн, туган авыл, туган өй искә төшеп куйды. Рәхәт булып китте Фәриткә. Әлфияне күргәч тә һәр вакыт шулай рәхәт минутлар кичерә иде ул.

Фәрит әле генә килеп кергән тәрәзәсез корпус электр лампалары белән әйбәт яктыртылган биек һәм иркен бер бина иде. Тышкы ишектән кергәч тә пыяла стена белән аерып алынган операционный. Монда операторлар кетәкнең буеннан-буена сузылган транспортерларның эшләвен тикшереп, аларны моторга тоташтырып, кирәгендә туктатып торалар. Бункер авызыннан сигнал буенча агарга тиешле комбиазыкның тигез төшүен тикшерәләр, эчергечләрдәге суның тиешенчә җибәрелүен тәэмин итәләр. Озын өстәл алдында табло, шунда ук телефон, үзгәрешләрне тоеп хәбәр итү күрсәткечләре. Оператор шулар ярдәмендә кетәктәге режимны, андагы яктылыкны, җылылыкны, һаваның сафлыгын өзлексез тикшереп торырга, кирәгендә, дежур слесарьне, я монтерны дәшеп, аварияне бетерергә тиеш.

Фәрит җирән чәчле сузан оператор кыз белән исәнләште дә барысы да тәртиптә икәнлеген белгәч, резин итекләрен лизоллы саламга бик нык ышкып, үстерелә торган чебиләр торган якка чыкты. Бу яландай иркен бер зал корпусның яртысын алып тора иде. Ике якта да, түнкәртелгән гигант буранкалар кебек, брудергаузлар бер-бер артлы тезелеп киткән. Алар астына җылыга чебиләр җыелган. Аларның күбесе зонтның җылырак урынына, уртагарак сыенганнар. Цех уртасыннан әледән-әле тирбәлеп тора торган азык йөрткеч улак-транспортерлар үтә. Брудерлар тирәсендә су эчергеч автоматлар, минераль азыклар савыты, эре ком тагараклары.

Һава Фәриткә шулай да тынчурак тоелды. Ул киштәләрдәге тыныч кына гөрләп торган вентиляторларга күз салды. Бер урында туктап приборларга карап һаваның дымлылыгы, температурасы белән кызыксынды. Биредәге чебешләргә әле ун көн дә тулмаган. Фәрит игътибар белән аларның кыяфәтенә, терелекләренә игътибар итте. Аннан цехны әйләнгәч, кош караучы оператор кыз янына килде. Кыз иң читтәге брудергауз янында чүгәләгән хәлдә, йөгерешеп йөргән чебиләрне күзәтә иде.

— Нәрсә күрдең, Әллә...? — диде Фәрит.

— Юк икән. Болай гына икән... әнә йөгереп китте.

— Шулай да әледән-әле марганцовка эретмәсе бирергә кирәк,— диде Фәрит. Оператор дәшмәде, икенче брудерга юнәлде.

— Син ничек уйлыйсың, Марфа, һава бераз бөркү түгелме?

— И, каян бөркү булсын! — диде кош караучы тыныч елмаю белән.— Сезгә ул урамнан яңа кергәнгә күрә шулай тоела.

— Шулай да микроклимат установкасын карыйк әле.

Алар уң як почмакта түшәмгә кадәр күтәрелгән һава алыштыргыч янына килделәр. Моторның эше, һаваның ничә кубометр алыштырылуы белән кызыксындылар.

— Шулай да бөркүрәк. Углекислота күбрәк, ахры, көйләргә кирәк,— диде Фәрит.

— Үзегезнең борын шәп сизә, Фәрит Зарипович,— диде Марфа,— чыннан да, мотор әкренрәк эшли икән шул.

— Һо, минем борын,— диде Фәрит, баш чөеп,— законный ул!

Фәрит канәгать иде. Әле бик күптән эшләмәсә дә, аның кәефен сиздергән чалымнарын белеп бетергәннәр иде инде.

— Сезнең зоотехник кайда соң? — дип сорады Фәрит китәр алдыннан. Белгечнең башка корпусларга чыгып киткәнен белгәч, ул, операторга һава алыштыруны көчәйтергә кушып, икенче корпуска таба юнәлде. Һәр корпуска кергәндә табанын лизоллы саламга сөртте, ак халатын төймәләде.

Гомумән ул эшнең барышыннан әлегә канәгать иде. Һәрбер кетәктә чебиләр үз яшьләренә карата нормада дип әйтерлек үлчәү артымы бирәләр. Аерым бәрелеп-сугылып имгәнү очракларыннан тыш, бернинди дә куркыныч чиргә, инфекциягә охшаш нәрсә күренми.

Соңгы корпустагы чебиләрнең яше сигез атна иде инде. Димәк, аларны озакламый тота башларга да вакыт. Әмма житлеккән бройлер чебиләрне идәндә асраганда тотып алу шактый катлаулы эш: имгәнүләр, стресслар була. Фәрит шуның турында уйлап алды. Һәм кинәт аңа бик авыр булып китте. Күрәсең, стресс сүзенә бәйләнештәдер, үзенең моннан бер ел элек өзлексез шул стресс хәлендә, тетрәнү, авыр кичерешләр газабында яшәвен хәтерләде. Ирексездән ул йөзен чытты, йөрәге сыкранып кысылгандай булды. Бу уйларына бәйләнештә аның исенә хатыны Фәһимә һәм ике баласы — Ләйлә белән Марат төште. Ул бер мәл онытылып уйларына батты. Әмма бераздан аның күз алдына, ни сәбәптәндер, кинәт килеп баскан Әлфия барысын да үзгәртеп куйды. Ул Фәритнең караңгыланган күңел күген сихри үз балкышы белән бизәде, ачып, яктыртып җибәрде. Юк, Фәрит Әлфиясез хәзер яши алмас иде. Ак йөзле, зифа буйлы тыйнак кыз — аның соңгы юанычы, шатлыгы һәм бәхете. Күптән инде ул Әлфияне югалту дәһшәте астында яши иде. Тик ни эшли ала соң ул? Тезләнеп Әлфиягә барлык дөреслекне бәян итсенме? Булмаслык бер эш бу. Ни булса шул, тик ул үзе ирке белән Әлфиягә бернәрсә дә әйтмәячәк. Менә шул!

Фәрит, үз кабинетына кергәч, әле бернинди эшкә дә кулы бармаган хәлдә креслосында кулларын салындырып, үзе артка авып, бер ноктага караган килеш уйланып утырды. Тик бүген эшләнәсе эшләр күп иде. Фәрит анысын да хәтерләде һәм үзен мәҗбүр итеп кулына каләм алды. Бераздан, язылачы квартал отчеты белән мавыгып, барысын да онытты. Дөньяда отчет һәм Фәрит Еникеев кенә калды.

## 5

Әлфия һәр көн иртә белән эшкә китәр алдыннан Галиәкбәргә нәрсәләр ашарга, ашны ничек җылытырга, кирәгендә ничек телевизор тоташтырырга, ничек магнитофон белән эш итәргә, нинди китап укырга, урманда йөреп кайтырга онытмаска һәм башка бик күп нәрсәләрне аңлата торган булды. Карт Әлфияне көлемсерәп тыңлый: — Ярар, ярар, барын да эшләрмен, кызым, эшеңә соңга кала күрмә,— дип озатып, ялгызлыкта кала. Аның өчен мондый игътибар бик сәер тоела. Чөнки Мәгъмүрә үлеп, өендә хуҗабикә сыйфатында Сафура калгач, мондый хәлләрнең булганы юк, һәм булуы да мөмкин түгел

иде. Күпме кирәк соң карт кешенең күңелен табу өчен! Әлфиянең кадерләп бер җылы сүз әйтүе дә картка җитә кала — күзләренә яшь йөгертә, тамак төбенә төер утырта иде.

— И, кызым, ник шул хәтле өтәләнәсең. Мин бит аяксыз калган мескен бер гарип түгел,— ди ул.

— Шаулама,— дия Әлфия авызын очландырып, ә күзләрендә — дустанә шуклык очкыннары.— Син минем кадерле кунагым, әти. Менә әле иртәгә — ял көне итеп! — әни өйрәткән башкорт кулламасы пешерербез. Ит бар.

Ләкин гомере буена эшләп өйрәнгән кеше тик тора аламы инде! Ашыкмыйча гына тәмләп иртәнге чәен эчкәч, Галиәкбәр колонкада җылынган су белән шулай ук тәмләп савыт-саба юа, аннан аларны урнаштыргач, шулай ук ашыкмыйча гына, кечкенә тузан суырткыч белән идән себерергә керешә.

Гаҗәп хәл, Казанда, өйдә, мондый эшләр аңа берниндн дә ләззәт бирмиләр иде. Чөнки, син эшләргә тиеш моны, син башкага лаек түгел дигән фәрман — Сафура фәрманы карт күңелне телгәли иде. Ә монда исә эш бөтенләй башкача. Рәхәт. Аһ итеп торган кеше өчен Галиәкбәр барысын да, хәтта булдыра алмаслыгын да, эшләргә әзер. Галиәкбәргә Әлфия менә нишә тапкыр инде, бернәрсә дә эшләмә, барысына да үзем өлгерәм бит, дисә дә ата үзенчә итте, һәр көнне савыт-табагын юып, идәнен себереп йөри торган булды. Шуннан соң ул фабрика поселогының артыннан ук башланып киткән урманга чыга. Саф һавада баштан кичкәннәрне искә төшереп, күңелдә төенләнеп калган рәнҗү, кимсенү кебек хәлләрне хыялында, җиңүче буларак, юкка чыгарулар, шатлыклы узган яшьлек көннәрен тагы бер тапкыр күңел түреннән уздырып, рәхәтлек тоюлар карлы урман юлларыннан ялгыз килеш барганда була. Яз галәмәтләрен урман ачык тоя иде инде. Кошлар, моңарчы тавыш-тыннарын чыгармыйча җан саклап яшәгән кошлар, инде уянганнар. Көртлекләр гөрләгәне, мәче башлы ябалакның тамак төбе белән урман яңгыратуы ишетелә. Ылыслы агачлар арасында шактый еш очраган усакларның кәүсәсенә яшеллек йөгерә, тирә-юньнәрендәге нарат-чыршыларны узып китәр өчен ярышка әзерләнгән зифа каеннарныкы исә күз камаштырырлык булып агарган.

Бүген шунда Галиәкбәр Брянск урманнарын хәтерләде. Ул аны беренче тапкыр кырык өченче елның җәендә Курск дугасыннан башланган мәшһүр һөҗүмнән соң күрде. Галиәкбәргә шул урман ешкынлыгында үз взводы белән адашып шактый күп михнәтләр чигеп йөрергә туры килде ул чакта. Искиткеч иде ул урман: анда көндезләрен дә караңгы, андагы юллар — эссе көннәрдә дә сазлы, пычрак. Галиәкбәр взводын дошман турында мәгълүмат алып кайту өчен җибәрделәр. Бәхетсезлеккә каршы, взвод адашты. Тирә-юньдәге нәрсәләрнең берсе дә топографик картада юк иде. Компас һәм сизенүгә таянып барырга туры килде. Һич билгесез юлларга килеп чыктылар. Ниһаять, шулай ук картада күрсәтелмәгән бер урман алачыгында сугыштан качып ятучы, инде тәмам кыргыйланып беткән бер дезертирга тап булдылар. Ул хаиннең йөзен куе кара төк баскан, өсте-башы тетелеп беткән, үзе адәм рәтле сөйләшүне дә оныта башлаган. Өзек-өзек җөмләләр белән аңлатуына караганда, ул инде шунда сугыш башланганнан бирле яткан. Ул барлык кешеләрдән качып гомер иткән: безнең гаскәрләрдән дә, немец баскыннарыннан да, партизаннардан да, хәтта авыл кешеләреннән дә. Ә менә Галиәкбәрләргә ярдәме дә тиде. Ул урман юлларын ерткычтан да шәбрәк белә икән. Тиз арада олы юлга — взводка кирәкле, картада төшерелгән юлга алып чыкты ул. Үзен кулларын каеш белән арттан бәйләп, полк штабына кайтарып тапшырдылар...

Галиәкбәр хәзер дә менә урман кочагында. Ул юлда очраган һәр

агачны диярлек күзеннән кичерә-кичерә, һәр тавышка колак салырга тырышып атлый.

Артыграк кызулады, ахры, йөрәк үзен сиздереп куйды. Иркенләп бер сулау өчен Галиәкбәр туктап торды. Колагына бик ерактан, күрәсең сөйгән ярын бик өзелеп сагынган ябалак тавышы ишетелде. Үзенчә мәхәббәт җырын, яисә серенада, башкара дип уйлады Галиәкбәр. Безнең дә бар иде ул мәхәббәттән чытырдап янарга әзер торган яшь чаклар. Күз алдына Мәгъмүрә, яшь, әле яңа гына Казанга авылдан килгән Мәгъмүрә, килеп басты. Шулай килеп чыкты ки, алар икесе дә — Әгерҗе ягыннан килгән Галиәкбәр һәм Мөслимнән Мәгъмүрә — утыз беренче елның көзендә институтның хәзерлек курсына бергә эләктеләр. Дөрес, Мәгъмүрә анда озак укый алмады — русча бер авыз сүз белмәгән авыл кызына курсны ташларга туры килде. Ләкин бер тулай торакта, бер группада узган ике ай гомер яшьләргә бер-берсенә гашыйк булу өчен җитте. Әле моңарчы Галиәкбәрнең чынлап торып кызлар сөйгәне дә юк иде. Ә менә, күрәчәгең булса дигәндәй, Әгерҗе егете Казанга килеп Мөслим кызына гашыйк булды. Гашыйк булмаслык түгел иде шул Мәгъмүрә: тыйнак табигатьле чибәр кыз иде ул. Күзләре дисеңме, авыз-борыннары, икегә чак кына аерылып торган матур ияге, хәтта колакка таба киткән ягында нәзек кыйгач кашларының өскәрәк күтәрелеп торуы да, барысы да, барысы да искиткеч гүзәл тоелды Галиәкбәргә. Кием-салым бик затлыдан булмаса да, бар кадәресен кыз үзенә килештереп, ару-пакь итеп кия белә иде. Кызыл чәчәк сурәте белән бизәлгән зәп-зәңгәр бала итәкле күлмәге, аягындагы шактый таушалган булса да һәр вакыт чистартылган ботинкалары әле дә исендә Галиәкбәрнең. Тукта, башына нәрсә бәйли иде соң? Шәле бар иде. Искерәк мамык шәл. Галиәкбәр Мәгъмүрәнең башъяулыгын да хәтерләргә тырышты. Аннан: «Ул ялан баш йөри иде. Кем белә, бәлки юньле яулыгы бөтенләй булмагандыр да ул ятим кызның. Куе чәчен бик шомартып тарар иде, толымнарының берсен алга, калку матур күкрәгенә төшерер, ә икенчесен артка салындырыр иде. Галиәкбәрнең шул чәч толымнарын учына салганы булды. Хәтта үпкәндә иснәп тә карады соңрак. Ниндидер хуш ис аңкый иде шул кызыйдан.

Мәгъмүрә институттан китеп фельдшер-акушерлык курсына керде. Монда ул үзен шактый кыю тотты. Күрәсең, күбрәк хәрәкәтләнергә, эш күрсәтә белергә кирәк булгандыр. Бу исә Мәгъмүрә өчен куркыныч нәрсә түгел. Башка торакка күчкәч, байтак вакытлар аның хәбәре булмыйча торды. Бу көннәрнең газабын Галиәкбәр гомере буена онытмас. Ниһаять, аның түземе калмады, ул, Казанны белер-белмәс килеш, кызын эзли чыкты. Дәрес бетү белән торактан китеп, кара кичкә кадәр Мәгъмүрәне өч көн буе эзләде һәм тапты. Баксаң-күрсәң, тулай торакта яшәми икән кыз, аларны аерым квартираларга таратканнар.

Урман юлыннан барган шәпкә яшь Мәгъмүрә Галиәкбәрнең күз алдына үзенең җуелмас матурлыгы белән шулай килеп басты. Кара күзләр, озын керфекле, ышанып, бераз сәерсенеп карый торган нурлы күзләр...

Галиәкбәр шундук ни өчендер Сафураның бораулап карый торган соргылт усал күзләрен хәтерләде. Кем күзләре соң Сафурада? Анасының күзләре бөтенләй мондый рәхимсез түгел иде бит. Әйе, Сафураның күзләре минекен хәтерләтә, ләкин мин дә шулай усал карашлы микәнни?

Инде таныш иркен аланга җитәм дигәндә генә Галиәкбәр каршысына унбер-унике яшьлек малай килеп чыкты. Тәгаен күрше авылдан поселокка мәктәпкә килә иде ул. Башында колаклары тырпайган йөнтәс бүрек, бишмәт изүләре ычкындырылган. Кулындагы портфелен болгый-болгый тирә-юненә карангалап эленке-салынкы гына атлый.

Галиәкбәрне күргәч, тукталып ук калды. Бу ят кеше аның өчен бик сәер күренеш иде, ахры. «Тик ни өчен бала болай сонгарган» дип уйланды карт. Аралары якынлашкач, сорамый булдыра алмады. Ә малай башына соры биек каракүл бүрек, өстенә шундый ук якалы кара драп пальто кигән бу бабай белән шул кадәр онытылып мавыккан иде ки, хәтта картның ни әйткәнен ишетмәде дә.

— Укытучыңнан эләкмәсме соң? Сабагыңны әзерләмәгәнсеңдер әле?

— Ә? — дип куйды малай, аннан дустанә сөйләшүне тоеп: — Бүген минем баш авырта,— дип өстәде.

— Баш авырткач шулай җилбәгәй генә йөриләрме?

Малай монысына игътибар итмәгән иде, күрәсең, агызап тагы Галиәкбәргә текәлде.

— Бар тизрәк өенә кайт та мич башына менеп ят,— диде карт.

Малай мич башының нәрсә икәнен шулай да белә иде, ахры, зур авызын ерып: «Безнең мичебез юк,— дип куйды — Газ.»

Бу сөйләшү картның хәтеренә онык-кызы Лиананы төшерде. Галиәкбәрнең аннан аерылганына — китәр алдыннан Займищега барып Лиананы күреп кайткан иде — әле бик аз ара үткән булса да, ул инде чынлап торып сары песнәген сагына башлаган иде. Юлның калган өлеше бәләкәче, үзе өчен бик-бик кадерле кешесе белән булашып узды. Баланы юньсез анасы кайчакларда бабасына каршы котырта иде, коточкыч мәгънәсезлекләргә барып, бичара сабыйны, инде әтисез калуы гына җитмәгән, үзен өзелеп яраткан бабасыннан да мәхрүм итәргә тели иде. Ләкин, шуңа да карамастан, бала өчен бабасы вакытлы рәвештә генә сөйкемсез булып тоела. Ул бик тиз арада анасы әйткән авыр сүзләрен оныта, аның муенына сарыла, үбә, гафу үтенә. Галиәкбәрне күзләренә яшь килү дәрәҗәсенә җиткереп эретә. Картның фикеренчә, бала бик акыллы, бик зирәк, барысын да белеп, дөреслекне күреп, тоеп тора. Күз алдыннан китә алмыйча, әле көлемсерәп, әле бабасының муенына атланган хәлдә, яки тәмам мәз бетеп, үзалдына сөйләнә-сөйләнә уенчыклары белән мавыккан хәлдә җанлана. Галиәкбәр әле күптән түгел үзенең Казаннан, инде кайтмас өчен, китәргә әзер булуын хәтерләде. Ә хәзер аны Лиана Казанга чакыра иде. Нәрсә бу, картлык йомшаклыгымы? дип сорады ул үзеннән. Ләкин җавап таба алмады. Юк, картаерга исәбе юк иде әле аның. Сафура гына аны тиражга чыккан кеше дип исәпли.

Галиәкбәр юллар чатында тукталып калды. Гадәттә ул шушы турыда сул якка, фабрикадан арырак урман артындагы авылга таба борыла иде. Ә уң яктагы юл буйлап бер тапкыр да йөрергә туры килмәде аңа. Анда, Әлфиянең әйтүенә караганда, кош фабрикасы урнашкан. Бу юлы ул, кызыксынып, уңга киткән юл буйлап атлады. Катнаш урман монда да күе иде. Галиәкбәр әле һаман күңеле белән оныккызы янында булган хәлдә, тирә-юнен күзәтеп, саф урман һавасын ничектер ачылып киткән иркен сулыш юллары аша уздыра. Ул байтак вакыт шулай барды. Лиана бер якынлашты, бер ераклашты. Арага башка хатирәләр, башка күренешләр килеп кысылгалады. Хатыны. Сугыш. Институт. Кызы Сафура. Аның белән артык катлауланган мөнәсәбәт. Тик бары бер нәрсәне генә карт хәтерләмәскә тырышты. Ул да булса — Галиәкбәрне кафедрасын ташлап китәргә мәҗбүр иткән бәхәс, ызгыш.

## 6

Ә институтта моннан ике ел элек булган хәл түбәндәгедән тора иде. Көннәрдән бер көнне Галиәкбәр җитәкләгән кафедраның чираттагы киңәшмәсендә профессор сотрудникларының артык йөгәнсез, үзенә карата хәтта дорфа тотуларына игътибар итте. Гадәттә институтка килгән диссертацияләрне, темасына, белгечлегенә карап, танышып

чыгу өчен тиешле кафедрага бирәләр. Кафедра, шул гыйльми хезмәт белән танышканнан соң, аның совет алдында якларга яраклымы-яраксызмы икәнлеген хәл итә. Яраса, булачак оппонентларның кандидатурасын билгели. Шундый әзерлектән соң диссертация гыйльми советка тагын куела һәм, совет кафедра фикере белән килешсә, кафедра сүзе карар буларак рәсми төс ала.

Галиәкбәрне сагайткан бу кафедра киңәшмәсендә сүз нәкъ бер диссертация турында барды. Мөдир ул диссертация белән башта ук танышкан иде инде. Ул бу фәнни хезмәтнең саерак икәнлеген шундук күреп алды. Мондый хезмәт белән гыйльми совет алдына чыгып, дәрәҗә дәгъва итү ярый торган эш түгел иде аныңча. Ләкин шулай да, хезмәтнең авторы производство вәкиле икәнлеген искә алып, үз тәҗрибәсе буенча, мондый категория диссертантларга, гадәттә, кайбер ташламалар ясалуын аңлаган хәлдә, Галиәкбәр диссертацияне бөтенләй үк тибәрмичә, авторын тагы бераз эшләтеп хезмәтен тулыландыру өчен үзенә кайтарырга кирәк дигән фикергә килде. Ул, шундый карашын куәтләү һәм нигезләү өчен, диссертацияне ныклап тикшерү вазифасын үзенең доценты, соңгы вакытларда аерата актив эшләүче Эльвира Хәкимовнага тапшырды. Ул доцентының гадел хөкем чыгарачагына әз генә дә шикләнми иде. Мәгәр хәл һич уйламаганча, көтмәгәнчә килеп чыкты. Эльвира киңәшмәдә авыз суларын корытып диссертацияне мактарга тотынды. Хезмәттән ниндидер алмаз бөртекләре тапты. Авторның производствода эшләүче икәнлегенә аерата басым ясап, хезмәтнең кимчелекләренә күз йомып узды. Галиәкбәр бу хәлгә хәйран калып, колакларына, күзләренә ышанмыйча утырды. Үкенечкә каршы, ул диссертацияне укыганда аның бит кырыйларына билгеләр ясап бармаган иде. Хәзер исә үзенең шул искәрмәләренә нигезләнеп ул Эльвирага үз фикерләрен исбатлау мөмкинлегеннән мәхрүм иде. Шуңа күрәдер, аның әйткәннәре кафедра әгъзаларына тиешле тәэсир ясамады. Киресенчә, хезмәтне укып кына чыккан, Эльвира кебек үк, аны җентекләп тикшермәгән ассистентлар да доцентны якларга керештеләр. Әйтергә кирәк, Галиәкбәрнең беркайчан да кул астындагы кешеләрне кысу, мәҗбүр итү юлларын кулланганы булмады. Ул һәркемгә ирек бирә, һәркем үз фикерен ачыктан-ачык әйтергә хаклы, чын гыйльми дәреслекне бары бәхәсләр аша гына табып була дигән караштa яши иде. Бу юлы да, күп тапкырлар кабатланганча, кулларны җәеп, елмайган хәлдә: «Әйдәгез алайса, сезнеңчә булсын, диссертацияне оппонентларга биреп карыйк, советка куйыйк, дөреслек шунда тантана итсен»,— диясе дә куясы иде бит инде. Ләкин ул алай эшли алмады. Чөнки профессорга кафедрадагы сотрудниклар яңа сыйфатлары белән күренделәр. Бу — фетнә иде. Бу кафедра җитәкчесенә каршы үзенә күрә баш күтәрү иде, бу — профессорны инкарь итү, аны санга сукмый башлау иде. Хезмәтнең кимчелекләренә күрәләтә күз йомып сөйләү, ул профессорча булмасын, дигән ахмак бер үзсүзлелек, дуамаллык иде. Әле мондый хәлнең кафедрада бер тапкыр да булганы юк. Галиәкбәргә шулай тоелды. Ул үзе тәрбияләп үстергән коллектив фикере белән килешмәсә дә, киңәшмәдә артык бер сүз дә әйтмәде. Диссертациягә, профессорның катнашыннан башка, оппонентлар кандидатурасын билгеләделәр. Күпчелек тавыш белән диссертацияне гыйльми советка «бара» дип тәкъдим итәргә булдылар. Дилбегә хәзер Эльвира Хакимовна кулында иде.

Бу Галиәкбәргә карата эшләнгән коточкыч бер хыянәт иде. Профессор бу эшне шулай гына бәяләде дә. Эш нәрсәдә? Нинди ялгышлар ясады соң ул? Ни өчен аның, шундый тәҗрибәле профессорның шәкертләре алдында кинәт кадере бетте? Галиәкбәр булып узган эшен-гамәлен бер җепкә тезеп башыннан уздырды, һәр сотрудникка карата булган мөгамәләсен барлык нечкәлекләренә кадәр хәтерләргә

тырышты. Лэкин ул аңларлык, төртеп күрсәтерлек берни дә юк иде. Ул беркайчан да кафедра сотрудникларының дәртләнеп, теләп керешкән эшләренә аяк чалмады. Хәтта, киресенчә, аларга бу очракта төрлечә ярдәм итәргә тырышты. Инде аерым кеше ялгышса, ул аны батыру түгел, ректорат һәм башка җитәкчеләр каршында акларга ашыкты. Инде нинди дә булса киңәш яки методик ярдәм кирәк икән, ул булганның барын-барын да кызганмыйча, яшермичә чыгарып аудара торган булды. Яхшылык, яхшылык, яхшылык. Аның эшләгәне бары шул булды. Инде нинди нәтиҗә килеп чыкты шуннан? Галиәкбәр аптырашта калды. Ул үзеннән-үзе кафедра әгъзаларыннан читтәрәк була башлады. Берәр йомыш белән мөрәҗәгать итсәләр, Эльвира Хәкимовнага җибәрә торган булды. Бәлки бу көннәрдә Мәгъмүрә каты авырый башламаган булса, аның үзен кулга алырга, кафедра белән уртак тел табарга көче дә җиткән булыр иде. Тик нәкъ шул көннәрдә хатыны аяктан егылды. Өлкән кызы читтә, Ростовта яши, Әлфия исә шулай ук читтә, елга якын инде район ветбаклабораториясендә эшли. Ул хезмәтеннән бик разый, аны Казанга кайтару һич килешмәгән бер эш. Кыскасы, Мәгъмүрәне карау башлыча (туганнар килгәләп торсалар да) Галиәкбәргә төште. Татулыкта гомер иткән, яратып алган хатынының хәзер кузгала алмыйча ятакта аунавы, котылгысыз катастрофаның күзгә күренеп якынлашуы Галиәкбәрнең канатларын бөтенләй каерып ташлады. Ул кафедрадагы күңелсез бер сөйләшүдән соң, бәлки минем эштән китүем Мәгъмүрәнең гомерен озынайту булып чыгар, дигән фикер белән үзен тынычландырып, пенсиягә чыгарга булды. Ректоратта да, партия оешмасында да аптырап калдылар. Мәгәр Галиәкбәр китүенең төп сәбәбен яшерде. Хатынының һәм үзенең дә сәламәтсезлеген, инде лекцияләр укуның артык авыр бер эшкә әйләнүен сылтау итеп күрсәтте. Аннан, яшьләргә дә юл ачылырга тиеш бит кебек гомуми һәм бу очракта җитәрлек нигез була алмаган сәбәпләр тапты. Хәер, ректор: бәлки атнага бер-ике килеп консультант сыйфатында эшләрсез, дигәч, күңел түрен бераз ачып күрсәтми булдыра алмады. Юк инде, диде, минем консультацияләремә мохтаҗ кеше калмады кафедрада.

Ул шулай эшеннән китте. Хәзер аның өчен бары Мәгъмүрәсе һәм читтәге кызлары гына калды. Галиәкбәр хатыны өчен булдыра алганның барысын да эшләде. Мәгәр хатынның бавыры да, йөрәге дә артык таушалган иде шул, бернинди дару, бернинди режим аңа ярдәм итә алмады. Көзге күңелсез яңгырлы көннәрнең берсендә ул бавыр чиреннән үлеп китте. Сафура Лиананы ияртеп Ростовтан иреннән аерылып кайтты. Яңа борчулар, яңа күңелсезлекләр башланды. Әйе, тормыш ул. Ул бик катлаулы дип авыз ачсаң бик гади кебек, ә ул гади бит дип карасаң — артык катлаулы.

Галиәкбәр институт белән араны бөтенләй өзәргә булды. Гыйльми совет члены булуына карамастан, утырышларга да чакырганда гына барды. Шулай аңа тынычрак тоела иде. Һәрхәлдә, институт еракта калган саен хәтер ярасы бетәшә баргандай һәм ул институт хәлләрен мөмкин кадәр искә алмаска тырышты. Әлбәттә, булдыра алганча...

Менә бу юлы да истәлекләр кино тасмасыдай сузылып бара-бара, ниһаять, кафедра хәлләренә җиткәч, кинәт өзелгәндәй тоелды. Дөресрәге, Галиәкбәр үзе өзде аны.

Хәлбуки, Казанда, үзе эшләгән кафедрада менә шушы минутларда нинди эшләр килеп чыгуын белсә, карт өчен бәлки шактый күңелле булыр иде. Моннан ике ел элек Галиәкбәр төзәттерергә теләгән, ә кафедра сотрудниклары исә, Эльвира Хәкимовнага ияреп, аны яхшы дип тапкан диссертация ВАК карамагында байтак вакытлар яткannan соң, ярәксыз табылып, кире кайтарылды. ВАКта диссертант-

ны алдынгы кош фабрикасының директоры да дип тормаганнар, берничә тапкыр орден белән бүләкләнүен дә искә алмаганнар, хезмәтенең сыйфатыннан чыгып, бу кеше авыл хуҗалыгы фәннәре кандидаты дәрәҗәсенә әле лаек түгел дигән нәтиҗәгә килгәннәр. Һәм барыннан да сәерраге шул — хезмәтнең кимчелекләрен кайчандыр нәкъ Галиәкбәр күрсәткәнчә язганнар. Бу хәлне белү белән башта Эльвирә Хәкимовна «тәгаен бу эштә безнең бабайның кулы уйнагандыр» дигән фикергә килде. Ләкин бу уй доцентны озак биләмәде. Чөнки моның булуы һич тә мөмкин түгел иде. Галиәкбәр беркайчан да эшне астыртын йөртә торган кеше булмады. Моңа Эльвираның вөҗданы каршы. Аннан Эльвира үзе дә диссертацияне укыганда шул ук кимчелекләрен шәйләмәдемени? Ләкин ул чагында аның күзләрен профессорга карата булган тәнкыйтьчәнлеге, дөресрәге, ачуы, аны өнәми башлавы томалады. Ни өчен ачулы иде ул профессорга? Әйе, ул үзе генә түгел, башка иптәшләр дә аның яклы булды. Чөнки, аларча, профессор үзенең артык яхшылыгы аркасында кафедраны бөтенләй таркатуга илтә иде. Әгәр кафедра каты кулларда булмаса, җитәкче төгәл ритм, шәп куелган тәртип буенча эшне алып бармаса, ничек итеп гыйльми эш, укыту, производствога ярдәм планнарын үтәргә мөмкин булсын, ди. Кафедра сотрудниклары, техник персоналдан зарланып еш кына үзара сөйләшкәндә, аларның хезмәткә салкын каравы профессорның артык юаш булуыннан килә дип картны күптән гаеплиләр иде инде.

Ләкин эш кешесенең кадерен ул үзе киткәннән соң гына тиешенчә белеп була, ахры. Галиәкбәр пенсиягә чыккан шәпкә барысы да үз урынына утыргандай тоелса да, бераздан кафедрага нидер җитмәгәнлеге, һәм бу нидер, баксаң-күрсәң, профессор икәнлеге сизелә башлады. Кафедра хезмәткәрләренең күпчелеге хәзер Галиәкбәргә булган карашларын йөз дә сиксән градуска үзгәртте: ул кешелекле, вөҗданлы, һәркемгә ачык йөзле иде. Ул һәркемнең хәл-әхвәле белән кызыксына иде, һәркемне аталарча якын күреп, кирәгендә яклый, кирәгендә, авыр сүз әйтмичә генә, эшләтә дә белә...

Кафедра сотрудниклары хәзер аерата бер игътибар белән яңа мөдирне, Эльвира Хәкимовнаны, күзәтә башладылар. Һа, карасана! Бер дә моңарчы игътибар ителмәгән ләбаса! Яңа себерке булып артыграк тырышлык күрсәтмиме соң? Әле берәүне, әле икенчене бүлмәсенә чакырып «акылга утырта» бит. Китче, бу инде бөтенләй югары мәктәп алымнары түгел. Болай булса...

Эльвира да иптәшләренең үзенә карата суынганлыгын, нинди дер ирония белән карауларын, хәтта ачу саклап йөри башлауларын сизде. Ләкин аныңча бу шулай булырга тиеш тә иде. Җитәкче белән җитәкләнүче арасында һәр вакыт билгеле бер ара булырга тиеш, рәсмилек булырга тиеш, бернинди агай-энелеккә, панибратствога юл куелмасын. Әгәр хезмәт интереслары таләп итә икән, җитәкче тегесен дә, монысын да алып ташларга хаклы, тегесенә дә, монысына да каты куллы, нык бәгырьле булырга тиеш, һәм моның өчен аның вөҗданы беркайчан да азапланмасын. Ничек диләр әле? Әйе, революцияне ак перчатка киеп ясамыйлар.

Ләкин Эльвира соңгы вакытларда Галиәкбәрне үз ихтыяҗларыннан чыгып юксына башлады. Ул инде күптән докторлык диссертациясе өстендә эшли. Шактый җитди экспериментлар уздырды — лаборатория шартларында да, производство шартларында да. Инде каралмада диссертация язылган да иде. Тик нәрсәдер җитми кебек, я булмаса инде аңа шулай тоела иде, ахры. Һәрхәлдә, тыныч рәвештә, аталарча кайгыртучанлык күрсәтеп киңәш бирүче кешенең үз янында булуы кирәк иде. Ул күптән инде Мәскәү белән элемтә урнаштырды. Андагы абруйлы галимнәр — аның консультанты. Ләкин ул гына җит-

ми иде. Андый кешенең Эльвира янында булуы да зарури иде. Менә утырсын иде ул, әйтик, шушы кабинетта, берәр төргә килеп төртелдеңме, кер дә киңәш ит. Ә андый кеше бар иде бит. Соңгы елларда кафедрада «бабай» дип аталган Галиәкбәр иде бит ул.

Эльвира Бабайга ихтыяҗ артканын көннән-көн күбрәк тоя барды. Ләкин аның кафедрадан китүендә үзенең дә гаебе барлыгын чамалап, ул профессорның өенә барырга батырчылык итми иде. Әле ВАКтан килгән кәгазь белән танышкач, ул ирексездән тагы бер тапкыр Галиәкбәрне хәтерләде.

Өч көн икеләнеп йөрде. Аннан, ниһаять, батырлыгын җыеп, иелгән башны кылыч кисми дигән кагыйдә буенча, Галиәкбәрнең үзенә шалтыратырга булды. Сылтау бик әйбәт иде. Инде бу юлы да Эльвира аңа мөрәҗәгать итмәсә, тагы кайчан мондый мөмкинлек туачак!?

Ул мөдир кабинетында, юан аяклы, өсте яшел постау белән тышланган яландай зур борынгы язу өстәле янында утыра иде. Бу өстәл тирәсендә революциягә кадәр үк эшләгән профессорлар да утырган. Ак халаттан, күпереп торган кара куе чәчле, шактый кырыс, ләкин матур йөзле, кылыч борынлы, ихтыяр көчен чагылдырып торган матур авызлы Эльвира, үзен мәҗбүр итеп, тиз-тиз генә номерлар җыйды да озын гудокларны тыңлый-тыңлый телефоннан таныш аваз көтә башлады.

## 7

Телефон трубкасын Сафура алды.

— Тыңлыйм мин сезне, — диде гадәттәге гамьсезлек чагылган тон белән.

— Гафу итегез, — диде Эльвира, — миңа Галиәкбәр Хафизович кирәк иде.

— Ә, — дип куйды Сафура, буш кулының тырнаклары маникюрлы һәм берничә алтын йөзекле ак озын тулы бармакларын илтифатсыз, җиңелчә генә селкеп. — Ул өйдә юк.

Сафураның озаклап сөйләшеп торырга һич вакыты да, теләге дә юк иде. Олы якта кунаклар көтә. Әллә кайчаннан бирле җыела алмый тәмам сагындырган дус-иш. Әле моннан унбиш минут элек кенә очраштылар. Сафура шатланып очына-очына табын әзерли башлаган иде. Кырыкка ярылырлык шундый чакта кемдер аны телефонга бәйләсен, имеш. Ул трубкадан котылу өчен аны сапфир кашлы алка тагылган матур ак колагыннан аера башлады. Ләкин Эльвираның тагы әйтер сүзе бар икән:

— Гафу итегез, миңа ул бик-бик кирәк иде. Аның кайда икәнен һәм кайчан кайтачагын әйтегезсәнә.

Сафура җитдиләнә төште.

— Кем сорый аны?

— Бу ул эшләгән кафедрадан. Эльвира Хәкимовна Нуриева. Ә сез кем буласыз?

Сафура үзенең кем икәнлеген әйтмәде.

— Ул юк. Мин аның кая киткәнен дә анык белмим.

— Ничек инде алай? — диде Эльвира аптырый төшеп,— сез аның кызымы?

— Әйе, — диде теләмичә генә Сафура. — Калдырган язуында ул үзенең кайда китүен әйтмәгән.

— Сез аның кызы Сафура ханыммы?

Сафура тагы бер сүз дә әйтмәде, бары ишек якка житез бер караш ташлап карандаш белән сызылган нәзек кашларын гына җыерды. Эльвираның сүзе һаман бетмәде.

— Кая китүе ихтимал соң аның? — дип сорады.

— Кая китүе, — дип кайтадан сорады Сафура, тәмам ачуы кабынган хәлдә. — Әйтә алмыйм. Гафу итегез, мине көтәләр, — диде һәм тагы берәр сүз әйтмәгәе дигәндәй кабаланып, трубканы куйды.

Аны залда иптәшләре көтәләр иде. Табын тирәсен тутырып утырышканнар, рюмкаларга винолар салынган, бары хуҗабикәнең беренче тостны әйтүе генә кирәк. Кримплен тар макси юбкасын бармак очлары белән генә чеметеп тоткан хәлдә, Сафура ашыгып кунаклары янына чыкты.

— Кем шалтыратты, Светланочка түгелдер бит? — дип сорадылар кунаклар. Ни өчендер вәгъдә бирүенә карамастан, Светлана күренми иде.

— Юк, — диде Сафура, телефон турында сөйләшеп торуның кирәге дә юк дигәндәй, гадәтенчә сул кул бармакларын хәлсез генә селтәп алып. — Атай картны эзлиләр. Әйдәгез, күтәрик бокалларны. Хәзер бик оригиналь тост әйтәм.

Ләкин Сафураның иҗат җимеше кунакларның исләрен әллә ни китәрмәде. Ул мәңгелек яшьлек өчен, тормышның рәхәтен даулашып, киреләнеп маташса, балта белән ишеген каерып ачып кулга эләктерү өчен тост тәкъдим итте. Мондый тостлар күп кабатланган иде инде.

— Әти-әниләрнең газап чигүе дә җиткән, без бер кешечә яшик, ичмаса, — диде Сафура тостын тәгәлләп. Ул матур йөзен тантаналы һәм ничектер моңсурак рәвештә югары күтәрде.

Тост әллә ни оригиналь булмавы өстенә бераз минор тондарак булып чыкты, мәҗлеснең программасына тәңгәл килмичә артык акыл сатуга тартымрак иде. Шулай булса да, Сафураның күңеле булсын өчен, кунаклар тостны хуплап рюмкаларын күтәрделәр. Сүзне уенга бора төшеп, берсе яңа гына ишетелгән «сакалсыз» анекдот сөйләп алды. Икенчесе мәҗлес күрке өчен тагын бер анекдот сөйләп көлдерде. Сафураның тосты тудыра язган күңелсезлек эссез-нисез юкка чыкты. Табында күтәренкелек хөкем сөрә башлады.

Сафураның кунаклары ул үзе якын күргән, серләре килешә торган яшь кешеләр иде. Арада аның элек-электән, хәтта балалар бакчасыннан бирле аралашкан дуслары, инде иреннән аерылып Казанга кайтканнан соң танышкан якыннары һәм соңгы вакытларда гына очрашып арада дуслык җепләре сузылган ахирәтләр дә бар. Шулай ук ялгызак, әле өйләнмәгән, я кияүгә чыкмаганнары да, өйләнешкән, семьялы, мәҗлескә парлашып килгәннәре дә бар иде. Бу нинди дер зур тантана уңае белән җыелган мәҗлес түгел. Болай гына, ял көне алды итеп кенә күңел ачып бер утырышу, кагыйдәгә әйләнә башлаган бер очрашу иде инде. Бер җомгада берсендә, икенчесендә бүтәнендә күңелле итеп бер сыйланып күңел ачу.

Бүген исә чират буенча мәҗлес Светланада булырга тиеш иде. Ул кыз картайган әнисе белән генә тора. Кечкенә бер бүлмә, тыгыз, кысан. Шуңа күрә аулак өй иркен, тыныч дип, шул мәҗлесне Сафураларда уздырырга булдылар. Светлана кичә үк салкын закускага һәм чәйгә кирәк ризыкларны, кайнар ашка дип кукаен, итен калдырып киткән иде. Ә эчемлекне, йола буенча, кунаклар үзләре китерергә тиеш. Шулай җайлы, арзанга төшә.

Кунакларның күпчелеге бик күңелле, җор, тапкыр кешеләр, өстәвенә, яшь булсалар да, институт бетергәч шактый зур тормыш тәҗрибәсе туплаганнары да бар. Араларында бары берсе, Димка дигәне, тәҗрибәгә фәкыйрьрәк, әле күптән түгел институт бетереп, диплом яклаган инженер.

Сафура табигате белән аралашырга яратучан, хәзергечә әйткәндә,

коммуникабель сыйфатларга ия кеше. Аның һәркайчан дус-ишләре күп һәм бу дуслар арасында берсе аерата якын була. Бу хәл Сафура кияүгә чыкканга кадәр дә шулай иде, аерылып кайткач та дәвам итә. Моны яшь хатын логик яктан аклый да иде. Аның ышануынча, хатын-кыз берәр химаячесез яши алмый. Әгәр шундый яклаучысы булмаса, төрле ловеласлар [1] аңа көн бирмәячәк. Димәк, бу яклаучы ир аны шундый бозык әхлаклы донжуаннардан сакларга тиеш. Ләкин, кызганычка каршы, Сафураның яклаучысы белән булган мөнәсәбәт һәр вакыт артык тирәнгә китә. Һәм ул, яшь лейтенант белән узган вакытын исәпләмәгәндә, һәр очракта больницада ятып чыгу белән чикләнә торган булды. Бу Сафура сигезенче класста укыган көннәрдән башланды. Сафура әнисе тәрбиясендәге кыз иде. Аның «иптәш кызымда кундым» сылтавы белән югалып торуларыннан, әлбәттә, әнисе кайда булу ихтималын әйтмәсә дә сизенә, кызына рәнҗи, аның өчен ут йота, кайчагында ләгънәтли дә иде. Әмма Сафура этисе белән генә тора башлагач, бу яктан эшләр җайланды. Бичара эти карт мондый эшнең булу ихтималы турында уйламый да иде...

Бераздан Светланочка да килде. Ул әйбәт торт күтәреп керде. Аңлатуына карганда, тортка заказ өченче көн үк бирелсә дә, аны әле яңа гына эшләп биргәннәр икән. Светлана шуны көтеп соңгарган.

Ул килгәндә мәҗлес кыза төшкән, вино шактый эчелгән һәм кунаклар туарылып, кызарынып киткәннәр иде. Бүгенге кунаклар арасында да Сафураның яклаучысы бар. Бу — әлеге Дима исемле аксыл чәчле буйчан атлет егет. Аның Сафура кунаклары арасында әле беренче утыруы. Аңа Сафура урынны үз яныннан бирде. Ул Дима белән моннан ике атна элек кенә танышкан иде. Гадәтенчә, ул егет белән бик тиз дуслашып китте һәм аны шундук үзенең чираттагы химаячесе итеп сайлады. Дима армиядән кайткач кына институтка эләгә алуы аркасында үзенең шәрикләреннән олы булды. Ә монда исә, кунакта, ул күпчелек ир-аттан яше белән артык аерылмаса да, тоткан дәрәҗәсе, тәҗрибәсе белән түбәнрәк иде. Сафура таныштырганда мәҗлестә ике фән кандидаты, калганнары институт бетергәннән соң тәҗрибә туплап шактый күтәрелгән кешеләр булуын әйткән иде аңа. Күрәсең, шуңадыр, Дима бу яңа даирәдә үзен шактый югала төшкән хәлдә, берникадәр кыюсыз тота иде. Мондый уңайсыз хәлдән коткару өчен Сафура егетенә карата аерата игътибарлы булды. Кайнар аш белән чәй арасында көнбатышның модалы көйләренә әрсез боргаланып биегәндә ул гел аның белән иде. Сафура торт аркасында соңгарып калган Светланага мәҗлес дилбегәсен тоттырган иде инде. Биегән арада аның Диманы кинәт тәкатьсез каты кочып үбәсе килде. Бу, ихтимал, хәмер тәэсиреннәндер, ә бәлки каршында кулларын тирбәндереп, күкрәк мускулларын уйнатып биегән яшь, матур, тыгыз тәнле егетнең, аның якты күзләренең, елмайган тулы иреннәренең тәэсире дә булмый калмагандыр. Сафура рәхәт бер изрәү белән башта аның киң иңбашына маңгаен терәде, аннан егетен бармак очларыннан тотып этисенең бүлмәсенә әкрен генә тартты.

Бүлмәдә беркем дә юк. Яшьләр утның өстәл өстендәгесен, сыек яшел төстәге абажур астындагысын калдырып, түшәмгә асылганнарын сүндерделәр. Аулак, тыныч булып китте. Яшьләр туйганчы, сулышлары беткәнче, үбештеләр. Аннан алар кочаклашкан килеш хәлсезләнеп диванга утырдылар. Сафура егетнең куенына ук кереп беткән иде. Дима исә аны бер кулы белән кочаклаган хәлдә, икенче кулы белән яңакларын сыйпый, иркәләү сүзләре әйтеп һаман иренәә таба үрелә иде. Бераздан алар өстәлдә яткан сигарет тартмасына су-

[1] Ловелас — хатын-кызлар аздыручы кеше.

зылдылар. Дима ашыгып шырпы кабызды. Икесе дә хәзер иркенләп диванга ярым яткан килеш ял итеп тәмәке тарталар иде.

— Син мәҗлесне ачканда тостыңда ни өчендер әти-әниләреңне искә алып сөйләдең. Күрәсең, син әтиеңнең китүен шулай да авыр кичерәсең булса кирәк, — диде, ниһаять, Дима.

Сафура ярым елмайган хәлдә төтенне авыз читеннән генә өреп чыгарды да:

— Рәхмәт игътибарың өчен, — дип куйды. — Ә әти мине, чыннан да, уңайсыз бер хәлдә калдырды.

— Нигә, син кичә генә аның мыжгуларыннан котылдым дип куанган идең бит?

— И тел ни сөйләмәс! Әгәр дә ул миңа акча калдырып киткән булса... Тик картлар бит, үзең беләсең, коточкыч саран булалар. Бер тиеннәре өчен калтыранып торалар, җаннары чыга.

— Ну, Софа, кирәкми! Ташла!

— Ник, дөрес түгелмени? — диде Сафура, Димага сынап карады.— Әллә синекеләр башка камырданмы?

— Син артыграк гомумиләштерәсең, минемчә. — Ул сүзен әйтеп бетермәде. Сафура аны бүлдерде.

— Ихтимал, шулайдыр да. Ихтимал, минем өлешемә чыккан бәхет кенәдер бу. — Ул, үрелеп, өстәлдә торган пепельницага сигаретның көлен төшерде. — Миңа хәзер материально бик авыр, Дима. Менә син шундый хәлдә, әле яңа аякка басып, эштә ныклап үзен күрсәтмәгән хәлдә булган кызыңны, туган кызыңны ташлап, аннан качып, качканда да ничек әле — куркакларча качып китәр идеңме? Ярый, ул мине гомере буена яратмады. Ә минем кызымны өзелеп яратам дигән була. Шуның өчен, Лиана өчен, ичмаса... Я, ничек синеңчә?

— Әйе, ул картларны аңламассың, — дип куйды Дима. Сафура үз алдына сөйләнгәндәй уйчанланып дәвам иттерде.

— Бала чактан ук без ташландык бер хәлдә тәрбияләндек. Әти, әни тәрбиясе булмады. Башта яслегә, аннан балалар бакчасына илтеп ташладылар. Янәсе, алар эшли. Аларга карьера кирәк. Менә нәтиҗә! Синнән яшермим, әниемә карата да, әтигә карата да миндә тырнак очы кадәр генә дә хөрмәт юк. Ә бит баланың аңы өч яшькә кадәр формалаша.

— Шулаймыни? Ул кадәресен белми идем. Өч яшькә кадәр...

— Әйе, өч яшькә кадәр генә, — диде Сафура катгый рәвештә. Аннан ул тирән хәсрәт кичерүче буларак уфтанып куйды.

Егеткә кыз кызганыч булып тоелды.

— Син юкка үз-үзеңне бетерәсең,— диде ул.— Нигә кирәк ул уфтанулар! Исән киткән икән, әтиеңнән башка яшәп булмыймы?

— Акча кирәк, акча, Дима, аңлыйсыңмы?

Сафура сигаретын көл савытына ташлады да Диманың дулкынланып торган куе аксыл чәчен учлап селкеде.

— Их син, Дима, белмисең син тормышның нинди рәхимсез икәнен!

— Юк, минемчә, син шулай да, Софа, бераз утрировать итәсең.

— Утрировать итмим. Без югалган буын.

Сафураның күзләренә яшь тулды.

Куркынган Дима аны тагы кочаклап алды.

— Ташласана, җанкисәгем. Ташла. Шулай үзеңне һич нигезсез газапларга ярыймы?!

Бу вакыт Диманың күкрәгенә башын куйган хәлдә Сафура тагы әтисе турында уйланды. «Мөгаен, ул Әлфия янына киткәндер, юкка теге хатынга шуның адресын бирмәдем».

Бераздан ул урыныннан торып чәчләрен тәртипкә китерде дә:

— Әйдә, Димочка, кунаклардан яхшы түгел, теге якка чыгыйк, — диде.

Залда мәхшәр иде.

8

Бройлер чебешләрен читлекләргә япканга ун көн узып китте. Фәрит бу көннәрдә тетрәнеп яшәде. Үзе өчен генә түгел, бөтен фабрика өчен җитди бер сынау иде бу. Директордан алып контроль капкада торучы абзыйларга кадәр, тәҗрибә барып чыкса, фабрика өчен зур яңалык буласын, корпусларда мәйдан артмаган хәлдә дә продукцияне фабрика күбрәк җитештерә алачагын беләләр иде. Әмма бу ысул эш башкаручылардан бик зур игътибар һәм белем таләп итә. Хәтта кечкенә генә чатаклыкның да фабрикага бик кыйммәткә төшүе мөмкин. Монысын исә күп кеше белми әле. Шуңа күрә Фәрит, башка барлык эшләрне читкә ташлап, бары читлектәге кошлар белән генә шөгыльләнде.

Гадәттә гибрид чебешләрне биредә ун атна үстерәләр. Менә шул санаулы ун атнаның ун көне узды. Беренче көннәрдә үлем-җитем әзмәз булса да, әйтерлек куркыныч хәл күренмәде. Чебешләр тиешле температура һәм һава режимында тотылалар. Фәрит операторлар янына өзлексез кереп тора — режим үзгәрешләрен күзәтеп, кирәк чагында тиешенчә аны төзәтеп тору кирәклеген тукый. Чебешләр беренче ай рецепты буенча төзелгән комбиазыкта хәзер. Ничек, тиешенчә ашаламы азык? Ашалса, ул азык иткә әйләнәме? Чебиләрнең берничә читлектәгесе контроль өчен тотыла. Аларны биш көн саен үлчи торалар. Шуларның авырлык үзгәрешенә карап, сынауның барышы билгеләнә.

Ун көн узды. Үлчәнгән контроль чебиләр өметле нәтиҗә бирде. Мондый уңышка ирешкәч, Фәритнең күңеле күтәрелеп китте. Әйе, ул хәзер эшнең барышы белән Закирҗановка сүз биргәне өчен генә кызыксынмый. Яңа тәҗрибә аны үзе шулай мавыктырды. Аның бу эшне барысыннан битәр үзенең эчке ихтыяҗы канәгатьләнсен өчен дә эшлисе килә башлады. Әйтергә кирәк, үзенең шул дәрте белән ул цехның башка эшчеләрен дә кузгатып җибәрде. Ул «авырган чир» эшчеләргә дә йокты.

Ләкин ул артыграк мавыга иде булса кирәк. Директор бүген гадәттә уздырыла торган көндәлек планеркада бик мәгънәле генә итеп аңа әйтеп куйды: «Сынаулар яхшы старт алган. Ярый. Ә башка цехларның эше ничек, онытылдымы?» — диде.

— Онытылмады, — диде Фәрит кинәт кызарга чамалап. — Бик җитди эш башладык бит. Көйли алсак...

— Ни әйттең иде дә, — диде директор, — тик син үз вазифаларыңны истән чыгармасаң тагы да шәбрәк булыр иде.

Бу сүзләрдән соң планеркага җыелган кешеләр ни өчендер тавышланып ук көлештеләр.

Әлфия сынауның беренче көннәрендә үк Фәрит өчен борчыла башлаган иде инде. Бүген иртән эшкә килгәндә алтынчы цехта эшләрнең начарлана башлавы турында ишеткәч, ул бөтенләй пошаманга калды. Фәрит белән сөйләшергә кирәк, һич югында, үзем икенче сменага күчеп, аңа булышырмын дигән фикергә килде. Әле тавышланып, үз шатлыгын уртаклашырга Әлфия янына лабораториягә Фәрит килеп кергәндә, кыз рефрактометр[1] шкаласын көйли-көйли, нәкъ шул турыда план кора башлаган иде.

[1] Рефрактометр — эремә аша узган яктылыкның сыну микъдарын үлчәү приборы.

— Мине котлый аласың, — диде Фәрит ашыгып.

Әлфия башын күтәрде.

— Нәрсә белән?

— Контроль группаны үлчәдек, артым уртачадан ким түгел.

— Оһо, — диде Әлфия. Аның аксыл йөзен елмаю һәм шәфәкъ кызыллыгы бизәп алды. — Тәбрик итәм. Тик шуннан чыгып кына, бары да яхшы булыр дип, әйтергә иртәдер бит әле, Фәрит?

Фәрит үзенең ни дәрәҗәдә арганлыгын әле генә сизде. Ул тирән сулап утыргычка чүкте. Бераз вакыт Әлфиянең бюреткадан химик стаканга селте эремәсе тамызып, әледән-әле стаканны селкеткәләп, ара-тирә яктыга куеп карап утыруын күзәтте. Аннан кинәт нидер хәтерләп чәчрәп урыныннан торды.

— Шалтыратырга кирәк бит! Менә си-ин...

Әлфия эшеннән аерылып аның борчулы йөзенә күз ташлады.

— Кемгә?

Фәритнең, мөгаен, кызга якын ук килеп, һич югында, аның матур эшчән кулын кысасы, үзенең аңа булган мәхәббәтен белдерәсе килә иде. Ләкин эш вакытында бу мөмкин нәрсә түгел икәнлеген ул шундук абайлап алды. Һәм әйтерсең гаепле эштә тотылгандай, тирә-юнегә кыюсыз гына күз ташлады. Шулай да Әлфия яныннан узышлый ул шыпырт кына, «бүген кичен сугылырмын» дип әйтергә батырчылык итте.

— Син минем соравыма җавап бирмәдең әле, Фәрит, — диде Әлфия.

— Нинди соравыңа?

— Кемгә шулай ашыгыч телефон шалтыратырга булдың?

— Закирҗановка.

Фәритнең ышануынча, Казанда Закирҗанов түземсезлек белән сынауларның хәлен белергә тели. Фәрит дустына сынау башланган көнне үк бер шалтыраткан иде инде. Закирҗанов аңа: «Әйдә, уңыш телим. Бу эш безнең өчен бик мөһим, сынатма», — диде. Ә менә бүген беренче нәтиҗә турында дусын тынычландырырлык хәбәр әйтергә була.

Фәрит үз бүлмәсенә керде дә өстәлендәге аппаратка үрелде. Бәлки бәхеткә каршыдыр, трестта баш белгечнең командировкага киткәнен әйттеләр. Фәрит исә трест директорына ук хәбәр итәргә кыймады. Инде бу очракта ашыкмаска кирәк дип уйлады.

Һәм бу очраклылык баш белгечне бик зур күңелсезлекләрдән коткарды. Чөнки уңыш турындагы хәбәрне Казанга җиткерергә әле иртә икәнлеген Фәрит икенче көнне үк аңлады.

Әйе, икенче көнне эшкә килеп үз бүлмәсенә керергә өлгермәде, контора коридорында фабриканың баш ветеринары, исәнләшмәстәнниtmәстән, «читлектәге чебиләрең кырыла бит», дип шомлы хәбәр салды. Ветврач тыштан үзен тыныч тота иде, ләкин аның куркынган һәм ачулы күзләрен күрү белән Фәрит карт белгечнең ни дәрәҗәдә тетрәнгәнен тиз аңлады, ул чын хакыйкатьне әйтә иде. Шулай да Фәрит сорады:

— Ничек инде кырыла? Мин бит кичә генә...

— Син аны кирәгеннән артык тыгыз утырткансың. Аларның күбесе азык тагарагына якын да килә алмый.

Бу кадәресен белгеч арттырыбрак сөйли иде. Фәрит югалып калды.

— Барысы да инструкция буенча эшләнде!

Алар артык сөйләшеп тормадылар. Фәрит бүлмәсенә кереп ак халатын алды да, алар ашыгып арткы ишектән корпуслар территориясенә йөгерделәр.

Чыннан да, ветврачның әйткәннәре хак иде. Дүрт катлы батареяләрнең һәр читлегеннән кимендә бер-ике чеби үләксәсе алынды. Ләкин эш шулай да тыгызлыктан түгел иде, Фәритчә.

Ап-ак чәчле, чандыр, сузан ветеринар тәнбиһ белән Фәриткә әйтеп куйды.

— Мин кайчаннан бирле чебиләрне тыгыз утыртмаска кирәк дип зар җылыйм!

Фәрит берни дә әйтмәде. Ул бары инструкция кагыйдәсе төгәл үтәлгән, ләкин эш нәрсәдә соң, дип баш вата иде. Кара инде син аны! Оят, билләһи, үзенә ышанып эшне тапшырган дустыннан оят. Аннан гына да түгел, фабрикада эшләүчеләрнең барысы алдында оят. Ул бит эшнең барып чыгачагына шул кадәр ышанган иде!

Ярып карау өчен ветврач үләксәләр сайлый башлады.

— Зинһар, бакпосевка да, Степан Илларионович, — диде Фәрит.

— Минемчә, бары алиментар[1] житешсезлек.

— Шулай да... — дип үтенде Фәрит.

Ветеринар, каршылык күрсәтмәстән, иңбашларын сикертеп куйды.

Фабрикада ике лаборатория: берсе азыкныкы, икенчесе ветеринар лабораториясы. Фәритнең әле ветеринарга бакпосев турында әйтүе бәлки үлем-җитем берәр йогышлы авыру аркасындадыр дип уйлаудан иде. Инфекция булган тәкъдирдә уздырыла торган сынау барып чыкмаса да, хөкем ителмәячәк, чөнки сәбәп бар.

Степан Илларионовичның җилкәләрен җыерыбрак ирониялe елмаюы Фәритне йокысыннан уяткандай булды. Аның башына: «Мине, күрәсең, куркак бер эгоист дип уйлый»,— дигән фикер килде. Ул үзе дә тоймастан ветеринар каршында акланырга теләде. Әйтерсең аның ялангачланган эчке сыйфатын карт белгеч шунда ук күреп алды.

— Карагыз әле, — диде Фәрит, — контроль группада бөтенләй үлем-җитем юк бит. Алар нәкъ башкалар кадәр үк мәйданда үстереләләр.

— Азыкның төрлечә эләгүе мөмкин.

Фәрит дәшмәде, бәлки чыннан да премикс[2] тигез таратылмагандыр дип кенә уйлый алды.

Хәбәре барып ирешкән, ахры, тиздән Әлфия дә килеп җитте. Фәрит аның белән ияк кагып кына исәнләште. Хәзер кыз Фәриткә: «Кичә мин сиңа ашыкма дип әйттем бит. Алдан кычкырган күкенең башы авырта», дияр кебек иде. Ләкин алай булмады. Әлфиянең йөзенә, кыяфәтенә караганда, ул да бу күңелсезлекне Фәриттән ким кичерми иде. Гадәттә ниндидер сәбәпләр аркасында үлеп калган чебешләрне кош караучылар үзләре җыеп алалар һәм, артык күп булмасалар, шундук утильцехка тапшыралар. Ләкин ул чебиләрне гадәти ысул белән пычкы чүбе түшәлгән идәндә үстергәндә шулай. Ә инде читлеккә килгәндә, монда һәрбер яңалык тирәнтен уйланып бәяләнергә тиеш, һәм, кирәк икән, үтә ашыгыч чаралар күрелергә тиеш. Әлфиянең үзен аңлавы һәм кайгысын уртаклашуы аркасында ничектер тынычлана төшкән Фәрит:

— Менә эшләр ни формалай китте, — дип күңеленнән генә елмаеп куйды.

Әлфия:

— Бавырын, эчәгеләрен тикшерәсездер бит? — диде.

— Тикшерәбез, и бик җентекләп. — Фәрит яңа исенә төшкәндәй өстәде: — Бүксәдәге азыкны да тикшерик әле, яме. Белмәссең, бәлки азык юлда селкенү аркасында аерым өлешләрдә тиешле составын үзгәрткәндер.

---

[1] Алиментар — туклануга бәйләнешле.

[2] Премикс — азыкка өстәлә торган файдалы матдәләр.

— Яхшы, — диде Әлфия. Фәрит хәзер инде бөтенләй тынычланып сорау бирде.
— Галиәкбәр абзый китәргә җыенмыймы әле?
Бу юлы ул Әлфиянең йөзендә аптырау билгеләре күрде.
— Юк, — диде кыз, — нигә?
— Болай гына, — диде Фәрит, — ничектер аны безгә ярдәм иттерәсе иде.
— Мондый ЧПдан соң бәлки ул үзе дә түзмәс.

## 9

Ул көнне Фәрит фабрикада шактый озак вакыт тоткарланды. Житди эш бит. Моңарчы да ул шулай уйлады һәм эшләде. Лаборатория анализлары чебешләрнең, чыннан да, азыкта кирәкле матдәләр житешмәү сәбәпле хәлсезләнеп, агуланып, соңыннан шуның аркасында тапталып үлүләре турында сөйләде. Бүксәдәге азыкның да составы рецептагыча түгел, димәк, комбиазыкны машинада алып килгәндә ул тирбәлә-тирбәлә үзенең дөрес нисбәтен югалткан, авыррак бөртекләр аска төшеп, җиңелрәкләре өстә калган. Димәк, кайбер чебешләргә төрле-төрле азык эләккән, туклыклы матдәләр тигез таратылганы түгел. Әйе, азыкны, читлекләр янындагы тагаракта шуышканда, әледән-әле төрле урыннан алып тикшерә торырга кирәк. Юкса, барлык чебине агулап харап итәргә күп кирәкми. Ветебаклаборатория әле өзеп кенә бернинди дә җавап бирмәгән иде. Чөнки тикшерену тәмамланмаган.
Кыскасы, читлекләр янында өзлексез утырырга кирәк. Фәрит, вакытлыча гына булса да, баш зоотехник эшен кемгәдер тапшырырга тиеш. Башкача мөмкин түгел. Үзенең бу карарын ул фабрика директоры Гатауллинга да әйтте. Күрәсең, чебешләрне читлеккә күчерү мәсьәләсе буенча трестта директорның колак итен житәрлек ашаганнар иде инде. Ул, хәлнең торышын ишеткәч тә, бүген уздырылачак планеркада моның турында ныклап сөйләшергә булган. Аның кара тутлы киң йөзе Фәритне күрү белән кырысланып китте. Ул каршысында утырган урынбасарына әйтәсе сүзен йотып, Фәриткә текәлде.
— Я, нәрсә кыйраттыгыз анда?
— Исәпләгәнчә барып чыкмый, — диде Фәрит, кепкасын өстәлгә ташлап. Яшел постау ябылган озын өстәл янына борчулы кыяфәттә утырды. Ул үзенең вакытлыча бары читлектәге чебиләр белән шөгыльләнергә тиешлелеген әйткәч, директорның чырае бөтенләй караңгыланып китте.
— Син нәрсә, безнең планны бөтенләй өзәргә үк җыенасыңмыни? Безгә бит читлектәге чебиләр өчен план бирмиләр... Бу фикерең батмый. Берәрсенә тапшыр ул эшне, цех мөдире дә җаваплылыкны күбрәк тойсын, аңлат.
— Алай гына булмый. Аның эше болай да житәрлек. Махсус бер кеше куярга кирәк.
— Я, кемне куябыз соң? Болай да белгечләр житмеш процентка гына укомплектован.
Фәрит тирән итеп сулады да: «Белмим инде», — дип куйды.
Сүзгә тәбәнәк буйлы, пләш башлы урынбасар кысылды.
— Бүген миңа КамАЗдан шалтыраттылар, — диде, — зоотехник кирәкмиме, дип сорадылар.
Икесе дә кызыксынып урынбасарга текәлде.
— КамАЗ шулай зоотехниклар да әзерлимени? — диде директор.
— Күрәсең, шулайдыр, — диде урынбасар көлемсерәп, — Кадрлар бүлегенең әйтүенә караганда, анда бер зоотехник моңарчы сле-

сарь булып эшләгән. Но аны фаш иткәннәр. Ә колхозга кире кайтмыйм, дип әйтә ди.

— Да? Бу як кешесеме үзе?

— Әйе, колхоз стипендиаты булган. Бераз гына колхозда эшләгән дә КамАЗга кыяклаган.

— Ну, ул егетне чакыртырга кирәк, — диде директор.

— Мин сезнең белән сөйләшми торып ул кадәресен эшли алмадым.

Директор Фәриткә карап әйтте:

— Менә сиңа ярдәмче. Алыгыз шул егетне. Башта ул синең кул астында теге читлектәге бройлерлар белән маташсын. Соңыннан, рәт чыгарлык булса, штатный урын бирербез.

Фәрит ышанычсыз гына җилкәләрен җыерды.

— Кем белә бит әле аның нинди кеше икәнен! Бер тапкыр үз һөнәрен ташлап качкан кеше кабат качмас дип уйлыйсызмы?

— Әйтәм ич, сынап карарга кирәк дип, — диде директор ачулана төшеп.

Фәрит планеркага кадәр тамак ялгап алу өчен территориядәге ашханәгә төшеп китте.

Атналык планерка беткәндә вакыт бик соң иде инде. Фәрит үзенең тәҗрибәдәге чебиләре янына кереп барлык күрсәткечләрне тикшерде дә, кетәк ишеген бикләп, ачкычын кош караучы гына белә торган җиргә яшереп, территориядән чыгып китте. Ул үз бүлмәсенә кайту белән ашап та тормады, тиз генә чишенеп, караватына ауды. Башы мендәргә тию белән сау-сәламәт яшь кешегә хас булганча тирән йокыга да талды.

Фәрит ишек звоногы шалтыравына уянды. Кемдер моңарчы һич күрелмәгән әрсезлек белән, өзми-куймый звонок төймәсен басып тора иде. Чебиләр белән бер-бер хәл булдымы әллә дип куркынып, Фәрит аякка басты.

— Хәзер, хәзер!

Чалбар балакларында бутала-бутала ул киенә башлады. Иңенә пижамасын гына салып, ишеккә таба йөгерде. Ишекне ачып җибәрүгә ул ирексездән тетрәнеп артка чигенде. Ишек төбендә торучы кеше аның этисе Зариф иде.

— Ә, эләктеңме, малай актыгы, — диде Зариф, улын тану белән,— коерыгыңа бастым бит тәки!

Зариф тавышланып көлеп җибәрде. Фәрит, күршеләр ишетмәсен тагын дигәндәй, этисен тартып диярлек ишекнең эчке ягына кертте. Зарифның кулында кечкенә генә саквояж, өстендә мутон якалы кыска тун өстеннән киелгән кара яңгырлык, аякларында кирза итекләр иде. Өйгә керү белән ул, саквояжын стена кырына куеп, башындагы боярка бүреген салды. Кесәсеннән зур ак яулык алып битен, маңгай түбәсен сөртте.

— Фу чорт, син эшкә киткәнче барып житим дип, мышкылдыгым чыкты. Исәнме. — Ул нишләргә белмичә аптырап торган Фәритнең кулын кысты.

Фәрит, ниһаять, өнен җыйды.

— Әйдә, эзләп килгәнсең икән, өстеңне сал, чишен, эчкә уз, эти,— диде.

Фәрит этисенең монда ни сәбәпле килүен сизенеп, бик нык сагайган хәлдә, аның киемнәр элгече янында маташуын күзәтте. Ул әлениндирәк мөгамәлә булачагын юрап бетерә алмый иде. Шуңа күрә этисенең сүз башлавын көтте. Ирексездән этисенең, дөньяда алтмыш биш ел яшәвенә карамастан, һаман әле имәндәй нык булуына, дөнья

мәшәкатьләренә дә, картлыкка да артык бирешмәвенә игътибар итте. Зариф, чишенеп, киемнәрен элгәч, аягындагы итекләрен салып почмакка куйды, ак йон оекбашчан гына кухня якка таба атлады.

— Кая, берәр чынаяк калган чәең юкмы? Бик сусатты...

Фәрит шундук итагатьле рәвештә этисенә термостан чәй салып бирде. Һаман көтте. Карт исә чәйне пешә-пешә, ах-вах килеп комсызланып эчкәч, иркен бер сулады да, күрәсең, әле яңа гына күзләренә ул-бу чагылырлык хәл кергәндер, тирә-юнен карап чыкты.

— Әйбәт кухнә, — дип куйды ул. — Тик бик алама яшисең икән. Ашагач тәлинкә-кашыкны шулай пычрак килеш калдыраламмыни?!

Өстәл, чыннан да, өсте-өстенә өелгән юылмаган савыт-саба белән тулы иде. Этисенең кирәкмәс, үзенә бер дә катнашы булмаган нәрсәләрне күреп, оп-олы улын баласытып акыл сатуына Фәритнең ачуы килде. Тик дәшмәде. Тешен кысып түзде. Никельле чәйнеккә шарлатып краннан су агызды, газ плитәсен яндырып, чәй куйды.

— Шаулама, эти, — диде Фәрит киеренке җитдилекне йомшарту теләге белән шаярта төшеп.— Бераздан барысы да тәртиптә булыр. Бер минутлык эш ул.

Зариф җавап бирмәде.

— Кая, шунда утырышабызмы? — дип кенә сорады.

— Кухняда утырмыйбыз, теге якка чыгабыз.

Фәрит этисен ияртеп зур бүлмәгә керде. Тиз-тиз урынын җыйды. Утыргычларда аунап яткан кием-салымны алып, көзгеле шифоньерга тыкты. Зариф бу вакытны кечкенә генә җыелма өстәл янына утырган килеш бик җитди кыяфәт белән улын күзәтә иде. Фәрит, иртәнге эшләрен төгәлләп, аның каршысына барып утырды.

— Я, ни хәлләр бар соң, эти? Әниең сәламәтлеге ничек?

Бу сораудан соң Зарифның төсе күзгә күренеп үзгәрде, уңа башлаган коңгырт күзләреннән явыз бер шәүлә узды.

— Ничек икәнлеге сиңа аңлашыла торгандыр инде, Фәрит. Аннан башка җаны уч төбендәге әниеңне нинди хәсрәт упкыннарына ташлавыңны тоя торгансыңдыр. Ә минем килеш өйдән түгел бит әле, Фәһимәләрдән.

Фәрит шундук сүзнең гаиләсеннән качып китүе турында барачагын аңлады. «Димәк, эти карт Оренбург ягына барып чыккан, минекеләрне күргән», — дип уйлап алды ул. Тик тиз генә ачылмады.

— Мин әнине яхшы беләм, — диде. — Ул минем бәхетле кеше булуымны тели. Әгәр Фәһимә минем бәхетемне...

Ул әйтеп бетермәде. Зариф, йөзен чытып, кул селтәде.

— Бәхет, бәхет! Куй әле, пожалысты, шул сафсатаңны! — Ул, нык дәлилле сүз көрәшенә әзер булуын ачыктан-ачык аңлатып, утыргычына ипләбрәк утырды да улына таба иелде.

— Фәһимә бит синең бу дезертирлыгыңны бик авыр кичерә.

— Бер дә әйтә алмыйм. Җаның сөймәгән кеше яныңнан киткән икән...

— Ә-ә, тагы сафсата! Мәхәббәттәмени эш, тормыш авырлыгын сөйрәргә кирәк. Әллә кеше сөешеп яшәү өчен генә өйләнә, кияүгә чыгамы?!

— Шулай да...

— Юкны сөйләмә. Инде балаларың турында ни уйлыйсың син? Аларны ятимлек кимсетүләренә дучар итүеңне беләсеңме?

— Балалар өчен борчылма, аларның өлеше төгәл килеш саклана. Синеңчә, мин ике йөзле кеше булырга тиеш? Үзем яратмаган хатын белән яшәргә, аны иркәләргә, сөяргә, мин сине яратам дип, күрәләтә алдап яшәргә... Шулаймы?

— Нәрсә карадың соң өйләнгәндә? Мин, яратасыңмы соң, ул кыз белән тормыш көтә алырсыңмы, дигәч, «җан фида» дип ант эчүләреңне оныттыңмыни. Яле, исеңә төшер. Мин сиңа: ашыкма, улым, бу вак-төяк эш түгел, дигәч, нәрсә дип җавап бирүләреңне хәтерләмисеңме? Инде яратмыйм, имеш.

Фәрит хатынының үзенә кабарынган күркәдәй ташлануын, иң соңгы хурлау сүзләре белән үзен хәкарәтләүләрен исенә төшерде.

— Теләсәң нәрсә сөйлә, әти, мин яңадан ул хатын янына кайтачак кеше түгел. Ә балалар турында борчылма, мин аларны ятим итмәм.

— Син инде, элек мин Фәһимәне ярата идем, соңыннан яратмый башладым, дип барасың.

— Әйе, шулай дим. Кешенең ялгышуы бер дә мөмкин түгелмени?

Карт зәһәрле бер елмаю белән йөзен җыерды.

— Һа! Өйрәнгән син юкны бушка аударып судан коры чыгарга. Синеңчә, ярату яратмауга күчә ала. Шулаймы?

— Алай гына түгел, шулай булган инде, әти.

— Ә мена яратмау яратуга күчә аламы соң?

Фәрит соң дәрәҗәдә ачуы кабарган хәлдә урыныннан торды. Чәйнек кайнап чыккан булырга тиеш иде. Ишеккә таба юнәлгәндә улы әтисен соңгы тапкыр кисәтергә тиеш тапты.

— Бу темага нокта куйыйк, әти. Мин беркемгә дә үземнең эчке эшләремә тыгылырга рөхсәт итмәячәкмен. Хәтта сиңа да.

Фәрит кухня якка таба китте. Әтисенең башын чайкап, һаман әле мыскыллы елмайган хәлдә:

— Һо, подумаешь, суверенный государство, — дип мыгырданганын гына ишетте.

Өстәлгә чәйнекләр, стаканнар, суык тавык ите, атланмай, күмәч һәм башка чәй кирәкләре куелгач, Фәрит сүзне тыныч агымга күчерергә теләп:

— Әйдә, әти, башта, үзең әйтмешли, булганына шөкер әйтеп чәйлик әле, — диде. Әтисенә куе итеп чәй агызды, аның алдындагы тәлинкәгә итнең иң әйбәт калҗаларын салды.

Алар бераз вакыт тынып чәй белән булаштылар.

— Шулай да кызык, — диде Фәрит елмая төшеп, — син ничек минем биредә икәнлегемне белдең?

— Анысы минем эш.

— Шулай да?

Зариф ашыга-ашыга чәен чөмерде дә:

— Миңа сине кире өеңә алып кайтырга куштылар, — диде. — Давай без шуның турында иплэп кенә сөйләшик әле.

Фәритнең каракучкыл йөзенә кан йөгерде. Матур кара күзләре зәһәр чәчү аркасында тагы да нурлана, хәтта матурлана төштеләр.

— Әти! — диде ул, сулышы кысылып. — Мин бит сиңа «җитте» дидем. Минем личный тормышыма тыгыласы булма. Юкса...

Ул әйтеп бетермәде, калтыранган бармакларыннан стаканы ычкына башлавын тоеп, аны чынаяк табагына куйды.

Ул әйтәчәк сүзне сизгер әтисе башкарды:

— Нәрсә «юкса»? Әллә әтиеңне куып чыгарырга да намусың житәр идеме?

Фәрит дәшмәде, ләкин нәкъ шул сүзләр әйтелергә тиешлеге аның йөз чалымнарына язылган иде.

## 10

Аркасына гитара аскан, кулына ясалма күн чемодан тоткан яшь егет фабрика алдындагы мәйданчыкка тукталган төрле маркадагы машиналар арасыннан узып, контораның таш баскычына таба юнәлде. Һава салкынча, җылы пальто киярлек булса да, аның өстендә модалы куртка, ботларында джинс, башында колакчынлы ак куян бүрек. Егетнең чем кара чәчләре җилкәсенә төшеп тора, кара елтыр мыегы исә авыз читеннән түбән няккә таба җибәреп үстерелгән. Аны татар малае дию дән битәр, француз язучысы Дюма романнарыннан сикереп төшкән мушкетчы дип атарга булыр иде. Хәлбуки, ул шушы якның татар малае, Шәрифуллин Рәмзи иде. Егет бераздан, бүреген салырга да онытып, фабриканың баш зоотехнигы бүлмәсенә барып керде. Фәрит азыкка ясалган анализ белешмәләре белән булашып утыра иде. Рөхсәтсез-нисез килеп кергән яшь егетне беренче күрүдә үк яратмады. Егет аңа үзенең КамАЗдан килүче Рәмзи Шәрифуллин икәнлеген әйткәч, бирегә зоотехник буларак килгәнлеген дә аңлаткач, ул бөтенләй аптырап калды. Фәритнең болай да кәефе артык сүрән, читлектәге кошлар борчуы өстенә этисе китергән «күчтәнәч» аны тәмам чыгырыннан чыгарган иде. Ул Рәмзине тыңлаган вакытта ук үзе дөрес дип тапкан карарны чыгарды. Аныңча, фабриканы мондый озын яллы шалапайлар белән чүпләргә ярамый. Шулай да ул яшь зоотехникның кыяфәтен һич өнәмичә күзләреннән кичергәч, сорамый булдыра алмады.

— Зоотехниклык эшенә теләк җитәрлекме соң?

Егет ни әйтергә дә белмәгәндәй җилкәләрен сикертеп кенә куйды.

— Бездә эшләүнең шактый үзенчәлекле икәнен сез чамалыйсыздыр инде, шулаймы? Ничегрәк, булдыра алырсызмы? — дип кабатлады Фәрит кычкыра төшеп.

— Бройлер фабрикасындамы?

— Әйе, менә бездә.

— Нигә эшләмәскә! Мин техникумда укыганда практиканы нәкъ шундый фабрикада уздым.

Фәрит егет белән кызыксына төште. Рәмзинең кайда, ничек практикада булуын сорашты.

— Сез бик тәфсилләп, сүз бик яраткан эшегез турында баргандагыдай, сөйләдегез. Ни өчен соң алайса зоотехниклык эшен ташлап КамАЗга тайдыгыз?

Рәмзи бик авыр итеп сулады да стена буенда торган утыргычка карап куйды.

— Утырыгыз, — диде Фәрит, — утырып иркенләп барысын да сөйләгез.

Рәмзи башта күпереп торган йөнтәс куян бүреген салды. Аннан аркасындагы гитараны ычкындырып стена буена сөяде. Ниһаять, утыргычны өстәл янына китереп куйды да, утыргач әйтте.

— Дөресен генә сөйләгәндә, абый, мин безнең колхоз председателе Нургали абый белән уртак тел таба алмадым.

Фәриткә егетнең үзенә «абый» дип дәшүе ошады. Ничектер болай эндәшү аның садә, эчкерсез булуын сиздергәндәй иде.

— Инициативаны буа идеме? — дип сорады ул, җылына төшеп.

— Булды инде, барысы да булды. Мин колхоз стипендиаты булгач теге, беркая да китә алмас дип, ахры, мине бер йомышчы малайсыман итә башлады.

— Ә сез тоттыгыз да КамАЗга ычкындыгыз?

— Ну, — диде Рәмзи шулай икәнлеген аңлатып. Фәрит «бу сүзне егет КамАЗда үзләштергән» дип теркәп куйды.

— Кем булып эшләдегез КамАЗда?

— Техникумда укуымны яшердем. Башта төрле эшләрдә. Аннары слесарь-сантехник булдым.

Фәрит «ә слесарьлеге безгә дә бата. Кирәге чыгуы бар» дип күңеленә тагы монысын да теркәп куйды.

— Сезне бераздан фаш иттеләр, шулаймы? — диде.

— Чуртым да итмиләр иде. Мин инде анда үз кеше идем. Акчаны бик шәп төшерә башладым, үземне Почет тактасына яздылар. Эшне тагы Нургали абый бозды. Минем өстән язу җибәргән. Анда да әле арттырып язган. Колхоз стипендиаты булып укыды, үзе бер ел да эшләмәде, качты, хәзер фәлән җирдә слесарь булып эшли, ә безнең зоотехник юк, фәлән-төгән... Во-первых, мин ел ярым эшләдем, аннан үзеңә кешечә караш булмаса, ничек эшләмәк кирәк. То-то! Бу бит дөрес түгел. Мин аны сельхозуправлениедә дә әйттем. Үтерсәгез дә, төрмәгә ябу белән генә чикләнсәгез дә, мин Нургали абый янына кайтмыйм, дидем. Мин КамАЗда эшләгән дәвердә үземнең кеше икәнлегемне белдем, анда ул председатель булганда кайтмыйм, дидем. Кая барыр идең соң? дип сорадылар. Мин менә сезгә барыр идем, дидем.

— Чөнки бройлер фабрикасында практикада булып, андагы хезмәтне яраттыгыз?

— Ну!

Хәзер инде бу егет Фәриткә тагы да ныграк ошый башлады. Аның хәтта борчулары-хәсрәтләре дә онытыла төште, күңеле күтәрелә барды.

— Менә нәрсә, Рәмзи дус,— диде ул егетне бөтенләй якын итеп.— Син практикада булган җирдә чебешләрне идәндә үстерәләр. Ә менә безнең исәп читлектә асраурга күчү. Бу эшнең син уңайлыкларын да, кыенлыкларын да беләсеңдер инде.

Рәмзи эре ак тешләрен күрсәтеп, иркенләп бер елмаеп куйды.

— Күбесе онытылган инде, абый. Соңгы өч елда башта сантехника хикмәтләре генә булды.

— Шулайдыр. Тик теләк көчле булса, гитараны азрак уйнап күбрәк китапка ябышып ятсаң, булдырырсың.

Егет сүз дәшмәде, тагы «тырышырмын инде» дигәнне аңлатып кулларын аерып кына куйды. Фәрит аның озын чәчләренә карап әйтми кала алмады.

— Чәч хәтәр синең. Аңа тиешле тәрбия кирәктер бит. Вакыт җитәрлекме соң?

Рәмзинең йөзенә җитдилек йөгерде.

— Мин аны шулай йөртәчәкмен. Принцип өчен.

Фәрит кызыксынып аңа сораулы караш ташлады.

— Шулай, узган ел бер иптәш, үзебезнең төзелештәге иптәш белән авылга отпускага кайттым. Минем дусның чәч менә хәзер минеке ничек, нәкъ шундый иде. Ә мин үзем чәч үстерүгә каршы идем. Дөресрәге, ул, минемчә, бик личный эш иде. Менә шул, авылга кайтып кеше күзенә күренә башлавыбыз булды, тотындылар бит авылдашлар егеттән көләргә. Рәмзи, имеш, поп алып кайткан, аның дус егете поп икән. Фәлән-төгән. Аннары кыз алып кайткан Рәмзи дия башладылар. Минем бик ачу килде. Авылдашларымның ваклыкларына, кеше эшенә тыгылуларына ачуым килде. Аларча, барысы да по правилам, алар белгәнчә генә булырга тиеш. Шуннан КамАЗга кайту белән тоттым да юри, авылдашларга үч итеп, үзем дә чәч үстерә башладым. Мәшәкатьле, еш юарга, әйбәт тарарга кирәк, тик шулай да принцип өчен мин чәчне үстерәм.

Фәрит эчтән генә елмаю белән чикләнде, сүз дәшмәде.

Ләкин ул шуны сизде — егет аңа ошаганнан-ошый бара иде. Бу үз сүзле кеше әгәр «принцип»ларына туры килә торган эшкә керешсә, әлбәттә, шактый эшләр майтара ала торгандай күренә.

Фәрит, ниһаять, катгый бер карарга килеп, Рәмзи Шәрифуллинны эшкә алуга каршы булмавын директор урынбасарына телефоннан шалтыратырга булды. Егеткә вазифаларының нидән гыйбарәт булачагын аңлатты. Бүген үк барлык формальностьларны узып, иртәгә иртүк эшкә килергә, менә шушында булырга кушты. Егеттән тагын бераз гаилә мәсьәләләрен сорашканнан соң, ул аны чыгарып җибәрде, һәм кинәт үзенең көчәя барган күңел сызлавы белән тагы япаялгыз калганлыгын аңлады. Әйе, эштәге бөреләнеп килә торган күңелсезлек җитмәгән, этисенең котмәгәндә килеп чыгуы тагы. Җаны сөймәгән хатыны яклы булып адвокатлануы, булмаган демагогия белән шөгыльләнүе, хәтта шантажга кадәр барып җитүе. Әлбәттә, Фәритнең аңлавынча, бу вакыйга бүген булмаса иртәгә Әлфиягә барып җитешәчәк һәм Фәритнең соңгы таянычы, соңгы шатлыгы гөрселдәп җимереләчәк. Ә аннан соң ниләр көтә Фәритне? Бушлык, караңгылык? Фәрит, йөрәгенең януына түзә алмастан, аягүрә басты, кайда барып туктaлырга белмичә бүлмә буйлап әрле-бирле йөренергә тотынды. Күңел түрендә аҗаган утларыдай ялтырап өмет яктылыгы чайкалып алды. Бәлки Әлфиягә бөтен хакыйкатьне һич яшермәстән сөйләп бирергәдер? Бәлки ул, әгәр мине чын күңелдән яратса, гафу итәр, элеккечә үк ярата бирер. Ләкин ничек, ничек беренче сүзне әйтергә? Ничек итеп аның якты, гөнаһсыз, балаларча беркатлы карый торган зур коңгырт күзләренә карарга. Ә ул кинәт?.. Фәрит артыгын уйларга да базмады. Чөнки күз алдына килеп басачак Әлфиянең рәнҗүле, мыскыл ителгән, ә бәлки эле рәхимсез нәфрәт чагылдырган йөзе артык дәһшәтле, үлемнән көчлерәк бер күренеш иде.

Фәрит нишләргә дә, нинди чаралар күреп, үзен хәсрәт утларыннан ничек коткарырга да белмичә, кемнендер җиңелчә ишек шакуы ишетелгәнгә кадәр йөренде. Шакуны абайлау белән ул тиз генә утыргычына барып утырды, коры гына «керегез» диде. Ишектә күренгән кеше Әлфия иде. Ул гадәттәгечә ачык чырайлы, матур, пөхтә. Фәрит аның йөзен шәйләгәнче шомлана төште, мәгәр кызның бик әйбәт, күтәренке күңел белән килеп кергәнлеге мәгълүм булгач, шундук тынычланды, бағы очындагы караңгы яшен болытларының әле хәзергә читләтеп узганлыгын тойды.

— Син ялгыз гынамыни? — диде Әлфия. Фәрит аны каршы алу өчен урыныннан купты.

— Әле бухгалтериягә килешем иде, — диде Әлфия. — Хәлеңне белим дидем. Ничек?

— Бүген бераз кими төште. Күрәсең, азыкны болгаткыч аша уздыру ярдәм итте.

Фәрит кызның кулын кысты да озак вакыт ычкындырмый торды.

— Кыяфәтең бик борчулы, — диде Әлфия.

«Әтинең килүен әйтергәме, юкмы?» дип уйлап алды Фәрит. Аннан, Әлфия үзе башламыйча торып, ул турыда сүз катмаска булды. Кызга өстәл яныннан урын тәкъдим итеп, үзе дә өстәл артындагы утыргычына күчеп утырды.

— Галиәкбәр ага ни ди соң? — диде Фәрит. — Син, шәт, чебиләр хәлен сөйләгәнсеңдер?

— Сөйләштем. Аның җавабын сиңа җиткерү өчен керешем иде.

Фәритнең каракучкыл матур йөзенә чиксез кызыксыну һәм курку билгеләре бәреп чыкты.

— Я, нәрсә ди?

— Кереп карарга кирәк, миңа бөтен анализларны әзерләп бирегез, ди.

Фәритнең йөзен шатлыклы елмаю балкытты. Ул Әлфиянең өстәлдә яткан йомшак кулын үзенең учына алды.

— Рәхмәт сиңа, жанкисәгем, рәхмәт. — Фәритнең башына, әллә өстәл аша гына булса да кызны үбим микән, дигән дуамал уй килде. Кыз, моны сизенгәндәй, артка чигенде, матур ак кулын да егетнең учыннан тартып чыгарды. Хәзер Фәрит үзе дә тынычланган иде инде. Ул эшлекле бер кыяфәт белән профессорның кайчангарак фабрикага керү мөмкинлеге турында сораша башлады. Әлфия фикеренчә, картны Фәрит үзе алып керсә яхшырак буласы иде. Кинәт телефон шалтырады. Директор икән.

— Ни хәл синең анда, теге читлектәге чебиләр хәлен сорыйм? — диде директор шомлана төшеп.

— Бүген үлем-җитем кимрәк, — диде Фәрит, — тик шулай да юк түгел. Ә алай булмаска тиеш...

— Алынгансың икән, барысы да синең җаваплылыкта, бел аны.

— Нигә кирәк әле мондый читләтеп сөйләшү? — диде хәтере кала төшеп Фәрит.

Әлфия урыныннан торды, мин китим әле, диде.

— Тукта, тукта, әз генә сабыр ит. Әле бит әтиеңне кайчан барып алу турында сөйләшмәдек, — дияргә чак өлгерде. Трубкада директорның «тресттан шалтыраттылар. Кызыксыналар. Эшкә керештегезме, диләр» дип әйткән сүзләре ишетелде. Фәрит Әлфиягә кулын җәһәт-җәһәт селкеп «утыр әле» дигәнне аңлатты да, телефон трубкасына:

— Мин сезгә әйткән идем ич. Монда бит кызында кунак булып профессор Максудов ята. Светила!

— Ятса ни? — диде директор.

— Ул безгә эшне көйләп җибәрүдә ярдәм итәр дип уйлыйм.

— Соң ул бит пенсиядә. Нишләп синең чебиләрең белән маташып йөрсен!

— Анысын миңа калдырыгыз инде. Аннан менә нәрсә: бүген теге КамАЗда эшләп яткан зоотехник белән сөйләштем. Ярыйсы кебек.

— Аңламадым.

— Соң бит үзегез зоотехник алырга кирәк, вакытлыча гына булса да читлекләр корпусына шуны утыртырга кирәк, дидегез ич. Оныттыгызмыни?

— Аңладым. Эшләрлекме соң егет? Аркасына аскан гитарасына, попныкыдай чәченә караганда, безнең эшкә ябышып ятарлык белгечкә бик үк охшамаган.

— Анысы тышкы кабык кына. Модага ияру. Ә, гомумән, ул эшләр.

— Ну, кара, — диде директор. — Казанга ни дип җавап бирим соң? Әйт, тилмертмә, бу эшкә син җаваплы. — Фәритнең каш аралары тарайды. Йөзенә кырыслык чыкты, үзе еш-еш сулаган хәлдә:

— Казанга әйтегез, ничек тә булдырырбыз. Фәрит Еникеев сүз биреп алынган икән, булдырмый калмас, диегез.

— Оһо,— диде директор.— Шапырыну булмаса, бу җилле сүз!

Фәрит директорның селектор клавишына басканын аңлады да үзе дә трубканы куйды. Директор белән сөйләшкән арада Әлфиянең үзенә карап, теләктәшлек күрсәтеп, борчылып торуын ул абайламады. Әлфия Фәритнең күзләренә телефондагы сүз беткәч кенә чалынды. Кыз хәзер тынычланган иде. Фәрит, күңеле рәхәт бер нәрсәгә орынгандай, күзләре белән генә елмая башлады.

— Менә нинди бит ул кешеләр, — диде ул. — Эш уңышлы барса, берсе дә читкә тайпылмас иде. Ә хәзер беренче авырлык туу белән: «Син генә җаваплы...»

Әлфия, ни әйтергә дә белмичә, Фәритнең туры борынлы, куе кара кашлы, колак йомшагы турысында кыек киселгән бакенбардлы йөзен тагын күзеннән кичерде. Аның бу минутта сөйгәнен тынычландырасы, дулкынланып торган ялтыр чәчләрен сыйпыйсы килеп китте. Ләкин шундук тыелды, мондый уйлары өчен хәтта үзеннән-үзе оялды да.

— Галиәкбәр абыйны кайчан алып килергә булыр соң? — дип сорады Фәрит.

Әлфия ак беләгендәге сәгатенә карап алды.

— Ул әле урманда. Һәркөн шулай бу вакытта прогулкага чыгып китә. Берәр сәгатьтән өйдә булыр.

— Яхшы, — диде Фәрит, — бер сәгатьтән мин синең бүлмәңдә булырмын.

— Сөйләштек, — диде Әлфия, урыныннан кубып. Фәрит кызның төз сынын күзәтеп торды. Әлфия чыгып китте һәм баягы албастыдай авыр уйлар егетнең күңелен тагын сыкрата башладылар. Нишләргә? Ничек итеп, Әлфияне рәнҗетмәгән хәлдә, барлык дөреслекне әйтеп бирергә?

## 11

Нәкъ бер сәгатьтән Фәрит Әлфия квартирына килде. Ләкин ишек бикле икәнлеген күргәч, аптырап калды. Галиәкбәр урманга йөрергә чыгуыннан кайтмаган иде әле. Фәрит аны эзләп өй тирәсендә йөргән мизгелдә ул бик сүзчән юлдаш табып, шуның белән гәпкә чумган иде.

Очрашу һич уйламаганда булды. Галиәкбәр инде кайтырга кирәк дип кире борылганда, аның каршысына төптән юан, тупасрак йөзле бер карт кеше килеп басты. Йөреш-кыяфәтенә караганда, бу кеше дә эш куып йөрүчеләрдән түгел иде. Мөгаен, ул да Галиәкбәр кебек урман һавасын сулар өчен генә чыккандыр. Йөзенә карау белән Галиәкбәр аның татар икәнлеген чамалады. Якты чырай күрсәтеп:

— Нихәл, кордаш, сәйранга чыктыкмы? — диде. Кеше мутон якалы кыска туннан, кулларын артка куйган хәлдә, бик уйчан кыяфәттә. Галиәкбәрнең сүзләренә каршы ул, күптәнге танышын очраткандай, артык тәкәллефләнмәстән, корырак бер тон белән җавап кайтарды.

— Менә марш суктырып йөрим әле. Әйдә, бергә кайтыйк, алайса. — Алар акыртын гына кары тыгызланган урман юлы буйлап киттеләр. — Башыңдагы уйлар хәттин ашса, аякка да покой юк икән, — диде кеше. — Җанымны кая куярга белмичә чыгып киттем әле.

Бу Фәритнең этисе Зариф иде. Әлбәттә, эч серләрен ул беренче минутта ук Галиәкбәргә актарып ташламады. Ләкин шулай да бирегә бала-чага хәсрәте белән килеп чыкканлыгын аңлатты. Күрәсең, аның бу турыда озаклап сөйләшәсе килми иде. Ул сүзне шунда ук икенчегә борды. Кулларын артка куеп иркен урман юлыннан икесе дә бер якка, фабрика ягына таба атладылар. Гадәти сүзләр башланды. Кыш, һавалар торышы, кар азлыгы турында... Башкортстан һәм Оренбург якларындагы, аннан Казандагы тормыш шартлары турында сүз булып алды. Кибетләрдә ниләр бар? Ит мәсьәләләре ничегрәк тора? Гәп бераз үрли төшкәч, якыннанрак танышу башланды. Зарифның, нинди сәбәпләр аркасында монда килдегез, дигән соравына Галиәкбәр, яшереп-батырып тормыйча, турысын әйтеп бирде. Үз чиратында:

— Сезне нинди җилләр китереп ташлады? — дип сорады.

— Шул әйткәнемчә инде, — диде Зариф һаман әле артык ачылырга теләмичә, — шул бала кайгысы инде.

— Ни булды соң балагызга?

— Ни булды дип, үлгәнче шулар өчен ут йотып яшисең икән инде ул, кордаш. Улым бар минем. Ипле генә, җүнле генә кебек үзе. Шул алмадай ике баласын, бер дигән, арсландай хатынын ташлап качкан. Абдуллинода мәхшәр, Бакалыда, безнең өйдә инде значит, тоже мәхшәр. Хатын минем болай да чирле нәрсә. Инде бу хәл килеп чыккач, йөрәгенә хәтәр приступ булып, айдан артык больницада ятты. Көне-төне җылый. Ятим калдылар дип, балаларны кызганып җылый. Нишләргә кала миңа? Киттем Башкортстаннан Оренбург ягына. Андагы хәлләрне үз күзем белән күргәч, туктале, арт сабагын укытыйм әле шуның дип, малайны эзләргә чыгып киттем.

— Һәм шушында таптыгызмы?

— Әйе, менә шунда килеп урнашкан сафсата.

— Шулай инде, — дип куйды Галиәкбәр, тирән сулап, — һәркемнең үз хәсрәте. — Инде ничегрәк соң, ипкә килердәйме?

— Бу турыда миңа сүз катма, Фәһимә янына кире кайтмыйм и баста, ди.

— Ә балалары?

Зариф ачуланган кыяфәттә кул селтәде:

— Әй, хәзерге яшьләрдә бала кайгысы бармы соң ул! Төкереп тә бирми. Мәхәббәт кирәк аңа. Имеш, сөймим.

Галиәкбәр Зарифның сүзләрен җөпләп сүзсез генә ияк кагып барды.

— Үзебез гаепле, — диде Зариф, — эгоистлар белән тутырдык дөньяны. Янәсе, без рәхәт күрмәдек. Барысы да аларга. Тәмле-томлысы да, затлы кием-күнчеге дә.

— Булды, булды шундый хата. Тик бит, кордаш, ул яшьләр бозылсын дип эшләнми.

— Беләм мин аның, яшьләр бозылсын әле дип эшләнмәгәнлеген, аларга әйбәт булсын дип эшләнә.

— Алай дип тә түгел. Үзебезгә шулай эшләү рәхәтлек биргәнгә күрә эшләнә.

Зариф, берни дә аңламыйча, аптырап Галиәкбәргә текәлде.

— Шулай, кордаш. Якын, газиз кешеңә яхшылык эшләү, аның күңелен табу һәркемгә рәхәтлек бирә. Менә хикмәт шунда гына, минемчә.

— Бәлки шулайдыр да, — дип куйды Зариф, — сүз көрәштермим. Бәлки шулайдыр да.

— Шулай ул, шулай булган, шулай булачак. Монда безнең беләнисләр идарә итә, ә педагогия кагыйдәләре түгел.

— Педагогия фәне дигәннән, кордаш, балага тәрбия бирүчеләр: ата-ана, мәктәп, үсә төшкәч хезмәт урыны дип сөйләнә торгач, без тәрбияләнергә тиешле кешене бөтенләй чуттан чыгарып ташлый башладык. Шуңа күрә хәзер берәр яшь-җилбәзәк чатак эш ясап әләксә, мин гаепле түгел, мине шулай тәрбияләгәннәр, дип крокодил яшьләре агыза башлый.

— Була андый хәлләр дә, — диде Галиәкбәр көлемсерәп. Ул үзенең Сафурасын хәтерләде. Берәр житешсезлеген күрсәтсәң, ул сез начар тәрбияләгәнсез дип әтисен гаепли башлый. — Мин монысы белән килешәм.

Зариф бераз вакыт ютәлләп барды. Аннан сүзне дәвам иттереп:

— Килешми мөмкин түгел. Әгәр акны карадан аерырга теләми икән кеше, аның башына бу сәләтне шүре белән дә кертеп булмый. Ана сөте белән кермәсә, тана сөте белән керми, дип халык хак сөйли.

— Безнең шартлар өчен тәрбия фәне дә бит әле камил житеш бер хәлдә түгел, — дип куйды Галиәкбәр. — Ул әле туып кына килә.

— Аның нормалары туганчы кыран галәмәт килеп бетмәсәк ярый инде.

— Юк, анысы булмас, кордаш. Ни әйтсәң дә, күпчелек яхшылык, дөреслек юлыннан бара, дип беләм мин. Бер карасаң, безнең мыжгулар да таләпчәнлегебез артудан гынадыр әле. Начарга сизгерлек үсте. Димәк, безнең идеаль камиллеккә тизрәк ирешәсебез килә.

Зариф шундук каршы төште:

— Юк инде, монысы белән бер дә килешә алмыйм, — диде ул, башын селки-селки. — Бары да безнең күз алдында бит. Сугышка кадәр нинди иде безнең халык, ә? Ә хәзер? Хәзерге кебек егылып эчүләр күп идеме соң элек? Инде семья хәлләренә килик. Хәзер ныгракмы ул, әллә элек ныграк идеме? Ә инде комагайлыкны кая куясың син? Мал өчен хәзерге кебек җанын бирергә тора идеме соң безнең кеше?

Галиәкбәр дәшмәде. Моны Зариф үзе белән килешү дип аңлады булса кирәк:

— Минә шул-шул, — дип куйды. — Җәннәт ихаталары корганга кадәр безгә бик күп нәрсәне тәнкыйть күзеннән кичерергә кирәк. Күрәсең, барлык куләгәләр җыелып күзгә ташланырлык хәлгә килә башлады. Барысы да җыйналып галәмәт бер хәл килеп чыкмагае, кордаш. Әйтсәң сүз чыга дигәндәй, бармы менә я баласыннан, я киленкиявеннән рәнҗеш күрмәгән берәр танышың?

Галиәкбәр күңел иләге аша туган-тумача, дус-ишне уздырырга тырышты. Аннан Әлфиясен хәтерләп Зарифка каршы төшәргә булды, ләкин шул ук мизгелдә аның күз алдына үзенең цинк төсендәге зур ачулы күзләре белән Сафура килеп басты.

— Алай да, — дип куйды ул.

Күренүенчә, Зариф артык ярсыган иде. Аны шулай барсыннан да ваз кичүгә нинди сәбәпләр китергәнен Галиәкбәр, әлбәттә, аңламады. Улының шулай ата-бабада, нәселдә булмаганча гаиләсен ташлап, качып китүедер дип уйлады ул. Хәзер инде Бакалы кунагы моң-зарларын гаилә белән генә чикләмичә, республика, ил мәйданнарына күчерә башлады. Профессор ирексездән сагая төште, ак мыеклары астыннан гына елмайган хәлдә, аска карап, дәшмичә генә баруында булды. Әйе, мондый негатив карашлы кешеләрне күрмәде түгел ул. Кайчагында үзе дә ярсуга, тойгыга бирелеп киткәли иде. Тик ул һәр, вакыт мондый кызышуларның беркемгә дә, бер тиенгә дә хаҗәте булмавын, бары тик төп эшенә сүлпәнлек китерү ихтималын тиз аңлый һәм үзен шулай тәртәгә кертә иде. Зариф тумышы буенча Казан арты районнарының берсеннән икән. Әле сугышка кадәр ук, армия хезмәтеннән кайтып, Башкортстанга киткән булган. Шунда өйләнеп, төпләнеп калган. Инде сугыштан соң Татарстанга бары бер тапкыр гына кайткан, анысы да әнисен җирләү, мирас бүлешү өчен.

Сүздән-сүз чыгып, ул үзенең сугыштан кайткач берничә ел авыл районнарының берсендә район башкарма комитеты председателе булып эшләгәнлеген дә сөйләп алды. Галиәкбәр заманында зур совет эшендә хезмәт иткән Зарифның хәзер безнең чынбарлыкка шактый тискәре караштa булуына гаҗәпсенә төште. Үз тәҗрибәсенә таянып, тәгаен, моның хәтерен калдырганнардыр, тәгаен, югарыга үрмәләгәндә, аска мәтәлдергәннәрдер, андыйлар да була, дип уйлады. Мәгәр Зарифның авыртырга тиешле җиренә сугылмады — ул турыда сүз катмады. Бары сүзне яңадан азгын улына таба борып:

— Инде нишләргә уйлыйсыз соң? — дип кенә сорады. Зариф аңлады:

— Сез минем малай турындадыр инде, — диде. — Юк, алай тиз генә чигенергә исәп юк.

Алар тагы сүзсез-өнсез, кышкы нарат урманының гүзәллеген күзә-

теп, ашыкмыйча гына алга баруларында булдылар. Ниһаять, өзелгән сүзне Зариф ялгап җибәрде.

— Инде бер дә малайны җайга китереп булмый икән, тотам да хатынын, балаларын ияртеп киләм. Беркая китә алмас!

Галиәкбәр, ризасызлык белдереп, тамак кырып куйды.

— Кирәк микән соң шулай кеше гаиләсенең эчке эшләренә тыгылырга, кордаш?

— Кирәк, — диде Зариф катгый рәвештә, — мин тапкан хатын түгел бит ул. Үзе яратып алган хатын. Яратып алгансың икән инде, җанекием, яшә. Кайбер синә ошамаган якларына да түз, балаларын өчен түз. Аларның бәхете өчен түз. Мин моны үземнең тәҗрибәдән чыгып сөйлим. Булмады түгел, булды шундый хәл. Берзаман яратып алган хатыным җен булып күренә башлады. Биздем, вәссәләм. Аның холкын да, эшен-гамәлен дә яратмый башладым. Әйе, була икән ул. Семья ишәйде. Килер ашарга да җитми. Булды бит шундый еллар. Туклык ялаштыра, ачлык талаштыра, ди. Читләргә күз төшә башлады. Яшерен-батырын түгел, теләсәң күңел юаткычын табып булмыймыни! Булды шундый хәл дә. Инде эш аерылышуга барып җитте. Яздым абыйларга хат, киңәш сорап. Аерылышырга туры киләдем. сез нинди киңәш бирәсез дип сорыйм. Бу сугышка кадәр булган хәл инде. Ул чагында абыйларның бишесе дә исән иде әле. Хатымны алу белән, җавап хаты язу урынына, тотканнар да бишесе бердәй минем янга үзләре килгәннәр. Шаклар каттым, хәйраннар калдым. Утырыштык бер өстәл тирәсенә, ак эскәтер җәеп. Тотындылар болар мине сүгәргә. Барысы бер сүзне кабатлый. Җүләр син, ди. Безнең менә өчебез синең кебек тинтәкләнеп беренче хатыннарыбызны аерган идек. Әллә шуннан соң бәхеткә ирештекме? — диләр. Киресенчә, эшләгән хатабыз өчен гомер буе сыкранабыз. Болар мине шулай ике көн үгетләделәр. Бу вакыт хатын балалар белән әтиләренә кайтып киткән иде инде. Без утырабыз да сыра эчәбез, сыра эчәбез дә сүзгә керешәбез. Әңгәмә тагын дәвам итте. Тәки мине күндерделәр, минем кулда бер козырь да калмады, мин җиңелдем. Абыйлар әйткәнчә, икенче көнне юындым, кырындым, рәтлерәк киенеп киттем хатын, балалар янына. Нәкъ абыйлар кушканча хатын каршысына барып тезләндем, түбәнчелек белән хатыннан гафу үтенә башладым. Абыйлар әйтеп җибәргәннәр иде: акыллы хатын иренең ихлас гафу үтенүен беркайчан да аяк астына салып таптамый, чөнки аның өчен ир бирмәк, ул җан бирмәк, дигәннәр иде. Нәкъ шулай килеп чыкты да. Минем Бибисарам мине кичерде. Нәтиҗә нинди? Менә, әйтмәгәнем булсын, шул көннән бирле кеше арасында ким-хур булмаенча, әйбәт яшибез. Өч малай, ике кыз үстердек. Барысы да үсеп җитеп, тормышта үз урыннарын таптылар. Тик менә бу мәгънәсез генә... Менә шулай ул, кордаш. Бәхетнең алтын тәнкәдәй түм-түгәрәк булуын өмет иткән кеше гомергә бәхетен таба алмыйча каңгырып йөрер, дигән.

Урман юлы тып-тын. Ашыкмый гына атлаучы ике карт кешенең әңгәмәсен тыңлагандай, яз кояшы нурларында алтын кәүсәләрен ялтыратып, ылысларын кыймылдатмастан, төз, зифа пәһлеван наратлар торалар. Агач төпләрендә кар катламы эреп чокырланган. Галиәкбәр Зарифны тыңлый-тыңлый үзенең Мәгъмүрәсен хәтерләде. Юк, аларга беркайчан да бер-берсеннән гафу үтенергә туры килмәде. Беркайчан да, бу Зариф әйтмешли, алар бер-берсен җен кебек күрмәделәр. Һәр вакыт бер-берсен уйлап, бер-берсенә ашкынып яшәделәр. Әйе, әйе, шулай. Шулаймы соң? Галиәкбәр шул җирдә бераз шикле уйга калды. Хәтер сандыгын тагы актарды. Хәер, дөнья ул үбешеп, ялашып яшәүдән генә тормый. Алар арасында да кайбер килешмәүчәнлекләр булгандыр. Мәсәлән (Галиәкбәр үз алдына елмаеп куйды), Мәгъмүрәнең артык гарьчеллеген аңламый иде ул. Ләкин

нишләмәк кирәк, табигате шундый булгач, аны бик сак мөгамәлә белән генә үзгәртергә була. Каты бәрелеп холыкны төзәтеп булмый. Галиәкбәр шулай итте дә. Һәм, әйтергә кирәк, хатынының соңгы елларда юкка-барга сөмсере коелмый торган булды. Бик ихтимал, Галиәкбәрнең дә кимчелекләре булгандыр. Әйе, булгандыр гына түгел, булды, булды. Мәгъмүрә аңа һәрдаим җайлап кына аңлата иде. Кешенең нинди икәнлеген анык белмичә торып, һәрбер очраган белән артык төчеләнмә ди торган иде. Бар сине аңлаучы кеше, бар моны мескенлеккә санаучы. Андыйлар, ә бу бер бичара әлләзи икән, дип уйлыйлар.

Пенсионерлар ашыкмыйча гына сөйләшеп бардылар. Сүз бау кебек үрелде. Ул, ниһаять, халыкара хәлләргә барып җитте. Алар илләргә, континентларга кагылышлы мәсьәләләрдә икесе дә уртак фикердә булдылар. Әңгәмә хәзер бер-берсенең сүзен хуплаудан һәм тулыландырудан гына торды.

Шулай алар урман авызына килеп чыкканнарын сизми дә калдылар. Алда фабрика поселогының ике катлы ак таш өйләре күренде.

## 12

Фәрит ишек төбендә бераз вакыт көткәннән соң, профессорны тиз генә күрә алудан өметен өзеп, баскыч буйлап түбән төшә башлады. Юравынча, карт урманга гына китмәгән, еракkарак юл тоткан. Ләкин Фәрит тәбәнәк чуен рәшәткә белән әйләндереп алынган тротуарга чыгарга өлгермәде, шатланып елмайган хәлдә туктап калды. Фабрика корпуслары ягыннан ашыгудан йөзе алсуланган Әлфия килә иде. Аның өстендә кеш якалы зәңгәр пальто, аягында йомшак куныччлы, биек үкчәле елтыр кара итекләр. Башындагы юка, челтәр шәле ашыгудан бөтенләй маңгай чәчләре өстеннән артка шуышкан. Ул шундук Фәритне күреп алды, аның алсу йөзен елмаю тагы да матурлый төште. Якынлашкач, ул:

— Бетте дә мени сүзегез? Әти кайда? — диде. Фәритнең әйткәннәрен бик җитди кыяфәттә тыңлады.

— Озакламый кайтыр, — диде ул, егетне тынычландырырга тырышып. — Бераз тоткарлангандыр. — Һәм Фәритне квартирына кире алып кереп китте.

— Чәй эчәрбез, сөйләшеп утырган арада кайтыр ул. Тозлы балык ашаган идем кичә. Көнозын сусап интектем. Булса булыр икән.

Кыз, өйгә керү белән, ашыгып киемнәрен салды, газ плитәсенә чәйнек куйды. Фәрит ботинкаларын салып маташканда ул инде кухнядан эшләрен бетереп чыгып килә иде. Үзенә якынлашкач, Фәрит аны кочаклап, татлы, рәхәт итеп иреннәреннән үпте, аннан алар култыклашып, көлешә-көлешә коридордан бүлмәгә уздылар. Урталыкка куелган канатлы өстәл янына җиткәч, Фәрит кискен рәвештә борылып кызны тагы күкрәгенә кысты. Күрәсең, Әлфия өчен бу көтелгән нәрсә иде. Ул әз генә дә каршылык күрсәтмәде, киресенчә, Фәриткә ныграк сыена гына төште.

— Сагынып беттем, — диде Фәрит пышылдап. Кыз дәшмәде. Ләкин аның да шундый кичерешләр белән яшәвен Фәрит ачык тойды. Әлфиянең йөзе Фәритнең күкрәгендә, шуңа күрә ул күренми иде. Йөзен күрергә тырышып, Фәрит аның кызган яңакларына учларын куйды.— Бер генә...— диде,— тагы бер генә.

Кызның көләч, якты, бик бәхетле икәнлеген чагылдырган күзләрен күргәч, ул тагы аның кайнар иреннәренә таба иелә башлады. Фәриткә сөйгән кешесенең йомшак иреннәрен үбү бик, бик рәхәт иде. Ул

аңа да шулай рәхәт булды микән дигәндәй, башын күтәрде һәм Әлфиянең елмайган йөзен, очкынланган күзләрен күрде.

— Тагы бер генә.

Әлфия имән бармагын күтәреп, һаман елмайган килеш, шуклык белән янап алды. Аның наянлыгын көчәйтеп сул кашы да бер сикереп куйды.

— Җитәр, этинең кайтып керүе бар,— диде ул кинәт житдиләнеп.

— Мескен Таһир белән Зөһрә кебек инде без. Рәхәтләнеп аулакта очраша да алмыйбыз, — диде Фәрит.

Ул тагы Әлфияне кочып алды. Кызның тыгыз күкрәкләрен тою аны бер мизгелдә әйтерсең миңгерәүләндереп җибәрде. Ниһаять, ул үзен кулга алды. Ярамый. Әлфия бу вакытны, сабырсызланып, ычкынырга талпына иде инде.

— Житте, кадерлем. Әти менеп килә булса кирәк, әнә аяк тавышлары...

Фәрит ирексездән, читкә китеп, өстәл янындагы утыргычка чүкте. Әлфия исә көзге янына ашыкты. Тик аяк тавышлары Галиәкбәрнеке булып чыкмады. Баскычтан менүче кеше күрше ишекнең звоногына басты.

Яшьләрдәге әле күптән түгел генә ялкынланып дөрләгән мәхәббәт дәрте сүрелә төшкән иде инде. Әлфия, төзәтенеп беткәч, кухня якка чыгып китте, Фәрит исә өстәлдә яткан «Азат хатын» журналына үрелде.

Әлфия бераздан чәйнек алып чыгып чәй ясый башлады. Шул чакны гына Фәрит, батырчылык итеп, әйтер сүзен Әлфиягә җиткерү өчен авызын ачты:

— Минем сиңа күптән әйтәсе сүзем бар, Әлфия.

Әлфия үзенчә аңлады.

— Әле иртә анысына. Сиңа шундый җаваплы эш тагылган чак. Аннан... өлгерербез. Түз. Син бит тәти егет.

Фәрит елмаеп куйды. Бик шат, бик бәхетле иде шул Әлфия! Фәрит аның мондый гүзәл, бәхетле вакытын ничек, ничек челпәрәмә китерсен! Ул бүген аерата бәхетле, шуңа күрә аерата гүзәл дә. Үзенең шул сабыйларча беркатлы, ләкин комга корылган куанычлары аркасында кинәт Фәриткә ифрат кызганыч булып тоелды. Менә ул чын дөреслекне ярып салачак һәм кыз дәһшәт упкыннарына чумачак.

Фәрит чарасызлык газабын кичереп, үзе дә сизмәстән, өстәл тактасында бармакларын тыпырдата башлады. Ниһаять, кирәгеннән дә бигрәк, котсыз тойгыларын басу өчен генә, Галиәкбәр ага бик озаклады, дип куйды ул.

— Хәзер кайтыр инде, көтик, — диде Әлфия гамьсез генә. Ул ни арададыр кечкенә таш чәйнегендәге чәйне дә кайнатып өлгергән, ни арададыр бәрәңге кыздырып алган, икмәген дә матур итеп тураган. Ләззәтле ис бөркеп торган кайнар ризыкны табасы белән өстәлгә китереп куйгач, Фәрит йокыдан уянып киткәндәй булды. Иртәнге ашын да юньләп ашамаган иде ул. Кинәт бөтен эче сулкылдап ашыйсы килгәнлеген тойды.

— Кичә калган токмачлы аш та бар, җылытыйммы? — диде Әлфия бик эшлекле кыяфәт белән.

— Ә? Юк, юк.

Әлфия егете алдына тәлинкә, чәнечке-кашык куйды да, утыргычны бик якын китереп, Фәриткә яны белән терәлеп диярлек утырды. Кызның кадерлесенә сыенып, бөтен гәүдәсе, җаны-тәне белән аның барлыгын, җылысын тоеп утырасы килә иде. Бик көчле яратканда гына шулай була ала. Моны Фәрит аңлый. Һәм бу аны отыры тетрәтә, әйтергә булган серен тагы да тирәнгәрәк яшерергә мәҗбүр итә иде.

Алар сөйләшмичә генә, ара-тирә бер-берсенә якты, җылы карашлар ташлап, тамак ялгарга керештеләр.

— Нидер булган сиңа,— диде Әлфия,— сынау шулай борчыймы? Бирешмә шул кадәр, Фәриткәем. Мин синең ул эшне башкарып чыгуыңа ышанам. Менә үлем-җитем кими башлады бит инде. Әти кайткач сөйләшербез, анализларны күрсәтербез. Ул файдалы киңәш бирер дип ышанам.

«Ах, шул гына булса иде», дип куйды Фәрит эчтән генә. Әмма үзен көчләп булса да елмайды, сүзне бөтенләй башкага борып, шушы көннәрдә генә укып чыккан фантастик бер әсәрнең эчтәлеген сөйли башлады.

Хикәянең иң кызык җиренә җиткәндә генә ишектә ачкыч борылганы ишетелде.

— Әти, — диде Әлфия елмаеп. Җитез генә сикереп торды да Галиәкбәрне каршылап бүлмә ишеген ачты.

— Озакладың, әти. Сине көтеп утырабыз.

Фәриткә картның авыр сулап кием салганы ишетелде.

— Урманда үзем кебек бер картны очраттым әле, — диде Галиәкбәр Әлфиягә. — Сөйләшеп йөрдек. Улы хатынын, балаларын ташлап качкан.

Фәрит агарынып артка чикте, тәмам утыргычына сеңеп сүзнең дәвамын көтте. Ләкин ни Әлфия, ни карт артык бу турыда сүз куертмадылар.

— Әйдә, чәйгә, әти, без Фәрит белән эчә идек әле, — диде Әлфия.

— Хәзер, кулымны гына юыйм да...

Әлфия әтисенә өстәл янынннан тиз генә урын әзерләде. Фәритнең хәзер куркынуы беткән, мәгәр ул авыр кичерештән соң тәмам хәлдән тайган иде.

## 13

Кошчылыкта бройлер җитештерү сәнгатенең үзенчәлеге шуннан тора: тиз җитлегә торган итләч тавык токымнары гибридын[1] тиешле шартларда үстерәләр. Табигатьтәге гетерозис[2] дигән күренеш законнары нигезендә тәннәрендә берничә токымның каны аккан бу чебиләр ай үсәсен көн үсәләр, искиткеч тиз арада җитлегеп, 7—8 атна дигәндә, бәләкәйрәк тавыкны куып җитәләр, сугым өчен камил үлчәүдә булалар. Аларның итләре йомшак, тәмле була. Җитмәсә гибрид чебиләрне үстерү өчен гади бер токымдагы чебиләрне үстерүгә тотылган азыкның яртысы да китми. Ләкин бу эш бик зур игътибар һәм төгәллек сорый. Монда инде «әйдә ярар»га исәп тотып булмый. Ата-бабалары һәм әни-әбиләре токым ягыннан әйбәт чыгышлы, асыл затлардан булсын, яшәү, үсү шартлары һәр яктан яшь организм таләпләренә туры килсен. Анда яктылык та, җылылык та, бинадагы дым да, һаваның сафлыгы да — барсы да норма буенча тотылсын. Инде тирәлек белән организмны аерата нык бәйли торган шарт, тукландыру шартлары, бик төгәл һәм фән кушканча булырга тиеш. Азыкта витаминнарның майда эри торганнары да, суда эри торганнары да — барысы да җитәрлек булсын. Алай гына да түгел, минераль элементларның һәр төрлесе, май да, аксым да, аксым бинасының «кирпечләре» — амин кислоталар да һәм, кирәк икән, төрле чирләргә каршы кулланыла торган дәвалар да, үсүне көчәйтүдә файдаланыла торган химик кушылмалар да, хәтта бик начар сеңешле булган салам-

[1] Гибрид — төрле токым, яки төр вәкилләре кушылудан туган җан иясе.
[2] Гетерозис — кушылдык организмнарның ата-аналарына караганда да тизрәк үсү, тәрәккый итү күренеше.

ның, кәгазьнең күпчелек өлешен тәшкил иткән клетчатка да, көндәлек рационның колориясе дә төгәл үлчәнеп, тиешле микъдарда бирелергә тиеш. Әгәр шундый тиешле шартлар тудырылмаса, итнең сыйфаты түбән — сусыл, тәмсез була.

Мондый төгәллекне булдыру өчен биналар тиешенчә салына, һава, яктылык, дым режимнарын күзәтү өчен төрле автоматлар куела, азык та, су да автоматик рәвештә бирелә. Галиәкбәр гыйльми хезмәт юлына баскан көннән алып, пенсиягә чыкканга кадәр дип әйтерлек, шул өлкәдә хезмәт күрсәткән кеше буларак, бройлер үстерү сәнгатенең серләрен, әлбәттә, әйбәт белә иде. Хәер, моны белгеч, практик буларак Фәрит тә белми түгел. Ләкин белү бер, ә белгәнеңне тормышка ашыру икенче нәрсә. Шуңа күрә Галиәкбәр, иң беренче чиратта, кызына һәм булачак киявенә ярдәм күрсәтү өчен яшьләрнең үтенечен аяк астына салып таптый алмады, авырсыныбрак булса да, ярдәм итәргә булды.

Алар азыкның составына ясалган анализ белешмәләрен озак кына тикшереп утырдылар. Галиәкбәр, алдындагы кәгазьләргә шактый вакыт текәлеп уйланганнан соң:

— Әйдәгез әле, бергәләп корпусларга чыгыйк. Нишлисен шунда аныкларбыз, — диде.

Алар контроль капкадан узышлый ак халатлар, резин итекләр киеп фабрика территориясенә керделәр. Борынга Галиәкбәр өчен бик күптән таныш тавык кетәге исе бәрелде. Бер уңайдан тавыклар урнашкан корпуска да сугылдылар, идәндә үстерелә торган чебиләр янында да булдылар. Яссы ягына яткырылган шырпы тартмаларыдай тезелгән бер катлы таш биналар кырыкка якын. Аларны ашыкпошык карап әйләнү өчен дә ике көн җитмәс. Галиәкбәр фабрика территориясенә керү белән үзендә ниндидер үзгәреш сизде. Ул контроль капка аша узу белән үзенә җаваплылык өстәлгәнен тоныкына булса да тойды. Корпусларда үзе күргән тәртипсезлекләр аның күңелен тырнап узалар иде. Мәгәр ул эшчеләр алдында белгечләргә бернинди дә искәрмә ясамады, соңыннан үзләренә генә әйтергә булды. Ниһаять, йөри торгач, алар бер почмакка рәт-рәт булып читлек батареялары тезелгән корпуска керделәр.

— Менә шул инде безнең тәҗрибә өчен үстерелә торган чебиләр!

Профессор, бер сүз дә әйтмәстән, игътибар белән идәннән түшәмгә кадәр берсе өстенә икенчесе куелган дүрт катлы тимер читлекләр рәтеннән алга китте. Читлекләр ике рәткә тезелгәннәр. Галиәкбәр аларның барысын да игътибар белән карап чыкты. Кайберләре янына тукталып, озаклап чебиләрне күзәтеп торгалады. Аннан, ягез әле, азык җибәреп карыйк, диде. Шундук читлекләр алдындагы азык тагарагы хәрәкәткә килде. Аңа әверелдерелгән комбиазык тар тагарак буйлап ага башлады. Профессор берничә тапкыр тагарактагы азыкны учына алып карап торды. Аларны, аерым кәгазьләргә төрдереп, тикшерү өчен кызына бирде. Әлбәттә, хәзер үк ниндидер нәтиҗә ясап булмый иде. Ләкин шулай да карт белгеч үзенең күп еллык тәҗрибәсенә таянып эшне нидән башларга кирәклеген чамалый алган иде инде.

Алар тәҗрибә уздырыла торган корпуста бик озак йөрделәр. Ниһаять, Әлфияне хәзер үк алынган пробаларга химик анализ ясау өчен кайтарып җибәрделәр. Үзләре һаман читлекләр тирәсендә кайнашты. Бу минутларда Галиәкбәр эш белән шул кадәр мавыккан иде ки, ул хәтта артык озакка сузылган бу тикшеренүгә эче поша башлаган Фәритнең әле бүген башка бик күп эшләр башкарырга тиешле икәнлеген дә онытты. Сизелеп тора, үз белгечлеге буенча хезмәткә карт бик сусаган икән. Моны тойган Фәрит түзде, ара-тирә үзе дә

профессорның хисләре җылылыгында дәртләнеп, бүген эшләнәчәк бик күп башка эшләрен оныткалады.

Сәгать икеләрдә барлык эш тәгәлләнде ахры. Белгечләр неон энҗе-утлар балкыган цехтан чыгып киттеләр. Аерым чебиләрнең ачы чиелдавы гына күңелгә сеңгән килеш колакларда яңгырап калды. Фәрит белән Галиәкбәр кабинетка керделәр. Сүзгә керештеләр. Әлфия алып киткән пробаларга анализны тиз ясап бетерергә тиеш иде. Чөнки нинди дә катлаулы химик анализларның кирәге юк. Максат бары улакта агып торган азык бер үк төрлеме икәнен генә белүдән гыйбарәт. Бу эшне исә Әлфия үзенең ярдәмчесе белән центрифугада[1] бик тиз башкара алачак иде. Һәм, чыннан да, белгечләр Фәрит бүлмәсендә элегрәк ясалган анализларны тагын бер тапкыр җентекләп тикшергән арада Әлфия килеп тә керде. Азыкта берниндн дә кимчелек юк иде.

Профессор, бу хәбәрне ишеткәч, уйланып Фәриткә карап торды.

— Димәк, болай инде, Фәрит туган, — диде ул бераздан. — безгә синең белән бәләкәй генә эксперимент уздырырга туры киләчәк.

Фәрит ризасызлык белдергәндәй йөзен җыерды.

— Ничек инде, тәҗрибә эчендә тәҗрибәме?

Галиәкбәр, картларча тыныч көлемсерәп, сүзен дәвам иттерде.

— Әйе, шулай, туган. Конкрет шартларның үзенчәлеген белү өчен читлектәге чебиләр белән сынаулар уздырырга туры килә.

— Да-а, — дип куйды Фәрит, кинәт кызарып киткән киң маңгаен учы белән угалап,— мин болай булыр дип уйламаган идем.

— Сез бераз ашыккансыз. Эшне башта ук шул эксперименттан башларга кирәк булган.

— Кем белә бит аны.

Егетнең кара кайгыга батуын тоеп, карт аны тынычландырырга тырышты.

— Зарар юк, әле соң түгел. Югалтулар ул кадәр күп булмас, дип уйлыйм. Тик инде без сезнең белән ул эксперимент белән үзебезгә нигезле җирлек әзерләячәкбез.

Фәритнең эшләре, борчулары болай да хәттин ашкан. Шулай да ул, сабырлыгын җыеп, булдыра алганча тыныч кына сорау бирде:

— Бу эштә минем миссиям нидән гыйбарәт булачак инде?

— Сез — хуҗа. Сез бу сынауларның нәтиҗәсе белән иң нык кызыксынучы кеше.

— Ах, шундый эшләргә вакыт җиткерә алса идем мин, — дип авыр сулап куйды Фәрит. Ләкин эчтән бик тиз тынычланды.

— Мин методикасын төзеп бирәм,— диде профессор,— хәтта сынауларның барышын вакытлыча күзәтеп тә тора алам. Миңа ышанычлы ярдәмче генә кирәк.

— Башта шунысын әйтегез әле, Галиәкбәр Хафизович. Ул экспериментларны ничегрәк күз алдына китерәсез соң?

Карт ашыкмыйча гына сүз башлады. Һич көтелмәгән әйберләр сөйли иде ул. Әйткән һәр нәрсә белән соң дәрәҗәдә кызыксынып, Әлфия белән Фәрит тыңлап утырдылар.

— Минемчә, моны уздыру бездә реаль, — диде Фәрит. — Мин үзем, әлбәттә, техник эшләрне башкара алмыйм.

— Бәлки берәр эшчегә тапшырып булыр. Билгеле, ул ышанычлы, төгәл һәм өлгер кеше булса диюем...

— Анысы да мөмкин түгел. Ышанычлы, булдыклы эшчеләр юк түгел. Ләкин аларның үз эшләре дә муеннан. Беләсез бит: производство! План, йөкләмәләр...

---

[1] Центрифуга — бик кызу әйләндерү ярдәмендә коры һәм сыек кушылмаларны бер-берсеннән аеру приборы.

— Андый очракта үз эшегезне минем ярдәмемнән башка гына үтисез инде, — диде профессор Фәриткә кырыс бер караш ташлап.

Фәрит бу күңелсез хәлне төзәтергә теләп елмая башлады, ә Әлфия исә аның көлүен килештермичә матур кашларын җыерды:

— Туктале, — диде ул, — син бит, Фәрит, бая бер яшь зоотехникны эшкә алдык дигән идең. Шуны ярдәмче итеп куйсак соң?

Фәрит җитдиләнеп бераз уйланды да:

— Аның аркасындагы гитарасы белән җилкәсенә кадәр төшкән чәчләре куркытмасмы соң Галиәкбәр аганы?

— Сүз кем турында? — диде профессор.

Фәрит аңа Рәмзи хакында сөйли башлады. Профессор Фәритне тыныч кына тыңлаганнан соң:

— Таныштырыгыз әле үзе белән, — диде. — Гитара ул музыка коралы, чәч... ул да ходай биргән нәрсә. Мода бит, нишлисең..

— Берәр яры чыгып китмәгән булса, мин аны сезнең белән хәзер үк таныштыра алам. Егеткә вакытлыча кызыл почмакта яшәргә кушылды.

— Чакырыгыз, — диде профессор, — карап карыйк, нинди гитаралы зоотехник икән ул?!

Фәрит шундук торып каты адымнар белән бүлмәдән чыгып китте.

— Синең эшләрең беттемени, кызым? — диде Галиәкбәр Әлфиягә карап.

— Бәлки кирәгем чыгар дип утырам мин.

— Юк, кирәкми, хәзер миңа барысы да ачык, бер бәләкәй экспериментсыз булмый. Син үз эшеңдә бул.

Әлфия аягүрә басты. Аның нидер әйтәсе килгәнлеге сизелә иде. Тик ул, күрәсең, кыймады, бераз ишек янында таптанып торганнан соң, ишекне тавышсыз гына ябып коридорга чыгып китте.

Фәрит исә бу вакыт «кызыл почмак» дип аталган иркен бүлмәгә җиткән, тонык кына ишетелгән гитара авазларыннан Рәмзинең анда икәнлеген белгән иде.

Рәмзи, үзенә йоклар өчен бирелгән раскладушка янында кәнәфигә утырган килеш, кызыл почмакның аргы очында гитарасын чыңлатып ниндидер көй чыгарырга азаплана иде. Фәритне күрүгә артык исе китмәде. Урыныннан кузгалмыйча гитарасын уйный бирде.

— Ну, егет, нихәл соң? — диде Фәрит. — Туңмадыңмы төнлә?

— Түзәрлек, — диде Рәмзи, гитарасын газета өемнәре өстенә куеп. — Әллә эшкә дәшә килдегезме?

— Менә бөтен хикмәт тә шунда шул. Сиңа эшнең бик хәтәреннән башларга туры киләчәк.

Рәмзи, берни аңламаганлыгын белдереп, хәйләкәр карый торган соргылт күзләрен Фәриткә текәде.

— Сиңа эшне, агайне, профессор кул астында башкарырга туры киләчәк.

— Нинди профессор?

— Хәзер мин сине аның белән таныштырам, күрерсең.

— Миңа авансҡа бераз акча кирәк иде, — диде Рәмзи, сүлпән генә аягүрә басып.

— Булыр, — диде Фәрит, — барысы да син дигәнчә булыр, тик син без теләгәнне эшлә.

Рәмзи дәшмәде, очлары бөдрәләнеп килгән озын чәчләрен сыпыргалый-сыпыргалый, Фәрит артыннан китте. Алар бүлмәгә килеп кергәндә профессор зур тырышлык белән нидер язып утыра иде.

— Менә ул егет, — диде Фәрит. Галиәкбәр агара башлаган күе

кашлары астыннан Рәмзигә сынап караганнан соң, аны каршысына утыртып сүз башлады.

Аңлату тәгәлләнгәч, сүзен бүлдермичә игътибар белән тыңлаган Рәмзидән сорап куйды.

— Я, ничек, шул мин әйткәннәрне башкарып чыга алырбызмы?

— Башкарабыз, — диде Рәмзи җемелдек хәйләкәр елмаю белән. Егетнең интонациясе Фәриткә ничектер ошамады. Ул җавапны уйламыйчарак бирә иде кебек.

— Бу эшнең нинди җаваплы икәнлеген тоясыңмы соң син?

— Ну, — диде Рәмзи. Галиәкбәр ирексездән елмаеп куйды.

— Инде сезгә барысы да аңлашыла икән, Рәмзи, — диде ул, — без эшне озын-озакка суза алмыйбыз. Иртәгә үк керешәбез. Мин монда кыскача эш планы яздым. Сез, аны күчереп алыгыз да, һәр вакыт яныгызда йөртегез. Ризамы?

— Аңлашыла, — диде егет. Ул Фәриткә текәлде.

— Ә аванс? Мин бүген соңгы егерме тиенемне столовойда калдырдым.

Фәрит егетнең әрсезлеген дә яратмады. Ләкин аңа караңгы чырай күрсәтмәде, каты бәрелмәде. Акчасыз яшәп булмый бит. Ярар, диде. Ярдәме өчен профессорга рәхмәт әйтеп, аның иртәгә фабрикага сәгать ничәләргә киләчәген белеште.

Профессорны озату өчен Рәмзи дә коридорга чыккан иде. Карт коридор очындагы баскычтан таянсага тотынган хәлдә сак адымнар белән аска төшеп киткәч, Фәрит Рәмзигә таба борылды.

— Хәзер аванс мәсьәләсен кайгыртабыз. Һәр эшнең үз урыны, үз вакыты бар, сэр.

Алар фабриканың бухгалтериясенә таба коридор буйлап киттеләр.

Инде шактый җитди эш башлануына фатиха хезмәтен үтәүче аванс Рәмзигә бирелгәндә, Галиәкбәр кызының квартирасына кайтып җиткән, ишекне ачкан һәм өске киемнәрен салып, чөйгә элгән иде.

Ул җылы ботинкаларын салып постау чүәктән генә бүлмәгә узгач, өстәлдә яткан газеталарга һәм күренсен өчен аларның өстенә куелган бер конвертка игътибар итте. Гаҗәпсенүенә каршы, хат үзенә адресланган булып чыкты. Язуына караганда, ул Сафурадан иде. Карт каударлана төшеп, берәр хәвефле хәл булмагае тагы дигән шомлы уй белән конвертны кулына алды, ертып аның эченнән кәгазь кисәге тартып чыгарды. Хат Сафурага хас булганча пәрвайсыз кеше кулы белән язылган иде. Галиәкбәр күкрәк кесәсеннән күзлеген алып киде дә, хат юлларыннан күзләрен йөгертергә тотынды:

«Әти, синең минем белән Лиананы ташлап, үзеңнең намус эшен булган безгә булышудан куркып качуыңны мин берничек тә гафу итә алмыйм. Һич булмаса безгә экономик ярдәм күрсәтсәң дә үлмәгән булыр идең әле. Лиана һаман санаторийда, кәефе шәп түгел, аңа бара алмыйм, телефон аша гына сорашып торам, вакыт юк. Хәер, син инде аны кызганмыйсың, сиңа барыбер. Аннан синең эшләгән җиреңнән миңа шалтыратып үзәккә үтәләр. Эльвира Хәкимовнаның сине бик күрәсе килә. Менә шул. Сафура».

Рәхимсез хат тетрәтте Галиәкбәрне, йөрәгенә капты. Тик шулай да аның йөрәк парәсе Лиана бик-бик кызганыч иде. Аның бабасына ышанып карый торган күзләре, кулларын сузып, мине күтәреп ал дигәнне аңлаткан хәрәкәтләре, хәтта «давати» дип дәшүе ирексездән күз алдына килеп, тамак төбенә төер тыгылдырды.

14

Галиәкбәр кинәт бөтен тәнендә ачу китергеч хәлсезлек сизде. Хәлбуки, ул бит мондагы эш, мондагы кешеләр арасында тәмам яшәреп киткәндәй иде. Карт, тәкатьсез калып, күңел сыкравын кичерә башлады. Үзенең уе, зиһене белән ул ни кадәр генә нык каршылык күрсәтмәсен, ниндидер яшерен хисләр аны җәберлиләр, чыннан да, мин Лианамны ташлап киттем бит, дигән уй салкын, чиркандыргыч җыландай үрмәләп, күңел түренә менә һәм йөрәккә шом сала иде. Галиәкбәрнең кинәт балтыр итләре авыртып куйды, ул баскан урынында бераз туктапып хәл алганнан соң гына аксый-туксый яшел дерматин белән тышланган диванга барып утыра алды. Чуалган уйларын тәртипкә китерергә тырышты. Ләкин һәр очракта теләк «Лиана авыр хәлдә» дигән диварга бәрелеп челпәрәмә килә, карт үзен берничек тә аклый алмый иде.

Кичке сәгать алтыларда Әлфия кайтты. Ул ишектән керү белән:

— Сафура апаның хатын күрдеңме? — диде. Аннан диван таянсасында яткан ачык конвертка күз ташлагач, барын да аңлады. — Мин аны иртәнге якта ук алган идем, тик сиңа биреп борчыйсым килмәде.

— Лиананың хәле бик авыр дип яза.

— Ни булган?

— Анысын әйтмәгән.

Әлфия Лиананың авыру балалар санаторийсында калганлыгын яхшы белә иде. Шулай да Галиәкбәр, хәлнең әйбәт булмау ихтималын аңлату өчен, өстәде:

— Бала янына үзем бара алмыйм, хәлен телефоннан гына белешәм ди Сафура.

— Монысы инде бик начар, — дип куйды Әлфия. Ул кискен хәрәкәтләр белән җил-җил атлап кухняга чыгып китте. Ни сәбәптәндер бүген аның апасына карата ачуы аерата көчле иде. Галиәкбәр «күрәсең, мин сөйләгәннәрнең нәтиҗәседер», дип уйланды. Аны шундук артык туарылып, барысын да Әлфиягә сөйләгәне өчен үкенү хисе били башлады. Аныңча, үзе дөнья куйгач та, әле озак вакытлар туганнарча яшәргә тиешле кешеләрнең арасын бозу әйбәт түгел иде. Ул кулына эләккән «Чаян» журналын һич кызыксынусыз күзләреннән кичергән хәлдә, шулай уйланды.

Бераздан эшләрен бетереп Әлфия яңадан әтисе янына керде. Хәзер инде ул шактый тынычланган, баягы ачуы сүрелгән иде. Үзе өчен бик мөһим, тик әйтүе генә шактый читен булган, бер сер җиткерергә җыенуы аның ак йөзенә шәүлә булып кунган. Чак кына икеләнү кичерешләре уздырганнан соң ул, утыргыч алып, әтисе каршысына урнашты.

— Әти, син килгәч тә, бик вакытлы килдең әле, синең белән киңәшәсем бар, дигән идем.

Галиәкбәр хәтерләде, «шулай шул» дигәнне белдереп, ияк кагып куйды.

— Синең белән бик җитди нәрсә турында киңәшмәкче булам, — диде Әлфия.

Галиәкбәр кәнәфиенә җайлабрак утырды.

— Тыңлыйм, кызым.

— Син бит, әти, Фәритне беләсең.

— Әйе, ул сезнең баш зоотехник.

— Ул миңа тәкъдим ясады.

Карт сәер генә елмаеп куйды.

— Күптәнме?..

— Күптән инде. Син килгәнче үк.

Карт агарган мыегын бармак очлары белән генә сыпырып куйды. Кинәт ул үзе үстергән һәм хәзер бердәнбер кадерле кешесе булган Әлфиядән мәхрүм калу дәһшәтен тойды. Ниндидер эчке бер каршылык туды аның күңелендә. Ләкин шул ук вакытта Әлфия кеше иде, кыз бала иде, ул үзенең бәхетен табарга, вакытында кияүгә чыгып гаилә корырга да тиеш иде. Уйлар белән хисләр бәрелешеп алдылар карт күңелендә.

— Ничек соң, кызым, — диде ул, ниһаять, — син аны үзең яратасыңмы соң? Күңелеңә хуш киләме?

— Бик-бик яратам, әти.

— Шулай икән, — дип куйды Галиәкбәр, мыегын бармак очлары белән тагы сыпырып. — Ә соң табигатен-холкын, гадәтен яхшы беләсеңме, кызым?

— Миңа барысы да, барысы да ошый, әти.

— Карале, кызым Әлфия,— диде бераз уйланып торгач карт.— Кияүгә чыгу, минем фикеремчә, бик җитди эш ул. Язмышыңны хәл итә торган иң мөһим факторларның берсе. Тагы бераз сынасаң ничек булыр соң егетне, ә?

Кыз уфтанып әтисенә таба иелә төште.

— И, әтием бәгырем, миңа бит инде егерме сигез яшь. Минем яшисем килә. Бары хезмәт ләззәтеннән генә авыз итеп яшәү, ул әле яшәү түгел. Үз янымда көчле, акыллы ир кешенең, үземне яраткан, авыр минутларда таяныч булырлык якын, кадерле кешенең булуын телим.

Әлфиянең күзләре дымланып китте, ул тиз генә җиң очыннан ак ефәк яулык чыгарып борынын каплады.

— Минем хәлемне син аңлыйсыңдыр инде, әти, — диде ул тынычлана төшеп. — Фәрит ул минем өлешемә чыккан көмешем.

— И кызым, аппагым минем, — диде Галиәкбәр, кызның маңгаеннан үбеп. — Син шундый сүзләр белән аңлатасың, әйтерсең мин синең бәхетеңә каршы килергә телим. Зинһар, бәхетле генә була күр. Мин барысын да аңлыйм. Миннән сиңа фатиха. Сүзем сиңа бары яхшылык теләүдән генә, акыллым. Башыңны югалтма, барысын да уйлап эшлә. Мин бары син ялгышмасын дип кенә тырышам бит, кызым.

— Ни өчендер Фәрит бу араларда бик тынычсыз әле, — дип куйды Әлфия. — Юкса, ике сүзнең берендә үзенең тәкъдимен кабатлый иде.

— Уйлана торгандыр. Аннан әнә эшендә дә бит нинди сынаулар кичерә кеше.

— Шулай шул, — дип куйды Әлфия риза булып.

— Мин ашыкма дип бары син ялгышмасын өчен әйтәм, — диде Галиәкбәр сүзне тагы шул ук мәсьәләгә борып. — Апаңның кияүгә китүе синең күз алдында булды бит. Киңәшү юк, нитү юк, очраган бер чибәр офицер, гашыйк булган, кияүгә чыгам, бетте китте вәссәләм. Нәрсә булып бетте? Аерылыштылар. Бала ятим. Кемгә кирәк мондый минутлык хисләргә кол булу. Аңлыйм мин синең хәлеңне дә. Тик шуны исеңдә тот, мәхәббәттә тойгыларыңны бер кабат кына үлчәргә ярамый.

— Әти, — диде кинәт Әлфия йөзен чытып, — син миңа бик гади аксиомалар аңлатасың. Берәү дә үзен бәхетсезлеккә дучар итәргә теләми. Тик бит, әти, хикмәт шунда: кеше мәхәббәт хисләренә буйсынмаса, аны салкын расчет белән алыштырса, барыннан да күбрәген югалта. Шулай түгелме?

Галиәкбәр ирексездән үзенең яшь вакытын хәтерләде. Әйе, диде ул эченнән генә, шулай, үзенең Мәгъмүрәсенә, җан кисәгенә, гашыйк булгач, мәхәббәттән башка нәрсә калдымы соң аңарда сөйгән кызы-

на карата?! Шулай шул, мәхәббәт кешене сукырайта диләр, һәм аны үзгәртергә дә кирәкмидер. Чөнки мәхәббәт саф бриллиант кебек затлы хис, инде аңа акыл гранитларын өстибез икән, гүзәл тойгы кыргый ташка әйләнә. Сөю — сәгадәт, дип белми әйтми олы әдип.

— Син минем рәхәтләнеп риза булуымны телисең, кызым, — диде карт, ниһаять. — Мин синең егетеңне белгеч буларак кына беләм, ләкин аны кеше буларак бөтенләй белмим диярлек. Тик синә ышанам. Синең сизгерлегеңә, акны карадан аера белүеңә. Менә шул: мин бик рәхәтләнеп риза, кызым.

— Инде туйны кайчангарак уздырырга синең исәп? — дип сорады ул бераздан.

— Менә сынаулар башкарылып, Фәритнең эшләре бераз көйләнсен инде.

Бу, карт фикеренчә дә, дөрес иде. Ашыгуда файда юк. Әле аны урмәкүч пәрәвезедәй чорнаган хис — сөекле кызын югалту дәһшәте һаман богаулап тора иде. Ул болай кичермәскә тиеш мин дип үзен ни хәтле табаламасын, күңел түрен шул мәгънәсез тойгы өзлексез тырнап газаплый иде.

— Беләсеңме нәрсә, Әлфия, — диде ул башына әле генә килгән фикердән җанланып, — мин, бер җаен туры китереп, сезнең мөнәсәбәтләр турында Фәрит белән ирләрчә сөйләшеп карасам ничек?

— Нигә кирәк ул, әти, — диде Әлфия, аягүрә басып. Ул плитәдәге ашын хәтерләде. Галиәкбәрнең ялгызын зур бүлмәдә калдырып, кухняга чыгып китте.

Башта Галиәкбәр Фәрит белән сөйләшү турында уйланды, аннан аның күзенә диван таянсасында яткан хат чалынды. Кинәт күз алдына тагы сары песнәге — Лианасы килеп басты. Карт, күңел сыкравына түзә алмыйча, урыныннан торып телевизорга таба атлады. Хоккей матчы күрсәтәләр. Карт телевизорны көйли башлады. Чөнки ул бу уенны ярата, уендагы яшендәй кызу хәрәкәт, көрәш аның хәзер инде йокымсырый башлаган егетлек хисләрен уятып җибәргәндәй мавыктыра иде. Бу уенга аның мәхәббәте Мәгъмүрәне җирләгәннән соң туды. Тик, гаҗәп хәл, нигәдер бу юлы ул һич элеккечә онытылып карый алмады матчны, әле Сафураның хаты, әле Әлфиянең әйткәннәре аны матчтан аерып үз якларына сөйриләр иде. Бераздан ул, борчулы уйларыннан качар өчен телевизорны сүндереп, кызы янына кухняга чыкты. Әлфия ашка токмач сала иде.

— Кызым, — диде Галиәкбәр. — Казанга барып кайтмый булмас ахры.

— Кирәкми, әти, азапланып йөрмә, ичмаса бераз гына тыныч яшә.

— Лиана бик йөрәкне яндыра бит.

Әлфия, токмачын ашка шыбырдатып төшерде дә;

— Син сөйләгәннәрне ишеткәч, миндә Сафура апага карата тырнак очы кадәр дә хөрмәт калмады, — диде. — Просто сине борчу өчен генә шулай язганлыгын әллә каян белеп торам.

— Әйдә, Әлфия, ул кадәр каты хөкем итмик. Бәлки миндә дә хаталар булгандыр.

Әлфия әтисен кызганып, җиңелчә елмайган хәлдә, аның йөзенә карап торды. Чыннан да, аның әтисе чын мәгънәсендә бабай инде. Күп тә үтмәс, ул картлыкның югары баскычына менеп, бәлтерәгән бер мескенгә әйләнер. Күрәсең, картлык шулай кыюсызлык, икеләнүчәнлек белән янәшә атлый торгандыр. Әлфия шулай уйлады. Мәгәр Галиәкбәр картлык алга барган саен кешедәге хикмәт иясе булу сәләте арта бара дигән бер карашта иде.

— Аннан синең Фәриткә биргән вәгъдәң дә бар, — диде Әлфия әтисен китмәскә күндерү өчен. — Теге яшь зоотехник нинди кешедер

бит әле? Аңа ышанып шундый җаваплы моментта китәргә синең вөҗданың рөхсәт итмәс, әти.

— Һе, аның турында ике төрле сүз була алмый инде. Барысын көйләгәч Казанга кайтып килү турында әйтәм мин.

Әлфия фабрика һәм поселок вакыйгаларын сөйли башлады. Ул арада аш пешеп чыкты. Әтиле-кызлы кухняда гына, дуслык-татулык рәхәтен тоеп сөйләшә-сөйләшә ашадылар.

— Нигәдер бу көннәрдә Фәрит кичләрен күренми башлады әле, — диде карт сүз арасында.

Чыннан да, дип уйланды Әлфия, ни кичә сугылмады, ни өченче көн. Әтисенең сүзләре кызның күңеленә борчу салды. Ул кияүгә чыгу турында зурдан кубып сүз ката. Мондый чакта егет кызның янында китмичә бөтерелеп йөрергә тиеш. Хәер, дип тынычландырды ул үзен, бу читлек чебешләре белән маташып, төп эшенә шактый зыян китерде бит ул. Йөридер цехлардан чыга алмыйча. Авыр аңа.

Кызның юраганы, әлбәттә, дөреслеккә туры килә иде. Ләкин бу дөреслекнең барысы да түгел иде. Фәритнең кыз янына кичләрен сугылуын тоткарлаган беренче сәбәп әтисе булды. Ул аны кичләрен япа-ялгыз өйдә калдырырга яхшысынмады.

Бүген кичен Фәритнең әтисе урманда бер картны очратуын һәм ул кешенең Казаннан килгән профессор икәнлеген әйткәч, Фәрит тәмам агарынып китте. Тотлыга төшеп сорады:

— Нинди гәп кордың соң шул профессор белән?

— Бик күңелле итеп уртак кайгыларыбызны бүлешеп йөрдек. Шул булды гәп.

Фәрит куркынып әтисенең күзләренә карады. Ниндидер хәйләкәр елмаю чалымнары күренә иде шешенке кабаклы ул кысык күзләрдә.

— Сөйләдеме соң профессор үзенең кызы турында, — дип сорады Фәрит агарынып.

— Сөйләмәгән кая, сөйләде! Хәзерге яшьләрдә бармени ул олыларга хөрмәт дигән нәрсә!

Фәрит иркен сулап куйды. Сүз Әлфиянең апасы Сафура турында барган икән.

Зариф тагы Фәритне гаиләсенә алып кайту өчен килгәнлеген тукый башлады.

— Инде дә кайтмыйсың икән, мин Фәһимәңне балалары белән ияртеп монда алып киләм, — диде ул ахырдан.

## 15

— Бүген миңа тулы порция токмачлы аш и ике второй — тавык ите бирәсең, — диде Рәмзи кассир хатынга. Кашларын җыерып бик җитди уйланды да, кулындагы көмеш акчаларны уйната биреп: — Тагы бер кесәл и өч телем ипи, — дип өстәде.

Ашханә кассиры, түм-түгәрәк битле, шук күзле яшь хатын, түземәде, шактый мут елмаеп:

— Баеган син бүген, Рәмзи, — диде. Егет, күз кысып, күкрәк кесәсенә сугып куйды. Кассир хатын белән алар беренче көнне үк таныштылар. Моңа сәбәп ханымның сүзчәнлеге, ачык йөзлелеге булды. Сүзне ул башлады. Ахырда күрше авыл кешеләре булып чыкканлыклары беленде.

Рәмзи аванс алган көн дип сыйланырга булды. Подносына ашлар төяп буш өстәлгә таба китте, урнашып ашарга кереште. Тыштан ни кадәр тыныч күренсә дә, аңа бик күңелсез иде. Әле ялгызлыкта, салкын кызыл почмакта уздырган ике көн, ике төн эчендә ул төрлесен уйлады. Моннан ычкынырга микән әллә, дигән теләк тә тумады ту-

гел аның башында. Тик авылга гына кайтармагыз, теләсә кайда барам дип сүз биргән килеш, аның теләген үтәгән кешеләргә карата вәгъдә бозуны яхшысынмады. Аннан кайчандыр үзе практикада булып яратып калган эшне ташлавы да шәп түгел бит. Ничек тә түзәргә кирәк, бу эш рәтләнер әле бер. Белмәссең, бәлкем әйбәт булыр.

Кызыл почмакта ул күбрәк үзенең КамАЗдагы иптәшләре турында уйланды. Әйбәт кенә ияләшкән иде бит. Тәмам дуслашып беткәннәр иде. Анда да башта бик авыр булды ич. Шыксыз баракта яшәде. Ул күзгә пычраклар, сумаладай кара балчык боламыгында йөрүләр, барак ашханәдәге чиратлар... Салынып ята торган биналарга торбалар үткәрү, торбалар бөгү, аларга резьбалар кисү, муфталар, фланецлар борып кертү җиңел түгел иде. Куллар салкында өшеп, бирчәеп бетә, юештә күшегә, аннан чебиләп әчетә. Мәгәр акчасы җитәрлек төшә, тамак тук, ә барыннан да битәр, монда эшләгән эшең күзгә күренеп тора, сине колхоздагы кебек юкка да, барга да табалаучы, хурлаучы Нургали юк. Рәмзиләр башта кысан бүлмәдә тордылар, аннан алар күпчәксез вагоннарга күчерелде, инде соңгы ел ярымын ул Мәскәү эшчеләре салган шәп таш өйдә яшәде. Кыскасы, Рәмзиләр бригадасына өч бүлмәле квартира бирделәр. Алар шунда һәр бүлмәдә дүртәр кеше, теге кем әйтмешли, патша кодасыдай рәхәтләнеп яшәделәр. Эшләре яхшы барды.

Рәмзинең әле үз гомерендә мондый әйбәт шартларда яшәгәне юк иде. Уты дисәң — уты, суы дисәң — суы, аның да әле теләсәң кайнары, теләсәң салкыны, кранны бору белән чаптырып ага. Хәтта чүп түгеп йөрисе дә юк. Баскыч мәйданчыгына чыгасың да өйнең өстеннән астына кадәр сузылган колачка сыймаслык тимер торбага түнкәрәсең чүп чиләгеңне.

Өйдә дә, эштә дә Рәмзиләр тату яшәделәр. Кайбер егет сирәкмирәк «юлдан язгалый» икән, — анысы әллә ни бәла түгел, андыйларны бергәләшеп бик тиз акылга утырталар иде. Барыннан да битәр, Рәмзи илнең төрле якларыннан килгән иптәшләреннән күп нәрсәгә өйрәнде, яшьләргә хас өлгерлек белән үзенә ошаган гореф-гадәтләрне үзләштереп алды. Хәтта бик күп мәсьәләләргә карашы да үзгәрде. Ул, белемле кеше буларак, эшнең серләренә дә тиз төшенде. Русчаны техникумда ук ярыйсы үзләштергән иде. Армиядә шомартты. Хәзер исә ул бөтенләй акцентсыз-нисез сөйләшә башлады. Русның төрле гыйбарәләргә бай телен үз теледәй күрә башлады. Гел русча сөйләшү аркасында, әйтергә кирәк, ул татарчасын оныта да төште. Авылга кайтып авылдашлары белән гәп кора башласа, еш-еш аңа русча сүзләрнең татарчасын әйтеп булышалар иде. Тик бу кыТыршылыклар озакка сузылмый, отпусканың азагында Рәмзи тагы чыкылдаган авыл кешесенә әйләнеп бетә иде инде.

Ул һәр отпускасын, колхоз башлыкларының күзләренә артык чалынырга теләмәсә дә, үз авылында үткәрде. Моның бер сәбәбе дә бар: авылда сигезенче класстан ук якын күргән, ә соңыннан инде үзе гыйшык тоткан кызы яши. Кыз ун класс бетерде дә шул ук авыл мәктәбендә пионер вожатые булып калды. Рәмзи аны үз янына КамАЗга ни чакырмасын, ул барасы итмәде, төрле сылтау табып, авылда яши бирде. Инде моннан ике ел элек Рәмзи авылга кайтып дәһшәтле бер хәбәр ишетте: аның Гөлфиясе әле язын гына институт бетереп шушы уку елында мәктәптә эшли башлаган бер укытучы егеткә кияүгә чыгып куйган. Кыз бу хыянәтен ни хат, ни кеше аша хәбәр җибәрмәстән эшләгән.

Бу яңалыкны ишеткәч, егет башын кая куярга белмичә, шашып йөрде. Тизрәк Чаллысына кайтып китте, калган отпускасын болагайланып шунда уздырды. Иптәшләреннән бер олырагы: «Ник исең китте шул кадәр, — диде ул вакыт, — кызлар алар шундый. Әгәр

йоклап торсаң, егетлегеңне күрсәтеп, җиләкне вакытында өзмәсәң, гел шулай була ул, алар сиңа төкермиләр дә. Үзең гаепле».

Бу кагыйдә Рәмзинең күңеленә нык сеңде. Ул шул көннән башлап хатын-кызга карашын бөтенләй үзгәртте, аларга карата күңелендә утлы нәфрәт саклап йөртә башлады. Хәзер ул хатын-кызны кеше булудан да бигрәк, бүтән җенес вәкиле буларак кына бәяли башлады.

Бройлер фабрикасына килеп төшкән көнне үк егерме җиде яшьлек егетнең күзләренә беренче булып хатын-кыз арасыннан Әлфия чалынды. Рәмзи аның шактый сирәк очрый торган гүзәллеккә ия бер кыз икәнлеген шундук чамалады. Терлекчелек белгече хайванның тышкы кыяфәтен ничек бәяләсә, ул кызгада шул рәвештә баллар куеп чыкты. Бу кемсәнең экстерьеры ярый торган, элита-рекордка туры килә. Буй-сын килгән, баш әйбәт утыртылган, күзләр якты, нурлы, эре, күңелне хушландырып, үзләренә тартып, нидер вәгъдә итеп карыйлар. Борын сөяктән юнып ясалгандай, иреннәр тәмләп үбешү өчен әйбәт. Муен артык нечкә дә, артык юан да түгел, үзе шактый биек, җилкәләр нәкъ хатын-кыз өчен килешле, правила кебек туры сызылмаган, ә көянтә кебек җай гына төшеп тулы матур кулбашларына тоташкан, үзләре киң дә түгел. Арка төп-төз, ә күкрәкләр тыгызланып югарыга ашарга торгандай күренәләр. Инде килеп, билгә күз ташласак, һай-һай уйнаклап тора торган нечкә бил. Ә янбашлар арасы җилкәдән киңрәк, аякларның тездән югары турылары хәйран тамаша, ләкин котсыз юан түгел. Кызның ботлары, аяк балтырлары тыгыз, килешле, бары да пропорциональ. Әйе, бу «чебеш» — хәтәр «чебеш», дип уйланды Рәмзи. Ярый, ярый, элита-рекорд. Ул Әлфиянең татармы, русмы икәнлеген чамаламаган иде әле. Тик кызның тышкы кыяфәте белән кызыксыну аңарда Әлфияне күргән саен арткannan-арта барды.

Әле Рәмзи фабриканың ашханәсендә бик тәмләп ашап утырганда ишектән Әлфия килеп керде. Кыз туп-туры Рәмзигә таба килә иде. Бу хәл егетне бөтенләй аптырашка калдырды. Ул арада Әлфия Рәмзи янына ук килде дә татарча: «Эти сезне көтә, тизрәк булыгыз», диде. Кулындагы тавык ботын кая куярга белмичә, авызын ачкан килеш калган Рәмзигә ул салкын, ят бер караш ташлады.

— Нинди «эти?» — диде Рәмзи берни дә аңламыйча.

— Профессор, — диде Әлфия, — кичә сөйләштегез бит. Шул. Рәмзи «хәзер» дип әйтергә өлгермәде, кыз җәһәт атлап, ашханәдән чыгып та китте.

Рәмзи берничә минуттан конторада, баш зоотехник кабинетында, профессор алдында иде инде.

— Я, сез әзерме? — диде Галиәкбәр.

— Әзер как будто.

— Әйдә, утырыгыз әле, — диде карт. Ул бүлмәдә ялгызы гына иде. Үзе Фәрит урнына утырды, Рәмзигә каршысыннан урын күрсәтте.

— Кичә уйланып яттым да сезгә аңлаткан методикага кайбер үзгәрешләр кертергә булдым, — диде ул. — Минә игътибар белән тыңлагыз.

Ул эшнең нидән торуын һәм нинди үзгәрешләр кертүен сөйли башлады.

Рәмзигә бу шактый кызык тоелды. Шуңа күрә үзенәниләр эшләргә туры киләчәген әле аңламаган хәлдә дә ул түземсезлек белән бирелеп тыңлады, профессорның командасын көтә башлады. Тик шулай да ул сүз арасында: «Эти, диде чибәр нәрсә, этисе белән кунакка килде микәнни? — дип уйлап алды. — Алай дисәң, ни өчен фабрика территориясенә кереп йөри?»

Ниһаять, бүлмәгә баш зоотехник килеп керде. Аның директор белән сүзе шактый җитди булгандыр ахры, күз карашында һәм үзен тотышында аңа хас булмаган таркаулык сизелә иде.

— Ничек, — диде Галиәкбәр, — читлектәгеләр һаман кимиме?

— Читлектәгенә әле кул да җиткәне юк. Ул эшне инде менә сезнең икегезгә ышанып тапшырырга кала.

Ул Рәмзигә мәгънәле бер караш ташлады:

— Эш аслык материал юклыктан катлаулана, ни туралган салам, ни пычкы чүбен кирәк хәтле табып булмый.

— Шулайдыр, — диде профессор, — Казандагы фабрикалар да интегәләр ул нәрсә аркасында.

— Моңарчы артык газап чикмәгән идек. Тирә-юньдәге колхоз-совхозлар тәэмин итәләр иде.

— Май белән эш ничегрәк тора? — дип сорады профессор.

— Хәзергә ярый. Технический майны Бөгелмә ит комбинатыннан алабыз. Тик...

Ул сүзен әйтеп бетермәде, телефон шалтырады.

Инкубаторда инде күкәйдән чыккан чебиләрне ни өчендер җиденче цех алмый иде. Фәрит, җиденче цех башлыгына хәзер үк эшкә керешергә фәрман биреп шалтыратты да карт белән Рәмзине читлектәге чебиләр урнашкан корпуска алып китте.

Рәмзинең фабрика территориясенә әле беренче тапкыр керүе иде. Ул ак кирпечтән салынган яссы түбәле тавык, чеби кетәкләренең күплегенә ихтыярсыз игътибар итте. Аларның һәрберсенә кызыл буяу белән номер сугылган. Юллар кардан арчыла башлаган инде, асфальт юллар зәңгәрсуланып ята. Кирпеч койма белән камалып алынган бу зур фабрика территориясенең аргы башында кызыл кирпечтән салынган ике катлы өй, аннан арырак җылыту үзәгенең моржасы һәм уңдарак, шулай ук тегe очта бетоннан эшләнгән силос, сенаж һәм үлән оны башнялары. Һәр корпус янында азык бункерлары. Территориянең өч ягында да койма аша куе нарат урманы күренә. Хәер, корпуслар арасында да агачлар бар. Төрле урында биек булып үскән төз, зифа наратлардан тыш юл читләрендә әле күптән түгел генә утыртылган яфраклы агачлар да җитәрлек. Чәчәклекләр, түтәл-клумба өсләре кардан әрчелеп килә инде. Җәй көннәрендә биредә, мөгаен, бик матур була торгандыр.

Төркем алга барган саен үсә торды. Күрәсең, Фәрит алдан ук әйтеп куйган. Корпуслардан чыгып, кешеләр әле һаман өстәлә бара.

Бераздан алар, шактый зур төркем булып, тәҗрибә уздырылырга тиешле корпуска керделәр. Һәм озакка сузмастан эшкә дә керештеләр. Тәҗрибәгә дигән чебиләр аерылды. Барысы да профессор күрсәткәнчә урнаштырылды. Бераздан барлык җаваплылыкны үз өстенә алган Рәмзи сынауга утыртылган чебиләр белән корпуста япа-ялгызы калды. Ул чебиләрнең шау-шуын тыңлап башта бер урында басып торды. Аннан читлекләр буенча китте. Юк, ул ялгыз түгел икән әле. Читлекләр артыннан аңа бер хатын якынлашты. Ул күптәнге кош караучы кызның алмаш операторы Елена Петровна икән.

— Менә шулай, — диде хатын, — сез яңа кеше, андый-мондый уңайсызлык килеп чыга калса, миңа әйтегез. Үзем булышырмын.

Рәмзи дәшмәде. Ул аннан башка да нишләсен белә. Бу аксыл кашлы тупас йөзле хатынның әле әйтер сүзе бетмәгән икән. Ул бик җитди рәвештә Рәмзи янына ук килде дә аның җилкәсенә кадәр төшеп торган куе коңгырт-кара чәченә үрелде.

— Бүләк ит моны, юкса, минем чәч сирәкләнде, коела, каһәр.

— Нигә, була, — диде Рәмзи елмаеп, — тик аны мыек белән бергә генә бүләк итеп була бит.

Хатын көлеп җибәрде:

— Андый нагрузка белән хаҗәте юк. Кибеттә дә җитәрлек ул, нагрузкалы дефицит товар.

Ул идарә пульты урнашкан алгы якка китте.

Рәмзи, бер кулы белән бөеренә таянган килеш үз алдына: «Менә сиңа пәрәмәч!» дип куйды. Читлекләрдә чиелдап утырган кара күзле сары чебиләрне тагы бер карап чыкты, аларның кайберсе читлектән башларын чыгарып азыкка үреләләр, икенчеләре автомат су эчергеч янында чират көтәләр иде.

Рәмзи ни өчендер тагы Әлфияне күз алдына китерде. Елмаеп куйды. «Кәеф нәмәрсә, чукынган җан», диде.

## 16

Самолеттан төшеп, үзенең Космонавтлар урамындагы квартира ишеге төбенә кайтып җиткәч, сулышы капкан Галиәкбәр бераз ял итеп алды. Өйдә беркем дә юк иде ахры. Профессор калтыранган бармакларын үзенә һич буйсындыра алмастан, юка әчкечне йозак ярыгына туры китерә алмый азапланды. Ахырда ишек ачылды һәм карт таныш, якын үз оясына килеп керде. Ишекнең уң ягындагы электр тоташтыргычка үрелде. Кабызгыч чакмасы шыртлап аска төшсә дә, ут кабынмады, лампасы янгандыр ахрысы. Картның моңа артык исе китмәде. Өске киемнәрен ярым караңгы коридорда салып металл аяклы элгечкә урнаштырды. Аннан туп-туры кухняга узды. Картны рәнҗетеп күзләренә ташланган беренче нәрсә кухня өстәлендәге юмаган савыт-саба булды. Аннары тешләп ташланган котлет кисәкләре, чынаяк-табаклардагы балык койрыклары... Әллә ничә көннән бирле юылмыйча, төбендә калдык чәе кибеп, каралып беткән, кыйммәтле, юка чынаяклар... Нәкъ өстәл уртасында кибеп, катып беткән башланмаган бер бөтен икмәк, ни өчендер кыл урталай киселгән, шулай ук катып беткән ак көмәч батоны. Кыскасы, өстәл пычрак тәлинкә, кашыклар һәм башка төрле-төрле кайчандыр Мәгъмүрә кадерләп кенә торган савыт-саба белән тулган иде.

Галиәкбәр газ плитәсенә күз ташлады, анда көйгән бәрәңге телемнәре тутырылган зур эмаль табадан башка берни дә юк иде. Һәр көн чәй кайнатыла торган ялтыр ак чәйнек ни өчендер идәндә, аш калдыклары салына торган чиләк янында, үзе корымга баткан. Ә чиләк исә өеп тутырылган, эчендәге әйберләр бозылган, аннан авыр, сәрсегән ис аңкып тора.

Галиәкбәр көн караңгысында ук директор машинасы белән аэродромга чыгып киткән иде. Хәзер исә исәбе Әлфия юлга биреп җибәргән ризыгын ашап, кухняда бер стакан чәй эчү иде. Юравынча, Сафура кайнаткан чәй әле суынмаган булырга тиеш. Тик чәйнек сапсалкын, җитмәсә кечкенә фарфор чәйнектән, күрәсең, беркем дә файдаланмаган, аның эчендәге чәй шулай ук кибеп, чәйнекнең төбенә ябышып каткан.

Картның күңеленә шөбһәле уй керде. Ул, Сафурага ул-бу булгандыр, юкса мондый ук тәртипсезлек хөкем сөрмәс иде, дип уйлады. Үзенең плитәгә чәй куярга ниятләнүен онытып, карт, аксый төшеп, олы бүлмәгә таба китте. Тик анда да кем дә юк, анда да җен аягын сындырырлык тәртипсезлек иде.

Кунаклар булганы күренеп тора. Аш өстәле бөтен зурлыгына ачылган, аның өстенә ак зур ашъяулык ябылган, ә өстәл өстендә исә савыт-саба, ашамлык калдыклары, тешләп ташланган торт һәм печенье кисәкләре, алма, груша...

Карт уң як стена буена куелган сервантка күз ташлады. Аның пыяла киштәләре буш иде. Димәк, Сафура савыт-саба юып азапланмаган, берсе пычранса, икенчесен алып кына файдаланган.

— Кеше түгелсендер лә син, кызый, — дип куйды Галиәкбәр, рәнжеп. Аның күзләренә идәндә яткан ике фужер һәм бер рюмка чалынды. Алар ватык иде. Пианино өстенә бер коньяк һәм биш озын муенлы вино шешәләре тезеп куелган.

Ул төнне өйдә ниләр булганын инде Галиәкбәр үз тәҗрибәсеннән чыгып күз алдына китерә ала. Ул ачуыннан бөтенләй хәлсезләнеп калды, авыраеп киткән аякларын көчкә өстерәп үз бүлмәсенә юнәлде. Биредә дә тәртип Галиәкбәр киткәндәгечә түгел иде. Аның язу өстәлендә ике фужер һәм конфет кәгазьләре ята. Кемдер аның китапларын актарган, алар үз урынында түгел. Әмма барыннан да бигрәк картның җанын әрнеткәне шул — аның ятагы туздырылган. Кемдер (ә бәлки кемнәрдер?) ятып аунаган. Карт бүлмәсен бикләп китмәгәнгә үкенеп куйды.

Галиәкбәр туздырылып ташланган урынын җыйды, өстәлдәге фужерларны зал якка чыгарып, вино һәм чәйгә буялып беткән эскәтер өстенә куйды. Үзе янадан бүлмәсенә кереп, пальто кесәсеннән полиэтилен капчыкка Әлфия хасиятләп салган ризыкларын чыгарды. Галиәкбәрнең тешләре хәзер элеккедәй нык түгел. Шуны исәпләптер, Әлфия әтисенә итнең дә, икмәкнең дә иң йомшак җирләрен генә салган. Карт моңа игътибар итми кала алмады. Рәхмәт аңа! Ул тамак ялгарга керește.

Эшне нидән башларга, дип уйланды ул. Хәзер үк Лианага китәргәме, әллә институтка сугылыргамы? Ләкин электричканы ике сәгать көтәсе бар иде әле. Димәк, башта институтка. Ул, ашагач, электробритва белән сакалын кырды, мыекларын төзәткәләде, пычрак керләр белән тулы юыну бүлмәсендә сукрана-сукрана авызын чайкады, кулларын юды. Соңыннан чиста сөлге тапмагач, кулъяулыгы белән сөртенеп шифоньердагы ару күлмәген киеп алды. Үзе аһ орып һаман Сафураның булдыксызлыгы турында уйланды. Прачечныйга гына илтеп бирәсе бит инде, аның өчен әллә ни азап та, вакыт та кирәкми, керләр барысы да тамгалы, прачечныйдагы кешеләр үз итеп, якын күреп торалар. Эх, егетләр! Булса да булыр икән!

Ул сукранса сукранды, мәгәр киенде, ясанды, галстугын такты, киемен щеткалады һәм, бүлмәсен тагы бикләргә онытып, өйдән чыгып китте. Баскычтан төшкәндә аңа күрше хатыны очрады.

— Безнең кыз исәндер бит? — дип сорады карт.

— Исә-ә-н,— дип сузды олыгая башлаган юан хатын һәм көлеп җибәрде: — типтереп кенә яши кызыгыз. Молодец!

Галиәкбәр ачуын яшерү өчен тамак кырып куйды. Урамга чыгып трамвай тукталышына таба юнәлде.

Профессор Галиәкбәр Максудовны институтта, чыннан да, көтәләр иде. Ул вестибюльгә кергәч, сулыш яңарту өчен, бераз тукталып торды. Институтта тәнәфес вакыты иде. Бик күп еллардан бирде каңга сеңгән таныш ыгы-зыгы хөкем сөрә монда. Исәнләшәләр. Кайберсен белә Галиәкбәр, кайберсе истә дә калмаган. Ә, менә болары бик якын үз кешеләр, мөгезле эре терлекләр кафедрасының мөдире, яшь профессор. Кайчандыр Галиәкбәр аның оппоненты булган иде. Ул ашыгып картка таба килә, ләкин ашыкканда да үз дәрәҗәсен белеп, тиешенчә генә вәкарь саклый. Менә килеп кулны кыса, дустанә елмаеп хәл-әхвәлне сораша, күңел өчен, сезгә әле Галиәкбәр Хафизович, җигелеп эшләргә иде ди, картның институттан китүенә үкенеч белдерә. Ул кала, башкалар очрый, исәнләшәләр, тукталып хәл, сәламәтлек сорашалар. Әйе, монда Галиәкбәрнең туган йорты, монда аны беләләр, тәкъдир итәләр, монда ул барлык хокукларга ия, кирәкле кеше.

Киң мәрмәр баскычтан күтәрелә башлау белән аңа үзенең кор-

дашы, РСФСРның атказанган фән эшлеклесе очрады. Ул Галиәкбәрне күрү белән үз итеп аның кулын кысты, иңбашына сугып алды.

— Юләрләрнең сүзен тыңладың, кордаш. Шулай ашыгып китәләрме соң, сине җигеп җир сөрергә була әле, — диде.

— Нишлисең, — диде карт шаяртуга шаярту белән җавап биреп, — җиһан юләрләр җилкәсендә тора ди бит, ничек аларны тыңламыйсың?!

— Синең полкташлар синнән башка хөрт көнгә калдылар. Хәзер алар җыелышларда телдән төшми, — диде ул инде җитди тонга күчеп.

— Зарар юк, олыгая-олыгая акылга утырырлар әле, —-диде Галиәкбәр елмаеп.

— Ну, ничек яшисең соң, ирекле казак? Рәхәт, тыныч булырга тиеш.

— Искиткеч! Пенсиягә чыгу бу кадәр дә әйбәт нәрсә дип һич уйламаган идем...

— Ну, бывай, — диде профессор. Аның кулында указка таягы, күрәсең, ул аскы каттагы аудиторияләрнең берсенә лекция укырга төшеп килә иде.

Галиәкбәргә монда бөтенләй җиңел булып китте. Ничектер аяклар да тизрәк йөргәндәй иде, гәүдә дә җиңеләеп киткәндәй. Ул, шаушулы студентлар төркеме арасыннан узып, бик-бик таныш, әле моннан ике ел элек үзе җитәкләгән кафедраның ишекләренә якынлашты. Башта ассистентлар бүлмәсенә сугылырга булды. Килгән-килгән, барысын да күреп китәргә кирәк. Тик бүлмә бикле булып чыкты. Бәлки доцентлар бүлмәсендәдер алар? Ләкин ул бүлмә дә бикле иде. Хәзер картка барысы да аңлашылды. Димәк, кафедра халкы мөдир бүлмәсендә. Анда киңәшмә булырга тиеш.

Галиәкбәр ялгышмаган иде. Чыннан да, мөдир кабинетында чираттагы кафедра утырышы бара икән. Картның керми чарасы калмады. Чөнки ул поездга соңга кала алмый. Галиәкбәр ишек какты. Эльвира Хәкимовнаның «керегез» дигәнен ишеткәч, эчкә үтте. Аның күренүе гомуми шатлык тудырды. Барысы да гүләп урыннарыннан куптылар. Юк, бу ясалма кылану түгел иде, бу ихлас күңелдән картка күрсәтелгән хөрмәт һәм бәлки әле, сагыну билгесе дә булгандыр. Ләкин ни булса да үзен болай якты чырай белән каршы алу Галиәкбәр өчен бик тә күңелле иде. Берәм-берәм кул кысып исәнләштеләр, урын тәкъдим иттеләр. Хәтта берсе: «Мин Галиәкбәр Хафизовичның түр башына утыруын теләр идем, ичмаса рәхәт чаклар искә төшеп китәр иде», — диде. Аңа каршы Эльвира Хәкимовна көлә-көлә: «Мин рәхәтләнеп һәм бөтенләйгә үз урынымны Галиәкбәр Хафизовичка бирергә риза», — диде. Бусы ихластан әйтелгәндерме, ләкин барыбер күңелгә май булып ягыла торган сүзләр иде.

— Сез мине, гафу итегез, — диде карт, — эшегезне бүлдердем булса кирәк.

— Һич бүлдермәдегез! Утырыгыз, — диде Эльвира Хәкимовна. — Безнең тикшерәсе төп мәсьәлә нигездә хәл кылынды инде, хәзер киңәшмәне япсак та була. Мин сезне бик-бик көтә идем.

Өстәл кырыендагы утыргычка урнашкач, Галиәкбәр тирә-юньдәге сагындырган кешеләрне тагы бер тапкыр күзеннән кичерде. Ул арада Эльвира кулларын кресло таянсаларына куеп үзе креслосыннан күтәрелә төште.

— Бүгенгә шуның белән туктатабыз, тагы кайчан җыеласын алдан әйтермен, — диде. — Сез китә аласыз. Мине гафу итегез, минем Галиәкбәр Хафизовичка конфеденциаль сүзләрем бар.

Мөдирәнең кыяфәте җитди, аның үзен хуҗа итеп сизүе ачык ярылып ята. Монысы Галиәкбәргә ошамады. Аныңча, башлык җитәкче

икәнлегән поза, тавыш белән сиздерергә тырыша икән, ул инде чын житәкче түгел.

Сотрудникларның Галиәкбәрдән аерылып чыгып китәселәре килми иде. Алар хәл-әхвәл сораштыра башладылар. Ләкин, ничшләмәк кирәк, Эльвираның әмерен башкармыйча булмый, алар, эленке-салынкы гына булса да, Галиәкбәр янында туктала-туктала чыгып беттеләр.

Эльвира үзе барып ишекне бикләде. Комачауламасыннар әле, диде һәм, яңадан урнына утырды да, мөлаем бер елмаю белән картка текәлеп, сүз башлады.

— Мин сезне көтә-көтә, Галиәкбәр Хафизович, көт булдым инде. Өегезгә ничә тапкыр шалтыраттым. Сезнең кызыгызны да борчып бетергәнмендер инде. Зинһар ул миңа ачуланмасын, әйтегез.

Моңарчы Эльвира һәрвакыт Галиәкбәр белән русча сөйләште. Хәтта татарча дәшкәндә дә ул рус телендә җавап кайтара торган иде. Шуңа күрә профессор бу ханымны, татарча белми яки бик начар белә дип, үзе дә русча гына сөйләшә башлаган иде. Күрәсең, бу очракта Галиәкбәргә аерата зур хөрмәт күрсәтүедер, аның белән ана телендә сөйләште.

— Мин әле генә кайтып төштем, — диде Галиәкбәр. — Кызымның хаты буенча кайттым. Ул хатында сезнең мине күрергә теләвегез турында да язган. Аның хатыннан сезгә карата алай ниндидер үпкәләүфәлән тоймадым мин.

— Алайса бик әйбәт, — диде Эльвира житди бер кыяфәткә кереп. Аның йөз чалымнары шул дәрәҗәдә кискен иде ки, ул бер халәттән икенчесенә күчкәндә бөтенләй үзгәрә иде. Көлсә артык көләч кыяфәткә керә, житдиләнсә шулай ук артык житди бер төс ала. Аның киң маңгае, күпереп торган матур шевилюрасы, борыны өстендә кушылып киткән кап-кара кашлары, кылыч борыны, чак алгарак чыккан очлы ияге һәм хәтта колагындагы зур алкалары аны, гыйльми хезмәткәрдән бигрәк, чегән труппасының берәр солисткасына охшаталар иде. Галиәкбәр бер нәрсәгә игътибар итте. Бу ханым ашыгыч күзгә ташланганда гына сокланырлык матур икән, ә һәр йөз чалымсызыгына игътибар белән карап торсаң, гаҗәп хәл, ул әкренләп үзенең матурлыгын җуя башлый. Мондый кешеләр гадәттә сурәткә матур булып төшәләр. Аларны фотогеничный диләр.

— Мин үземне бу утенечне әйтергә хаклы дип исәплим, — дип сүз башлады Эльвира, — чөнки мин сезнең оядан очып чыккан кош. Сезнең кул астында озак еллар эшләп аякка баскан кеше...

— Тыңлыйм сезне, Эльвира Хәкимовна, — диде Галиәкбәр сагая төшеп.

— Беләсезме нәрсә, — диде кинәт янгыравык югары бер тонда доцент. Ул хәзер сүзне рус телендә алып бара башлады. — Мин бөтенләй ялгызлыкта калдым, Галиәкбәр Хафизович. Аңлыйсызмы, ялгызлыкта... ком чүлендә адашкан бер юлчыдай.

— Нигә алай дип уйлыйсыз? — диде карт йомшак кына.

— Шулай. Менә күз алдыгызга китерегез, докторскиемны тапшыру вакыты дәһшәтле бер кызулык белән якынлаша, ә мине шик-шөбһәләр зынҗыры көннән-көн ныграк буа. Беркем, беркем ярдәм кулы сузарга уйламый.

— Ничек инде ул алай? Сезнең бит Мәскәүдә консультантыгыз бар. Ул зур галим. Хәтеремдә, докторлыкны яклаганда ул минем оппонентым иде... Членкор.

— Әйе, ул минем эшемне карап чыкты. Үзенең искәрмәләрен дә ясады. Ләкин мин бит инде аны гел борчып йөри алмыйм, инде бул-

ганмы, әйтегез, Георгий Спиридонович, дип абынган саен диссертациямне аның алдына куя алмыйм.

— Сезнең биредә кафедра бар. Коллектив. Алар акны карадан аералар.

— Алар миңа дөресен әйтмәячәкләр, — диде Эльвира өметсез бер кыяфәт белән.

— Ничек инде? — диде, бик аптырап, профессор.

— Безнең кафедрада хәзер болганчык чор башланды. Брожение.

— Бу ни дигән сүз? Мин аңламыйм, Эльвира Хәкимовна!

Эльвира урыныннан торды да өстәл артыннан чыгып Галиәкбәр янына барып басты. Кулын сак кына профессорның иңенә тидереп алды.

— Кайтыгыз кафедрага, Галиәкбәр Хафизович, алла хакы өчен кайтыгыз. Мин менә бүген үк сезгә урнымны бушатам, теләсәгез хәзер үк ректорга үтенеч язып кертәм. Бары бер нәрсәне генә үтенәм сездән: минем диссертациямне карап чыгыгыз. Үзегезнең әйбәт, акыллы бәйләнчеклегегез белән ярдәм итегез, миңа киңәшләр бирегез. Мин сезне шул үтенечемне әйтер өчен зарыгып көттем.

Карт башын селкеде.

— Бик теләгән хәлдә дә, мин сезнең бу үтенечегезне башкара алмам кебек, Эльвира Хәкимовна.

Хатынның кискен карашы тагы да кискенләшә төшкәндәй булды.

— Ни өчен?

— Һич сезгә яхшылык эшләргә теләмәүдән түгел. Эш шунда, миңа хәзер гомумән җитди нәрсәләр уку бик авыр. Җөмләләр бутала, фикерләр чуала, бер үк абзацны кабат-кабат укырга туры килә, — Галиәкбәр көлеп куйды, тел шартлатты.— Менә шулай. Аннан тагы икенче бер сәбәбе дә бар, ул, хәзер буш вакытымның булмавы. Сезгә минем кызым Сафура әйткәндер, бәлки. Мин бит вакытлыча кече кызымда Кама буенда кунакта ятам. Шунда миңа эш йөкләнде. Дөресрәге, үзем йөкләдем ул эшне үземә.

Доцентның гаҗәпсенеп берни дә аңламый карап торганын күргәч, профессор шәрехләбрәк сүзен дәвам иттерде.

— Кызым минем Кама бройлер фабрикасында эшли. Хәтерегездә булса, мин бер вакыт бройлерлар өчен безнең конкрет шартлардан чыгып ашату нормалары, аларны асрау режимы нормалары эшкәртеп маташкан идем. Ул чакны бу оригиналь нормалар производство шартларында тикшерелмичә калды. Хәзер шул эшне гамәлгә ашырырга мөмкинлек таптым.

— Кызык ул, — дип куйды Эльвира күзләрен очкынландырып. — Мин сезнең институт шартларында уздырган тәҗрибәләрегезне хәтерлим. Тик шулай да, минемчә, болар әле сезнең мине кызганмыйча ялгызлыкта калдыруыгызны аклый алмаячак, кадерле Галиәкбәр Хафизович.

Профессор хатынның шаяртуын аңласа да артык туарылмады, доцентка җитди генә карап торды. Ул арада поездны хәтерләп, сәгатенә күз ташлады, вакытның аз калганын белгәч, кабаланып урыныннан торды.

— Гафу итегез, мин оньк кызым янына Займищега китәргә тиеш. Мин кузгалдым. Ә сезнең үтенеч турында мин уйлармын һәм үземнең карарымны иртәгә иртәнге сигезләрдә өй телефоныгызга шалтыратып хәбәр итәрмен, чөнки мин иртәгә өйләдән соң Кама буена очам.

## 17

Тау башындагы нарат урманына салынган ике катлы зур агач өйгә кергәч, Галиәкбәр балаларның әле аштан соңгы йокыдан уянмаганлыгын белде. Коридорлар киң, якты, идәннәргә линолеум җәелгән, стеналарга беркетелгән фаянс савытларда гөлләр чәчәк атып утыра. Стена буйларында кечкенә генә утыргычлар, һәр диварда әкият каһарманнары ясалган сурәтләр. Бөтен тирә-юнь, әле беркем күренмәсә дә, монда балалар йорты икәнлеген ачык сөйли иде. Бина эчендәге чисталык күзгә ташланып тора. Һавасы — әйбәт һәм саф, урман һавасы.

Галиәкбәр директор кабинетының кайда икәнлеген онытмаган иде. Ул туп-туры шунда юнәлде. Яшь кенә, ләкин, күренүенчә, бик кыю һәм эшлекле хатыннан ул, балалар белән очрашу көне булмавына карамастан, Лиана белән күрешергә рөхсәтне тиз алды.

Директор рөхсәт биреп кенә калмады, бүлмәсенә Лиана группасының тәрбиячесен дә чакыртты. Тәрбияче хатын ничектер дорфарак булып тоелды профессорга. Шулай да картларга хас сабырлык белән ул ашыгыч нәтиҗәләр ясарга теләмәде. Лиана турында, аның ашавы, йокысы, сәламәтлеге турында сораша башлады. Алар нинди-дер эш белән мәшгуль директорга комачауламас өчен коридорда бәләкәй утыргычларга утырып сөйләштеләр. Гомумән начар түгел иде биредә, өстәвенә, мөрәббиянең әйтүенә караганда, Лиананың, Сафура язганча, бер тапкыр да ятып авырганы булмаган. Ул көр, ярыйсы гына ашый, йокысы да зарланырлык түгел. Тик менә әнисен сагына. Әйе, ни өчен аның әнисе бер дә килми, узган ял көнне дә булмады ул, аннан элек тә.

Әйтерсең, моңа Галиәкбәр гаепле иде. Тәрбияче хатын батырып, җыерчыклы кабаклар эченә яшеренгән, сөзеп карый торган күзләре белән картка текәлде. Галиәкбәр ихтыярсыздан күзләрен яшерде, башта, ни әйтергә белмичә, тамак кырып куйды, аннан:

— Әнисе дә аның бик мәшгуль кеше бит, — дип мыгырданды, — иртәдән кичкәчә эштә, командировкаларга да...— Ул алдашуын дәвам иттерә алмады. Хатын аны бүлдерде.

— Сез бит әле менә оныгыгызны сагынып әллә кайлардан да кайткансыз.

— Мин бит ул, — диде Галиәкбәр ничектер кызганычрак рәвештә елмаеп.

— Менә шул шул. Яшь аналар...

Кинәт Галиәкбәр пышылдап кына кемнеңдер «давати» дип үзенә дәшкәнен ишетеп калды. Ярым ачык ишектән күп тапкырлар юылып искерә төшкән буй-буй саргылт пижама кигән, тузгыган чәчле Лиана карап тора иде. Галиәкбәр, оныкызын күрү белән, чайкала-чайкала тәбәнәк җайсыз урыныннан торды, ашыгып сары песнәгенә таба атлады. Лиананың бабасына шыпырт кына дәшүе, аның өстендәге иске пижамасы картта оныгына карата чиксез кызгану тойгысы уятты. Ул күзләрен яшь элпәсе каплау, тамагына төер тыгылу аркасында ачык берни дә әйтә алмады. Лиананы күтәреп күкрәгенә кысты, аптак битләреннән үбеп алды, бераздан соң гына тынычлана төшкәч телгә килде.

— Ай, минем Лианам, сары песнәгем, мысыр күгәрченем.

Лиана кыюлана төште, сорады:

— Ә син үзең генә килденме, давати?

— Үзем генә, кызым.

— Әни килмәде, ийе?

— Ул килер әле, кызым, бүген бит эш көне, ул эштә.

Лиана артык бу турыда сүз катмады, күрәсең, хәсрәтен йотарга өйрәнгән иде инде, сүзне икенчегә борды.

— Син миңа нәрсә алып килдең соң? — дип сорады.

— Лиана, Лианочка, син башта пижамаңны салып өс киемнәреңне киеп чык, аннан соң бабаң белән булырсың, аңладыңмы? — диде тәрбияче.

— Шулай ит, кызым, шунда мин сиңа күчтәнәчләремне дә бирермен, — диде Галиәкбәр, кызчыкны сак кына идәнгә төшереп.

— Мин киенгәндә син китмә, — диде Лиана бик җитди үтенеп.

— Нишләп китим, кызым, мин синең яныңа килдем бит.

Апасы да әйтте:

— Син әйбәтләп киен дә бабаң белән кичке ашка кадәр бергә булырсың.

Көтелмәгән шатлык балага әле яңа гына барып җитте, ахры, ул көмеш кыңгыравыктай чыңлап бер көлде дә, йоклап яткан иптәшләре янына кереп китте.

— Әнисенә әйтегез, Лианага чана китерсен. Бездә әле кар әнә нык ята, — диде хатын. — Монда алар бик күңелле итеп тау шуып уйныйлар. Барлык баланың әти-әнисе чана китерде, ә Лианага китерүче юк. Иптәшләре таудан чанада шуганда, бу бичара чабуына утырып шуа, я читтә тик туңып тора.

— Әйтәм, әйтәм, — диде Галиәкбәр, — бәлки әле үзем китерергә дә өлгерермен.

— Шулай итегез.

— Ашау ярыйсы булса кирәк, менюны карадым,— диде Галиәкбәр.

— Ашау начар түгел. Бер иш баланы ашата алмый гаҗиз булабыз. Өйләрен сагыналар. Ностальгия.

— Һәм шул аппетитка тәэсир итәме? Шулайдыр.

Тиздән өс киемнәрен күтәреп Лиана коридорга бабасы янына чыкты. Аларны киендереп, чәчләрен тарарга тиеш булган няня, балалар йоклаган арада, каядыр киткән иде. Шуңа күрә бу эшләрне тәрбияче үзе башкарды. Чәчен тарап, бантик бәйләде һәм Лианага мех киемен, мех башлыгын, киез итекләрен кидерткәч, аны бабасына тапшырды. Астагы тышкы ишеккә кадәр үзе озата төште. Баскыч астындагы чоланны ачып, җиңел, дюраль чана бирде.

— Моның хуҗасы әле кәефсезрәк, изоляторда. Сез хәзергә шул чанада шуыгыз, — диде.

Юк, Галиәкбәрнең беренче тойгысы хатарак булган, ахры, бу төксерәк күренгән хатын бик кешелекле, әйбәт булып хәтергә сеңде.

Карт бер кулына чана тоткан килеш, икенчесе белән Лиананы җитәкләп санаторийның ишегалдына чыкты.

Язгы кояш төшлектән шактый авышкан булса да, көн җылы, якты иде. Кызчык белән карт каршыдагы түгәрәк беседкага кереп утырдылар. Лиана ни өчен анда кергәнлекләрен сизенә иде ахры. Ул балаларча яшерен-батырынсыз дәү әтисенең уртадагы өстәлгә нинди мәмәйләр чыгарып саласын көтте. Галиәкбәр исә башта өстәлгә кызыл кикрикле әтәчләр, тавыклар сурәте төшерелгән зур шоколад плиткасы чыгарып салды. Лиана шатлыгын яшерә алмастан тагы кыңгыравын чылтыратып алды. Күрәсең, бала, әти-әниләре башкаларга тәмле әйберләр китергәндә шактый нәүмизләнеп кимсенә торган булгандыр. Ул шоколадны шатланып күкрәгенә кысты. Бабасы серле генә елмаеп күз кысты.

— Әле бетмәде, — диде, ике кесәсеннән ике түм-түгәрәк кызгылтсары апельсин чыгарып салды. Казанда мондый нәрсә бик сирәк була. Бәхеткә каршы, апельсин Галиәкбәргә бүген самолетка утырыр алдыннан аэродром ресторанында очрады. Мондый да тәмле әйбер-

ләрне күргәч, Лиана инде хәзер бәхетнең җиденче катында иде, ул рәхәтләнеп чыркылдап көлә башлады.

Лиана бик юмарт иде. Ул шоколадын ачты да аның берничә бүлемтәсен сындырып башта бабасына сузды.

— Бусы сиңа, давати.

Күпме кирәк карт кешегә. Шул бәләкәй генә яхшылык та Галиәкбәрнең тагы күзләрен яшь белән каплады. Лиананың күңеле өчен шоколадны әз генә китеп капты, калганын кызының нәни авызына сузды.

— Монысы здачасы.

Алар күңелле итеп, дөньяларын онытып, шат һәм бәхетле кешеләр булып, гөр-гөр сөйләшеп утырдылар. Лиана шоколадының яртысын гына ашады, калганын дус кызы Фәридәгә калдырып, апельсинга кереште. Аның да ул яртысын ашады, калганын иптәшләренә күрсәтергә һәм иптәшләре белән бүлешеп ашарга булды.

Галиәкбәр ирексездән: «Кем өйрәткән аны шундый булырга», дип уйланды. Хәтерендә, әнисе нәкъ шундый чагында булса кирәк, артык комагай иде. Тигез итеп бүлеп биргәндә дә Әлфиягә бирелгән өлеш аңа күбрәк булып күренә, аның хәтерен калдыра иде. Белмәссең, дип уйлады Галиәкбәр, кеше дигәнең катлаулы йомгак, очына чыгып житмәслек серле тирәнлеккә ия нәрсә.

Алар беседкадан чыгып, капкага таба юнәлделәр. Ә алда, ап-ак кар белән өртелгән кояшта ялтырап яткан сөзәк таулар, урман һәм саф зәңгәр һава иде. Кояш кар өсләрен эретеп чәрдәкләндергән. Көне буе кояш нурларын йоткан нарат урманының җылы сулышы еraktан ук сизелә.

Капкадан чыгу белән Галиәкбәр кечкенә көрпәне чанага әйбәтләп җаеп куйды да, кызына: «Яле, утыр әле», диде. Лиананың хәзер куанычтан күзләре генә көлә иде. Ул, һаман шул күзләрен очкынландырган хәлдә, артлы чанага менеп утырды һәм рәхәт минутлар кичерәсен өметләнеп дәүәтисенә текәлде. Я, хода, моны, сабыйның шатлыгын, куанычын тоймый идеме соң карт! Гомумән бала кешегә, ә аерата үз баланның баласына, шатлык бүләк итүдән дә күңеллерәк нәрсә бар микән әле дөньяда?! Галиәкбәр, аяклары авыртуын да тоймыйча, әлдертеп Лиананы ялтыр, шома юл буйлап урманга таба алып китте.

Ниһаять, тыны кысылудан карт артык бара алмас булды. Авызын көпшәкләндереп сулый-сулый туктап торды. Ләкин аның да йөзендә шатлык, көләчлек уйный иде. Рәхәт авырлык, шатлыклы газап иде болар барысы да.

— Хәзер таудан шуабыз, — диде ул кызына. — Шуабызмы?

— Шуабыз.

— Минә шушы таудан курыкмассыңмы?

Бала курыкмаячагын белдереп башын боргалады.

Алар барган юлдан уң яктарак аска таба чана эзләре сузылган, монда балаларның тау шуганлыклары ачык.

Галиәкбәр чана бавын Лианага тоттырды да аны шактый нык уелган эз буенча сак кына этеп, аска төшереп җибәрде. Лиана көлә-көлә таудан аска төшеп китте. Аңа бик рәхәт иде, ләкин Галиәкбәргә шулай да тау текәрәк булып күренде, бала егылып имгәнмәгәе дигән куркыныч уй узды башыннан. Ләкин барысы да әйбәт булып бетте. Лиана, аста, әллә кай ераклыкларга кадәр чанасында шуып барды да тукталгач төшеп, бабасын тагы чакыра башлады.

— Әйдә, әйдә, мен, кызым, мен! — дип кычкырып карады карт. Ләкин Лиана тауга каршы ун адымнар чамасы гына барды, аннан туктап, бөтен көченә кычкыра-кычкыра бабасын чакыра башлады.

Берәр җирен авырттырган ахры, балакай, дип уйлады Галиәкбәр, тайгак юлдан шуа-тая чатанлап аска таба китте.

Төшеп житкәч белде: Лианага чана тартып менү авыр икән, шуңа күрә дә ул ярдәмгә бабасын чакыра.

— Болай булмый, — диде Галиәкбәр, — шуарга яратасың икән, чана сөйрәргә дә иренмә.

Алар икәүләп буш чананы көч-хәл белән өскә сөйрәп алып менеп киттеләр. Әйе, бу зур таудан шуып уйнауга караганда, ишегалдындагы, такталардан корылган, өстенә боз катырылган таудан шуу кулайрак иде. Алар санаторий ишегалдына кайтып калган вакытны шунда уздырдылар.

Галиәкбәр Казанга кичке поезд белән кайтты. Ул барыбер Сафураны өйдә очратмады. Кызый тагы берәр ахирәтендә кунып калгандыр, ахры, дип уйлады ул.

## 18

Ләкин карт ялгыша иде. Аның кызы Сафура бу юлы да, моңарчы бик күп тапкырлар булган кебек, үзенең Димкасында иде.

Ни өчен Сафура егетен аулак иркен квартирына чакырмады? Моның ике сәбәбе булды. Беренчесе: өйдә тәртип урнаштырылмаган, егет чакырырлык хәлгә китерү өчен савыт-саба юып, кием-салымны, урын-җирне урнаштырып, ким дигәндә, ярты көн маташырга кирәк. Ни әйтсәң дә, Сафура яхшыдан яманны аера белә. Аның кеше алдында яхшы булып күренергә теләве дә кешенекеннән ким түгел, артык ук булмаса...

Икенче сәбәп: күршеләр күзенә чагылудан курку. Ягымлы, ачык чырайлы Мәгъмүрә заманында күршеләр белән дуслашып, үз булып бетелде. Әле хәзер дә алар, иске гадәтләре буенча, бу сигезенче квартира бусагасын онытмыйлар, кирәкме, кирәкмиме, йомыш белән дә, йомышсыз, бары хәл белү өчен дә, киләләр дә керәләр, җитмәсә, җәелеп рәхәтләнеп сүзгә керешәләр.

Җене сөйми иде шундый ачык чырайлы, лыбырдык хатыннарны Сафура. Мәгәр караңгы чырай күрсәтергә дә, берәм-берәм хурлап куып чыгарырга да аның кодрәтеннән килми. Белмәссең, бер булмаса бер кирәкләре чыгуы ихтимал. Аннан кара гайбәтне дә өнәми Сафура.

Сәбәпләр җитди иде. Шуңа күрә ул, егете белән ятак бүлешергә ни кадәр генә теләмәсен, аулак өй була торып та, әтисе киткәннән бирле Диманы өйгә алып кайта алмады. Хәер, кунаклар арасында Дима булмый түгел. Сафура әтисе киткән көнне үк кунак җыйды. Аннан иптәш кызының туган көне мәҗлесен тагы Сафурада уздырырга туры килде. Анда да Дима булды. Тик башкалар белән бергә килде, башкалар белән бергә кайтып та китте. Сафура аңа стеналарның да колагы, күзе бар, мөмкин түгел, диде.

Инде Сафура белән аулакта кунар өчен Димага иптәшеннән күрше егетләрдә кунып торуын үтенергә туры килде. Иптәше эшнең серенә шундук төшенде.

— Тик бәйрәм ашы кара-каршы, аны бел, — диде.

Дима бер кулын өскә күтәрә төшеп, күз кысты.

— Бетте, нәкъ син теләгәнчә булачак!

Сафура эштән кайткач та аны Дима «Акчарлак» ресторанына алып китте. Анда варьете карап, артык исермичә генә, виноград шәрабыннан аз-маз авыз иткәләп утырдылар. Димка Дербышка поселогында яши иде. Автобустан төшкәч, язгы төннең исерткеч җылы һавасын тоеп, әкрен генә сөйләшә-сөйләшә Дима яшәгән буйдаклар торагына юнәлделәр.

Төн шунда узды. Сафура уянып киткәндә көн яңа гына яктыра башлаган иде. Сафура Димка муены астында калган кулының оюына түзмичә уянды. Ул, егетен уятмас өчен, кулын аның муен астыннан сак кына чыгарды да, ятакта утырган килеш, агачка әверелеп сиземен югалткан беләген уарга кереште. Бармакларга бераздан җан керә башлады, аларга хәзер чиксез күп вак инәләр кадалгандай иде. Әкренләп ул да узды. Аннары ул тәрәзәдән тонык яктылык төшкән Димканың аксыл чәчле зур, матур йөзен, ап-ак шома маңгаен, киң ияген, сузынкы нык муенын елмаеп күзәтеп торды. Егетнең йөзе генә түгел, ачык күкрәк мускуллары, тыгыз атлет гәүдәсе дә һәйкәл матурлыгына тиң иде.

Сафура рәхәт йокыда яткан Димкага шулай, һаман әле елмайган кыяфәттә, сокланып карап торды да, ялан тәпи килеш кенә, пәрдәләре төшерелгән тәрәзә янына барды. Бәләкәй өстәл җыелмаган килеш калган иде. Әйе, Сафура хәтерли, алар әле торакка кергәч тә ресторанннан алып кайткан виноны эчтеләр. Әзләп, әзләп кенә эчелсә дә, шактый исерелгән иде шул. Сафура форточканы ачты. Бераз вакыт тыштан бөркелеп кергән сәрин һаваны сулап торды. Суык һава ничектер чиркандырып җибәрде. Ни әйтсәң дә, әле март кына, шактый суык һавалы ай.

Сафура, иңенә йон кофточкасын салып, бераз кулбашларын, терсәкләрен угалап җылынганнан соң, оекларын кия башлады. Күзе капрон оегының сүтелеп киткән бер җиренә төште, йөрәге жу итеп китте. Кайчан булган бу хәл? Ничек сизми калган ул аны? Яңа оек алырга кирәк. Ә акча юк. Димкадан сорарга? Бу эш тә мөмкин түгел. Әле дә инде бичара ничек зарплатага кадәр яшәр. Аның соңгы сумнарына алынды бит кичәге «Үгез каны» исемле вино.

Сафура төз, матур аякларына оек кигәч, утырган урнында хәрәкәтсез калды. Кинәт үзен бурап алган караңгы, күңелсез уйларга чумды. Уйларының җеп очы оек алырлык та акчасы булмаудан башланды, ләкин бу болганчык уйлар дәрьясының субашы гына иде әле. Тора-бара ул тирәнәйде, киңәйде, тормышның бик күп якларын, ярны ашап агывып алып киткән су агымыдай, үзе белән барысын да бергә агыза башлады. Бераздан ул башындагы уйларын, үзе дә сизмәстән, пышылдап телдән сөйләргә кереште.

— Син Софа (ул үзен Сафура дигәнне яратмый иде), бу дөньяга вызов ташладың. Ни өчен? Чөнки син үзеңне аңардан көчлерәк итеп тойдың. Я нәрсә килеп чыкты соң инде? Матур егетләр сокланып карый торган матур аякларыңа лаеклы оек алырлык та акчаң юк. Менә шул булдымы нәтиҗә?

Ул үзеннән-үзе, нишләргә кирәк соң, дип сорады. Нәкъ бик күп мәхлукләр кебек бөкереңне чыгарып эшләргәме, яшьлекнең, инде озакламый шиңеп саргаячак яшьлекнең, соңгы көннәрендә матурлык, гүзәллек чорының бары бер генә тапкыр була торган рәхәтеннән ваз кичәргәме?

Юк, мондый юл да Сафурага кулай түгел иде. Ни өчен? Чөнки ул аны теләми. Менә ни өчен. Бу дөньяга килгән кеше үзе теләгән нәрсәсен эшләргә хаклыдыр бит! Әллә андый дөнья юкмы? Әллә адәм баласы туганнан үлгәнгә кадәр «ни телим» формуласы белән түгел, «дөнья ни куша» формуласы белән яшәргә тиешме? Әйе, әгәр мин бу тирә-юнемдәге чынбарлыкка вызов ташлаганмын икән, ул бит бик табигый хәл, ул просто кешенең инстинктив рәвештә хөрлеккә ашкынуы. Идиот хөрлекнең нәрсә икәнен белми, ә чын кеше белә!

— Белүен белә, — дип куйды ул, уйларыннан тагы пышылдауга күчеп, — ә оек алырга акча юк.

Ул үз алдына ямьсез итеп, ачы итеп елмаеп куйды. Юк, бары да җимерелде, хәзер артык начар иде аның кәефе. Ярым шаян, ярым

зәһәрле бер тонда: «Ичмаса берәр баерак бәндә белән флирт оештырырга да туры килмәде бит, — дип куйды. — Мәсәлән, минем министр агай белән. Ха-ха-ха».

Ул һаман әле тирән йокыда яткан Димага тагын елмаеп карап куйды. Ул хәзер йөзен яктыга, Сафурага таба борган, авызын чак кына ачкан, мендәрендә тап. Сафура болай да артык өнәмичә караган иде егетенә. Инде Диманың селәгәй агызып йоклавын күргәч, бөтенләй җирәнеп борынын җыерды.

Сафура ашыга-ашыга күлмәген кия башлады. Стенадагы көзге янына килеп чәчен тарады. Кашларын-керфекләрен төзәтте, юынмаган булса да, гадәткә буйсынып, битенә пудра якты, иреннәренә саргылт помада сөртте. Барлык нәрсәсен барлап, итәгенә мех тоткан, кеш якалы көрән пальтосын өстенә кигәч, ул Дима янына килде.

— Әй, Димка! Күзеңне бер генә минутка ач әле. Мин китәм.

Дима борынын кысып тоткач кына, тыны бетүдән уянып китте. Алдында Сафураны күргәч, елмая башлады.

— Син нәрсә, Софа?

— Кайтам. Эшкә барасы бар.

Егетнең әле тагы сөеклесе куенында иркәләнәсе килгән иде, ул ризасызлык белдереп:

— Әле бит иртә, нәрсә шул кадәр ашыгасың, — диде.

— Хуш, — диде Сафура, егетнең мендәргә таралган аксыл тузгак чәчләрен учында дуылдатып. Аннары ишеккә таба китте.

— Вот җен, — диде Дмитрий үз алдына көлемсерәп. Борылып яктыга арты белән ятты һәм тагы гырлап йокыга китте.

Сафура иртә тордым дип уйласа да ялгышкан икән, урам эшкә баручылар белән тулы иде. Ул, завод, фабрика төтеннәре күрми яши торган, бер ягын ылыслы, икенче ягын яфраклы агачлар урманы әйләндереп алган гүзәл поселокның саф һавасын үзенә бер рәхәтлек тоеп сулый-сулый автобуслар тукталышына таба ашыкты. Анда халык күп иде. Сафура автобусның икенчесенә генә эләкте. Өйгә кайтып ишекне ачу белән, кухняда кемнеңдер кыштырдавын ишеткәч аптырап калды. Чишенгәнче үк кухня ишеген ачып карады. Әтисен күргәч, хатынның йөзенә шатлык билгесе чыкты. Карт краннан чәйнеккә су агызып маташа иде.

— Кайчан кайттың? — диде Сафура.

— Ә, исәнме. Кичә үк кайткан идем.

Сафура әтисенең өстәл өстендәге пычрак савыт-сабага күз ташлавын күрү белән контр удар әзерләргә җыенды. Тик өлгермәде, әтисе:

— Кая булдың? — дип сорады, — Лиана сине сагына, әнә шунда барып кайтырга кирәк иде, ичмаса.

— Нигә, синең өчен минем кайда кунуым барыбер түгелмени? Безнең нинди хәлдә яшәвебезне белә торып та Әлфиягә китеп барганда без барыбер идек ич.

Галиәкбәр кызының алымын яхшы белә иде. Андый-мондый хәвефле хәл кӛтелсә, ул шулай һөҗүмне үзе башлый. Җаен таба. Күрәсең, ул шулай акландым дип уйлый. Мәгәр карт барыбер савыт-саба турында әйтергә булды. Ләкин тагы Сафура беренче буларак ударны ясап өлгерде.

— Кичә кайттым дисең, эти. Ничек итеп, бер тиенлек эшең булмаган килеш, бу өстәлләрдәге тәртипсезлеккә түздең. Ичмаса, әкрен генә кыймылдасаң да бу посуданы бер көн эчендә юып бетергән булыр идең.

— Син пычраткансың, син ю инде, кызым. — Галиәкбәр әле кичә генә Лиана белән чана шуып уйнаганын хәтерләдә. — Чана шуарга яратасың икән, чана өстерәүне дә өнә.

— Бу бик банально, эти. Мин синең урында хет эз генә шәфкатьлерәк, юмартрак булырга тырышыр идем.

Картның ачуы килде. Ләкин ул үзен кулында нык тотты.

— Минем бу темага синең белән артык сөйләшәсем килми, — диде. Ул газ плитәсенә ут кабызды, чәйнеген плитәгә утыртты. Үзе ашыкмыйча гына бүлмәсенә чыгып китте.

Кичә дә үзе югында килгән газета-журналларны карап чыга алмады. Аларны өстәл янындагы утыргычка тәртипсез рәвештә ташлаганнар иде. Галиәкбәр чәй кайнаганчы шуларны караштыра башлады. Кызыклы, һичшиксез укылырга тиешлеләрен аерып өстәленә сала барды, әһәмиятле дип тапмаганнарын яки инде аңа таныш нәрсәләр язылганын идәнгә ташлады. Газеталар арасыннан бер хат та килеп чыкты. Бусын аның Ташкентта яшәүче энесе яза иде. Галиәкбәрнең күптән хат алганы юк иде Кәбирдән.

Карт үз алдына куанычлы гаҗәпсенү белән хатны ачты, тиз генә күзлеген киеп алып укырга тотынды. Исәнлек-саулык яза иде энесе. Пенсиягә чыгарга җыена икән. Менә җәйге айларда, тәмам эшеннән бушап, хөр, лаеклы ялда булачак ул. Хат язуы да шул мөнәсәбәт белән икән. Инде эштән бушап үз вакытына үзе хуҗа булгач, озаклап торырга кайту өчен туган якларга, ягъни Галиәкбәрләргә җыена икән. «Абый, син минем бу теләгемә ничегрәк карыйсың? Дөресен генә әйткәндә, минем исәпләр Наполеонныкыдай. Бик сагындырды. Әгәр дә сездәге тормышлар күңелемә хуш килсә, минем исәп шунда бөтенләйгә күчеп кайту. Күңел каберемнең туган якларда булуын тели».

Әйе, моннан биш еллар элек ул бер кайтып киткән иде. Аның ике улы, бер кызы бар. Хатыныннан бик зарланды ул чакны. Холыксыз бер истеричка иде ул, сөйләвенә караганда. Күрәсең, энекәшнең монда кайтырга теләве һәм сүзне бары үзе турында гына алып баруы, хатыныннан, балаларыннан ни сәлам, ни амәнәт тапшырмавы үзенең ялгызлыкта калуына ишарәдер.

Галиәкбәр энесеннән килгән хатны өстәлгә куеп уйга калды. Сафура кухняда гасабиланып пиләрдер җимерә, пиләрдер вата иде. Карт, яңа хәбәр җиткерүдән дә бигрәк, кызының нишләве белән кызыксынып, кухняга керде: Сафура тәлинкәләрне чиләк кырына кагакага аш калдыкларын бушата.

— Кәбир абыеңнан хат бар. Кунакка киләм дип яза, — диде Галиәкбәр. Сафура кызарынган ачулы йөзен әтисенә төбәде.

— Шул гына җитмәгән иде шул!

— Әй син тәлинкәне алай бушатма, кашык белән кырып төшер. Аннан менә нәрсә. Мин бүген тагы Әлфия янына очам. Лиана янына бармый калма. Начальнигыннан үтен, җибәрсен. Чана илт аңа. Андагы барлык баланың чанасы бар, безнең бичара гына чанасыз. Чана подвалда. Былтыр үзем сатып алган идем аңа.

— Нигә соң илтмәдең, илтергә иде.

— Әйтәм ич, мин бүген китәм дип. Ә анда барганда мин чананың кирәклеген белми идем әле.

— Китми тор, бүгенгә кал. Сары песнәгем дә, мысыр күгәрченем дигән буласың бит үзең. Яратам дисең.

— Яратам, бик яратам. Ләкин мине анда эш көтә.

— Көтә пычак, — диде Сафура. Ул әтисенә бик ачы, үзәккә үтәрлек сүз әйтергә җыенды. Тик карттан ничек булса да акча алып калырга кирәклеген хәтерләп, тыелырга мәҗбүр булды.

— Менә шул. Чана илтергә онытма, — диде Галиәкбәр, кире үз бүлмәсенә юнәлеп.

Ул чәй кайнап чыкканчы эш өстәле янында газета һәм журнал укып утырды. Су кайнагач, кухняга чыгып, куе итеп чәй пешерде.

Кухнядагы шкафтан әле башланмаган печенье пакеты табып, бер чынаякны юып арулаганнан соң, үз бүлмәсенә чәй эчәргә кереп китте. Сафура бу вакытта башлаган эшен гадәтенчә ярты юлда калдырган килеш олы бүлмәдә ертылган оегы белән маташа иде.

Галиәкбәр бер чынаяк чәен тәмләп эчкәннән соң, икенчесен ясау өчен кухняга чыкканда кухня ишеге янында Сафураны очратты. Аптыравына каршы, бу юлы аның чырае ачык, ягымлы иде.

— Әлфия ничек яши соң? — дип сорады ул үтә яктырып. Аһ, этисе белән гел шулай сөйләшсен иде бу кыз. Бу чырайның бары маска икәнлеген, аның астында ниндидер үз мәнфәгатен үтәргә тырышу ятуын белгән хәлдә дә карт эреде, әйтер сүзен онытып:

— Әлфия бик әйбәт яши, — диде. — Кияүгә чыгарга җыена. Бик эшлекле чибәр бер егет тәкъдим ясаган. Кыскасы, Әлфия бик бәхетле, эшендә яраталар, абруе зур.

— Бик әйбәт, — диде Сафура ничектер уңайсызланып елмая-елмая, — мин аның өчен бик шат.

— Синең эшләр ничек соң?

— Һәр вакыттагыча финансовый кризис кичерәм.

— Кунак-кунак уйнауны туктатырга кирәк. Барын-югын белмидер, бал телидер тамагым, дип тамакка буйсынып яшәп булмый ул. Юрганыңа карап аяк суз. Хезмәттән рәхәт табарга өйрәнергә кирәк.

— Башланды нотацияләр, — диде Сафура күңелсезләнеп. — Әгәр беләсең килсә, мин бу өстәл әзерләүгә үз кесәмнән бер тиен дә тотмадым.

Ул кинәт борылды да җилләнеп олы бүлмәгә кереп китте.

Галиәкбәр чәен эчкәннән соң, чынаягын кухняда чайкап торганда Сафура тагы аның янына килде.

— Син миңа, эти, зарплата алганга кадәр беразакча биреп тора алмассыңмы?

Ул һәр вакыт этисеннән акчаны бурычка дип сорый иде. Ала һәм бурычка алганлыгын «оныта» иде. Хәер, Галиәкбәр дә аңа беркайчан да акчаны бурычка дип бирмәде, булса, болай ярдәм йөзеннән генә, бирә килде.

— Күпме кирәк? — диде ул.

— Ну күпме? Хотя бы егерме биш сум.

Галиәкбәр бүлмәсенә кереп утыргыч аркасына эленгән пиджак кесәсендә кармаланды. Бумажнигыннан чыгарып кызына утыз сум акча сузды.

— Акча бирәм, сүзеңне тыңлыйм, тик син дә тыңла. Бүген үк Лианага чана илт.

— Кайчан?

— Ничек кайчан? Эштән соң. Бездә эш көне сигез сәгать кенә лә. Җиде сәгате йокыга, бер сәгате ашау-эчүгә, тагы сигез сәгате кала бит әле. Моннан да зуррак байлык була аламы?

— Тагы!..

— Әйе тагы. Чана подвалда. Поездлар төнге уникегә кадәр йөри. Ишеттеңме? Әгәр сүземне тыңламасаң, мин дә икенче тыңламам.

— Бу нинди обращение инде, эти! Мин бит сиңа кечкенә бала түгел.

— Син кечкенә баладан да болайрак.

Сафура этисе юган чынаякка чәй ясап өстәлдә яткан коры-сарыны капкаларга кereште. Бераздан киенеп, эшкә китәргә җыенды.

— Мин үз бүлмәмне бу юлы биклэп китәм, — диде карт кырыс кына. — Кем ул минем ятагымда кунды?

— Мин лә. Укып ятарга җайлы анда. Син бикләмә бүлмәне. Кем тисен синең әйберләреңә?

Карт китапларны кемдер туздырган димәкче иде, артык ваклану кебек тоеп, дәшмәде. Бары үҗәтләнеп:

— Биклим, — дип кенә кабатлады.

— Ә телефон?

— Мин аны коридорга чыгарып калдырам.

Сафура нәфрәт тулы күзләре белән зәһәрләнеп этисенә карап торды.

— Бөтенләй акылыннан язды инде бу картлыктан!

Әйе, хәзер ул карттан үзенә кирәген алган иде инде, теләсә ничек кыланса да була.

Галиәкбәр аның кыргый бер кыяфәткә кергән йөзен күрмәс өчен бүлмә ишеген ябып куйды.

Сафураның каты шапылдатып тышкы ишекне япканы ишетелде. Эшенә китүедер, дип уйлады Галиәкбәр. Ә шулай да бу акылсыз кыз Галиәкбәргә кызганыч иде. Шул иде бит аның кешелек дөньясына калдырасы үзенең дәвамы. «Нинди сәбәпләр аркасында син шундый булып чыктың, кызым, дип уйланды ул. Ни өчен синдә олыларга, хезмәткә әз генә дә хөрмәт юк. Ни өчен син шундый вульгар прагматизм кәсафәтенә бирелдең? Әниең дә, мин дә, мәктәп тә алай тәрбияләмәде бит, югыйсә». Галиәкбәр өстәленә терсәге белән таянган хәлдә, маңгаен учына куеп бик озак утырды. Сорауларына бер генә дә төпле җавап таба алмады. Ахырда, тумыштан шундый холыксыз нәрсәдер инде ул, гомере буена үзе дә азапланачак, якыннарын да интектерәчәк дип уйланды.

Сәгать сигез тулгач ул, вәгъдәсен үтәп, Эльвира Хәкимовнага телефон шалтыратты. Сәгать унбергә кадәр үзенең диссертациясен квартирага җибәрергә кушты. Чөнки ул нәкъ унберде аэропортка китәчәк иде.

*Дәвамы бар*

## Нәби Дәүли

### Хатлар килә миңа...

Хатлар килә миңа, хатлар килә,
Ерактагы дуслар сагынган.
Шәһәрләрдән, авыл якларыннан
Минем йортка юллар салынган.

Бистәләрдән килә, төзелешләрдән...
Хатлар килә иртә-кичләрен.
Чалыш-полыш язган сүзләреннән
Сизеп торам кайнар хисләрен.

Мин күрешәм кебек алар белән,
Кул алышып шушы бер мәлдә.
Елмаюлар балкый хат өстендә,
Карый кебек күзләр күзләргә.

Исемнәрен алар яшермиләр.
Адреслары конверт читендә.
Сызып куйган хәреф асларына —
Калсын диеп минем исемдә.

Алар яза үз куллары белән,
Үз сүзләре белән уйларын.
Алар белә минем язмышымны,
Нигә чәчем ап-ак булганын.

Мактамыйлар алар, хурламыйлар,
Алар әйтә бары дөресен.
Менә шуңы гади, гади кешеләр,
Миңа бирә тормыш дәресен.

Мин үземне көчле итеп сизәм,
Бәхетемнең булмый чикләре.
Әйтерсең лә юлдаш җилләр исеп,
Киерә минем кыю җилкәнне.

Алар яза. Ачык, туры итеп —
Боргаланмый, сыргаланмыйча.
Алар да бит тыныч яши алмый,
Минем белән бергә янмыйча.

Хаталансам — алар гафу итә,
Янамыйлар ләкин беркайчан.
Кызганмыйлар минем өлешемне,
Нур сорасам әгәр кояштан.

Минем өчен тагы нәрсә кирәк,
Бер медальме әллә күкрәккә?
Медальләр бит кайчак тутыгалар,
Ә яхшы сүз яши йөрәктә.

Менә мин дә язам бу шигырьне,
Сагышланып калган чагымда.
Тәнкыйтьчеләр булса, булмаса ни,
Шундый дуслар булса янымда.

1977

●

Без язмышка үпкә белдермибез:
Тормасак та таулар илендә, —
Татарстан —
Үзенең исеме белән,
КамАЗлары белән
Күренеп тора дөнья түрендә.
Күренеп тора
Кечкенә генә Кырлай белән.
Күренеп тора
Нәни генә тургай белән.
Күренеп тора
Татар улы, Ватан улы,
Габдулла Тукай белән.

Тормышыбыз Идел ярларында,
Без Иделне сөйдек гомергә,
Татарстан —
Каеннары белән,
Арышлары белән
Күренеп тора дөнья түрендә.
Күренеп тора
Ап-ак кына карлар белән,
Күренеп тора
Кояш төшкән җире белән.
Күренеп тора
Татар улы, Ватан улы,
Муса Җәлиле белән.

1978

●

Ялгыз торна узып бара,
Кешеләр аңа карап кала:
— Әнә, диләр, торна оча.
Әйе, ялгыз торна оча.
Бер ятим ул безнең очта.

Мөмкин түгел кызганмаска,
Кошны күреп сызланмаска.
Торна оча, торна оча.
Кайгыларын уйлап оча.
Шул турыда беләләрме,
Беләләрме безнең очта?

1977

●

Төн буенча йоклый алмыйм,
Төн буенча уйда мин.
Әйтерсең лә капчык аскан
Юлчы кебек юлда мин.

Капчык авыр: анда — еллар,
Анда минем язмышым.
Кайгыларым, шатлыкларым,
Эзләп алган табышым...

Кая җитеп тукталырмын —
Юл азагын кем белә?
Миңа әле кояш белән
Иртәгә дә көн килә.

1977

## Миргазыян Юныс

# ТАБУ һӘМ ЮГАЛТУ

ПОВЕСТЬ

1



Баланы... Ишетәсеңме? Баланы су буена ялгызын җибәрә күрмә! Ишетәсеңме!..

Яшел вагоннар бер-берсенә бәреләә-бәреләә, тимер тавышы чыгарып, Мәрьям янынан узалар иде. Ул кызын алып китүче вагонны куып җитәргә теләп, йөгерә-атлый баруын дәвам итте:

— Ишетәсеңме?

Әйтерсең анын күкрәгенә төрттеләр. Мәрьям артка тайпылды... Перрон астында шәрә салкын рельс ята иде. Соңгы вагон артындагы кызыл ут чекрәеп Мәрьямгә карап бара. Ниһаять, кызыл ут та соргылт таш корылмалар артына күмелде. Ире дә, кызы да юк хәзер Мәрьямнең. Ялгызлык. Шыксыз бушлык чорнап алды.

«... Кәримәне... су коенырга ялгызын җибәрмәсә инде? Аңа ышансаң... Ул бит баланы чыныктырам дип авылга алып китте. Кәримәнең ашказаны начар. Габдрахман аңламый, авылда суыткыч та булмый бит ичмасам. Ачыган аш ашатып баланы харап итмәсә инде... Әллә ияреп барырга кирәк идеме? Мәрьям үкенеп куйды. «Баланы...»

Перрон очына утырткан тимер баганада семафорның салкын уты чекрәеп поезд киткән якка карап тора иде. Тирә-якта таш корылмалар. Таш һәм асфальт дөньясы. Кызы да юк хәзер Мәрьямнең, ире дә. Алар башкаладан минут саен, секунд саен ераклаша баралар.

Перронга яңа пассажирлар җыела башлады. «Әллә ял сорап алырга инде?.. И раббым, баланы гына харап итмәсә ярар иде инде!»

2

Шәһәр артта калды. Аннары шәһәр читендәге төзелеп бетмәгән йортлар, бакчалар, кырлар күренеп калды. Менә хәзер тәрәзә яныннан нарат агачлары йөгерә башладылар. Таза матур хатын бидон белән сөт алып кайта. Яшел койма буенда чәченә ак лента таккан кыз

скакалка аша сикерә. Агачлар арасыннан поезд ягына тәкәббер караш ташлап торган бай дачалар.

Кәримә тәрәзә янагына ябышып коридорда вагон яныннан йөгереп үтүче нәратларны күзәтеп тора иде.

— Әти, агачлар кая баралар?

— Агачлар урыннарында тора, кызым. Без барабыз.

— Юк, агачлар поездан куркып качалар. Әнә ничек йөгерәләр.

Габдрахман кызын тәрәзәдән куптарып алды:

— Йокларга вакыт. Әйдә, купега керик.

Баланың күзләреннән яшь тәгәрәп чыкты.

— Минем барасым килми. Төшик, әти. Өйгә кайтыйк. Зинһар өйгә кайтыйк, әти. Әниемне күрәсем килә. Мин әниемне сагындым. Ә-ә-ә-ә...

— Сагынырга иртә әле, кызым. Барган чакта поездан төшеп булмый. Күрмисеңмени, ничек тиз барабыз?

Кыз елавыннан туктады. Өлкәннәрчә итеп әйтте:

— Туктатыйк. Үзең әнә теге тотканы тартсаң, поезд туктый диден.

— Ул тоткага кагылырга ярамый, кызым. Әйдә, керик. Йокларга вакыт.

Купега кергәч Габдрахман урын җәйде. Кызын чишендерде. Төнге пижама кигерде.

— Ят, матурым, йокла. Бик иртә тордык бит. Арыгансыңдыр.

— Син дә ят. Вагон астында кемдер йөри, ишетәсеңме? Дөп-дөп басып йөри. Мин куркам. Ул кеше вагонны аударып ташламасмы соң?

Әти кеше кызының өстенә япкан одеялның читен матрац астына кыстырды. Чишенмичә генә кызы янына ятты. Сабыйны кысып кочаклады.

— Вагон астында ике кеше йөри, ишетәсеңме?

— Йөрми, кызым. Тәгәрмәчләр шулай дөпелди. Көпчәк тавышы ул. Йокла, кызым, яме.

— Кеше бар, әти, бар. — Кәримә этисенең муенын кысып кочаклады. Вагон астында көпчәкләр дөпелди. Өстә, түбә белән түшәм арасында, нәрсәдер шыгырдый. Ярый әле, купедашлар, бер карчык белән кызмача ир, коридорда сөйләшеп торалар.

Бала йоклады дип уйлап, Габдрахман урыныннан тора башлаган иде, Кәримә аның муенын җибәрмәде.

— Бездән башка әнием нишләр инде? Иртән эшкә киткәндә аңа баш тарагын кем табып китерер?

— Бездән котылгач, әниең рәхәтләнеп ял итәр. Өйдә уенчыкларын идәнгә таратып ташлаучы юк хәзер. Пычрак туфли белән идән таптаучы да юк. Уенчыгын идәндә онытып калдыручы кем әле?

— Бүре.

— Укыган китабын диванда онытып калдыручы кем?

— Син, — диде Кәримә шатланып. — Син онытып калдырасың. Әни җыештыра. Әниемне сагынам.

«Мәрьям метродан чыгып, автобуска утыргандыр инде, — дип уйлады Габдрахман. — Азык магазины янындагы тукталышка төшкәндер. «Яшь техниклар йорты» дип язып фронтонга кадакланган язу астыннан да узгандыр. Җидеме, сигезме катлы шул шыксыз бина яныннан узганда сак булырга кирәк. Балконнар астыннан барганда башыңа утлы тәмәке төпчеге төшүе бар. Бер мәртәбә, получка алган көнне, Габдрахманның түбәсенә буш шешә төшә язган иде. Ул бинаның ничә катлы икәнлеген Габдрахман белми иде әле. Һаман санарга оныта. Командировкада чакта нигәдер шул йорт искә төшә. Шуның ничә катлы икәнлеген беләсе килә башлый. Ә кайткач оныта Габ-

драхман. Әллә җиде, әллә сигез катлы ул. Сугышка кадәр салынган бина. Квартирларының түшәмнәре биек.

Шул соры бинага янәшә биш катлы типовой йорт. Йортның беренче катында балалар бакчасы. Мәрьям ул йортны да үткәндер инде. Бәлки инде ул өйгә дә кайтып җиткәндер. Габдрахман хатынының ялгыз буш караңгы бүлмәгә керүен күз алдына китерде дә йөрәк әрнүен басар өчен кызын кысып кочаклады. Узган җәйне Мәрьям Кәримәне алып Балтик диңгезе буена ял итәргә киткәч, беренче төнне буш калган фатирда куна алмыйча, Габдрахман төн уртасында торып Останкинога энесе янына китте.

### 3

Фатирда бушлык хөкем сөрә. Бала тавышы югалу белән бүлмә җансызланды. Мәрьям тизрәк ут алды. Тынычлык. Сәгать вакытны секундларга тураклап гомерне узган заманга озата: кит-тек, кит-тек, кит-тек — мәңгегә...

Тынычлык. Мәет чыккан йорттагы кебек. Башта уйлар, күңелдә тынгысызлык. Әйтерсең күкрәк эчендә кара кырмыска йөри.

Кәримә туганчы, икәү генә яшәгәндә ире бирәр җиргә китсә, хәтердә аның яхшылыгы гына кала иде. Әле дә шулай тоела. Менә хәзер, шушы мизгелдә, Мәрьямнең йөрәгендә бары тик ире күрсәткән игелекләр, аның юмартлыгы, кешелеклеге. Гел шулай. Аерылсалар, гел әйбәт хатирәләре генә кала, ә бергә чакта... Әле китәр алдыннан гына бик каты ызгышып алдылар. Габдрахманның авылга өчәүләп кайтасы килгән иде. Хатыны, кызы белән. Аның кызын күтәреп, хатынын култыклап Караяр урамыннан үтәсе килә иде. Мәрьям авылга кайтудан баш тартты. Габдрахман аны кыйнар хәлгә җиткән иде. Үзен интеллигент саный, ә Мәрьямнең хәлен аңларга сәләте җитми. Йа алла! Нигә болай катлаулы икән бу яшәү? Килен кеше авыл җирендә ял итә аламени ул? Мәрьям шушы хәлне никадәр аңлатырга тырышып карады. Юк, аңларга теләми. Соң бит инде аңгыра кеше дә түгел. Җан сизгерлеге гаҗәп көчле үзенең. Теләми аңларга: «Бергә кайтабыз!» — ди дә бетте китте.

Кайтып төшү белән Габдрахманның туган-тумачасы җыелачак. Тышкы яктан оялчан, ипле кешеләр алар. Сөйләшкәндә авызларын тотып, пышылдап кына сөйләшәләр. Ә күзләре Мәрьямнең һәр хәрәкәтен, һәр сулышын тикшереп, сынап тора. Юк, алар гаеп табып көлмиләр, мәсхәрәләмиләр. Шул астыртын гына карап тору чыгырыннан чыгара, үтерә Мәрьямне. Арый, хәлдән тая ул берничә көннән. Нервылары чыдамый. Габдрахман белән икәү генә калган чакларда үкереп елый башлый. Ә ире аңламый. «Гади психоз бу, — ди ул. — Алар сине яраталар, ихтирам итәләр. Күрмисеңмени сине өрмәгән җиргә дә утыртмыйлар. Син төчкергәндә ярхамкалла дип торалар». Габдрахманга туганнарының карашы табигый тоела. Ә бит үзе шундый сизгер, бер карау белән кешенең башыннан узганын һәм киләчәген әйтә ала торган кеше. Йа алла!

Мәрьям башкалада туып үсте. Балалар үзара русча сөйләшәләр иде. Бары тик әнисе белән генә татарча (Габдрахман «мишәрчә» дип урти). Әнисе русча яхшы белсә дә, үлгәнче татарчасын ташламады. Авылча яшәде, гел татар ашлары пешереп ашатты балаларына. Шуңа карамастан, Габдрахманның авылыннан килгән кешеләр чит ил кешеләре кебек тоела иде Мәрьямгә. Сөйләшүләре дә чит, кыланулары да чит, чит һәм ят, ят һәм чит. Әнисенең сөйләшүе дә татарча иде, ләкин аның сөйләшүе үзенчә татарча, туган әнинеке. Ә Караяр авылыннан килгән кешеләрнеке ят, инглизчә шикелле. Мәрьям белән авыл-

дан килгән кешеләр арасында аерма шул кадәр зур иде. Габдрахманның туганнары чиксез юаш, үзләрен бер сәбәпсез кимсетеп күрсәтергә яраталар. «Бед ни, бед авыл кешесе. Бед инде, кая, башкала кешесе белән ярыша алмайбыд...» Ә карашларында — сынау. Һәр әйткән сүзеңнән, һәр хәрәкәтеңнән гаеп эзләгән шикелле карыйлар. Юк, алар сиңа бернинди начарлык эшләмиләр. Киресенчә, сиңа ярдәм итәргә теләп, бөтерелеп торалар. Ләкин алар — читләр. Гадәтләре, зәвыклары, культуралары белән чит. Эш менә нәрсәдә. Ә Габдрахман рәнҗи. Аңлый алмый ул, рәнҗи генә.

Квартирада шыксыз тынычлык. Беркем юк. Хәтта тәрәзә астындагы юлдан үтүче дә юк. Кәримә өйдә чакта Измаил паркыннан кайтучы яшь-җилбәзәк Габдрахманнарның тәрәзәсе астына туктап үбешәләр иде. Үбешеп туйгач, бер-берсенә интим сүзләр әйтәләр. Кәримә шул сүзләрне ишетеп торган булса кирәк. Бер мәртәбә сабыйлар әчкерсезлеге белән әтисенә сөйләп торды: «Кыргыйланма инде, күкрәгеңне генә тотам бит...» Менә хәзер Кәримә дә юк, Габдрахман да. Бушлык квартирда. Һәм тынычлык. Тынычлык бар, иминлек — юк. Сәгать тә элеккегә караганда аяусызрак текелди. Өске каттагы алты яшьлек кыз, яһүд кызы да нигәдер фортепиано уйнарга утырмады бүген. Әллә алар да ялга киттеләр инде?

Тынычлык бар, рәхәтлек юк. Җан тыныч түгел. Бала да өйдә юк. Җан бала белән вагонга утырып китте. Шуңа күрә үзеңне ташу чыгарып ташлаган бүрәнә итеп сизәсең. Тойгыларда газаплы киеренкелек. Зур каза көткәндә менә шулай сизәсең үзеңне. Бала кызганыч — Кәримә. Моңа кадәр Мәрьямнең кызыннан аерылганы юк иде әле. Ирен бер үзен җибәреп Кәримә белән калган чаклары еш булды. Чөнки Габдрахман бер генә урында утырып эшли алмый. Каядыр ашкына, ашыга, җирсенә башлый. Өйләнешкән чорны ул диңгездә йөзә иде. Аңа кадәр ул һавада очкан. Кәримәсе тәпи йөри, сөйләшә башлагач, Габдрахман аерылып яшәүгә түзә алмыйча диңгезне ташлады. Диңгез министрлыгына эшкә урнашты. Эше бик әйбәт иде. Бүлек начальнигы иде. Почетлы эш. Акчаны күп түлиләр. Түзмәде, өйрәнчек булып журналда эшли башлады. Гел үзенә авырлык эзләп йөри, тынгы белми. Кайчакта Мәрьям аны кызганып та куя. Үгетләп карый, ачулана, юк, файдасы тими.

«Баланы ялгызын су буенда җибәрмәсә инде. Иң куркынычы — ачыган аш ашатып агулау. И раббым, ярдәм бир».

## 4

— Йокларга теләмәсәң, берүзеңне калдырып торып китәм, — диде Габдрахман ачуланып. Купедагы күршеләре, Уфага кайтучы карчык һәм кызмача ир, инде күптән йоклыйлар. Габдрахман үзе дә йокыга киткән иде, аны кызы уятты. Һаман көйсезләнә. Әллә нәрсә булды балага. Әллә авырып китте инде. Аның болай көйсезләнгәне дә, бу кадәр елаганы да юк иде.

— Йоклый алмыйм, әти. Күзем йомылмый. Мин өстә йоклаган абыйдан куркам. Нигә гырылдый ул? Үләме әллә. Әти, мин куркам, елыйсым килә.

— Иртәгә төнлә Бөгелмәгә кайтып җитәбез. Йоклап кал, кызым. Иртәгә көне буе интегерсең, бүген йоклап калмасаң.

— Минем әни янына кайтасым килә, шуңа йоклый алмыйм, ул да бер үзе куркып ята торгандыр инде?

«Нинди бала бу?» — дип уйлады Габдрахман. — Башка балалар белән аралашмый. Үзендә сабыйлар ваемсызлыгы юк. Мавыгуы — этисе белән әнисе арасындагы мөнәсәбәтне тикшереп, төпченеп тору. Ара-

да эз генә киеренкелек туа башлады исә шунда ук сизеп ала. Өлкәннәр шикелле, ихлас күңелдән, ут йотып борчыла. Әллә бердәнбер булганга шулай, әллә заманасы шундый? Бала мондый булмаска тиеш. Ваемсыз, шат күңелле булырга тиеш. Уен-көлке белән, сайрар кош шикелле яшәргә тиеш бала. Бала чакта без шулай идек. Кәримә кебек чакта без табигать кочагында, экияттәге кебек яшәдек. Бәлки авыл балалары әле дә шулай яши торганнардыр?

— Әти, минем экият тыңлыйсым килә,— диде Кәримә әтисенең колагына.— Син бит экият белән йокы китертә беләсең. Синең экиятең йокы алып килсен әле.

— Тагын сөйлә дип интектермәсәң генә,— Габдрахман кызының башыннан сыпыра башлады. Баланың чәче шундый йомшак, үзәк өзгеч газиз иде. Шушы чәчне сыпырганда бар җыелган гөнаһың, күңел кереңҗуелып төшә шикелле. Кәриманең нәни бармагы әтисенең колак яфрагын сыпыра. Сабыйның саф сулышы йомшак кына булып биткә тиеп тора.— Караяр авылы турындагы экиятләрне беләсең бит, кызым! Ул турыда мин сиңа күп сөйләдем. Без хәзер шул авылга кайтабыз.

— «Кайтабыз» түгел, «барабыз». Әни миңа «сез барасы авыл» диде.

— Дөресе — «кайтабыз», кызым. Мин бит шунда туып үскән кеше. Син — минем кызым. Шунлыктан, ул синең авылың да.

— Ә әни кайда туып үскән?

— Мәскәүдә.

— Мин дә Мәскәүдә. Караяр минем авылым түгел. Минем авылым — Мәскәү. Синеке дә Мәскәү, әни шулай диде. «Хәзер синең этиең москвич инде» диде.

— Юк, кызым, синең авылың Караяр. Мәскәү авыл түгел — шәһәр. Зур шәһәр, башкала.

— Минем авылым Мәскәү. Әнинеке дә, синеке дә шул. «Түгел», дисәң, хәзер үк елый башлыйм.

— Ярый, сүз көрәштермик. Соң инде. Син «барасы», мин «кайтасы» авылның урамында ямь-яшел чирәм. Анда йом-йомшак бәбкә үләне үсә. Каз бәбкәләре шул үләнне нәни томшыклары белән өзеп ашыйлар. Шул үләннәргә куна-куна күбәләкләр оча анда. Каз бәбкәләре күбәләк куып уйныйлар. Арыгач, үләнгә чумып, рәхәтләнеп йоклыйлар. Каз бәбкәләре шундый акыллылар, яту белән йокыга китәләр. Авылдагы балалар да бик акыллы. Алар җәй буе ялан аяк бәбкә үләненә басып йөриләр. Шунлыктан аларга томау төшми. Җылы үләнгә басып йөрүе шундый рәхәт. Авыл сиңа да ошар әле. Анда көне буе кошлар сайрап тора. Балаларны йокыдан әтәч кычкырып уята. Әтәч кычкыргач, каз бәбкәләре, күбәләкләр, бозаулар йокыдан уяна. Куян балалары да, йокыдан уянып, битләрен юа башлыйлар. Сине дә көн саен йокыдан әтәч уятыр. Сине уятыр өчен ул шундый матур итеп кычкырачак, синең авылдан кайтасың да килмәс әле. Син каз бәбкәләре белән уйнарсың. Алар да сине яратыр, әтәч тә, бозау да. Син күбәләкләр белән дә дуслашырсың. Күбәләкләр яту белән йокыга китә торган баланы бик яраталар.

— Әти, без баймы, ярлымы?

Габдрахман тетрәнеп китте:

— Каян ишеттең син бу сүзләрне?

— Тетя Ларисаларга баргач, дядя Леня әнигә әйтте: «Ирең нефть чыга торган якка бара икән. Ул якта халык бай яши»,— диде.

— Байлык турында баш ватарга сиңа иртә әле. Күбәләкләр турында сөйләшик, яме.

— Без баймы, ярлымы? Шуны беләсем килә минем. Әйт инде.

— Байлыгыбыз житәрлек безнең. Пластинкаларга язылган борынгы татар көйләребез бар. Без аларны яратабыз. Ярату — байлык. Шәһәр музейларында без яраткан данлыклы картиналар бар. Теләгән чакта

без аларны түйганчы карыйбыз. Китаплар турыда сөйләп тә торасы юк. Китапларыбызның күпме икәнлеген үзең дә беләсең. Олы бүлмәдә генә ике шкаф, ике киштә. Кече бүлмәдә дә җитәрлек. Китапны әниең дә, син дә, мин дә яратам. Бу ярату бик зур байлык. Аңладыңмы?

— Китап байлык түгел, кәгазь генә. Ира Зельдинага көн саен магазиннан курчак алып бирәләр. Аның миллион күлмәге бар — менә кайда ул чын байлык. Сез минем туган көнемә генә курчак сатып аласыз. Әнинең институт кичәсенә киеп барырга юньле күлмәге дә юк. Без ярлы, белдеңме?

— Юк, күлмәк байлык түгел, кызым. Күлмәк туза да бетә. Яраткан музыка, яраткан китап, яраткан картина — менә кайда ул байлык. Яшел үләнгә ялан аяк басып йөрү дә зур байлык. Аннан соң, тынычлык — байлык, тату яшәү — байлык,— Габдрахман китәр алдыннан Мәрьям белән ызгышуын капыл исенә төшерде дә аның йөрәге ачытып китте: — Мин сине бик яратам, кызым. Бу да зур байлык. Авылга кайткач, син каз бәбкәләре, күбәләкләр белән дуслашырсың. Дуслашу сине баетыр. Байлык ул дуслашу, зур байлык.

— Әни миңа ялан аяк йөрмәскә кушты. Аягыңа пыяла кадалыр, диде.

— Авыл балаларының аякларына бернәрсә кадалмый. Аларның табаннары чыныккан була.

— Безнең белән кайтса, әни дә ялан аяк йөрер идеме?

Бу сорау Габдрахманның йөрәген тагын әрнетеп җибәрде. «Нигә бергәләп кайтмаска инде? — дип уйлады ул.— Ял бирмәүләре сылтау гына иде. Ныклап, ялынып сораса, ял бирәләр иде Мәрьямгә. Аның авылга кайтасы килмәде — эш менә нәрсәдә».

Мәрьям белән очрашканда, хат язышып хәбәр алышканда бар нәрсә ачык иде. Карашлары да бер иде аларның, зәвыклары да. Мәрьямнең бар ягы ошый иде Габдрахманга, холкы да, эшчәнлеге дә, җыйнаклыгы да. Мәрьям унынчыны алтын медальга бетерде. Институтны да гел бишлегә тәмамлады. Мәктәптә дә, институтта да комсомол оешмасы секретаре иде. Өйләнгәч һәр көнне, һәр сәгатьне — гомер буе бәхетле яшәрбез дип уйлыйлар иде алар. Чөнки Мәрьям дә Габдрахманны чын күңелдән ярата, гадәтләрен ихтирам итә, аның белән горурлана иде. Өйләнешеп, бергә яши башлагач, мәсьәләләр катлауланып китте. Алар һаман яратышалар иде. Ихтирам да бетмәгән иде әле. Бар мөнәсәбәт элеккегечә, үзләре еш кына бер-берсен аңлый алмыйлар. Мөнәсәбәттә ниндидер тоныклыклар барлыкка килә. Кояшлы көндәге болыт шикелле, шатлыкны, бәхетне кайгы каплап китә. Араны тоташтырып торган җепләр өзелә, йөрәккә җылылык биреп торган мәхәббәтне кара томан каплап китә. Нилектән бу? Мондый кыенлыклардан ничек котылырга? Ничек? Газапның иң авыр чагы шунда — бернинди киңәш, бернинди фикер ярдәм итә алмый мондый чакларда.

Мәрьям авылны, авыл җиренең табигатен, анда яшәүче кешеләрне ярата иде. Яраткан булып кыланмый иде Мәрьям, чын күңелдән ярата иде. Габдрахманның яраткан булып кыланучы кызларны да очратканы бар. Яратуның нәрсә икәнен белмәүчеләр, никадәр тырышып та мәхәббәткә ирешә алмаучылар да җитәрлек бу дөньяда. Ләкин Мәрьямнең авыл яратуы белән Габдрахманның яратуы арасында аерма зур иде. Мәрьям авылны шәһәрчә ярата, дачада яшәүче шикелле итеп, ә шул ук авыл Габдрахманның иманында, вөҗданында. Менә кайдан туа аларның бер-берсен аңлый алмыйча газапланулары. Бәлки Габдрахманның шәһәр тормышына авылча каравын да Мәрьям аңлый алмый торгандыр. Бер-береңне аңлый алмау газаплый, ачуны китерә.

Габдрахманның исенә күптән түгел генә булган бер сөйләшү килеп төште. «Рәхәт яши дә инде авыл кешесе. Мәскәүдә мин үземне бәйге-

дә чабышкан ат шикелле тоям. Иртән яңу белән кабаланып йөгереп йөри башлыйсың, авып йокыга киткәнче туктый алмый йөгерәсең. Темпны әкренәйтеп тә, туктап та булмый, чөнки яшәү ритмы шундый. Стресс. Авылда һәркем үз көенчә йөри. Житез кеше — жәһәт, пошмас кеше — атлар-атламас. Ожмах тормышы авылда, җәннәт»,— диде ул хатынына. «Анда шундый рәхәт булгач, нигә башкалада интегеп яшисең? Син бит бик тәвәккәл кеше. Министрлыктагы өч йөз илле сумлык урыныңны редакция өйрәнчеклегенә бер минут икеләнеп, тормыйча алыштырдың бит. Аңламыйм мин сине, акыллым. Авыл тормышы миңа шулай ошаса, мин бер минут шәһәрдә тормас идем».

Һаман туган авылын сагынса да, Габдрахман шәһәр тормышының җиңеллегенә күнеккән иде. Эчкече аракыга шулай күнегә. Уйнашчы хатын үзенең хыянәтенә.

Өйләнешкән елны алар икәүләп авылга кайттылар. Мәрьям үзен авылда гаҗәп әдәпле тотты. Авылда киленне бик нык сынасалар да ошаттылар. Габдрахманның хатыны сынатмады. Йорт эшләрен бөтерелеп эшләп йөрде. Күршеләре каршында үзен шул кадәр әйбәт тотты. Шуңа күрә дә аны бөтен Караяр яратып калды. Авылдан кайткач, Мәрьям иренә болай дип сөйләде: «Туганнарың әйбәт, кешелекле. Алар шундый табигый — сабый шикелле. Ләкин шәһәр кешесе андый әйбәтлеккә битараф. Миңа, мәсәлән, шәһәр кешесенең үзара дикъкатьсезлеге, туганнарына сүлпән каравы ошый». Хакыйкать Мәрьям фикерендә иде. Шуңа карамастан, бу сүзләргә Габдрахманның хәтере калды.

Вагон түшәмендәге тонык зәңгәр лампочкага карап Рахманкулов менә шушы турыда уйлап ята иде. Вагон тәгәрмәчләре рельс арасындагы җөйләрне саный. Кәримә йоклый.



## 5

Йөгереп урам аша чыкканда Мәрьям кинәт туктап калды. Трамвай юлы. Аның үкчәсе ике рельс арасына кысылган иде. Аягын суырып карады Мәрьям. Ярдәм көтеп як-ягына каранып алды. Урам буш. Зур кызыл трамвай һаман якынлаша. Трамвай белән бергә үлем якынлаша. Менә сигнал бирә башладылар. Шундый зәһәр көчле сигнал. Мәрьям соңгы көчен җыеп ыргылды да уянып китте. Өстәлдә шашынып будильник чылтырый иде.

«Нинди әшәке саташу бу?» — дип уйлады Мәрьям. Ул төшкә бераз ышана иде. Гомумән, начар төш кәефне боза.

Мәрьям төнге күлмәген салып ташлап, ваннага юнәлде. Бәләкәй бүлмә янынан үткәндә баланы уятудан куркып бармак очына гына басып бара иде, Кәримәнең өйдә юклыгы исенә төште. Рузаевкага җитеп килә торганнардыр инде? Поезд кузгалып киткәч, «Кәримәне ялгызын су буена җибәрмә» дип кычкырган иде, этисе ишеттеме икән».

Авылга барудан Мәрьям баш тартты. Менә хәзер ул үкенә иде. Хәзер ул квартирда бер үзе. Ире эшкә киткәнче аш әзерлисе, Кәримәне бакчага илтәсе юк. Мәшәкать кимеде. Ләкин мәшәкать кимү нигәдер куандырмый. Квартир буш. Ниндидер җансызлык хөкем итә ятим калган фатирда. Габдрахман китте. Өйдә аның яхшылыклары гына калды. Аерылып торган чакларда гына Мәрьям иренең шундый әйбәт, шундый акыллы кеше икәнен тоя башлый иде. Бергә яшәгәндә көндәлек мәшәкатьләр, ыгы-зыгы мәхәббәтне каплап китә башлый. Көч хуҗалыкны алып баруга, йорт эше вакчыллыгына тотылып бетә. Йөрәк җылысын, ихтирамыңны өзелеп яраткан иреңә генә багышлап торырга да вакыт калмый. Вак-төяк эш, дөнья куу яшәү куанычын каплап китмәсен өчен нәрсә эшләргә кирәк икән? Вакчыллыкка ничек каршы торырга, аны ничек җиңәргә?

Битен югач, Мәрьям, озаклап, шушы эшеннән тәм табып, чәчен тарады. Көзге каршысына килеп, битенә пудра сөртергә кереште. Көзгедән Мәрьямгә утыз биш яшьлек бер хатын карап тора иде. Тирән урнашкан көнгырт уйчан күзләр, зуррак булса да матур уелган сизгер иреннәр. Ә тойгылар һаман унҗиде яшьлек кызныкы. Теләкләр дә, өметләр дә шул чордагы шикелле. Кешенең елдан-ел картая барганын Мәрьям яхшы белә иде. Күрә иде яшьтәшләренең, дусларының әкренләп картая килгәннәрен. Ләкин шул картаюны үз тормышыңа, үзеңә берничек тә кабул итеп булмый иде. Күңел тирәнлегендә «мин гомер буе шушылай яшь килеш сакланырмын» дигән дуамал өмет туктаусыз яши иде. Әнә, көзгедән карап торган хатынның күз читләрендә вак кына җыерчыклар...

«...Тукта әле, мин нигә болай чекрәеп көзгегә карап торам? Әллә берәрсенә ошарга азапланам инде? Оятсыз, ирең киткәнгә тәүлек тә үтмәде бит әле». Уңайсызланды Мәрьям, кызарынып китте.

Ваннадан чыккач, газ яндырды, чәй куйды. «Нәрсә пешерим икән — боткамы, йомыркамы? Әллә коймак пешереп ашыйммы икән?». Бернәрсә дә ашыйсы килми. Үзең өчен пешеренеп торасы да килми. Ни куаныч, син пешергәнне ләззәтләнеп ашаучы булмагач. Бер телем ипигә май ягып ашады, ике чынаяк чәй эчте дә ишегён бикләп институтка юнәлде Мәрьям.

Ул милли мәктәпләр фәнни институтында фәнни хезмәткәр булып эшли иде. Эшли торган җир ерак — бер сәгать унбиш минутлык юл. Унбиш минут автобус белән, илле минут метрода, ун минут троллейбуска утырып барасы. Җаныңны чыгарырлык итеп кысалар. Һәм тынчу була шәһәр транспортында.

Автобус тукталышына озын чират тезелгән иде. Ике машинаны үткәреп җибәрде һәм метроның иң тыгын чагына туры килде. Шул кадәр кыстылар вагон эченә кергәндә, кереп җиткәнче Мәрьямнең аяклары җиргә тимәде. «Сак булыгыз, ишекләр ябыла!» Метро поезды ургылып урыныннан кузгалды. Мәрьямне ике яктан ике ир кеше кыса. Уң яктагысы бәләкәй, юан, үзе туктаусыз мышкылдый, тыныннан кичә эчкән аракы сасысы аңкый. Шушы авыр ис борынына килеп бәрелгәндә Рахманкулованың күз аллары караңгыланып китә иде. Юан ир симез гәүдәсе белән Мәрьямгә сырыша иде. Сул яктагы ир чандыр һәм чибәр. Америка вестерннарында ковбой ролен уйнаучы артистларны хәтерләтә. Бу адәм симез шикелле сырышмый, киресенчә, читкә тайпылырга тырышып, Мәрьямне кысылудан сакламакчы була. Аның бу кыланышы тактика гына булып чыкты: ковбой, сизмәмешкә салышып, кулын Мәрьямнең күкрәгенә тери иде. Иң кабахәт ирләр менә шушындый булалар. Тышкы яктан әдәплә, культуралы, эчтән — намуслары пычрак, вөҗданнарыннан сасы ис бөркелеп тора, аракы исеннән дә әшәке, кабахәт ис...

Мәрьям ирләр арасыннан чыгып, почмакта китап укып торган хатын янына барып сырышты. Аның артындагы кешеләр эсселек турында сөйләшәләр. Инде ике атна башкаланың бар кайгысы — эсселек. Айдан артык яңгыр яуганы юк. Кыямәт көне. Корылыктан агач яфраклары кибеп корый башлады. Урманга керсәң, аяк астында коры яфрак кыштырдый. Метрода, трамвай тукталышында, институтта шушы турыда сөйләшәләр. Икмәк көеп бетте, кытлык килә, диләр паникага бирелергә яратучы куркаклар.

Әнә, Мәрьямгә сырышкан юан кеше елак тавыш белән зарланып азаплана:

— Квартирабызда төтен. Тын алып булмый. Мин урамда чүп яндыралар дип торам. Горький юлы буенда торф яна икән. Сүндереп булмый, ди. Җир астыннан янып бара да өскә бәреп чыга, ди. Больницаларда урын юк, ди. Астма белән авыручылар чебен шикелле кырыла, ди.

Төтен исе минем йөрәгемә ярамый.— «Ә үзең караваг аягы шикелле мускулсыз беләкләрең белән хатыннарга сырышасың»,— дип җирәнеп куйды Рахманкулова.

Эшли торган җиренә барып җиткәнче тәмам арыган иде ул.

Институтта да һаман шул кайгы иде. Горький юлы буенда торф яна. Сүндереп булырлык түгел. Сазлыкларны киптереп бетергәннәр. Сазлык кирәк нәрсә икән ул. Табигатьтә артык, кирәкмәгән нәрсә юк. Экологик бәйләнеш... Сүз һәм сүз, сүз һәм сүз...

6

— Әти, нигә сөйләмисең? Нигә туктадың? Минем әбием дә урамда ялан аяк йөриме?

— Син уянып та өлгерденмени әле? Кичә бик соң йокыга киткән идең бит. Йокла, кызым, йокла, яме.

— Минем өйгә кайтасым килә. Әниемне сагынам,— Кәримә тыелып кына еларга кереште.

«Әнисенең тәэсире»,— дип уйлады Габдрахман. Мәрьямнең күп сыйфатлары Кәримәдә дә бар иде. Тынгысызлык, киеренке яшәү, каза булыр дип инстинктив куркып яшәү әкренләп балага да күчә башлаган иде инде. Әти-әнисенең сыйфатлары балага күчкән геннарга да язылган бит. Кызын юатыр өчен Габдрахман тагын сөйләргә кереште.

— Безнең урамдагы йортларның бакчалары инешкә төшә. Инеш аръягында — таулар. Аларның исемнәре нинди матур: Урындык тау, Бакыр тау, Карагыш кулы. Карагыш кулы дигән тау астыннан чишмә бәреп чыга. Суы салкын, чиста, көмеш кебек.

— Тау астында водопровод күмгәннәрмени?

— Күммәгәннәр. Су үзе саркып чыга. Яңгыр яуганда җиргә сеңә дә чишмә булып саркып чыга.

— Җирдән чыккан су чиста буламени? Җир астыннан чыккан су балчыкка буялган була. Андый суны эни эчмәскә кушты. Кайнатмаган су эчсәң, авызыңа чирләтә торган микроб керер, диде.

— Чишмә суында микроб юк. Әйдә, йокла. Чишмәнең суы нинди икәнен кайткач күрерсең әле. Әле иртә.

— «Кайткач» түгел, «баргач».— Бала юри бәхәс кузгатырга тырыша иде. Габдрахман кызын кысып кочаклады, бармаклары белән аның йомшак чәчен араларга кереште. Бераздан сабыйның буыннары йомшарып китте.

Йоклаганда бала шул кадәр газиз, шул кадәр кадерле була иде. Йоклап яткан сабыйга карап торганда ярату җелекләргә үтеп керә иде. Хис йомшарудан күздән яшь тәгәрәп чыга. Нәни беләкләр әтисенең муенына сырышкан. Йоклап яткан баланың йөзенә карау белән җир йөзендәге ызгышлар, кансызлыклар бетә, юкка чыга иде. Бала йоклаганда вагон тәгәрмәчләре дә тавышсыз тәгәри, тимер вагон ефәк чатырга әйләнә.

Кинәт Габдрахманның баланы уятып сөйләшәсе килә башлады. Ялгызлыкка түзеп булмый — ямансу. Бала якынлыгы ямансулыкны тагын да көчәйтә иде.

Поезд Рузаевкага килеп туктады. Ике кеше татарча сөйләшеп коридордан уздылар. Габдрахман Мәрьям белән русча сөйләшә иде. Уйлаганда, фикер йөрткәндә дә рус сүзләрен куллана иде ул. Авылга кайтып бер ай торса, исәпләгәндә һәм фикер йөрткәндә татар сүзләре кулланыла башлый. Мәскәүгә әйләнеп кайткач, эшләгән җирендә еш кына сизмәстән татарча сөйләшә башлый иде Габдрахман.

Яки менә Мәскәүдән авылга кайтканда: Казан вокзалына килү белән беренче мәртәбә татарча сөйләшкән кеше тавышы ишетәсең. Поездга утыргач та вагонда берме, икеме, кай вакытларда, бәхетеңә

каршы, татарча сөйләшеп барган биш-алты кеше очрый. Бөгелмәгә якынлашкан саен таныш «и туган тел, и матур тел» ешрак ишетелә.

Поезд Рузаевкада озак торырга ниятләде булса кирәк. Әле һаман кузгалырга исәпләми. Габдрахман урыныннан торды. Чалбарын киеп коридорга чыкты.

Көн саен эшкә йөргәндә аруыңны сизә алмыйсың. Чөнки арып-алҗуга да күнегеп була. Адәм баласының күнекмәгән нәрсәсе юк. Ялга чыгып, үз иркеңә яши башлау белән тәмам хәлдән тайганлыгыңны сизеп аласың. Кичәге дәрт, авылга кайту белән канатлану сүрелә башлаган иде. Тәндә нинди дер хәлсезлек. Баш миңрәүләнгән. Кыймылдасы да килми. Калган гомерне кыймылдамыйча, ятып үткәрәсе килә.

Габдрахман перронга төште. Станция буш. Тирә-юньдә төнге сизгер тынлык. Пакгауз артында ипле генә дөпелдәп мотор эшләп тора. «Ике тактлы двигатель»,— дип искәреп куйды Рахманкулов. Вагон көпчәкләренә озын саплы чүкеч белән бәргәләп перроннан обходчик узды. Кызыл фуражкалы чандыр бер бәндә дежурка ишегеннән гәүдәсен яртылаш күрсәтеп, сары флаг сузды. Проводниклар да сары флаг тоткан кулларын перрон ягына суздылар. Поезд теләр-теләмәс кенә урыныннан кузгала башлады.

Икенче мәртәбә уянганда поезд Мәләкәскә килеп җиткән иде инде. Пассажирлар вагонга тозлы кыяр, карлыган, җиләк ташыйлар. Кайнар бәрәңге сатучы хатын тәрәзә астыннан кычкырып узып китте. Мәләкәстән кузгалу белән Габдрахман кызын туалетка кертеп юындырды. Проводниктан чәй сорап алды да Мәрьямнең юлга әзерләгән ашамлыкларын сумкадан алып өстәлгә куйды. Ипи, сыр, пешкән ит. Һәр ашамлык пөхтә итеп кәгазь салфеткага төрелгән. Валидол савытына салган тоз да бар. Кәримәнең яраткан зефиры да. Мәрьямнең юлга дигән ризыкларны шул кадәр җентекләп әзерләве кичәге рәнҗүне бераз йомшартып җибәрде. Һәркемнең үз иркен сакларга хакы бар. Авылга кайтырга теләми икән, көчләп күндерүдә ни файда?

Тәүлек тулганда, поезд Бөгелмәгә килеп җитте. Перронга төшкәндә төн урталары узып бара иде инде.

## 7

Институтның тел секторындагы бердәм коллектив төш вакыты җитеп, ашау турында кайгырта башлау белән берничә төркемгә бүленә иде. Һәр фәнни хезмәткәр тамак ялгау проблемасын үзенчә, оптималь вариантта хәл итә. Һәркем үзе уйлап тапкан ысулны яклый, мактый һәм башкаларныкыннан артык күрә. Фән кандидаты, аристократ Теодорин үзенең «Жигули»енә дусты Лисицынны утыртып, ресторанга тая. Аңа рестораннан башка җирдә ашау мәсхәрәле тоела. Кыйммәтле күн куртка, вельвет чалбар киеп, иң соңгы модадагы галстук тагып ничек ашханәгә кереп булсын? Сарык арасына кергән бүре шикелле күренергәме? Гөлшат Аванесовна Бутко белән фән докторы һәм секторның җитәкчесе Жорес Әхмәтович Буйнаковский диеташханәгә йөриләр. Фән докторы дәрәҗәсенә күтәрелә алган кеше урам чатына утырып ашаса да ярый. Калган фәнни хезмәткәрләр бергә җыелып секторда чәй эчәләр иде. Һәркем портфеленнән ашамлыгын чыгарып өстәлгә куя, кәгазьләрен читкәрәк этәреп ташлый, өстәл тартмасыннан фарфор чынаяк ала. Юрганыңа карап аягыңны сузасың, күлнең тирәнлегенә карап чумасың. Кыйммәтле, зур мохер юрган ябынып, искиткеч тирән күлдә яшәүче өлкән фәнни хезмәткәр, иң яшь кандидат Инна Ивановна Ярославцева иде.

Менә бүген дә Мәрьям чәй кайнатып кергән арада Инна өстәленә өеннән алып килгән ашамлыкларны күргәзмәдәге шикелле итеп тезеп

куйган. Балык уылдыгы ягып ясаган бутерброд, семга бутерброды, ветчина бутерброды, кыздырылган тавык боты, бал, ике апельсин, салат, яшел кыяр, помидор, җиләк. Кечкенә генә порцияләр — Инна Ивановна фигурасын саклый. Ярославцеваның чынаягы японныкы, зәңгәр, аждаһа рәсеме төшкән. Чынаякны яктылыкка тотып карасаң, төбендә чибәр кыз күренә. Инна Ивановнаның һәр әйбере иң югары сыйфатлы, чиксез кыйммәтле күлмәге, итеге, каләме, төймәсе, ире, квартиры, эте, фәнни эш бүлешкәндә эләккән темасы — һәр нәрсәсе. Хәтта ул туалетка да чит илдә эшләнгән кәгазь белән йөри, сумкасына салып өеннән алып килә. Ире бик зур урында. Теләсә кайчан, теләсә кайсы илгә, күпмегә дә командировкага китә ала. Секторда эшләүчеләр арасында иң бәхетле хатын — Инна. Иң бәхетле, иң рәхәт, шат яшәгән кеше. Бары тик кечкенә генә бер күңелсезлек бар аның тормышында — Инна Ивановна үле бала таба... Секторда эшләүчеләр шушы хатынны, ни кадәр тырышсалар да, чын күңелдән кызгана һәм ярата алмыйлар иде. Болай, тыштан алар яраткан булып кыланалар, туктаусыз комплимент яудырып торалар, ләкин нигәдер ихтирамлый алмыйлар.

— Бу ашамлыкларны, Инна Ивановна, ирең эшләгән җирдән китереп торалармы? Ул бит спецпаек алырга тиештер, әйеме? — диде Теодорин секторның иң яшь, иң матур кандидатына. Инна гаҗәп матур итеп елмайды:

— Господи, Борис Израилевич, сез бит чын интеллигент. Интеллигент кеше, чын джентельмен мондый сорау бирергә тиеш түгел.

— Борис Израилевич, нишләп бүген ресторанга бармадыгыз? Принципка хыянәт итү түгелме соң бу? — диде Мәрьям Теодоринның чәй эчеп утырганын күреп.

— Бик эссе, иптәш Рахманкулова. Гаҗәп эссе. Аппетит юк. Сезнең группа чәйдән соң ярты сәгать һава сулап керә. Мин дә сезгә иярергә уйладым бүген.

— Ял алырга кирәк иде, Борис Израилевич, — диде лаборант Маша. Башкаланың элитасы хәзер Кара диңгез буенда, Адриатиканың данлыклы курортларында.

— Мин беләм Боречканың нигә ялга китмәгәнен, — диде Инна назланып. Назланганда аның матурлыгы бермә-бер арта иде. — Теодорин хатынын санаторийга озатты. Ул югында хәзер үзе ял итә.

— Инна Ивановна, сез һәркемнең гөнаһлы якларын беләсез. Ә менә Мәрьям Гыйлемдаровна, үзе эчкерсез кеше, башкаларны да изгегә санап йөри.

— Сезнең Изге Мәрьям мадоннагыз кичә кич ирен авылга озатты. Бүген ул холостячка, — Ярославцева күкрәкләрен дерелдәтеп көләргә кереште. Ул көлгән чакта ирләрнең касыкларында ут кабынып китә иде.

Өстәлдәге калган ашамлыкларны җыештырып, һава суларга чыга башладылар. Баскычтан төшкәндә Теодорин Мәрьямне куып җитте:

— Инна тыңлап торганда әйтергә кыймадым. Таганка театрына ике билетым бар. Есенинның «Пугачев»ын куйганнар. Премьера. Сәгать кичке җидедә башлана. Теләсәгез, рәхим итегез.

— Иремнең ялда икәнен ишетеп чакырасыз инде, әйеме?

— Мәрьям Гыйлемдаровна, ай-яй-яй. Белми идем сезнең шикле кеше икәнлегегезне. Чакыруымның сәбәбе шул, сезнең белән карасам, соңыннан рәхәтләнеп фикер алышып булыр. Хатыным санаторийдан кайткач, Рахманкулова белән театрга бардык дип яшермичә әйтә алам мин. Ул сезнең вөҗданлы кеше икәнлегегезне белә, көнләшмәячәк.

— Инна, Борис Израилевич мине театрга чакыра, — диде Мәрьям аларның артларыннан Ярославцева куып җиткәч, — барыйммы икән?

— Рахманкулова баш тартса, үзем барам. Кайсы театрга, Боречка? — диде Инна Ивановна назланып.

— Таганкага. Ничә ел эзәрлекләп, ниһаять, билет эләктергән идем, хатыным ялда чакка туры килде.

— Мине үпкәләтәсегез килсә, Мәрьямне чакырыгыз. Мәрьямгә сез һәр вакыт любезность ясап торасыз. Бу юлы мине алып барырга тиешсез. Баш тартсагыз, дуслык мәңгегә өзелә, — диде Ярославцева. Назлы итеп әйтелсә дә боерык иде бу. Катгый боерык иде. Иң югары сыйфатлы нәрсә анык булырга тиеш. Соңгы вакытта Таганка театры иң югары сыйфатлы тамаша санала иде. Моңа Мәрьямнең ачуы кабарып китте. «Комсыз, туймас тамак, — дип уйлады ул. — Көче житсә, кояшны да гел үзе өчен генә яктырттырып торыр иде». Ачуына бирелеп, сизмәстән Мәрьям әйтеп ташлады:

— Спектакль ничәдә бетә икән? — Нәкъ шушы мизгелдә ире искә төште. «Юк, мин болай гына сорадым», — дип баш тартырга уйлап торганда Теодорин мәсьәләне хәл итеп үк куйды:

— Курыкмагыз, Мәрьям Гыйлемдаровна, соңга калынмый. Спектакль сәгать тугызлар тирәсендә тәмамлана.

Ярославцеваның бите матур итеп елмая иде, ә маңгай астыннан ике зәңгәр фирәзә лазер уты шикелле Мәрьямгә таба чаткы ата.

— Дөрес, Борис Израилевич, фәрештә хатын белән театрга баруның бер гөнаһы юк. Татар хатыннары ирләренә гаҗәп тугрылыклы булалар алар.

Мәрьямнең йөрәгендә ике ачы тойгы кайный иде: аянычлы җиңү һәм тагын да аянычлырак югалту...

## 8

Бөгелмә вокзалы бәләкәйләнгән. Бөгелмә кешеләре, элек, Габдрахман бала чакта, бик тә шәһәрчә иделәр. Хәзер алар провинциалларга тартым.

Ике кулына ике чемоданын күтәреп, Рахманкулов вокзал каршындагы мәйданга төшә башлады. Бөгелмәгә кайтучылар аз иде. Алар минут эчендә каядыр саркып беттеләр. Кәримә курчагын кочаклаган килеш әтисенең чалбарына ябышып бара. Әле йокыдан уянып житмәгән. «Читтән карап торган кешегә тол ир булып күренә торганмындыр инде, — дип уйлап куйды Габдрахман. Авылдашлар төпченәчәкләр: Кайчан кайттың? Бәй, үдең генә кайттыңмени?» Бала житәкләгән ир нигәдер кызганыч күренә. Бигрәк тә кыз бала житәкләгән ир. Шушы авылга кайтулар тормышның астын-өскә китереп ташлый. Әмма кайту булмаса, яшәүнең кирәге дә бетәр иде. Габдрахман армиягә киткән көннән башлап авылга кайту өмете белән яшәде. Нindидер көч кайтармый шәһәрдә тота, икенче бер көч авылга суыра. Икесе дә аяусыз, бер-берсе белән килешә алмый торган көчләр.

Вокзал каршында, элекке заманда ат бәйли торган жирдә, машиналар тезелеп тора. Ат заманы булса, Габдрахман Караяр атын шундук танып алыр иде. Һәр авылның үзенә хас атлары, арбалары, ат жигү ысулы бар иде. Машиналар бер стандартта. Сахалинда да, Одессада да һәм Караярда да бер төсле машиналар йөри. Машиналарга әһәмият бирмичә, шоферларга гына карап барды. Караяр кешесенә охшашлы шофер юк иде монда. Авылдашын күрү белән танып алырына ышана иде Габдрахман. Ләкин бу юлы Әтәмби егетенең яныннан узып китте. Аны каршыларга килгән шофер үзе дәште:

— Габдрахман абый түгелме соң бу? Танымай торам икән. Әйдә, утырыгыз, — шофер Рахманкуловның кулыннан чемоданын алып машинасына урнаштыра башлады. Егетнең чәче кызларныкы шикелле

озын, джинс чалбар. Менә нигә Габдрахман бу егетнең яныннан узып киткән икән. Бу монда Караярга да барып житәр дип кем уйлаган.

— Акыллым, сез кем малае?

— Мәдинә малае,— диде шофер һәм Рахманкулов аның елмаюыннан күрше егете икәнлеген абайлап алды. «Сугыштан соң барлыкка килде әнисе малайлары. Элек Караярда әти балалары гына бар иде», — дип уйлады ул.

Мотор кабынды, машина, пошкырып, урыныннан кузгалды. Йортларның тәбәнәклеге тагын Габдрахманның эчен ачыттырып алды. «Мәскәү масштабыннан котылырга тырышырга кирәк»,— дип уйлап куйды ул. Армиягә киткәнче мондагы йортлар шундый биек иде. Кече Бөгелмәнең үре шул кадәр текә иде, Бөгелмә үзе гаҗәп ерак иде. «Күк йөзе искиткеч зәңгәр иде, ипи шул кадәр тәмле иде. Ә гармун тавышы? Гармун тавышы кичләрен үзәкләрне өзеп яңгырый иде. Шундый моңлы иде ул чакта тальян гармунның тавышы!» Ә хәзер шәһәр читендәге сыек утлар чагылып кына үттеләр. Кече Бөгелмә үре сизелми дә калды. Ә элек бу шәһәрнең спирт заводына ашлык ташучы атларның җаннарын ала иде бу каһәрле үр. Патшалар һәр яулап алган җиргә спирт заводы салдыра килгән...

Баулы юлыннан читтәрәк, сул якта, тонык утлар күренде. Авылның исеме онытылган иде.

— Бу авылның исеме ничек әле? — дип сорады Габдрахман Мәдинә малаеннан.

— Бәрәшәү, икенчесе Исәкәү.

Олаудан кайткан ирләрнең шушы авыл янына туктап ат ашатканнары турында тыңлап утырганда «Исәкәү» һәм «Бәрәшәү» романтикалы күңелгә «Рио-де-Жанейро», «Лас-Пальмас» булып яңгырый иде. Иван Грозный заманында барлыкка килгәннәр бу авыллар...

Чуваш Наратлысы уңда калды. Газик Никкүчтем үренә күтәрелә башлады. Калкулыкка менеп житкәч, Ык үзәне ачылачак. Габдрахманның йөрәге рәхәт булып әрни, ачыта иде шушы таныш, газиз калкулыкларга караганда. Нәрсә соң бу туган авылга кайту? Туган авылга кайту — ләззәтле газап, газаплы ләззәт, утлы моң. Катарсис бу. Ә катарсис сүзенең татарчасы да, русчасы да юк. Якынча пакьләнү дип тәрҗемә итәргә була, ләкин тулы мәгънәсен бары тик шушы грек сүзе генә ача ала. Туган авылга кайту — шәһитләрнең гашүрә бәйрәме. Туган авылга кайту булмаса, тыныч яшәп булыр иде. Яшәп булыр иде, әмма үзеңнең кеше затыннан икәнлегеңне белмәс идең. Дөнья гизүләр, эш алыштырулар, сагынулар, җирсенүләр, динамит шикелле кабынып киткән гаугалар шушы авылга кайту белән бәйләнгән. Бер якта яшәү, икенче якта — авыл, шул ике нәрсә Габдрахманның йөрәге аша бергә тоташкан.

Уң якта шомлы төнге урман. Промысел насослары — сәмруг кошына охшашлы тимер җәнлекләр җирнең маен суыралар. Нәрсә соң бу туган авылга кайту? Үзәктән ераклашкан саен тәкъдирнең рәхимсез көчен тою ул.

Акбуаның утлары шәм тотып яуга баручы гаскәр шикелле машина яныннан йөгереп уздылар. Иске Баулы утлары үтеп китте колхоз газигы яныннан. Нефть көчле чакта салынган монтаж участоклары, бараклар сырпаеп калды сул якта.

Киртә белән урап алынган түбән оч зираты. Сәрби агачлары, моңсу каеннар астында, кызыл балчыкка җиткереп казылган тар ләхетләрдә Караярның ничәмә буын тарихка кермәгән кешеләре. Поклыйлар.

Ниһаять, Уртамәй үре — авыл үзәге, Караярның кыл уртасы. Кибет — авылның бердәнбер таш бинасы. Клуб, авыл советы. Машина үр төшә. Инеш күпере тәпән тавышы чыгарып дөпелдәп калды. Нер-

валар скрипка көйләгәндә тартылган кыл шикелле зыңлап, сыкрый лар...

Машина өянке астына килеп туктады.

— И-и-и, улым! Бәбкәм! — Тире һәм сөяк, картаюдан куллар ки беп беткән. Бишектән бирле таныш бармаклар... Йөрәктә ләззәтле у дөрли. Күзләрдә — яшь.

«И-и-и, раббым! Бу бит минем малаем түгел... Өлкән бер ир. Ми нем Габдрахманымның битенә төк тә чыкмаган иде әле. Ә үзе минем улым, тавышы да шуныкы, елмаюы да. Нәкъ әтисенең елмаюы...»

— Ә килен кая? Килен кайтмадымени?

— Ял бирмәделәр, — диде Габдрахман авызыннан чыккан ялган ның исен тоеп.

— Бусы кем? Менә кем кайткан икә-ә-ән, — карчык машинадан төшеп килгән Кәримәне күтәреп алды: — И-и-и, бәбкәм!

Кәримә әбисеннән ычкынып әтисенә сырышты.

— Әти, нәрсә сөйли ул? Мин аны аңламыйм.

— Кызым, әбиең ул, татарча сөйләшә. Зур үскәнсең, ди. Бәбкәм, ди. Яратам, ди.

— Нигә ул безнеңчә сөйләшми? Безнеңчә сөйләшсен. Мин аннан куркам.

— Бәрәкәт! Татарча үрәтмәдегезмени? И ходаем, ничек сүләшер без икән инде?

— Кайгырма, үзем тәрҗемә итәрмен, — диде Габдрахман әнисен юатырга тырышып. Бумажнигын ачып, шоферга акча сузды.

— Кит аннан, кит. Нишләп кунак кешедән акча аласың ди, — Мә динә малаеның хәтере калды. Ул машинасын фырылдатып урыннан кузгатты.

Ниндидер киеренкелек сизеп өйгә керделәр.

## 9

Мәрьям Теодоринның машинасына утырмады. Үгетләп тә карады Борис Израилевич, тәнкыйтьләп тә. Файдасы тимәде. Мәрьям кырт кисте:

— Ирләр янына утырып йөрергә тартынам мин.

Теодоринның күңелендә үкенү туа башлаган иде. «Иннадан баш тартырга кирәк булмаган, ахры?» Гомумән, Таганка театрына ул те-ләгән кешесен чакыра ала иде. Соңгы вакытта башкала интеллигент-лары Таганка театры дип акылдан шашалар иде. Әллә мода, әллә, чыннан да, шедевр күрсәтәләр? «Театрдан соң күз күрер. Ул да бит бары тик хатын кеше генә». Ә хатын-кыз белән эш итүдә Теодорин фән докторы гына түгел, академик иде. «Аларның күбесе башта менә шушылай кылана. Бәяләрен күтәрү өчен кыланалар», — дип уйлады Теодорин һәм тынычланып, ялгызы үзәккә таба юл тотты. Мәрьям белән театр янында очрашырга булдылар.

Мәрьям метродан төште. Монда да эссе һәм бөркү иде. Таш ко-рылмалар, урам асфальты көяшка ут кебек кыза да кичләрен көндез җыйган эсселекне кире кайтара. Бәлки Теодоринның машинасына уты-рып барса да берни булмас иде. Машинада болай тынчу булмый бит. Бәлки чит ир янына ялгыз утырып бару тынчу метрода кысылып ин-тегүдән дә кыендыр? Хәзерге заман хатыннары гадәти санаган күп нәрсәне кабул итә алмый иде Мәрьям. Ана сөте белән кергәндер ин-де. Иптәшләре аның искечә гадәтләреннән көләләр иде. Кайберәү-ләр, киресенчә, ихтирамлый иде.

Таганка станциясенең перронында бер төркем яшь кыз муеннары-на каты кәгазьдән ясалган камыт аскан. Кәгазьгә эре хәрефләр бе-

ләр «Артык билетыгыз юкмы?» дип язылып куелган. Чибәрләр, яшьләр, модалы киенгәннәр. Студентлар булса кирәк. Нинди хәл бу? Яшьләр теләгән нәрсәләрен, кыенлыкларга әһәмият бирмичә, барыбер табалар. Яшь кызлар арасында тәмәке тарту, ресторанга йөрү гадәти санала башлады. Нинди кыйммәтле киемнәр кияләр үнҗиде-унсигез яшьлек кызлар. Хәйран калырлык хәл бу. Театрга керәселәре килә икән, берниндн авырлык алдында да туктап тормыйлар алар. Данлыклы театр дип акылдан язарга ярыймы икән соң? Яшьләр генә түгел, Мәрьямнең яшьтәшләре арасында да шундый кешеләр бар. Мәсәлән, Инна Ярославцева. Кирәк нәрсәсен кулга төшерү өчен вөҗдан дип тә, әхлак дип тә тормый. Таба. Муллык, кыйммәтлелек белән ләззәтләнеп яши. Әз генә булса да әдәп сакларга кирәк иде. «Ә үзең саклыйсыңмы соң? Ирең, синең күңелеңне күреп, бала карау мәшәкатен үз өстенә алды. Ә син? Әллә кайтып китәргә инде?» — дип уйлап алды Мәрьям метродан чыккач.

Теодорин аны метро ишеге янында көтеп тора иде. Өстен дә алыштырып өлгергән. Замша курткасын салып, кичке костюм кигән. Галстук урынына «күбәләк» таккан. «Артык билет юкмы?» — дип өстенә ташланырга торган театраллар гаскәре Таганка театрын урап алган иде.

— Менә монда, — Теодорин Коммунистическая урамы ягына таба ымлап күрсәтте. — «Кама» исемле ресторан бар. Әллә тамак ялгап, авыз чылатып чыгабызмы?

— Рәхмәт, минем ашыйсым килми, — диде Мәрьям. — Миңа шул кадәр уңайсыз. Урлашырга барган кеше шикелле сизәм үземне.

— Господи, Мәрьям Гыйлемдаровна. Биш ел бергә эшлибез. Бер ганлә бит. Безгә күптән аралашырга, бер-беребезгә парлап кунакка йөрергә кирәк иде. Вакыт таба алмыйбыз. Эш тә эш, эш тә эш, ә гомер үтә, — үзе уйлады: «Юк, бу хатынны чакырмаска кирәк иде. Таганкага алып барам дисәм, Жаклин Кеннеди да баш тартмас иде. Үкенүнең бер файдасы юк. Киресенчә, үкенү — ялгыш өстенә ялгышлык». Ә үзе Мәрьямгә сөйләргә тотынды:

— Безнең яшәү баштанаяк конформизмга бәйле. Нәрсә теләгәнебезне белмибез, белсәк тә үти алмыйбыз. Башкалар нәрсә теләсә, шуны телибез. Шулай, башкаларга карап, гавам ихтыяҗына яши торгач, шәхеслегебезне тәмам югалтып бетерәбез.

Шушы турыда сөйләшеп фойэга керделәр һәм залга үттеләр. Бераздан спектакль башланды.

Декорация дә, пәрдә дә юк иде бу театрда. Шәп-шәрә сәхнә. Уртада ит чаба торган зур түмәр. Түмәр янынннан залга таба сөзәкләп җәйгән такта. Тамашачылар тын да алмыйча, шушы түмәргә карап утыралар. Тамашачы искиткеч зур, хәйран калырлык хикмәт көтә. Көтмәс иде, билетны шундый зур авырлык белән тапты. Өстәвенә, театр каршында керергә өметләнеп торган меңләгән гавамны күрде. Гадәти спектакльга бу кадәр ашкынып ташланмаслар иде.

Ут сүнде. Залны тылсымлы караңгылык чорнады. Нәкъ шушы мизгелдә ике яктан ике прожектор уты сәхнәдәге түмәрне тотып алдылар. Балалайканың бер кылы стаккатода «Иван кода, ишеттеңме, халык нәрсә сөйли?» — дигән борынгы көйне көйли. Балалайка тавышы турыдан-туры тамашачыларның нервыларына бәрелеп тора. Туздан киндер ыштан гына кигән шәрә мужик сәхнәгә атылып килеп чыкты да баш кисә торган зур балтаны түмәргә чапты. Сәхнәнең икенче ягыннан чыккан мужик та балтасын түмәргә каптырып юк булды. Сөзәкләп куйган тактадан тамашачыларга таба кисек башлар тәгәрәп төшә башладылар. Халык телсез калып, тораташ булып катты. Нәрсә бу? Балалайка тоткан ике дивана сәхнәгә чыгып частушка әйтергә керештеләр: «Иван кода, ишеттеңме?..»

Тамашачы режиссер кулында иде. Залда утыручыларны хәзер нәрсәгә дә ышандырып була. Сәер, аңлап булмаслык символика тамашачыны гипнозлады.

Артистлар ялан аяк, күлмәксез, алама киндер ыштан киеп кенә сәхнәгә чыгалар иде. Монологларын каргыш шикелле итеп көчле пафос белән кычкыралар. Монолог сөйләгәндә тәннәреннән шарлап тир ага.

Мәрьямнең хәтерендә ике эпизод гаҗәп ачык сурәтләнеп калды. Әби патшаның идарә итеп утыруы һәм Пугачевны бәйләп патша гаскәрләренә тапшырган чак.

Власть өчен җанын, иманын бирергә әзер булган, кырыктан узган хатын. Аны куштаннар чорнап алган. Власть комсызлыгы куштанлык тудыра. Бу ике сыйфат үзара шул кадәр бәйле икән, кайда буйсындыру, кайда куштанлык икәнен аерып та булмый. Икейөзлелек идарә итүчедә, икейөзлелек тәхеткә тугрылыклы булырга тырышып куштанланучыларда. Әби патша халкына бәхетле, мул тормыш биргән булып күз буйый, аның тирәсендәгеләр тырышкан булып кылана. Әби патшаның идарә итүен күрсәткән эпизодта властьның икейөзлелек, куштанлык, ялган тудыруы турындагы хакыйкатьне ачып салдылар.

Бергә азатлык өчен көрәшкән кешеләр Пугачевны тотып патша кулына тапшыру турында киңәшмә алып баралар. «Ул безне гаиләбездән аерды», — дип кычкыра берәү үзенең сатлык җан булуын яшерер өчен. «Азатлык бирәм дигән булып, ул безне иректе тормыштан аерды. Минем буаз сыерым, ярты дисәтинә җирем бар иде. Ул мине җиремнән, сыерымнан аерды», — дип күкрәгенә суга-суга кычкыра икенчесе. «Минем йортым, тәрәзә каршында үскән тирәгем бар иде. Ул мине йортымнан, тирәгемнән мәхрүм калдырды», — дип кычкыра өченчесе. Әле кичә генә азатлык өчен көрәшкән сугышчылар юлбашчыларын бәйләп патша генералына тапшырырга алып баралар...

Тамашачылар ике сәгать сәхнәдә барган вөҗдан белән вөҗдансызлык, иман белән имансызлык көрәшен карап утырдылар.

## 10

Элек бу түшәм шул кадәр биек иде. Бүлмә киң, иркен иде. Түшәм тәбәнәкләнгән. Бүлмә тар, кысынкы хәзер.

Фәриха карчык улы кайтуына өйне бизәп куйган. Яңа чаршавын корган, өй әйләнәсенә кашагалар, тәрәзә арасына кызыл башлы сөлгеләр элгән. Җиһазлар, язмышларына зарланмыйча, тыйнак кына эленеп торалар. Габдрахманның ничә мәртәбә җиһазларны яңартыйк дип әйткәне булды. Ничә тапкыр карчыкны шәһәргә күчәргә үгетләп карады. Юк, гомер буе башын да күтәрмичә эшләп йөргән карчык соңгы сулышына кадәр шушылар арасында булачак. Җиһазларын да яңартмаячак. Җитенен үзе үстергән ул, җебен үзе эрләгән, киндерен үзе суккан. Кул көче генә түгел, яшьлек дәрте, кыз чакның бәхете, шатлыгы, өметләре кереп калган бу әйберләргә. Герман сугышы, революция, гражданнар сугышы, колхозлашу, ватан сугышы — менә нинди чорларда булып үткән вакыйгаларның шаһиты бу чаршау, сөлгеләр, кашагалар. Бу өйдә тулып бала үскән, ашаганда өстәл янына сигез кеше җыелып утырган чакларны хәтерли торганнардыр әле шушы җиһазлар.

Габдрахманның әтисе салган йорт, ул юнган бүрәнәләр. Алар йөз төрле тарих, йөз мең хатирә саклыйлар. Менә нигә картайган көнендә карчык кышкы бураннарда чишмәдән су ташып, утын кисеп, мич ягып, интегеп яши. Какшап беткән иске агач караваот та, чалыш аяк-

лы өстәл дә, тәрәзә төбендә елап утырган тамчы гөл дә карчыкның тормыш юлдашы. Шушы аксак өстәлгә карау белән ире Бакирның утынлыкта юнышып азапланганын күз алдына китерә торгандыр әле мескен карчык. Юк, бер генә әйберен дә чыгарып ташлый алмый ул. Бу йорттагы җиһазлар күптән әйберлекләрен югалтып тарихка, музей экспонатына әйләнгәннәр инде. Фәриха карчык музейда яши... «Нишлисең, нишлисең, нишлисең бит...» — дип өзгәләнде Габдрахман шушы әйберләргә карап. Тамак төбендәге утлы төерне йотып булмый — сулыш алырга комачаулый.

Ят, сәер җиһазлар Кәримәгә шом салдылар. Ул сагаеп кына матчага беркеткән кашагага карап тора иде:

— Әти, әнә теге чүпрәкне нигә түшәмгә элгәннәр?

— Чүпрәк түгел ул, кызым, кашага.

— Кашага нәрсә соң ул?

Чыннан да, нәрсә соң ул кашага? Кем уйлап тапкан аны? Нинди тормыш тудырган искиткеч матур итеп чиккән тукыманы? Меңләгән, йөз меңләгән рус сүзе арасында шушы яшел яфраклы сары чәчәкләр төшкән киндер кисәгенең нәрсә икәнлеген аңлатырлык сүз юк иде. Ә Кәримә татарча белми — менә кайда ул аптыраш... Шушы тукымага әбиеңнең матурлыкка омтылуы, тырышлыгы, таланты кергән дип әйтергәме әллә? Абстракт сүзләр. Бала яшь әле, аңлый алмас.

— Кашага — чигүле тукыма. Кыз чагында әбиең үзе чиккән, — диде Габдрахман ахыр чиктә.

— Әби кеше дә яшь кыз була аламыни?

— Әйе, кызым.

— Кашаганы магазиннан сатып алырга әбиемнең акчасы булмаганмени?

Тагын психологик киртә. Талантың, сәләтең, зәвыгың кергән нәрсәнең магазин әйбереннән кыйммәтрәк торганын балага барыбер аңлатып булмас.

— Нәрсә сорый ул? Әллә бәбкәмнең ашыйсы киләме? — диде Фәриха карчык тынычсызланып.

— Кашагаларны карый. Аның мондый әйберләрне күргәне юк иде әле.

— И ходаем, аларның карар җире калмады инде. Таушалып беткәнләр,— диде карчык борчыла төшеп.

Кәримә әтисенең колагына нәрсәдер әйтте. Әтисе аңа ишек ачты.

— Фонарь алыгыз. Кирәк булса дип өйалдына яндырып куйдым. Төз лапас астыннан үткәндә башыңны бәрә күрмә, улым. Караltылар басылды. Башымны иеп кенә йөрим.

— Әти, бу утны шешә эченә ничек тыгып куйганнар? — диде Кәримә, керосин фонарена күрсәтеп. Фонарьның куыгын, чыннан да, шешәдән ясаганнар иде. Габдрахманның әле дә хәтерендә. Киселәсе урынны керосинга манган җеп белән урап, шуңа ут төртеп, кызгач, салкын суга тыгып, шешә кискәннәре. Шушы фонарьны тотып Бакир агай төн урталарында малларга печән салып керә иде. Сыерның җилене тулгач, төненә өч-дүрт мәртәбә чыгыла иде. Шушы фонарьны ясаганда Габдрахманга алты-җиде яшь булгандыр. Әтисенең төнге юлдашы һаман исән, ә Бакир агай гүрдә. Берничә елдан Габдрахман әтисеннән өлкәнрәк булачак. Мәрхүм үзен саклый белмәде инде. Ике сугыш, окопта туңып, ревматизм эләктерү һәм колхоз подвалына дезинфекция ясаганда агуланып, үпкәсен яндыру. Намуслы кешегә яшәү катлаулырак шул.

— Аның эчендә баба-яга юкмы? Мин куркам, — Кәримә әтисенә сырышты.

«Ә әнкәй ничек өлгерә? Түземлеге ничек җитә? Җитмештән дә узды бит инде. Алтмыш ел бер генә көн дә камыт салып ял иткәне юк. Ул эрләгән җепләрне экваторга сузсаң, җир шарын ничә мәртәбә урап чыгар иде икән? Алтмыш ел бер караңгыдан икенче караңгыга кадәр. Зарлана белү юк. «Ирләр эшеме бу, хатыннарныкымы?» — дип ачыклап тору булмаган алар заманында. Кем нәрсә эшләргә тиеш икәнлеге ерак бабалар заманыннан ук ачыкланып калган булган.

Габдрахман белән Мәрьямнең бу ирләр эшеме, хатыннарныкымы дип баш ватуга күп көчләре китә. «Заманында ачык булган нәрсәнең серен нишләп югалттык икән без.— дип уйлады Габдрахман.— Күп эшне машина эшли. Ял озайды. Хатын белән кара-каршы утырып сөйләшергә вакыт табып булмый».

Шушы абзар-кураны, каралтыларны Бакир агай үзе салган. Каян тапкан ул вакыт. Җәен — кыр эше, кышын — мал карау, утын кисү. Габдрахманның бар нәрсәсе сатып алынган. Мебель — финныкы, суыткыч Чехословакиянеке. Хәтта бит сөртә торган сөлгеләренә кадәр магазиннан алынган. Үз кулы белән ясаган бер нәрсәсе юк аның квартирында. Күп җиһазлар кирәклектән түгел, башка кешеләрдә шундый җиһазлар булганлыктан, алардан ким булмаска теләп кенә алынган. Бәлки шуңа күрә, әйбергә ихтирам юктыр? Ә менә әтисенең үзе ясаган фонаре — юлдаш, ярдәмче. Сатып алган әйбернең җаны булмый шул.

Кәримә «алачык»тан атылып килеп чыкты:

— Әти, монда бүре бармы?

— Юк, кызым, юк. Юк хәзер бүреләр. Аларны кырып бетерделәр инде.

— Ә мин бүре тавышы ишеттем. Үкерә: у-у-у-у, — ди.

Фәриха карчык мичтән яңа чыгарган ит бәлешен кисеп азаплана иде. Өй эченә тәмле ит исе таралган. Җиз самавар бала чактан таныш моңлы көйне сызгырып утыра. «Табын тирәсендәге татулык». «Гаилә иминлеге көе», — дип уйлады Габдрахман. Нервыларны тынычландыра торган көй.

— Бу кайчан алынган самавар?

— Бирнәгә дип әткәй Мәкәрҗәдән апкайткан ие. Самаур картларда гына калды инде. Яшьләр чәй эчмәйдер, — карчык Кәриманең аркасыннан сөеп алды. — Инәкәң чирләп китмәгәндер бит, бәбкәм?

Бала күтәрелеп карады да әбисеннән читкәрәк шуышып утырды.

— Таза ул. Пыр туздырып эшләп йөри, — диде Габдрахман.

— Замана хатыннары кулларына шырпы кадалса да больниска йөгерәләр. Иркә яшәй башладылар. Синең сабакташың Оркыяны бүләкләп путүфкә биргәннәрие, бер көтү баласын иренә ташлап Кырымга китте барды. Кырым суының Ык суыннан ни аермасы бардыр инде? Безгә андый иркенлек тәтемәде шул. Ир күңелен күреп гомеребез үтте.

Габдрахман Мәрьям турында уйлый иде. Ул: «Исән булсак, киләсе елга бергәләп кайтырбыз инде», — дип әйткән иде.

Мәрьямнең кайтмый калуына Фәриха карчык та чын күңелдән, сабыйларча рәнҗи иде. Авылдашларының килене белән ачуланышкандыр дип уйлавыннан курка иде ул. «Минем кимсенәсемне белмәде микәнни. Миңа хурлык бит инде бу. Авыл кешесен санга санамавы шушыдыр инде. Борын чөя торгандыр. Әллә иренә ихтирамы сүнә башладымы икән? Картлык бит, и раббым! Аның бәхиллеген алмаенчы үлеп китсәң нишләрсең? Алла сакласын!»

Карчык улын да кызгана иде. «Ялгыз башы тырпаеп ничек кеше күзенә күренеп йөрер инде мескенкәем? Нәрсә уйламаслар. Аеры-

лышкан дип тә уйлаулары бар, алла сакласын. Ирләр сабыйлар шикелле бит алар. Ничек инде ир кеше бер үзе яшь алсын. Ичмасам, шуны аңларга кирәк ие. Йа раббым, мәрхәмәтеңнән ташлама!» — дип, ут йотып утырды Фәриха карчык ялгыз кайткан малаена карап.

— Кая ятасың, өйдәме, келәттәме? — дип сорады ул.— Армиягә киткәнче келәтне ярата иең бит. Мин сиңа шунда җәйгән идем.

— Инде ике тәүлек йокы күргән юк, — диде Габдрахман әнисенең келәткә урын җәюенә шатланып. Үзе уйлады: келәт ярата иден дип әйтүе «келәт» серен белгәнлектәнме икән? Ул чакта әни сизенгән идеме икән?

Кунакларын келәткә алып кергәч, җәйгән урынын ятарга уңайлы итеп йомшартты да балалар караватына күрсәтеп, сөйләп китте:

— Интернаттан сорап алдым. Интернат директоры синең сабакташың Фатима бит. Машина белән китертеп куйды. Габдрахманның кызына дигәч, бөтерелеп йөрде, балакаем. Бер бөртек картаймый үзе. Һаман матур, яшь киленнәр шикелле. Мескен, иреннән генә уңмады. Эчә. Эчкәч холыксызлана. Кай чакта яныма килеп хәлемне белеп китә.

«Келәт серен белә икән бу»,— дип уйлады Габдрахман. Аңа үкенечле һәм ямансу булып китте. Кем белгән бит? Әгәр ул дуамаллык эшләп, Фатиманы ташламаган булса, язмыш башка төрле булыр иде. Бәлки ул очракта авылдан мәхрүм булып та яшәмәс иде ул. Кем белгән бит...

Әнисе чыгып киткәч, Габдрахман ишеккә терәү салды. Кәримәне чишендерде, үпте, урынына яткырып, утны сүндерде.

— Әти, чормага елан асканнар. Кыймылдый.

— Курыкма, кызым. Елан түгел ул. Әбиең дару үләннәре җыйган.

— Әти, тәнемне әллә нәрсә тешләде. Әби безне монда кандаладан талатырга керттеме?

— Кем әйтте сиңа келәткә кандаладан талатырга кертәләр дип?

— Әнием әйтте.

— Ул әйтмәс. Ялгыш аңлагансыңдыр. Син фантазерка. Үзең уйлап чыгаргансыңдыр әле?

— Әнием мескен. Без булмагач нишләр инде ул?

Баланы бик озак юатырга туры килде.

Кәримә йоклап киткәч тә Габдрахман семья тормышының катлаулылыгы, ир белән хатын арасындагы мөнәсәбәтләрнең гаҗәп нечкә булуы турында бик озак уйлап ятты.

## 11

Мәрьям театр янында тамашачыларның таралганын карап тора иде. Театрдан чыккан кешегә дөнья алышынган шикелле күренә. Хисләреңне тетрәткән спектакльдән соң күп нәрсәгә озак төшенеп булмый. Әйбәт пьеса сине яңадан тудырып чыгара. «Теодорин нигә минем тирәдә бөтерелеп йөри икән? Яз көне ата үрдәк шулай кылана», — дип уйлады Мәрьям. Аның Теодорингә, бигрәк тә үзенә, ачуы килә башлады.

— Төнлә автобус сирәк йөри. Ә төн караңгы, айсыз. Хатын-кызга төннәрен ялгыз йөрергә ярамый. Исерек кеше, хулиган очравы бар. Мин сезне машина белән илтеп куям.

Мәрьям әллә нинди дәлилләр китереп карады. Колак та салмый. Менә култыклый ук башлады.

— Юк, юк, җибәрмим. Мин җаваплы. Төнлә әллә нәрсә очравы бар. Җибәрмим.

Мәрьямнең түземе бетте. Түзәр хәл калмагач, әйтте:

— Гафу итегез, Борис Израилевич. Минем беркемне дә күрәсем килми. Хәтта сезне дә. Гарык мин тигәнәк шикелле ябышып торган ирләрдән. Гафу итегез, ялгыз каласым килә.

— Рәхим итегез, рәхим итегез, Мәрьям Гыйлемдаровна. Рәхим итегез. Мин сезнең өчен генә. Сезнең өчен генә тырышам.

— Сау булыгыз, Борис Израилевич. Хәерле төн. — Мәрьям Таганка мәйданы аша йөгерә-атлый автобус тукталышына юнәлде. Артына борылып карарга курка иде ул. Борылып караса, Теодорин тагын тагылыр дип курка иде. «Тупас, дорфа, үзен әдәпсез тоткан ирләр мондый интеллигент сагыздан мең артык. Дикъкатеңне, зиһенеңне, теләкләреңне чорнап ала да җилем шикелле синең һәр күзәнәгеңә саркып керә башлый. Противно!» — дип уйлый иде Мәрьям тукталышта автобус көтеп торганда. — Ирең хыянәт итү чит кеше белән түшәктә яту гына түгел бит ул. Хыянәт чит ирнең сыйлыйм дигән булып биргән конфетын алудан башлана. Валлаһи шулай. Тән белән генә түгел, күңел белән дә хыянәт итеп була. Хыянәтнең зуры, кечкенәсе юк».

Мәрьям киткәч, машинасына утырмыйча Теодорин бик озак театр янында басып торды. «Әгәр театрдан чыгу белән җибәргән булсам бу кәнтәйне, — дип уйлады ул, — утыртып алып кайтыр кеше таба идем мин». Әйе, дип уйлый Теодорин, кем дә кире какмас иде. Чыннан да, моңа кадәр кире кагучы булмады. Кемне теләсә, шуны тотты Борис Израилевич — фән кандидаты, сәнгать нечкәлекләрен иң оста белүче, ел саен диярлек китап чыгарып торган чын галим. Кәефе бик нык кырылган иде аның. Театрдан соң кирәк булыр дип бер шешә шампанский, бер шешә коньяк алып куйды. Инде театрда утырганда ук ул хыялында Мәрьямнең йокы бүлмәсен күрә иде. Аның Мәрьям белән кызыксынуы «татар хатыннары нинди була икән?» дигән фикердән башланды. Ул хәзер юанырга тырыша иде. «Аларның шушындый примитив иканлекләрен алдан белергә тиеш идем мин. Овчинка выделки не стоит. Бетте, тынычлан, иптәш Теодорин. Бүген ял ит. Иртәгәсе көн синеке. Кемне теләсәң шул синеке булачак». Аның исенә Инна Ярославцева килеп төште. Инночка — иң югары дәрәҗәле интеллигент хатын. Ярый, бетте-китте. Бу мәсьәләгә әйләнеп кайту юк. Иртәгә Иннаны ресторанга чакырам. Зур бәхеткә ирешүгә санап кабул итәчәк.

Теодоринның хәтере калган иде. Өстәвенә машинасы кабынмый торды. Тынычланыр өчен коньяк шешәсен ачып, бер мәртәбә йотты. Затлы эчемлек аның авызын, тамагын рәхәт итеп яндырып ашказанына төшеп китте. «Яшәү гаҗәп күңелле яши белгән кешегә. Күпләр яши белми. Нәрсә теләгәннәрен аңламыйлар, чокыналар, һавадагы торнага карап, кулларындагы чыпчыкны очыралар. Мин чыпчык тотып яшим, әмма чыпчыкның тутый коштан да матурын, аннан да кыйммәтлерәген сайлыйм. Яшәү философиясенең иң дөресе шушы кагыйдәдә».

Ульяновский урамы белән барып, Садовое кольцога чыкканда Теодорин тәмам тынычланып беткән иде. Мотор эшләгәне ишетелми дә. Машина эчендә иркен, рәхәт, җиләс. Көчле машина аның һәр теләген эшкә ашырырга тора. Акча җитәрлек. Кирәк булса, тагын таба аны Теодорин. Ир кешенең башы эшләргә тиеш һәм ир кеше үзенең нәрсә теләгәнен белергә тиеш. Ә фән кандидаты Теодоринда рациональ акыл бар инде ул! Яшәү шундый рәхәт бу дөньяда. «Тегез» дөньяда да Борис Израилевич, унҗиде дәреслекнең авторы, җир тетрәтеп яши беләчәк. Хәтта докторлык дәрәҗәсенә дә төкерә ул. Диссертация белән азапланырга аның вакыты юк. Яшәп калырга кирәк.

Җир тетри иде. Келәт идәне дер селкенә. Кәримә атылып караватыннан төште дә әтисенең куенына чумды.

— Әти, сугышмы бу?

— Юк, кызым, трактор. Урамнан трактор уза.

— Ул безне таптап китмәсме соң. Әнә, һаман якынлаша, — сабый дер калтырый иде.

— Юк, таптый алмас. Тракторны кеше йөртә бит. Кеше кешене бер вакытта да таптап китми. Тракторның тавышы ерагая башлады. Ул узып китте инде.

— Поездда чакта авылда йокыдан әтәч кычкырып уята дип ялганладың. Кая синең әтәчең?

— Әтәч бик иртә кычкыра, кызым. Без ишетми калганбыз. — Кинәт, бернинди бәйләнешсез рәвештә әтисеннән калган дәфтәр Габдрахманның исенә килеп төште. Калын күн тышлы дәфтәргә Бакир Рахманкулов гражданнар сугышы чорыннан алып фикерләрен, башыннан үткән вакыйгаларны язып барган иде. Үләр алдыннан дәфтәр тышына латинча «Улым Габдрахманга» дип язып калдырган. Гарәп хәрефләре белән язылганга күрә Габдрахман кульязманы укый алмады. Чит кешегә күрсәтергә куркыныч иде. «Бәлки анда чит кеше белмәскә тиешле гаилә серләре бардыр». — дип уйлады Рахманкулов. «Дәфтәрне хәзер үк әнидән сорап алып, чемоданга салып куярга кирәк», — дип уйлады Габдрахман.

Трактор тавышы китеп югалгач, янәшә абзарда тавык кытаклый башлады.

— Әти, ишетәсеңме, әтәч кычкыра, — диде Кәримә шатланып.

— Әтәч түгел, тавык.

— Ник кычкыра ул? Әллә берәр җире авыртамы?

— Авыртмый. Тавык йомырка сала.

— Нигә мыштым гына салмый? Мәче ишетсә, йомыркасын ашап та китәр әле. Юләр тавык, кычкырма, ишетәсеңме?

— Йомырка салганын кешеләргә белгертергә тели ул. Ишеткәч, әбиең тавык астыннан йомырканы алыр да сиңа пешереп бирер.

Әкрен генә ишек шакыдылар. Габдрахман урыннан күтәрелеп, ишекнең тәрәвен алды.

— Сөйләшеп ятканыгызны ишетеп кердем, — диде Фәриха карчык.

— Трактор уятты. Туйганчы йокларга иде исәп.

— Келәт яныннан үтеп йөриләр шул. Читтәнрәк йөрегез дип әйткәләгән идем, тыңламыйлар. Тракторыбыз коймак исенә ымсынып сезгә таба борыла дип шаярталар, тәүфыйклары арткыры. Яз көне сабаннарына элэктереп келәтемне аударып китә яздылар.

— Әби сиңа тавык турында сөйлимени? — дип сорады Кәримә, әбисе сөйләгәннәрен тыңлап торганнан соң.

— Юк, кызым, трактор турында. Әбиеңнең келәтен без генә түгел, трактор да ярата икән.

— Улым, мин мунча ягканием, чәйгә хәтле кереп чыгасызмы?

— Кызым, әбиең мунча яккан. Кереп юынабызмы?

— Әнием миңа мунча кермәскә кушты. Анда заразалы чир була диде.

Фариха карчык тынгысызланды:

— Бармаем ди түгелме соң? Юлдан соң аны әйбәтләп юындырырга кирәк иде бит.

— Мунча яратмый ул. Әнисенең дә, Кәримәнең дә мунча кергәннәре юк. Алар ваннада юыналар.

— Үзеңә охшаган икән. Бәләкәй чакта син дә мунча яратмый иең. Баланы үзем юындырып чыгарырмын инде. Киленнең шикләнерен белеп, ләүкәләрне, утыргычларны селтәләп юдым.

— Үзем генә керермен инде. Баланы инештә юындырырмын,— диде Габдрахман.— Ул әле авыл тормышына күнекмәгән. Күнеккәч, мунча да керер. Кире шәһәргә кайтасы да килмәс әле бераз яшәгәннән соң.

— Инеш саекты шул. Хәзер анда су кирәрлек түгел. Кызымны таска утыртып кына юындырып алырмын инде.

Сөлге, алмаш күлмәк алып, Габдрахман мунчага китте. Мунча каршында тәккәббер кыяфәтле ак әтәч тирес актара иде. Әтәч үзен шул кадәр горур тота. Әйтерсең тавыкларның тәкъдире аның кулында. Мескен тавыклар язмышларына риза булып, әтәчнең «көт-көт-көт» дип җим чүпләргә чакыруын сабыр гына көтәләр. Габдрахман тагын Мәрьямне исенә төшерде. «Бергәләп кайтырга кирәк иде,— дип ачынып куйды ул.— Һава саф, тыныч. Иркен. Безнең кайтуга әни карчык сабыйларча шатлана. Шәһәрдәге тынгысыз тормыштан, андагы һава җитмәүдән соң монда рәхәтләнеп ял итәргә була иде. Мәрьям диңгез буена барырга тырышачак. Гаеп Габдрахманның үзендә. Инде ничә ел Мәрьямнең диңгез буена барасы килә. Ә ул ир башы белән путевка таба алмый. Һәр елны путевка алып ял иткән кешеләр бар. Ә Габдрахманның кем беләндер файда өчен генә танышуны, матди кирәклек өчен генә дуслашуны вөҗданы кабул итми. Дөньядагы иң кыйммәт нәрсәне — дуслыкны вак-төяк тормыш кирәклегенә сарыф ит инде. Зур җинаять булырлык эш ич бу. Кешенең рухын агулый, имансызландыра торган гадәт.

Каен яфрагы, мәтрүшкә исе аңкып торган мунчада Габдрахман әкренләп тынычлана башлады. Тәннән бәреп тир чыга. Тиргә иярep ару, алҗу чыга. Һәр күзәнәктә рәхәтлек, һава кайнар, тын алганда эсселек тешләрне пешереп китә, ә тәндә ләззәтле тынычлык. Рахманкулов тышка чыгып саф һава сулап керде дә мунча ташына эссе су җибәреп, туйганчы чабынды. Салкын су белән коенып, чиста күлмәк киеп җибәргәч, тын юллары иркенәеп китте. Тәнгә ябышкан авырлыкны, киеренкелекләрне юып ташлаган шикелле булды.

Дөнья ничектер киңәеп киткән. Һава нурлы. Кошлар сайрый. Ерак яланнан трактор тавышы ишетелә. Ләкин бу тавыш шәһәрдә ишетелгән мотор тавышына охшамаган. Саф һава, кояш нурлары металл дөбердәгән тавышны чистартып, йомшартып тора шикелле.

Урындыктан нәни тәпиләрен асылындырып Кәримә коймак ашап утыра иде. Әтисен күрү белән елмайды, ашыгып сөйләргә кереште:

— Сиңа дигән коймакның кая икәнен беләсеңме?

— Юк, белмим.

— Мичтә. Әбинең миче бар икән. Эчендә ут янып тора. Шул утка куеп әби коймак пешерде. Синең өлешне майлы табага салып, кире мичкә яшерде. Син мунчада чакта мин татарчага өйрәндем. «Бәбкәм» — внучка дигән сүз икән. «Ашакызымаша» нәрсә дигән сүз ул?

— Ашаганда сөйләшмә дигән сүз.

— Юк, әти, алай түгел. «Ашакызымаша» яратам дигән сүз ул. Әби мине ярата. Тыймый. Нәрсә сорасам, шуны бирә.

## 13

«Бу кадәр сагынырмын икән»,— дип уйлады Мәрьям автобус кузгалып киткәч. Кызы алдында үзенең гөнаһлы икәнен тою якынлыкны тагын да көчәйтә иде. «Минем ирем дә чит хатыннарга менә шушылай сыланса? Вөҗдан дигән нәрсә шулай көчсез микәнни? Институтта аны семьясына тугрылыклы, гадел, намуслы кеше дип санап йөртәләр бит?»

Алдагы утыргычта ирле-хатынлы бер пар утыра. Квартирларына ремонт ясарга җыеналар булса кирәк, обой турында сөйләшәләр. Менә, шушылай сөйләшеп утыру нинди бәхет. Чит кеше белән театрда утыру шундый газаплы икән. Синең ят ир белән утырганыңны читтән танышлары карап тора шикелле тоелып теңкәңне корыта...

Төнге шәһәр әллә нинди ямансу хисләр уята. Төннәрен үзенә үзең дә, башка кешеләргә дә шәфкатьлерәк булырга тырышасың. Бетон баганаларга аскан төнге фонарьлардан асфальт юлга сыек яктылык иңә. Йортларның таш гәүдәләрен тоныклык шәүләләр чорнаган. Як-якта ялгыз тәрәзә утлары автобусны озатып калалар. Төнге шәһәр шәүләләр карамагында. Утлар сүнсә төнге шәһәр куркыныч булып калыр иде. «Шәһәрләрдә генә утлар яна...» — дип уйлады Мәрьям Габдрахман яраткан борынгы җырны үзгәртеп. Урамда тылсымлы кызыл утлар яна. Кызыл утлар өерелеп алга баралар. Төнге урамның бар яме шул кызыл утларда. Шушы утларның матурлыгына, аларның батырлыгына хәйран калып бара Мәрьям. Автобус үткәндә светофор күз кысып кала. Төнге шәһәрнең төнге урамында җанлы кызыл җепләрдән тукылган төнге тормыш хөкем итә. Кабына-сүнә хәрәкәтләнгән кызыл утлар шәһәрдә яшәүчеләрнең теләкләре булып тоела аңа. Теләкләре генәме? Бу утлар аларның вөҗданнары, иманнары. Мәрьямнең бүгенге гөнаһлы эшен күреп кызарганнар алар. Вөҗдан тынычлыгы булмаганда бәхет тә юк, шатлык та. Вөҗданың тыныч булсын дисәң, ят ир белән театрга чапма. Хакыйкать менә шушы кагыйдәдә. Иман пакьлеген саклыйсың килсә, ят ирдән бернәрсә дә алма. Хәтта театр билетыннан да баш тарт, трамвайга да түләтмә. Чын гаиләдә тәрбияләнгән кызга ят ир белән театрга йөрү бик зур хурлык булырга тиеш. Бик зур хурлык.

Мәрьям бала чактагы бер эпизодны хәтеренә төшерде. Сугыш вакытында Мәскәү халкын эвакуациягә озаткач, алар, әниләренә ияреп, Олы Тиганәледәге туганнарына кайтканнар иде. Авылда яшәгәндә Мәрьям күршеләренең баскычларыннан бер сабын кисәге алып кайтты. «Каян алдың бу сабынны, әйт, үтерәм», — дип куркытты аны әнисе. Каян алганын әйткәч, шул сабынны хуҗаларына илткәндә әнисе урам буена сөйләп барды: «Минем кече кызым сабын урлаган. Кече кызым сабын урлаган». Шул вакыйгадан соң бүген урлап театрга барганга кадәр гөнаһ эшләгәнен хәтерләми иде Мәрьям. Әнисе исән чагында гомер буе кабатлады: «Кеше өлешенә тиясе булма, кеше хакына керәсе булма...» Аның шушы сүзләре әле һаман колакта яңгырый: «Кеше хакына керәсе булма». Шушы сүзләрне аяк атлаган саен очратырлык итеп, лозунг урынына элеп куяр иде Мәрьям, әгәр шуңа көче җитәрлек булса. Мәрьямнең әнисе кеше хакына керүне ачлыктан да, ялангачлыктан да, хәтта үлемнән дә куркыныч саный иде. «Шундый хатыннан менә ят ирләр белән урлашып театрга йөри торган кыз туган», — дип уйлады Мәрьям. Урамдагы кызыл утлар хәйран калып аңа карап торалар иде.

«Әгәр кинәт балам авырып китсә? Авыруның сәбәбе Мәрьямнең ят ир белән театрга чабуында булса. Ул гөнаһлы бит. Театрда утырганда Теодорин әллә ничә мәртәбә аның кулын тотты. Болай гына түгел, гөнаһлы итеп тотты...» Дөньяда бер генә нәрсә дә бушлай бирелми. Һәр нәрсә өчен хак түләргә туры килә. Бүгенге театр билеты өчен вөҗданының бер өлешен умырып алып бирде Мәрьям. Ул өлеш аның йөрәгеннән алынды. Элек тә сынап караганы булды Мәрьямнең. Үзен артык бәхетле сизгән чакларда: «Шушы бәхет өчен нәрсә белән түләрмен икән?» — дип пошына башлый иде. Һәм бер генә мәртәбә дә түләми калганы булмады. Матди түләүдән тыш рухи түләү дә бар бит әле бу дөньяда, күпләр аны юк дип уйлый. «Кеше хакына кермә...» Каян белгән безнең әни җир йөзендәге иң зур хакыйкатьне?»

Мәрьям баскычтан күтәрелә, ишеген ача — бүлмәдә аны Габдрахман көтеп утыра. Янында Кәримә. Әниләренең кайтканын йокламыйча көтеп утыралар. «Әни, шушы вакытка кадәр кайда йөрдең?» — дип сорый Кәримә?

Ә квартир буш иде. Авыр, киеренке бушлык таш йортның таш бүлмәләрендә. Ә сәгать вакытны секундларга тураклап, гомерне кыскарта: кит-тек, кит-тек, кит-тек...

Үтеп барган һәр мизгелне ялгызлык чорнап алган.

## 14

Урамда матур җәй көне. Күктә кояш, җирдә... ә уләннәр кая киткән?

Йортлар яңарган. Чыбык читән беткән, киртәләр дә күренми. Урамның ике ягыннан челтәрле такта коймалар сузыла. Салам түбәле бер, ике, өч йорт — ялгыз карчыклар яши торган йортлар гына салам түбәле. Койма эчендә җимеш агачлары: чия, кура җиләге, карлыган, алмагачлар. Сугышка кадәр Караярда икеме, өчме бакча үстерүче бар иде. Хәзер хуҗалык саен бакча.

Йортлар да икенче хәзер, алты почмаклы, сигез, ун, унике почмаклы. Алга да бура өстәгәннәр, артка да, як-якка да. Акча бар, дәрт бар — нигә киңәйтмәскә, нигә озынайтмаска? Бары тик биегәйгән йорт кына юк. Ике катлы, яисә чарлак ясап йорт салырга өйрәнмәгәннәр әле Караяр кешеләре. Авыл тәбәнәк, сәнгати яктан ярлы. Монысы инде архитектура үзенчәлеге булмаганлыктан. Ә бит, ниһаять, тәрәзә капкачлары да буяу күргә ирешкәннәр. Йортны такта белән тышлау да, пыялалы веранда ясау да модага кереп киткән. «Нигә йортларны ике катлы итеп салмыйлар икән? — дип уйлады Габдрахман.— Җылытырга уңайлы булыр иде, урын да әз кирәк ике катлы йортка».

— Авыл урамы шушымыни инде? — Кәримә гаҗәпләнеп урамны күзәтеп тора иде.

— Әйе, кызым, шушы.

— Кая соң яшел чирәм? Каз бәбкәләре кая?

Урам — кантарланып беткән кара балчык. Яңгыр яуган саен юлны үзгәртә торганнар. Урамны иңләп янәшә дүрт-биш ташландык юл сузыла.

— Өйгә кереп туфлиеңне киеп чык, кызым,— диде Габдрахман кәефе кырылуын яшерергә тырышып.

Кәримә аягына туфли киеп чыкты. Икәүләп су буена таба юл тоттылар.

— Без чирәм җиргә барабызмы?

— Чишмә карарга барабыз.

— Теге тау астыннан агып чыга торган салкын чишмәнемени?

— Шуны.

— Чишмә суы нигә салкын? Тау астына холодильник күмгәннәрмени?

— Җир астыннан чыкканга салкын,— диде Габдрахман. Ул кызына күптән түгел үзенең Везувий тавына менгәнен сөйләгән иде. Бала моны онытмаган икән.

— Үзең җир астында кызу була дидең, хәзер салкын дисең.

— Башта салкын була, аска төшкән саен җылына,— диде Габдрахман баланың хәтеренә сокланып. «Хәтер әйбәт дип, аны информация белән күмеп ташларга ярамый. Тормышта кулланырга ярамый торган белешмә барыбер акылга әйләнми»,— дип уйлады ул.

Аскы урамда бура күтәрәләр иде. Сөян бүрәнәләрдән тирә-якка тәмле бал исе таралган. Осталарның балталары астыннан ак йомычкалар очып чыга. Алар, балык күреп суга ташланган акчарлаклар шикелле, очып җиргә куналар. Балта тавышы яңгырый, осталар сөйләшкәне еракка ишетелеп тора. «Бу яңа йорт эченә нинди тормыш керер икән? Яңа гаилә белән өй эченә татулыкмы, ызгышмы керер?» Габдрахманның осталар белән бергә эшлисе килеп китте.

Бакчалар арасындагы тыкрыктан инеш үзәненә төштеләр. Суның ар ягында түгәрәк калкулык, борынгылардан калган курган. Габдрахман бала чакта калкулык кардан ачылу белән шунда «карга боткасы» пешерәләр иде. Казанда ботка кайнаган арада, аяк киемнәрен салып, йөгерешеп уйныйлар иде. Киез итектән, күтәртмәле чабатадан котылганнан соң, ялан аяк йөрүе шундый рәхәт, шундый тансык. Әйтерсең аякка аскан богауларны алып ташлаганнар. Хәзер андый бәйрәм юктыр инде.

«Карга боткасы» турында да Габдрахман кызына сөйли алмады. «Карга боткасы»ның русчага тәрҗемәсе юк иде. Өстәвенә Кәримә ботка яратмый. Шәһәр балаларына ботка тансык түгел хәзер. Тансык уеннары да әзәеп килә. Аларга уенны да, бәйрәмне дә әзер килеш китереп кулларына тоттыралар.

Бүрәнә басма астыннан инеш суы саркып ята. Су буенда уйнап йөргән балалар да күренми. Каз көтүләре дә юк.

Ур урамының бакчалары тау кабыргасына күтәрелә иде. Монда кар иртә эри, кояш нурлары мул төшә. Ур кешеләре сугышка кадәр бакча үстерәләр иде. Август урталарында алтын тышлы кавыннар, кыпкызыл помидорлар нур чәчеп тора башлыйлар иде. Шул бакчалар урынына сыер фермасы салганнар. Урамның инеш ягындагы йортлары гына калган.

Аяк астында җир депелдәгән тавыш ишетелә. Картлар урам астына күмелгән хәзинә тавыш бирә дип аңлаталар иде бу хикмәтне. «Монда торф бар шикелле»,— дип уйлады Габдрахман. Ачы чокырындагы сазлыктан төннәрен бөркелеп ут күтәрелә иде. Анда да хәзинә бар дип сөйлиләр иде картлар. Ул сүз дөрес булды — геологлар сазлык астыннан нефть күле таптылар.

Ур урамыннан чыккач, Чишмә башы урамына җиткәнче тау кабыргасындагы сукмактан барыла иде. Сукмакны киңәйтеп, машина юлы салганнар хәзер. Юл ясаучы бульдозер белән яр буендагы талларны да кырып ташлаган. Юлның ярты өлеше упкынга җимерелеп төшкән.

«Хәзер чишмә тавышы ишетелергә тиеш» — дип уйлады Габдрахман. Тавыш ишетелми иде. Чишмә өстендәге ак кыялар да күренде — тавыш һаман юк.

Кыялар астындагы таныш чокыр. Шушы чокырдан кайнап көмеш чыганак күтәрелеп тора иде. Элеккеге чишмә урынында сай гына күлләвек җыелып тора. Су читендә канатларын салындырып чыпчык юынып азаплана. Әкрен генә бака кычкырып алды. Кая соң чишмә? Җир астыннан ашкынып бәреп чыккан су тамыры кая?

Әнә Чишмә башы урамының зәңгәр коймалары. Чишмә тирәсендәге үләнлек. Тимерче алачыгы да җимерелеп бетмәгән әле. Чишмә генә зәгыйфьләнгән. Яз килгәндә әҗәл көткән матур кыз шикелле чишмә моңсу гына саркып ята.

Чиллә вакытында һәм раштуа суыкларында, көне-төне, гасырлар буе адәм балаларына, терлекләргә татлы су китереп торучы чишмә хастага юлыккан. Бизәкле көянтә асып, вак-вак атлап суга баручы сылу кызлар да күренми. Кыя артына качып кыз күзләүче егетләр дә юктыр инде монда? Чишмә янынннан үткәндә юрга атлар тезгеннәрен тартып туктап калалармы икән?

— Эти, минем чишмә янына барасым килә,— диде Кәримә.— Нигә туктадык?

— Чишмә менә шушы чокырдан чыга иде инде,— диде Габдрахман кызына.— Әллә нишләп суы беткән аның.

Авыл урамыннан дөбердәп узган машиналарның тавышы ишетелеп тора. Ә чишмә җансыз.

— Чишмә суын чыпчык эчеп бетергәнме?

— Юк. Аның суы чыпчык эчеп бетерерлек кенә түгел иде.

— Алай булгач, чишмә авырган. Доктор чакырып терелтергә кирәк аны,— диде Кәримә. Ул кешеләр, җәнлекләр, үсемлекләр бер төрле яшиләр, сөйләшә, уйлый беләләр дип ышана иде. Озакламый бу бала да өлкәннәр шикелле җир йөзендәге әйберләрне, җан ияләрен файдалы-файдасызга бүләргә өйрәнәчәк.

## 15

Өлкән яшьтәге бер кеше ак кыяларга язган язуларны карап йөри иде. Караярда бу язуларны укый алучылар бар, ләкин сүзләренең күбесен аңлый алмыйлар иде. Анда безнең ерак бабаларыбыз телендәге борынгы сүзләр язылган иде. Габдрахман кызын җитәкләп шул кыялар янына менде.

Өлкән кеше башлап исәнләште:

— Исәнлек-саулыкмы? Чишмә карарга килдегез, иеме?

Ят кеше һәр сүзен җентекләп сайлап әйтә, ашыкмыйча гына сөйләшә.

Карт, солдат шикелле, гәүдәсен киереп йөри. Күз карашы йомшак. Ләкин күз сирпеп алган арада синең үткәнеңне һәм киләчәгеңне күреп ала шикелле.

— Әллә археологмы сез? — диде Габдрахман.

— Юк, чишмә карап йөрүче.

— Шундый должность бармени хәзер?

— Чишмәләр турында китап язарга иде исәп. Ә сез шушы авылга кунакка кайткан кешеме? Әйбәт инде, читтә яшәп тә авыл чишмәсен онытмагач.

«Бу кешедә бераз күрәзәлек тә бар икән»,— дип уйлап куйды Габдрахман һәм сорады:

— Минем кунакка кайткан кеше икәнемне каян белдегез?

— Кыяфәтегездән. Телегездә дә сизелә. Татарча күптән сөйләшмәгәнсез шикелле. Әле телегез күнегеп җитмәгән.

— Сез районнан килгән кешемени? — диде Габдрахман аның белән кызыксына барып.

— Казаннан. Идел тирәсендә табигать таушала башлагач, бу төбәкне карарга килгән идем. Кичә авыл советында сөйләшеп утырдым. «Инешебезнең суын нефть чыгару өчен җир астына тутырып бетерделәр»,— дип зарланалар караярлылар. Агып яткан суны беркая тутырып бетереп булмый. Чишмәләр кипкәнгә инеш саеккан, ә чишмәләр урман кимегәнгә кибә башлаганнар. Әнә теге тау кабыргасында элек урман бар идеме?

— Мин бәләкәй чакта йөзяшәр имәннәр үсә иде.

— Кайбер бәндәләр халыкны акчага, малга баетып кына бәхетле итмәкче булалар,— диде өлкән кеше тирә-якка ымлап,— юк, булмый. Яшәгән җирендә чылтырап чишмә чыгып, шаулап үскән урманнарында кәккүкләр кычкырып, сандугачлар сайрап тормаса, адәм баласының хисләре ярлылана. Чыганакларны сакларга кирәк, табигатьнекен дә, халыкныкын да,— диде өлкән кеше саубуллашыр алдыннан.

Инде ул кеше ераклашкач, инеш басмасыннан чыгып килгәндә Габдрахман үкенеп куйды: «Адресын сорыйсы калган икән. Минә кемгә күрсәтергә иде әтинең дәфтәрен».

Алар икәүләп авыл урамыннан яланга чыктылар. Бакчалар артында бодай басуы башланды. Басу Ык буендагы әрәмәлеккә барып тоташканчы яшел хәтфә булып җәелеп ята иде.

16

Мәрьям эшкә ярты сәгать алдан килде. Пәнҗешәмбе директорның кабул итә торган көне. Бу көнне аның янына керергә теләүче күп була. Алдан килеп чират алып куймасаң, кабинетка эләгә алмыйсың.

Кабул итү бүлмәсе ачылмаган иде әле. Директорның секретаре килгәнен көтәргә туры килде. Милли мәктәпләр фәнни институтының директоры Кондратий Филиппович Чернуха әйбәт җитәкче иде. Озак еллар танкист булып хезмәт иткән кеше, генерал, отставкага чыккач, төрле урыннарда эшләп директорлыкка күтәрелгән кеше. Институт милли мәктәпләрдә рус телен өйрәнү мәсьәләсен камилләштерү өстендә эшли иде. Директорлыкка Чернуха утыргач, институт бик зур уңышларга иреште. Аның оештыра белүе аркасында фәнни институт елдан-ел планны арттырып үтәп килә. Тәртип каты. Тәртип каты җирдә эшләү җиңел була. Диссертацияләр елдан-ел арта, фәнни хезмәткәрләрнең дәрәҗәләре һаман күтәрелеп тора иде. Бары тик Мәрьям генә, планга кергән тема өстендә артык мавыгып эшләп, әле һаман диссертация яклый алганы юк иде.

Ниһаять, институтка директор да килеп җитте. Кабул итү бүлмәсе аша үзып, үзенең кабинетына үтте. Көтеп торучылар белән яхшылап исәнләште.

Директорның секретаре шеф килүгә иртәнге почтаны тикшереп, хатларны, югарыдан җибәрелгән күрсәтмәләрне регистрация журналына теркәп, өлгертеп куйган иде. Секретарь хатынның өс-башы җыйнак, пөхтә, чәч әйбәтләп таралган, ирен кызартылган, тырнаклар буялган. Кабинетка юнәлер алдыннан секретарь үзенең хәзерлеген тагын бер мәртәбә тикшереп чыкты. Кәгазьләр, өс-баш, кыяфәт, кәеф — һәрберсе нормада. Барысы да барланып беткәч, җиңел атлап ишектән кереп китте.

«Корыч пружина шикелле безнең Мария Ивановна,— дип уйлады Мәрьям.— Кнопкага бастың — хәрәкәткә килә. Кабаланмый, икеләнеп тормый, сәгать механизмы шикелле эшләп тора». Секретарьның шундый булуы Мәрьямгә дә тәэсир итте. Ул җанланып китте, икеләнеп торү кимеде, тәвәккәллек артты.

Секретарь хатын кабинеттан чыгып, машинкада суктырырга тотынгач:

— Керергә мөмкинме? — дип сорады Мәрьям.

— Юк, иртә әле.

«Ярты сәгать көтәм дә аллага тапшырам», дип уйлады Мәрьям.

Таң атканчы уйлап ятканнан соң Мәрьям кызы белән ире янына авылга китәргә ниятләгән иде. График буенча ялны шушы айда бирергә тиешләр иде. Ләкин бу мәсьәләне директор гына хәл итә ала. «Әгәр ял бирмичә, сәбәп табып, институтта калдырса нишләрсең?» Бу очракта директорның карарын аллаһы тәгалә дә үзгәртә алмаячак иде.

Егерме биш минут тулганда кабул итү бүлмәсенә директор урынбасары, фән кандидаты Борис Кәлимуллович Сабанчеев килеп керде. Сабанчеев Казанда туып үскән, шул шәһәрдән Мәскәүгә күчерелгән кеше иде. Булдыклы, тырыш кеше Борис Кәлимуллович. Аның белән

уртак тел табуы да кыен түгел. Билгеле, эшне аның аша йөртеп карасаң, ял алу шансы артыр да иде. Ләкин Мәрьям бу варианттан баш тартты. Казаннан килеп Мәскәүдә эшләүче кеше гадәттә бик өркәк була дип, Сабанчеев та шундый кеше дип уйлый иде Мәрьям. Ул директорның үзе белән сөйләшергә булды. Бары тик аның үзе белән сөйләшеп кенә ял алып булуга ышана иде Мәрьям.

Урынбасар шефының бүлмәсендә озак торды. Аның чыкканын көткән арада министрлыкта эшләүче, институттан алган темага диссертация язып азапланучы инспектор секретарьга баш кына кагып кабинетка узды. Шул кадәр газаплы үтә көтеп тору минутлары. Директор кабинеты каршында торганда вакыт тагын да авыррак уза.

Ниһаять, Сабанчеев эшен бетереп кабинеттан чыкты. Министрлыктан килгән кешенең чыгарга исәбе юк шикелле иде. Югары инстанциядән килгән кеше гадәттә озак сөйләшүне яратмый. Югарыдан килгән булса да, институтта диссертация язганлыктан, инспектор озак сөйләште. Шуның чыкканын көткән арада кабул итү бүлмәсендә Ярославцева күренде. Хәтта исәнләшмәде дә Инна Ивановна Мәрьям белән. Кичә Теодорин белән театрга бара алмый калганга ачу тота иде булса кирәк.

Инна тукталып тормыйча, турыдан-туры дерматин тышлы ишеккә юнәлде. Оятсыз хатын. Ул гел шундый инде. Май кискән пычак шикелле үтеп керә иде кешеләр арасыннан.

— Кондратий Филиппович кабул итми. Ул министрлыктан килгән кеше белән сөйләшә,— диде секретарь. Инна ишеккә таба баруын дәвам итте.

— Мин профсоюз эше белән керәм. Экстренный мәсьәлә,— диде ул борылып карамыйча.

Мәрьям Иннаның нинди йомыш белән кергәнен белә иде. Кавказ якларында хәзер иң ямьле вакыт. Инна директордан Дагстанга барырга командировка сорамакчы иде. Теләгенә ирешми калганы юк иде Инна Ивановнаның. Аның командировка алачагына Мәрьям ышана иде. Үзенең ялга чыга алуына гына ышанып бетми иде ул. Инна кабинетка кереп китте. Чибәр кешегә бер җирдә, берниндн тоткарлык булмаска тиеш дип уйлый һәм шушы кагыйдәгә ышана иде Ярославцева. Ул үзенең матурлыгын пропуск урынына куллана белә иде. Матурлыктан файдаланып күбрәк алу өчен вөҗдан дигән нәрсәгә әһәмият биреп тормаска туры килә иде аңа. Шушы кагыйдәне Инна Ивановна иртә үзләштерде.

Инспектор белән Ярославцеваның чыкканын көтеп утырган арада кабул итү бүлмәсенә Польша делегатлары килеп керде. Делегация унике кешедән тора иде. Күбесе чибәр хатыннар. «Йа алла, болар миннән алда керсә, баш бетте»,— дип уйлады Мәрьям. Бишәр минут кына сөйләшкәндә дә алтмыш минут вакыт кирәк булачак. Тәнәфескә илле минут вакыт калды, нишләргә?».

— Мария Ивановна, — диде ул секретарьга. — Сез күреп торасыз, иртәдән бирле көтәм. Йомышым бик җитди. Дүрт яшьлек кызымны авылга җибәргән идем, куркам. Ял сорамакчы идем директордан. Хәзер керә алмасам, төштән соң ул берәр җиргә китәр дип куркам.

— Төштән соң Кондратий Филиппович Бөтенсоюз аттестация комиссиясына киңәшмәгә барырга тиеш, — диде секретарь. — Мин сезне кертә алмыйм. Чит илдән килгән кешеләр чиратсыз керергә тиеш, этикасы шундый.

Делегатлар кереп киткәч, Мәрьям сәгатенә карап алды. Тәнәфескә кадәр утыз сигез минут вакыт калган иде. «Польшадан килгән кунаклар белән әңгәмә озакка сузылса, ялга чыгу турында өметләнеп тә торасы юк. Иртәгә җомга — директор кабул итми торган көн. Шимбә, якшәмбе — ял. Дүшәмбедә директорның иҗат көне, ул өендә эшли».

Ниһаять, мәгариф министрлыгыннан килгән кеше бик канәгать кыяфәттә елмаеп килеп чыкты. «Әше пешкән ахры моның, — дип уйлады Мәрьям,— директорның кәефе әйбәт булса кирәк, һәркем канәгать чыга».

«Инна Ярославцева директор белән делегат вәкилләре арасында барган әңгәмәгә кушылып китте булса кирәк, командировка мәсьәләсен күптән хәл иткәндер инде», — дип тагын борчылып алды Мәрьям. Инна чит ил кешеләре белән сөйләшергә ярата иде. Шундый сөйләшү вакытында ул үзен дөнья күләмендә данлыклы кеше итеп сизә. «Начальниклар һәм таныш булмаган кешеләр алдында үзен шул кадәр акыллы тотарга Инна каян өйрәнде икән?» — дип уйлады Мәрьям. Ят кеше белән сөйләшкәндә ул шул кадәр көчле тәэсир калдыра. Беренче мәртәбә Ярославцева белән очрашкан кеше аның матурлыгына, акылына, культурасына һәм тәрбияле булуына хәйран кала иде. Бу хатынның кимчелекләре озак аралашканнан соң гына ачыла башлый. Аның каравы, якынрак белгән саен Иннаның кимчелекләре арта, матурлыгы әкренләп югала бара...

«Кабинет каршында чират көтеп утырудан да газаплы кичереш юктыр бу дөньяда». Мәрьям хәлдән таярга җитеп арыган иде инде көтеп утыра торгач. Ниһаять, делегат вәкилләре дә эшләрен бетереп чыктылар. Инна һаман утыра. Әллә юри Мәрьямне кертмәс өчен шулай кылана инде? Төшкелеккә туктарга унсигез минут калды.

— Ярославцеваның чыкканын көтеп торсагыз, өлгерә алмыйсыз, — диде секретарь хатын һәм шундый ягымлы итеп ишеккә таба ымлады.



## 17

Һава тыныч. Җил исми һәм бер үлән яфрагы да селкенми. Ә бодай кыры ярсып дулкынлана. Бодайның серкәгә утырган вакыты. Инде башаклар авырая башлады. Боз сукмасмы, көзге яңгырларга кадәр җыеп алырга өлгерерләрме икән дип дулкынлана иде бодай кыры.

Яланны бер нәфис ис чорнап алган. Бодай серкәгә утырганда аткан чәчәкләр исе. Ак, зәңгәр, сары, ал чәчәкләр чорнап алган бодай кырын. Башаклар өстеннән дулкын йөгерә.

— Әти, менә бу зәңгәр чәчәкнең исеме ничек? — диде Кәримә юл кырыена чүгәләп.

— Чәчәк исемнәрен, кызым, мин белмим.

— Син бит җир йөзендәге бар нәрсәне дә беләсең. Нишләп моны белмисең, чәчәк исемен?

— Чәчәк исемнәрен бәләкәйдән өйрәнәләр. Мин бәләкәй чакта сугыш бара иде. Чәчәк исемнәрен өйрәнеп торырга вакыт булмады,— диде Габдрахман. Ул үлән һәм агач исемнәрен бары тик татарча гына белә иде. Тагын бер кызык нәрсә, русча сүзләр белән фикер йөртүенә карамастан, тапкырлау таблицасын татарча гына белә иде.

— Әнигә букет җыеп җибәрик әле,— диде Кәримә һәм нелеп чәчәк өзә башлады.

— Өзмә, кызым. Кирәкми, өзмә. Үссен.

— Өзмәгәч минеке булмый бит ул.

— Өзгәч, чәчәк үлә. Синең чәчәкне үтерәсең килми бит, әйеме?

— Өзмәгәч, әнигә биреп булмый бит аны,— мәсьәләнең катлаулылыгыннан Кәримә елар хәлгә җиткән иде.

— Шушы яландагы чәчәкләрнең барсы да синеке булсын. Теләсәң, яланы белән әниеңә бүләк итәрсең, яме.

— Яланны Мәскәүгә җибәреп булмас шул.

— Моңдагы килеш әниеңнеке булыр. Караяр авылын да Мәскәүгә илтеп булмый бит, еракта торса да авылымны мин үземнеке итеп йөрим. Чәчәкләрне дә шулай үзеңнеке итеп була.

— Бу чәчәкләрнең барысы да минеке. Мәскәүдә беркемнең дә бу кадәр чәчәкләре юк, — диде Кәримә шатланып.

Ашлык кырын дулкынланып торган диңгез белән чагыштыралар. Диңгез холкын белмәгән, аны ярдан гына күргән кеше ышана торгандыр мондый чагыштыруга. Диңгез — үзе бер дөнья. Фани дөнья шикелле диңгез шәфкатьле, мәрхәмәтле һәм аяусыз була ала. Ашлык кыры — кешенең өмете, иминлеге. Шашынып дулкын чөйгән диңгезнең ник холыксызланганын, давыл вакытында аның йөрәгендә, күңелендә ни барлыгын беркем дә белә алмый. Ә бодай кырының нигә дулкынлануы аңлашыла.

Һавада тургай сайрый иде. Тавыш биектән ишетелә. Әйтерсең ул җиденче кат күктән иңә. Тургай җыры һаман көчәя, һаман якыная һәм кинәт өзелә. Нәкъ тургай тавышы өзелгәндә йөрәк әрнеп китә. Искә сүнгән, тар-мар булган мәхәббәтләр килеп төшә.

Бер якыннан, бер ерактан кычкырган бүдәнә тавышы ишетелә. Бодайның җитлегеп килгәнлеген белгертеп бүдәнә елый: юк булдык, юк булдык, юк булдык.

— Әти, кем тавышы бу? — Габдрахманның кызы кошларга, җәнлекләргә «кем» дип дәшә иде.

— Бүдәнә кычкыра, кызым.

— Нигә алай әрнеп кычкыра соң ул?

— Шушы тирәдә аның оясы бар. Оясында балалары. Бодай кырына кергән кешене кычкыра-кычкыра үзенә ияртеп оясыннан читкә алып китә,— дип аңлатты Габдрахман кызына.

Әрәмәгә җитәрәк елый-елый күл яныннан күтәрелгән тәкәрлек тавышы ишетелде.

— Ә бусы кем?

— Тәкәрлек, кызым.

— Нәрсә ул тәкәрлек? Аның русча исеме ничек?

Тәкәрлекнең русча исемен белми иде Габдрахман. Кызык хәл. Моңа кадәр ул сүз запасының русчасы күбрәктер дип йөри иде. Бала чакта ишетелгән сүзләр хәтердә шул килеш, русчага әверелмичә сакланганнар. «Бу бик кызык нәрсә»,— дип уйлады Габдрахман.

— Ә тәкәрлек нигә елый?

— Әрәмәгә килгән кешеләр үләнне таптап бетерерләр, куакларны сындырырлар дип куркып елый ул, кызым. Бодай басуы белән әрәмә арасында элек бик матур болынлык бар иде. Хәзер аны сөргәннәр. Бәлки шуңа күрә дә елый торгандыр тәкәрлек. Кем белгән?

Сандугачлар тавышы каршы алды әрәмәгә кереп килүче кунакларны. Шул кадәр моңлы сайрыйлар иде Ык буенда яшәүче сандугачлар. Мәскәү тирәсендәге урманнарда сандугачлар башка төрле сайраган кебек иде Габдрахманга. Борынга ниндидер хуш ис бөркелеп килеп бәрелде.

Куаклар арасындагы кояшлы яланнарда җиләк кызарып килә. Шомырт карала башлаган. Гөлҗимешләргә дә саргылт төс кереп азаплана. Балан һәм бөрлегәннәр генә әлегә яшел килеш торалар. Кояшрак җирдә кара карлыганнар җитлегеп киләләр.

— Ыкка төшеп су коенабызмы? Әллә әрәмәгә кереп җиләк ашыйбызмы? Әрәмә шундый юмарт ул. Без бәләкәй чакта еш кына кытлык була иде.

— Нәрсә ул кытлык?

— Ашарга ипи булмаган чак, кызым. Ашарга ипекәй булмаган чакларда кар ачыла башлау белән без әрәмәгә килеп үрдәк йомыркалары җыеп ашый идек. Ташу киткәч, күлдәвекләрдән балык җыя идек. Аннан соң каты, юа, кузгалак өлгерә. Алардан соң җонлыкай, баллы көпшә, балтырган җитә. Әрәмәнең тәмле үләннәрен, аның җимешләрен ашаган кешегә витамин кирәк түгел. Әрәмә үләнен ашап

үскән кеше бик таза була, гомергә авырмый. Синең әбиең шундый. Ул бала чактан әрәмә җимешен, аның тәмле үләннәрен ашап үскән кеше. Ыктагы балыкларны күргәч, су буеннан кайтасың да килмәс әле. Ыкның теге ягындагы тауларны күрәсеңме? Шул тауларда үскән урманда чикләвек күп, анда ногыт, чия, кыргый алма үсә. Нинди генә җимешләр юк анда. Эзләсәң, куыш агач эченнән бал табып була. Җирне казып карасаң, алтын табып була ул тирәдән. Чикләвек җыярга барган җирдән алтын табып кайтучылар да була иде сугышка кадәр.

— Сугыштан соң алтын табучылар юкмыни инде?

— Белмим, кызым. Монда нефть чыгаручылар күп йөрде. Алар бу тирәдәге җирләрне бик нык айкадылар. Ыктагы балыкларны динамит белән шартлатып тоттылар. Бәлки хәзер Ык буйлары алай ук бай түгелдер инде.

Ата белән бала Ыкның көмеш суында озаклап коендылар. Аннан соң яр башыннан суда уйнаклап йөргән балыкларны күзәтеп утырдылар. Әрәмәгә кереп туйганчы җиләк ашагач, әбисенә дип сабаклап җиләк җыйдылар да кайтыр юлга чыктылар.

Тургай һаман сайрый, бүдәнә һаман кычкыра. Әрәмәдән чыкканда тәкәрлек елап озатып калды. Серкәгә утырып килгән бодай кыры һаман дулкынлана иде. «Шушы көннәрдә кичләрен нәҗәгай уйнарга тиеш. Кәримәгә нәҗәгай балкыганын күрсәтергә кирәк әле», — дип уйлады Габдрахман бакчалар артына кайтып җиткәндә.

Капка төбендә кызы белән ире әрәмәдән кайтканын Кәримәнең әнисе Мәрьям көтеп утыра иде. Аны күрү белән арыганын онытып, сабый әнисенә ташланды:

— Әни, синме бу?

— Мин, бәбкәм, мин, мин, — диде Мәрьям баланы күкрәгенә кысып. — Бәхетем бар икән минем, — диде ул Габдрахманга. — Директор ялга чыгарга рөхсәт итте. Бу якка очучы самолетларга билет ун көн алдан сатылып беткән иде. Быково аэродромыннан самолет Бөгелмәгә очарга әзерләнеп тора иде. Пассажирларны утыртыр алдыннан минем бәхетемә бер буш урын табылды.

Фәриха карчыкның самавары иминлек һәм гаилә татулыгы җырын көйләп утыра иде. «Менә шушыдыр инде ул чын бәхет», — дип уйлады Габдрахман. Чыннан да, шатлык нәкъ шушы иде.

**Әсхәл Әхмәтхуҗин,**
башкорт шагыйре

## Алсу кош турында

*Муса Галигә*

Күлдән калкып көмеш аккош
Канат какты зәңгәр таңда;
Туган төяк яңгырап калды
Чыңрап-чыңрап ул очканда.

Ялгыз аккош — гүя сагыш —
Очты биек-биекләргә;
Күк җырлады — кыйгач канат
Тигәч күкшел нур-җепләргә.

Зифа аккош — ярсу тавыш —
Күтәрелде янә өскә;
Аккош түгел — алсу кош ул!
Манчылды нәкъ алсу төскә.

Манчылды кош алсу төскә,
Туып килгән кояш сымак...
Кош та кояш — таулар аша
Йөзде алар салмак-салмак.

Кош һәм кояш йөзеп китте,
Алар нинди якты, горур!
Җиргә яуды чыңраулы нур!
Нинди бу таң затлы, хозур!

Куш кояшмы янып үтте:
Көн чыгышы — бурзат-алтын,
Караңгыны ялмап-ялмап,
Көнбатышка капты ялкын.

Куш кояшмы балкып китте:
Бөтен офык — тоташ балкыш.
... Күк аръягын нур итәргә
Кояш китте. Калды аккош.

Калды аккош, кайтты аккош:
Алсу түгел — инде балку!
Чыңратудан кая туктау!
Очудан ди кайда ялку!

Кайтты аккош — кояшлы кош:
Җаны күркәм, тәне бер ямь.
Кайтты аккош — җәйгор[1] катыш
Каурый койды берәм-берәм.

Чыңрап-урап туган кырны,
Тирә-якка бөркеп сафлык,
Табигатьне куандырды,
Күңелләргә сипте шатлык.

Күк капусы ачылдымы —
Дөнья шундый асыл-зиннәт!
... Җирем — ятим, әгәр моннан
Китсә аккош капылт-кинәт...

Әй гомерем! Кадерен бел,
Канатлы нур күктән яуса...
Туган төяк иңрәп калыр,
Янган йөрәк тетрәп талыр —
Бер мәл аккош чыңрап ауса!

## Айдар Хәлим,

башкорт шагыйре

## Гарсиа Лорка авазы

...Зыңк ачылды төрмә биге,
Сәгать тугыз чак тулганда,
Һәм конвоирлар, бишәүләп,
Шәраб эчеп, тыгынганда...

*Г. Лорка, «Антоньито эль Камборьоны, Севилья юлында...»*

Ай туа, туа иркенләп,
Туа ул җайлап кына.
Вакыт тар, әйтергә иде
Сүзләрне сайлап кына.

Үләнме, әллә кешеме,
Кошмы син, киекме син,
Табигать тере яраткач,
Үсәргә тиешле син!

Я үсәрмен, я үләрмен
Үлемсезлегем өчен.
Гасырларны тулгак тоткан
Мине тудыру өчен...

Ирекгә ирексез яшәп,
Вакланып маташканчы,
Көрәшчеләр белән бергә
Көрәшеп үлү яхшы.

Мин халкымның тугры улы,
Аның саф җырчысы да —
Булырмын беренчесе дә,
Булырмын соңгысы да.

... Севилья күгендә аунап,
Яңа ай әвәләнә —
Ул да конвой җәтмәсеннән
Чыгалмый чәбәләнә...

[1] Җәйгор — салават күпере.

**Галим Дәүләтов,**

башкорт шагыйре

## Туган моңнар

*Зөлфәткә*

Без йөрмибез әле чит илләрдә,
Агыйделдән бераз читтәбез.
Туган моңны әллә без ныграк
Сагынырга гына киткәнбез?
Таныш сүзләр әгәр ишетелсә,
Ник сагая безнең колаклар?
Сүзләр нәрсә...
Туган моң яңраса,
Үсеп чыга икән канатлар.
Шулай бер көн кичке аллеядан
Уйчан гына барып ятканда,
Тальян гармун тарткан егет белән
Җырлап үтте кызлар якында.
Онытылды барыр юлларыбыз,
Онытылды урам шау-шуы.
Күңел, язын зәңгәр күккә очкан
Сабантургай кебек, ярсыды.
Каян килде бу моң?
Уралданмы,
Әллә инде Арча ягыннан?
Тавышлары моңлы булды микән,
Әллә күңел өзелеп сагынган?
Тик торганда шул көй, бер гади көй,
Йөрәкләрне ничек дулатты!
Идел булып ташты...
Аннан сабыр
Ана тавышыдай юатты.
Туган моң, син язмыш җилләрендә
Тугансыңмы икән ялкыннан?
Син еракта — бигрәк моңлыраксың,
Аласың ла икән алкымнан![1]

1976—77. Мәскәү.

---

[1] Алкымнан (башкортча) — бугазымнан.

*Татарстан Язучылар союзы идарәсенең яшь авторлар белән эшләү комиссиясе соңгы вакытларда әдәбиятыбызга килергә омтылучы авторларны барлау, оештыру, әсәрләрен матбугатта чыгару юнәлешендә шактый күп эшләр башкарды. Урыннарда зона конференцияләре уздыру инде әйбәт бер традициягә кереп бара. Андагы семинарларда үзенчәлекле яңа авторлар ачыла, аларны Язучылар союзына тәкъдим итү яки китапларын эшләү буенча конкрет чаралар күрелә. Шунысы күңелле факт: бу конференцияләрдә төрле буын язучылары бик теләп катнашалар, алар әдәби алмаш әзерләүдә зур игътибарлык һәм таләпчәнлек күрсәтәләр. Апас, Чаллы, Арча зона конференцияләреннән соң, узган елның 5—6 декабрендә Азнакайда булып узган нефть зонасы яшь язучылары конференциясендә унбиш авторның әсәрләре тикшерелде. Шулардан Фәрит Гыйльметдинов, Марсель Галиев һәм Әхмәт Гадел СССР Язучылар союзына членлыкка, ә Ямаш Игәнәй һәм Нур Әхмәдиевләрнең шигырь җыентыклары Татарстан китап нәшриятына тәкъдим ителделәр.*

*Без соңгы елларда яшь талантларны мәктәптән, укучы балалар арасыннан да эзлибез. Һәрбер конференциягә иҗат белән шөгыльләнгән укучы балаларны чакырабыз. Шулай ук, аларны Язучылар союзына чакырып, индивидуаль эш алып барабыз. Соңгы вакытта гына унынчы класс укучылары Ркаил Зәйдуллин һәм Ләис Зөлкарнәевларның кульязмалары тикшерелде.*

*Ркаил — Чувашстаннан, Ләис — Башкортстаннан. Икесенә дә унҗиде яшь, ВЛКСМ членнары. Моңа кадәр пионер матбугатында катнашсалар, хәзер без аларның шигырьләрен беренче тапкыр калын журналга тәкъдим итәбез һәм укучылар кызыксынып кабул итәрләр дип уйлыйбыз.*

**ИЛДАР ЮЗЕЕВ,**
Союз идарәсе председателенең
яшь авторлар белән эшләү буенча урынбасары.

# Марсель Галиев

●

Атлантида
батқан чакта
кем ишеткән
соңгы кешесе
кычкырганны?!

Кеше — үз күңеленең
беренче һәм соңгы могиканы.

Кайчагында
батып барган утрауның
соңгы кешесыдәй
кычкырасы килә.

Оныттырып
бөтен шөбһәләрне
сабый көлә...

●

*Хәсән Туфанга*

Җырларда саргайган еллар,
чәчләрдә агарган еллар,
маңгайда сырланган еллар! —
сезме ишек кагасыз?..

Бүген аңа
уналты яшьлек кыз
чәчәкләр китерде...

Еллар, сезме ишек кагасыз?..

Бүген аңа
уналты яшьлек кыз
чәчәкләр китерде.

Чәчләренең чал кышымы,
чәчәкләрнең чагылышымы,
күз яшенең балкышымы? —
күзләрендә кызның ак болыт...

Еллар, сезме ишек кагасыз?..

Бүген аңа
уналты яшьлек кыз
чәчәкләр китерде...

●

Минем якта — япан тигезлекләр,
синең якта — башкорт таулары.
Ык суының ике яры буйлап
күпер эзләп чаба юллары.

Йөгерек юлдан күперләргә җиткәч
ярсу атлар килә тыюлы.
Ике ярны күрештергән күпер —
уртак язмыш юлы, туй юлы.

Хәерле таң, дисә безнекеләр,
хәерле көн, диләр башкортлар.
Бер үк үрдән караса да кояш
төрле икән әле вакытлар...

Минем якта — уклар адашырлык
тарих учы сыман киңлекләр.
Синең якта — кояш таянырлык
олпат таулар калкан кебекләр.

Син тугансың Ыкның тау ягында,
мин туганмын үзән ягында.
Без яшәрбез ике яры булып
мәңге агар елга барында.

## Асылына кайткан әкият

Кузгалдың да кинәт биеп киттең
карашымны чигеп идәнгә.
Шәм уты да чүгеп-чүгеп куйды,
әверелдә идән келәмгә.

Һәм аннан соң көлдең яңгыратып,
өстәлдәге шәраб чайпалды.
Җәйге төндә йөзек кашы булып
тәрәзәдә туңып ай калды.

Күз яшеңә кушып җыр җырладың,
стеналар артка чигенде.
Һәм без калдык ялан уртасында,
шәм кимеде, калды чиреге...

Кыргый сукмак алып төште безне
салкын сулы төнге арыкка.
Су эчтем дә, мин бер тирәк булдым,
син әйләндең алтын балыкка...

## Яз соңлыймы?

Шәмахә төн. Якты урам.
Куырып ала апрель җиле.
Нидер эзлим. Тапсам, җанда —
кабыныр яз яшеллеге.

Шәһәр йоклый. Мин ялгызым
туасы моңга табынып,
яшеллеккә сусап барам,
ачылмаган дөнья булып.

# Әхмәт Гадел

## Кызыма

Алтын балыгым минем!
Борчулы көннәремдә,
сихри елмаюың белән
миңа тынычлык бүләк итәр өчен,
ерак диңгезләрдән килгәнсең син.

Сайрар кошым минем!
Серле тавышың белән
мине кайгылардан йолыр өчен,
урманнарны ташлап килгәнсең син.

Әгәр син булмасаң, кемнәр генә, кызым,
кемнәр бу дөньяга бәйләр иде мине?

Әгәр мин булмасам, кемнәр генә, кызым,
татлы бу дөньяда назлар иде сине?

Кызым минем, кошым-сыерчыгым минем.
Кызым минем, кызым — язгы җырым минем.
Тормыш дәрьясында алтын балыгым син...
Бөтен барлыгым — син!..

●

> Башлары булганнар —
> Баш ияргә мәҗбүр булдылар,
> Аяклары булганнар — тезләнде...
>
> *Борынгы язмалардан.*

... Ә бит бар шундый йөрәкләр, —
Кылычка баш имәүчеләр!

Данла андый йөрәк көчен!
Баш и алдында —
Тезләнмәве өчен!

## Кайтар!

Сиңа биргән көннәремне кайтар,
Сиңа биргән төннәремне кайтар,
Хисләремнең йолдызларын кайтар,
Моңнарымның болытларын кайтар,
Урманымның серле шавын кайтар,
Суларымның дулкын-давын кайтар,
Кырларымның гаҗәп моңын кайтар,
Тауларымның серле шомын кайтар.

Кайтар минем утлы сүземне,
Кайтар миңа минем үземне.

## Келәтле авылы янындагы ялгыз кабер ташына карап

Кырда утрау булып калган:
Тимәгән сабаннар,
Җиңелгән заманнар,
Җил-буранга торган каршы
Кабер ташы!
Алып килгән болгар чорын
безнең көнгә...

Ташлар килә икән телгә,
Яннарына барып сөйләш кенә...

## Нур Әхмәдиев

### Мин — җирнеке!

«Тукта, җирем! Төшеп калам синнән...»
Кемнәр язган? Нигә язганнар?
Әллә инде шушы дәрәҗәдә
Берәр акылыннан язган бар?

Нәрсә белән җирем ярамыйдыр,
Суларын әйт, урман, һавасын!
Һәр адымы нидер хәтерләткән
Җирне ничек ташлый аласың?

Тик су белән түгел, кан белән дә
Кат-кат сугарылган бу җирне
Син иркәле көннән,
Син иркәле көннән
Үзең ташлап китәр идеңме?

Назлы ярның сусыл иреннәре
Иркәләгән шушы дөньядан
Ирексезләп Әҗәл кагылмаса,
Мин туялмам, һич тә туялмам.

«Тукта, җирем! Төшеп калам синнән...»
Кемнәр мәҗбүр булган язарга?
Үз-үзеннән туйса аңлар идең,
Җирдән туйган... Ничек аңларга?

Тынгысызлыгыннан киләчәкнең
Алынганмы әллә соң коты?
Ә кем белә, бәлки протесттыр,
Гаделсезлекләргә бойкоты?

Юк, барыбер бу сүзләрне язган
Кешене мин гафу итәлмим.
Кан тамырым белән җирнеке мин!
Китсәм дә, тик галәмнәрне иңләп
Җиргә кайтыр өчен китәм мин.

### Пистолет һәм шагыйрь

Пистолетын гаепләде Муса
Хыянәттә, аны алдауда.
Волхов ярларында солдат булып
Батырларча үлә алмауда.

Ничек әсир булсын илен сөйгән
Һәм җыр ташып торган ир җаны?!
Камерада яткан көе Муса
Әсир итте үзе дөньяны.

Пуля кебек утлы шигырь туды,
Нәфрәт арты нәфрәт өстәлеп.
Мондый шартта былбыл йөрәге дә
Була икән хәнҗәр, пистолет.

Пистолеты әгәр аткан булса,
Ауса Муса йөрәк тишелеп?..
Атылмыйча калган пуляга да
Күп бурычлы кайчак кешелек.

## Аллалар

Сабый чагы булган кешелекнең,
Табынган ул җыен юк-барга:
Бүреләрдә ил анасын күргән,
Һәм алласын күргән утларда.

Шул утлары, аллалары белән
И ваклаган җанын, шәхесен.
Теткәләнгән гарип җаның белән
Син бәхетле ничек яшисең?

Үз-үзеңә кайда анда хөрмәт,
Ни кадерләү көтмә, ни зурлык.
... Минем дә бар аллам. Өчәү алар...
Һәр өчесе — минем горурлык!

Әй Ватаным! Синме аллам түгел? —
Соңгы сулышым һәм юл башым?
Ил бәхете өчен көрәшкәндә,
Коммунистик иман — юлдашым.

Туган Анам! Синме аллам түгел?
Син намусым минем, вөҗданым.
Ана белән юкка ант итәме
Яклаганда егет ил данын?

Мәхәббәтем! Синме аллам түгел? —
Хур иткән дә мине, зур иткән.
Син булмасаң, яшәү нигә кирәк,
Өч аршинга якын җир җиткән.

Табынганым минем, әйе, өчәү,
Ялгыз-ялгыз ятим алар да.
Дошманыма да мин теләмәмен
Мәхәббәтсез, илсез,
Һәм әнкәсез яшәп карарга.

Аллаларым өчен яу чыгармын,
Мәсхәрәләргә тик бирмәмен.
Шул түгелме иң зур миссиясе —
Үзе исән чакта — ирләрнең!?

•

Җырлыйсы да килми, елыйсы да,
Күз яшьләре кипкән, түгелгән.
Ярсу йөрәк, сүнгән вулкан сыман,
Тынып калган кебек бүгеннән.

Җырлыйсы да килми, елыйсы да,
Күңелдә юк сөю, әрнү дә.
Шикләнү юк миндә, ачу да юк,
Исем китми кебек берни гә.

Җырлыйсы да килми, елыйсы да,
Уйлыйсы да килми — арылган.
Диңгез кебек тынып калган күңел,
Тынып калган — давыл алдыннан.

## Роберт Рәкыйпов

*Диңгезче дәфтәреннән*

### Диңгезләрдә кошлар түбән оча

Диңгезләрдә кошлар түбән оча,
Каурыйларын дулкын чылата,
Күкрәген ачкан ана кебек
Җылы сулап диңгез тын ята.

Диңгезләрдә кошлар түбән оча
Корабларны тиңләп ак ярга.
Акчарлактай моңсу күңелләрне
Ашкындырып туган якларга.

Диңгезләрдә кошлар түбән оча
Бер сулышта мәллә су белән,
Төнбоеклар кебек акчарлаклар
Диңгез өсләренә сибелгән.

Диңгезләрдә кошлар түбән оча,
Су юллары алда бер эзсез.
Акчарлаксыз диңгез диңгезмени,
Сагыну сагынумыни диңгезсез...

•

Диңгез өстен күксел томан баса
Җиз иләктән койса яңгырлар.
Күз алдымда җирем чәчәкләре
Хуш ис бөркеп һаман аңкырлар.

Күмеп китәр төсле тау-дулкыннар
Ыргылганда ярсып корабка,
Нигә эзлим икән җир кисәген
Карашымны төбәп еракка.

Җил-давыллы һава диңгез белән
Ишелеп аккан тоташ болытта.
Диңгезченең күңеленерактагы
Бозлы яр да икән җылыта.

Туган илдән искән көзге җил дә
Җырлап туймас моңлы җыр миңа.
Ватанымның корыч кораблары
Океаннарда — туган җир миңа.

Диңгез өсте кабат ак чәчәктә,
Күктә уйный акчарлакларым.
Минем дә шул җитез акчарлактай
Диңгезләрне гизәр чакларым...

## Белмисеңме, диңгез?

Дөньяны гиз, галәмнәрне буйла,
Туган җирне уйла.

*Г. Афзал*

Диңгез, диңгез, суың тозлы инде,
Нигә ява тозлы яңгырлар?
Иренемдә чишмә суларының
Тәме калган туган ягым бар.

Бозлы суың салкын, салкын инде,
Салкын карлар нигә ява соң?
Җаным-тәнем белән һаман тоям
Туган якның җылы һавасын.

Офыкларың ерак, ерак инде,
Нигә кирәк соры томаннар?
Белмисеңме, диңгез, күз алдымда
Ул озатып калган туган яр.

Кыяларың биек, биек инде,
Ник түбәннән исә җилләрең?
Сагышларым эреп юкка чыга
Диңгезләрдә тойсам Җир ямен...



## Ркаил Зәйдуллин

*Мин 1962 елның гыйнварында туганмын.*

*Быел урта мәктәп тәмамладым. Шигырьләрне бик яшьтән яза башладым.*

*Тукай, Такташ, Җәлил һәм Дәрдмәнд иҗатын өйрәнәм. Хәсән Туфан, Сибгат Хәкимнәргә гашыйкмын. Ә яхшы шагыйрьләр, куанычым зур! — бик күп.*

*Кешеләрне тетрәтә торган, чын мәгънәсендә шигырь дип аталырлык утлы, ярсулы, шул ук вакытта моңлы шигырьләр язасы килә...*

●

Әгәр җырда мактасам мин туган җирне,
Сөям, димәк, бу түгәрәк җир шарын да.
Әгәр җырда күккә чөйсәм үз халкымны —
Сөям, димәк, халыкларның мин барын да.

### Алмагач

Кояш көлә иде күктә,
Күңелле иде көннәр,
Ә һик чибәр алмагачның
Яшь акты каусәсеннән?!

Ташлап китте хуҗа аны,
Ташлады, игелексез.
... Бәхет монда гына түгел,
Янәсе, җирләр чиксез.

Кышкы кардан ачылган җир
Чәчүне сорап ята!
Алмагач көтте хуҗасын
Ак чәчкә ата-ата.

Өмет өзмәде ул һаман,
Көтте, зарыгып көтте.
Ботакларда аңа дигән
Алмалар пешеп җитте.

... Ул әйләнеп кайтты кире,
Тик шундый салкын көнне —
Алмагачның яфрагы да
Коелган иде инде.

## Җил гитара уйный

... Офыкка ук иңеп бара
Чия сыман кызыл кояш,
Күзгә кояш, гүзәл кояш,
Үзе сәер, үзе юаш.

Ә шаян җил каян гына
Болытларга менеп китә,
Ерактагы кояшның да
Ал битеннән үбеп үтә.

Серле кылга чиртеп ала —
Ул бит иң шәп гитарачы,
И табигать! Тыйма аны,
Әйдә, күңелләрне ачсын.

... Ә офыктан чыгып килә
Алтын кояш. Дөнья тынган —
Гитарасын югалткан җил,
Йоклап киткән таң алдыннан.

## Кыйтга эзлим

Һай, киң дә бу тормыш дигән диңгез,
Гомер — кораб.
Кабаланып фәрман
Бирәм, ашыктырам аны: — Тиз, тиз!
... Йөрәктә дәрт, беләгемдә дәрман.

Таныш түгел урыннардан узам,
Җем-җем итә йолдызларым: «Читкә китмә».
Давыл чыга.
Куәтле җил — диңгез туза,
Ә мин эзлим табылмаган яңа кыйтга.

Утрауларны үтәм.
Тик аларга
Тукталулар минем максат түгел.
... Туры юлдан бару, ай-һай, авыр —
Болытлана кайчак зәңгәр күгем.

Табасы иде бит...
«Мин җир күрәм!»
Диеп аваз саласы иде,
Тик бер теләк чынга ашмый никтер,
... Язмыш әле тотып калды өнне.

Кешеләр йөзгән моннан арып-талып
Миңа кадәр,
Йөзәр миннән соң да,
Һәм бик азлар тапкан кыйтгаларны,
Күпләр йотылганнар упкыннарда.

Күпләр туктатканнар эзләнүне:
«Җитәр.
Йөрдек юк нәрсәне куып».
Якорь төшергәннәр утрауларга
Кырыс язмыш белән риза булып.

Шаулый диңгез.
Шаулый тормыш шашып,
Мин онытылып офыкларны күзлим,
Як-ягымда тагын күпме кораб,
Барысы да яңа кыйтга эзли.

## Сорасалар әгәр...

Я җиңелгән татар, я җиңгән...

*Х. Туфан.*

Туган җиргә ныклап береккән мин,
Халкым өчен тибә йөрәгем,
Сорасалар әгәр, син кем? диеп,
Мин — татар, дип җавап бирәмен.

Утка-суга салсалар да барыбер
Мин халкымны өзелеп сөярмен,
Сорасалар әгәр, син кем? диеп,
Мин — Тукайлар токымы, диярмен.

Туган халкым — батыр татар халкы,
Шуңа күрә мәңге горурмын.
Катыйль алдында да Җәлил кебек
Тезләнмичә басып торырмын.

Сынатмастыр-сүрелмәстер күңел,
Дөрләр дә ул, балкыр, яныр да.
Гаҗәп түгел, Тукай каны ага —
Татар каны ага тамырда.

Бу башлардан барсы үткәндер шәт,
Давыл булып күпме яу килгән?!
Тузан баскан ташлар сөйли башлый:
Я җиңелгән татар, я җиңгән.

Бу дөньясы яралганнан бирле
Язмыш безне азмы кыйнады,
Беләзекне богау кысса кысты,
Югалтмадык әмма иманны.

Һәр гасырның ата шайтаны бар,
Урландылар кайбер өметләр,
Без һаман да татар булып калдык,
Бирелмичә калдык, егетләр!

Сорасалар әгәр, син кем? диеп
Мин — татар, дип җавап бирермен.
Халкым өчен булса икеләнми
Кайнар тәмугларга керермен.

# Ләис Зөлкарнәев



*Туган ягым — гүзәл табигатьле Башкортстан җире. Туган авылым — Бакалы районының Бишкаен авылы.*

*Әни, 1962 елда кошлар кайтканда тудың, ди. Инде 17 ел кошлар кайтуын каршылыйм. Хәзер үзем дә шул кошлар халәтендә — мәктәпне тәмамлап, нәкъ җиде юл чатында басып торган чагым.*

*Шигырьләрне 4—5 ел элек яза башладым. Этәргечләр авылым табигате һәм, әлбәттә, авылымның шигъри күңелле халкы булгандыр.*

*Остазларым — даһи Тукай, моңлы Туфан һәм ярсу 60 нчы еллар шагыйрьләре. Табынмасам да, алардан үрнәк алам.*

*Поэзия минем өчен якын дус. Киләчәктә дә аңа эч серемне сөйләргә телим. Кем белә, бәлки ул да үз итеп серләрен ачар...*

●

«Бәй өченмени ат — бәйге өчен!» —
Борынгыдан калган җыру ла.
Чабыш даулый йөрәк — давыл аты
Үрә басып алга ыргыла!

Дулап чапсын әйдә, дулап чапсын,
Томырылсын ярып һаваны.
Бабайларның җаны давыл булган,
Шул давылның без бит дәвамы.

Давыл аты җиргә шундый сугар,
Бер селкенер әле заман да! —
Юкка гына, тиккә генәмени
Давыл гүли безнең каннарда!

Давыл тынды диеп уйламагыз,
Тояк авазлары тынса да.
— Давыл аты алга ыргыла ул
Аяклары шартлап сынса да!

●

Шылтырап ук кипте печән,
Тик офыкта болыт табы. —
Каерылып очты күбә,
Шартлап сынды сәнәк сабы!

Югарыдан кибәнче карт
Уларын бик ашыктыра.
Җулмәген ул салып аткан,
Гүя көче ташып тора.

Өрлек кебек таза уллар,
Чуен тәннәре кызган — ут!
Сәнәкне дә, беләкне дә
Бер дә тормыйлар кызганып!

Нәни малай сәнәк сорый —
Үзен зурга санатмакчы.
Болытны ул күбә итеп
Офык артына атмакчы!

●

Тиктомалдан егылам да
Упкынга төшеп китәм.
Димәк, тиздән тәбикмәк мин, —
Йөрәгем өшеп китә.

Тирә-ягым шундый тыныч,
Ай, газаплы бу очыш.
Әйтерсең мин, күккә менгәч,
Пар канаты сынган кош.

Инде күпме шул упкынга
Егылып төшеп китәм.
Ә төштәге упкыннарга
Кем генә төшеп җиткән?..

●

Әллә киек каз кычкырды
Төнлә ерак инештә...
Аны бабам ишеттем, ди,
Гел саңгырау килеш тә.

Төнлә бабам ишеттем, ди,
Өзгәләнгән каз җыры:
«Туган илгә язны сөйри
Киек казлар чылбыры.

Астан бераү мылтык төзи,
Бәгыремне, ай, өзә.
... Бу мин — канлы су өстендә
Яраланган каз йөзә.

Бер буынга кимдер чылбыр,
Яз өзелеп калгандыр.
Канлы кулы белән бәндә,
Бу миңа, дип алгандыр...»

Төнлә бабам тыңладым, ди,
Авыр җырны җан кыйнап:
«... Әни, коткар, кыйгак-кыйгак!
Әти, коткар, кыйга-а-ак!..»

Мәгъсүм Хуҗин

# КӨРӘШЧЕ

хикәя



Пәһлеван елгага төшә торган баскычның кузгалган ташларын рәтләп тезә, аларны, дәү чүкеч белән сугып, тигезләп батыра, араларына чиләк белән ташып ком тутыра. Баскыч нык кирәк, моннан мал-туар эчерергә, кыяр-кишергә сибәргә җәй буена су ташыйсы бар Пәһлеван абзаңның, ташларны килделе-киттеле тезсәң, бер төшеп менүгә үк кыйшаеп-чалшаеп бетәрләр. Куш аяклап сикереп, баскычның тазалыгын сынап карады Пәһлеван — шәп, түзәчәк баскыч! Аннары ул, ак ыштан балакларын ботына тикле сызганып, имән казыклар сукты, өч тактадан гына кечкенә басма җәйде. Балакларын сызгануның кирәге дә булмаган икән, су биленә җитеп күлмәк итәген дә чылатты. Әмма юеш киемнәренең тәненә сылануы шифа гына кебек иде аңа, чөнки Пәһлеван ташу тынып елга үз эзенә кайткан иртәдә үк Мишәдә коенып рәхәтләнергә элек-электән күнеккән инде. Әнә бит, Мишәнең тилереп котырынган яз ташкыннарын куып арганнан соң, көч-куәтен кабат җыйгандай, йокымсырап агуы да Пәһлеванның күзләрен иркәли.

— Сиңа әйтәм, нишләвең бу? Чык тизрәк судан! — дигән тавышын ишетте ул карчыгы Җәмиләнең. — Салкын тидерәсең ич.

Пәһлеван яр өстенә баскан карчыгына борылып карады да:

— Шайтан да булмый миңа, салкын миннән курка ул, — диде.— Менә кара, ышанмасаң, чумып та күрсәтәм әле үзеңә!

Һәм ул капыл гына чүгәләп күздән югалды, башыннан түбәтәе салынды да салмак кына агып китте. Пәһлеванның, күбекләр чыгара-чыгара, зур куллары белән башын-битен ышкып юганы су астыннан күренеп торды.

— Бер әләксә, чир китә белми. Үкенерсең аннары, — дип нәсихәт бирүен дәвам итте Җәмилә, Пәһлеван юынып бетергәч. — Басма сугарга малайларыңа кушсаң, ни була инде, я?

— Үз көчемдә була торып, нигә мин кеше кулына калыйм, ди?!

Пәһлеван судан чыкты, яшь таллар арасына кереп киемнәрен салды, коры чалбарын киеп, аягына тирән галошын эләктерде. Шуннан соң гына агач ботагындагы пинжәген җилкәсенә элде. Җәмилә аңа түбәтәен китереп тоттырды.

— Шулай, карчык, мең шөкер, көчемдә. Ә малайларның үз эшләре үзләренә җитеп ашкан.

— Чирләп китәрсең дим шул. Гомеренә бер авырып карамаган кешегә чир йокса, яман бит.

— Ярар, кирәкмәсне сөйләмә. Мирҗан кайтып җитмәгәнме?

— Кайтса, шуңарчы әйтмим диме соң инде.

— Сөенче алырга кыймыйсыңмы дип торам тагын мин.

— Сугыш бетүгә үк җибәрмәүләре дә бар.

— Кайтам, дигән хәбәрен сорашмыйча гына салмагандыр Мирҗан.

— Шулай да... Кеше кулындагы кеше әле ул. — Кинәт Җәмиләгә күңелсез булып китте һәм ул, картын тынычландырырга теләп: — Кайтыр, аллаһы боерса, озакламас, — дип өстәде.

— Мин дә, кайтмас, димим. Кайтыр, әлбәттә. Тик сабан туена соңламагае дип кенә борчылам. Әллә соң авылдашларга сүз катып караргамы икән?

Алар эш коралларын лапаска менгереп куйдылар, шуннан ук шактый зур мичкә бәйләнгән бәләкәй арба тартып чыгардылар. Пәһлеван тәртә арасына керде, Җәмилә, мичкәгә тотынып, эткәндәй итеп барды. Бакча уртасында шушы арба сыяр өчен киң итеп калдырылган сукмактан, килер сабан туе турында гәпләшә-гәпләшә, су ташырга — басманың яңалыгын алырга төштеләр алар.

— Тыңламый калмас авыл халкы минем үтенечне. Ни өчен, дисәң, сугыш алдындагы сабан туенда без мәйдан тоттык, — дип үз фикерен расларга тырышты Пәһлеван. — Сугыштан соңгы беренче сабан туенда минем малайларның нигә барысы да катнашмаска тиеш икән?!

— Әллә сүз кузгатмыйсыңмы дим, сиңа әйтәм. Хуҗаҗан белән Галиҗан барыбер көрәшми калмаслар. Сабан туеның ахыргысы түгел, Мирҗаны киләсе елда көрәшер. Ике олы малаең көрәшкәч, җитмәгәнмени тагын.

— Нигә икәү генә? Нигә өчесе дә түгел? Сугышта өчесе дә исән калганнар икән, өчесе дә көрәшсеннәр. Пәһлеванның шатлыгы — бөтен авыл өчен дә шатлык. Бәлкем, сабан туена аты таралган көрәшчеләр кирәк булган өчен кайтканнардыр минем малайлар.

— Әле кечесе, Мирҗаны кайтмаган ич.

— Әйтеп яздым мин аңа, әгәренки бөтенләйгә җибәрмәсәләр, көрәшергә генә кайт, дидем. Тыңлар минем кушканны, моңарчы берсе дә сүземнән чыкмады. Аннары килеп, алгы көндә малайларның кайсысы мәйдан тотачагын ачыклыйсы бар. Димәк ки, өчесе дә көрәшергә тиеш. Бәлкем әле, — дип кинәт арбаны туктатып артка борылды Пәһлеван, — дүртәүләп көрәшербез, менә күрерсең, карчык! Бәлкем, әй-йе, батыр сөлгесе миндә калыр, әй-йе!

— Кирәкмәс, ватылып йөрмә, карт, — дип тагын иплән кенә үгеткә кереште Җәмилә. — Кабыргаларыңны сындырырлар, имгәтеп бетерерләр.

— Кабырга сынган чаклар да булмады түгел, күнегелгән анысына. Мәйданда кабырга сыну була ул.

— Картаеп беткәч, яшең җитмешкә үрләгәч инде.

— Һаман ышанмыйсың, көчемдә, дип әйтеп торам ләбаса. Малайларны үзем сынап карыйм, өчесе белән дә көрәшәм.

— Нәрсәгә сыныйсың инде аларны, аллага шөкер, исән-саулар.

— Ә минем үз уем, сыныйсым килә, бетте-китте, вәссәлам!

— Үз холкым, диген, ичмасам.

— Сугыш ул сабан туе түгел. Дүрт ел сугышта йөреп, көрәшне оныткан булсалар, өйрәнерләр.

Авыл җитәкчеләре дә, картлар да Пәһлеванның үтенечен кире какмады: язгы кыр эшләре беткән булса да, сабан туен бер якшәмбегә кичектерергә килештеләр. Пәһлеван моңа бик шатланды, ә башлыклар:

— Син хаклы, Пәһлеван абзый, кәтәрбез Мирҗанны, дүртегезнең бергә көрәшүен күрүе авылдашлар күңеленә дә хуш килер. Син авылның мөхтәрәм кешесе, фронтка бер үзең бер танк төзетеп биргән кеше, — дигәч, түбәсе күккә тиде Пәһлеванның. — Әйбәт малайлар үстердегез Җәмилә җиңги белән.

Фронтка танк бүләк итүен авыл җитәкчеләренең ихтирам белән искә алуларына сөенде Пәһлеван һәм хәтта күңеле дә нечкәреп куйды аның. Гадәттә ул хискә бирелми, кызгануны-җәлләүне ят күрә. Кешеләргә усаллык-әшәкелек эшләмәсә дә, хәйран кырыс холыклы адәм. Әмма бу гадәт-сыйфатларын мәйданга ияртеп керми, бәхәс-тавыш куптармый, көрәшүне изге санап, көндәшенең биленә елмаеп сөлге сала. Бүтән чакта гаҗәп холкын үзе белән йөртә һәм кайчак ап-ачык мәсьәләләрне дә, карышуга урын калдырмыйча, сәер-үзгә хәл итә.

Хуҗаҗан белән Галиҗан бер-бер артлы өйләнгәч, аларны төп йортта берәр ел яшәтте. Гаилә тәртипләренә күнектерү ата-ана янында мәслихәт, дип санады. Аннары аларны башка чыгарды. Хуҗаҗанына олы урамның югары очында, Галиҗанына түбән очында йорт салды, башка каралты-кураларны җиткерергә үзләренә кушты. Ике малаена да сүзе бер булды:

— Бу йортларыгызны мин салып бирәм, болары тузгач, үзегез салырсыз һәм балаларыгызга да беренче йортларын сез үк торгызырсыз, — диде ул һәм мондый карашының серен ансат кына аңлатты.— Әлегә сез йорт салуның мүклисе дә чутлыйсы гына түгел икәнен белмисез һәм кесәгез дә сай, шуңа мин булышам. Киләчәктәгеләрен җиткерергә менә хәзер тәҗрибә җыегыз. Тагын бер нәрсәне онытасы булмагыз — кеше үз гомерендә кимендә ике йорт салырга тиеш.

Кече малае Мирҗан да өйләнде. Инде анысы, гадәт-йола буенча төп йортта калырга тиеш иде. Әмма Пәһлеван карчыгы Җәмиләнең:

— Картайган көндә үзебезне карарга да кирәк булырлар, — дип искәртүенә карамастан, Мирҗанны башка чыгарды һәм төпчегенә йорт урынын абыйлары күрше-тирәсендә дә, төп йорт янында — су буенда да түгел, тау башы урамыннан сайлады. Малайларын авылның төрле төшенә урнаштыруның да үз сере бар икән: якын торсалар, бер-берсенә, болай да күз алдында, дип, кереп йөрмәүләре ихтимал, ә хәзер белешми-йөрешми хәлләре юк.

Хуҗаҗан белән Галиҗаны сугыштан әйләнеп кайттылар, ә Мирҗаны тоткарлана менә. Олыларында үзгәреш сизелми диярлек. Хуҗаҗанның чәченә чал кергән дә, ияк астына сызык сызылган. Галиҗаны гел дә элеккечә, кичә китеп бүген кайтып кергән кебек. Хәрби киеме генә бүтән төс бирә. Мирҗаны да, шәт, элекке көч-куәтендә үк кайтыр, чөнки анысы арада иң яше, ә яшьлек тиз бирешми ул. Хуҗаҗаны олыгаеп килә, шул сәбәпле генә аңа сугыш эз төшергәндер. Я, Мирҗан, кайтып күрен әле, көчең югалмадымы икән, сөлге салып карыйк биленә...

Шулай, көч сынашырга ярата Пәһлеван. Күп булды инде аның көч сынашулары, бу озын гомерендә кемнәр белән генә алышырга туры килмәгәндер дә, күпме көч чыкмагандыр. Ә көч, шөкер, һаман бар, көрәшеп-сынашып яшәсәң, чыкканы да кайтып тора икән аның, бетми икән ул. Таяк та тартыш, бүрәнәгә атланып капчык белән дә сугыш, юан тумранны ялгызың гына күтәреп арбага да сал — ярыштан беркайчан да йөз чөермә, үзеңне гел күнектереп тор...

Әмма бервакытны Пәһлеван көч сынашудан баш тарткан иде. Байтау ягындагы сабан туенда батыр калгач булган иде бу хәл. Мәйдан халкы таралыр чакта бер шаяны Пәһлеван янына килде дә:

— Батыр дигән даның бөтен тирә-юньгә таралган, Пәһлеван абый, — диде. — Менә шушыны салып бетерсәң, батырның да батыры буласың. — Һәм аның алдына тулы чирек аракы куйды.

Пәһлеван кәгазь бөке тыккан чирекле шешәгә озак карап торды, аннары аны муеныннан тотып күтәрде дә, көлемсерәп, җиргә кире утыртты. Әлеге егеткә:

— Көчле икән бу нәрсәкәй, — диде. — Моны, шул, ексаң, син генә ега аласыңдыр. Шешә белән көрәшү миңа фараз ителмәгән.

Түгәрәктәге кешеләр Пәһлеванның сүзен хуплап теге егеткә:

— Көрәштә дә, монда да җиңде сине Пәһлеван, — диделәр.

— Ашау-эчүдә минем белән көч сынашасың килгәч, без болай бәхәсләшик, — диде Пәһлеван үзен аракы белән сыйламакчы егеткә.— Мәй эчүдән түгел, май ашаудан! Бер кадак майны коры килеш дүрт кабуда ашап бетерештән!

Мондый бәхәс халыкка ошый калды, каяндыр ике кадак май да табып китерделәр. Һәм Пәһлеван зур йомарлам майны беренче булып ялт иттерде.

— Сыегыз өчен рәхмәт, егетләр! — диде һәм җигүле атына утырып китеп тә барды.

Әйе, күп тапкыр көч сынашты инде ул. Сабан туйларында үз малайлары белән дә көрәште, быел да алышырга исәбе, тик менә Мирҗаны көттерә. Быел малайлары белән көрәшүнең соңгысы булуы да бар. Карчыгы Җәмилә әйтеп тора, җиткән инде сиңа, ди, бер дә чамаламыйча такылдамый торгандыр. Әйе, бәлки, ул да дөрес фикерлидер, мәйдан тотуны башкаларга калдырырга кирәктер. Тик малайларның кайсы алыр икән Пәһлеван батыр урынын? Яшь буенча барса, олысы — Хуҗаҗаны инде. Әллә уртанчысы — Галиҗанымы? Әллә бүген-иртәгә кайтып төшәсесе — төпчеге — Мирҗанымы? Әллә... Сабан туе батырлар табарга ярата, ул — батырлар җыены, Пәһлеванга мәйдан тотуны чит кешегә тапшырырга туры килерме?..

Пәһлеван еш кырынмый, сакал-мыегы чәчләрен куып җитеп, йомры башы тоташ агаргач кына чалгы пәкесен беләүли. Бу арада исә көн саен кырына. Моның бер сәбәбе сабан туе якынлашу булса, икенче сәбәбе Мирҗанны чистарынып каршылыйсы килү иде. Ә Мирҗан бүген кайтып та җитәчәк, шулай дип хәбәр суккан. Димәк, яшәрүчибәрләнү шарт. Һәм Пәһлеван чәчен алдыртырга күрше картына керде, тегесе бер уңайдан сакал-мыегын да кырды. Бәйрәм ашы — кара-каршы, дип, Пәһлеван күршесен үзе дә чибәрләде. Хуҗалыктагы иртәнге эшләрдән соңгы мәшәкате шушы булды аның. Хәзер менә Җәмиләсе белән чишмәгә суга баралар. Чәйлек-ашлык суны оныклары да алып кайтып китәрләр инде, ләкин Пәһлеван моңа риза түгел, үз эшегезне миңа өймәгез генә, безне дә хезмәттән мәхрүм итмәгез, ди ул аларга. Чыннан да, чишмәгә суга бару — бу ике агылый белән тагылыйның яраткан шөгыльләреннән берсе. Пәһлеван тәгәрмәчләр урынына трактор подшипникларын куеп ясаган арбага имән кисмәк утырта. Җәмиләсе, тулы булмаса да ярар, дип, көянтә-чиләкләрен күтәрә. Болай көйләү җайлы булды: Пәһлеван сулы кисмәкне, ике колагыннан күтәреп, өйалдындагы бүкән өстенә эһ тә итмичә кертеп куя, чайпалган өлешен тутырырга Җәмилә чиләкләрендәге су җитә.

— Карале, сиңа әйтәм, — диде Җәмилә, чишмәдән су алгач, — синең авылга чыбыркы шартлатып кайтканыңны шушында ишеткән идем инде миң.

— Булгандыр, ишеткәнсеңдер, чишмә юлында хәбәр тиз йөрүчән, — дип төрттерде Пәһлеван.

— Бик кызганган идем мин сине ул чакта.

— Ялгышкансың.

— Кызгану да түгел инде, әмма гел сине уйладым ул көннәрдә.

— Шулай диген, яраттым, диген, югыйсә, кызганган, имеш.

— Аңарчы да икешәр йөк бүләк төяп кайта идең, бергә яшәгәндә дә сабан туе бүләген ат белән ташыдың. Ә шул елны гына нигә буш кул белән кайттың соң син?

— Сиңа өйләнәсе булганга. — Пәһлеван көлемсерәде. — Сабан туе бүләгенә көн итәргә җыенмасын әле Җәмилә, дип алып кайтмадым ул елны.

— Ә чыны? Авыл саен көрәшеп йөреп, бер бүләксез дә калмагансыңдыр инде. Алты-җиде тәкәң була иде башка елны. Әллә кыйнадылар-таладылармы? Атың да юк иде бит. Сатмагансыңдыр ла инде ул атыңны? Чыбыркы шартлатып кайтып керүеңнең серен авылда хәзергә чаклы берәү дә белми. Мин дә сорарга базмый йөрдем моңарчы.

— Сорасагыз, мин яшермәс идем. Авылдашларның да беләсе килмәгән, димәк. Ә чыбыркы үземә иптәш иде. Шартлаткан саен күп хикмәтләр сөйләде ул миңа...

Алар кайту ягына борылдылар. Җәмилә алга төште — һәй, әттәгенәсе, яшь чагындагы кебек диярлек Җәмиләсе, җиңел-җитез атлаганда, талир тәңкәләре челтерәп куя. Тик кәшемир яулыгын гына җилкәләренә салып, көянтәсе астына кертеп калдырган, күлмәге дә киң, озын, итәге болганмый.

Пәһлеван карчыгы артыннан кисмәкле тәбәнәк арбаны тарта-тарта Җәмиләсе соравына кайтты:

— Булды, чыбыркы шартлатып бүләксез кайткан чак та булды, — дип сөйләп китте ул. — Инде өч авылда батыр калырга өлгергән идем, бүләк белән бер йөгем яртылаш иде. Дүртенче авылда ектылар мине. Каяндыр килгән егет иде ул, исемен дә белмәдем мин аның. Икенче елны очрашкач та сорамадым. Хәер, исеме билгеле инде — Батыр. Ә икенче очрашуда ул көрәшмәде, авырый иде, синең көрәшүеңне күрергә килдем, диде. Менә шул егет салган иде мине. Шәп салды, хәрәмләшмичә. Көч белән күтәреп алды да табага коймак җәелгән кебек итеп аркам белән китереп салды, кулын биреп тартып та торгызды. Чиста салды, андый егулар чын батырларга гына хас. Әйтәм бит, сабан туе батырлар җыела торган урын ул дип...

Пәһлеван бүген кырынган яңакларын сыпырып-ышкып алды, — төксез шома булса да, җыерчык бразналары тирәнәя икән.

— Шулай, көрәштә гел җиңеп кенә тормыйсың. Колхоз башланган елны Хуҗаҗан мине екканны онытмагансыңдыр, шәт. Әле сугыш алды сабан туенда Мирҗан да ега язды бит үземне. Гел җиңсәң, бервакытны бөтенләй җиңеләсең, ә мин гомерем буе җиңелүдән курыкмый яшәдем. Җиңелгәч, ныграк уйланыла һәм рәттән батыр калуым ишәя генә иде. Теге чакта нигә чыбыркы шартлатып кайттыммы? — дип йомгаклады Пәһлеван. — Бүләкләрне һәм ике атымны үземне еккан егеткә бирдем һәм бүтән көрәшмәдем ул елны. Алмаска әйткән иде дә теге егет, ай-ваена карамадым, батыр — син, барысы да синеке, сөлге-яулыклар сиңа сабан туе бүләге булса, атлар — миннән бүләк, дидем. Менә шул. Сере юк ул чыбыркы шартлатуның. Ә теге егет минем көрәшкәнне карарга икенче елны авыру килеш тә килгән бит әле, димәк, яраткан минем көрәшкәнне, үзенә тиң күргән...

Калган юлны, уйга чумып, сөйләшмичә кайттылар. Икесенең дә уе бер иде — быелгы сабан туенда кем батыр калыр? Хуҗаҗанмы? Галиҗанмы? Мирҗанмы? Пәһлеван, әлбәттә, үзе дә тырышып караячак. Пәһлеванны исәптән төшерергә иртәрәк түгелме? Әллә сабан туе өр-яңа батырлар табармы? Шаярмагыз, Гитлерны чәнчелдергән, Гитлерның оясын туздырган егетләр чыга быел мәйданга! Шулай да Пәһлеван барын да онытмасыннар...

Сабан туен кичектереп торулары шәп булды, — төш турында Мирҗан да кайтып җитте. Күкрәге орден-медальләр белән тулы егетнең, бүләк ягыннан да ике абыйсын егып салган! Хуҗаҗан белән Галиҗанда да орден-медальләр җитәрлек, алар да сынатмаган, тик, ни әйтсәң дә, Мирҗанда дәрәҗәлерәк бүләкләр шул. Менә иртәгәсе көрәштә ничек булыр тагын, малайларның кайсысы батыр калыр, әллә быелга Пәһлеван үзе калырмы?..

Иртәгә күрербез-белербез инде, иртәгә сабан туе.

Җәмиләгә утырырга җайлырак урын сайлыйсы булыр иртәгә, картының һәм малайларының көрәшүен бөтен-бар нечкәлекләренә хәтле күреп торсын ул. Ә менә... Кайсысы җиңсен дип теләр соң? Иң көчлесе, киләчәктә мәйдан тотардае батыр калсын. Ә кайсысы иң көчле батыр соң...

Пәһлеван читек кунычларын җыерып куйган, ак күлмәгенең итәген чыгарып салып, кара камзулының изүен ычкындырган, укалы түбәтәен ялтыравык башына батырып кигән. Ул, җил-җил килеп, көрәшкә зарыгуын халыкка ирештереп, мәйдан уртасына керде. Солдат малайлары, күкрәкләрендә орден-медальләрен чыңлатып, артыннан иярде. Һәм мәйдан түгәрәге берьюлы тулып китте.

— Без көрәшкә әзер, җәмәгать, — диде Пәһлеван, түбәтәен салып, һәм халыкка башын иде.

Аның бөтен тәне-рухы көрәшче көченнән кайный иде.

1977

Марсель Зарипов

# ЯҢА ЭШ—КИҢ КОЛАЧ

Элек бер башак үскән җирдә — ике башак, бер үлән-кыяк үскән төштә ике кыяк үстерә алган кеше бөтен кешелек дөньясының рәхмәтенә лаек булыр, үз иленә зур хезмәт күрсәтер иде.

ДЖОНАТАН СВИФТ.



Нефть эшкәртү һәм нефть химиясе промышленносте министры Федоров Түбән Кама «Нефтехимия» берләшмәсендә ярдәмче производство оештыру турындагы приказга 1978 елның 22 февралендә кул куйган. Анда мондый пунктлар була:

1. ...Түбән Кама «Нефтехимия» берләшмәсенә бирелгән җирләрдә 1978 елның 1 февраленнән «Нефтехимик» совхозы оештырырга...

2. Бу максатлар өчен 1978 елга... хезмәт лимитлары һәм кирәк кадәр акча бирү тәэмин ителә...

«Кирәк кадәр акча» — биш миллион сум!

Соңгы елларда онытыла башлаган бу тармакны — производство предприятиесенең ярдәмче хуҗалыгын җәелдереп җибәрү өчен ике мең ярым гектар җир билгеләнде, үзәктән биш миллион сум акча бүленде. Шул нигездә көн саен ике тонна ит җитештерерлек кошчылык фабрикасы һәм дуңгыз симертү фермалары — моңарчы бу якларда күрелмәгән зур-зур биналар салырга кирәк иде. Елына иткә ике йөз мең тавык һәм һәркайсы кимендә алты пот авырлыктагы җиде мең баш дуңгыз үстерү планлаштырылды.

Совхозны оештыру турындагы боерык башкалада мондый эшләр башланган чагында була торган урау юлларда йөри иде әле. Түбән Камада исә аны көтеп тормастан, җиң сызганып эшкә дә керештеләр. Җитмеш сигезенче елның март аенда ит фабрикасы төзелешенә бетон юллар салынды. Бу җирләрдәге элеккеге колхоз фермалары ремонтланды — аларга су керттеләр, улак-тагараклар урнаштырдылар. Кошчылык фабрикасы төзү башланды. Камага балыкчы артельләре чыкты. Якынтирә авыллардан мең ярым баш умарта сатып алынды.

Яңа хуҗалык үзенең оеша башлау чорында ук, дәүләттән бер килограмм азык та алмыйча, 256 баш дуңгыз симертеп, ашханәләргә итнең беренче тонналарын озатты.

— Көзен инде һәр умартадан кимендә берәр пот бал алдык,— ди Чигвинцев.— Приказ көтеп ятсак, бармак яларлык та булмас иде...

— Бал кортлары ашарга сорамый, алар чәчәктән ризык таба, — дип каршы төштем мин.— Дуңгызлар бөтенләй башка бит: һәркайсына көнгә ун килограмм азык кирәк. Аны кайдан аласы!

— Анысын да таптык. Ике кешегә бер машина бирдек тә, балалар бакчаларына, ашханәләргә җибәрдек. Азык калдыкларын төяп кайтырга. Тоннасына җитмеш биш тиен түлибез. Мул да, арзан да. Җыймасак, әрәм генә булыр иде. Фуражга күчереп исәпләсәң, без кайтарткан азыкның тоннасы өч сумга төшә, ә концентратка дүрт-биш тапкыр артыграк түлисе...

Журнал укучылары Григорий Никифорович Чигвинцевны хәтерлиләрдер әле. Мин аның эшчәнлеге хакында элегрәк тә бер язып чыккан идем. Аның мондагы эзләнүләре тагын да кызыклырак.

Кама буендагы «Красный ключ» кошчылык фабрикасы комбиазыкны Чаллы элеваторыннан кайтара. Дистәләгән машина — махсус җиһазландырылган фургоннар — иртүк чыгып китә. Баруы — кырык, кайтуы кырык километр, шактый ара бит! Гадәттә, элеватордагы лаборатория азыкның рецептын яза, бу инде, үзенә күрә, продукциянең сыйфат билгесе. Алып кайт та тавыкларга ашат. Юк бит, Чигвинцевның үз сиксәне сиксән, азыкның сыйфатын тикшерү өчен, фабрикада да лаборантлар билгели. Элеватордан бирелгән кәгазьләрдә «азык шәп» дип язалар, ә фабрика лаборантларының тикшерүе моны расламый. Азыкта иң кирәкле кушылмалар булмый. Нишләсен Чигвинцев — уйлый да кошчылык фабрикасында элеватор филиалы ачып җибәрә. Әллә кайлардан — Кара диңгез буйларыннан кабырчык кайтарта, Камадан чуерташ китерә, ит комбинатыннан май алдыра, «А», «В», «С» витаминнары эзләргә кешеләрен Белгород шәһәренә, Мари республикасына юллый.

Чигвинцев белән исәп-хисап ясаганыбыз бар. Бик кызыклы, мавыктырырлык һәм уйландырырлык саннар килеп чыкты. Бер ел дәвамында «Красный ключ» фабрикасында элеватордан алынган азыкка өстәү өчен 120 центнер балык мае, 1558 центнер техник майлар, 958 центнер балык шпроты, 2042 центнер кабырчык, 964 центнер чуерташ, 252 центнер сөяк оны, 319 центнер тоз файдаланылган. Болар өчен тотылган чыгым — 230 мең сум. Аз акча түгел! Ә бу өстәмә эшне башкару өчен күпме тырышлык салынган, күпме көч куелган...

Шуларны уйлыйм да Чигвинцевка сорау бирәм:

— Кош караучыларга мондый өстәмә мәшәкатьләр кирәк микән соң! Элеватор азыкны тиешенчә әзерләдек дигән паспорт-гарантия биргәч, аңа тагын ниндидер кушылмалар эзләп йөрү — өстәмә мәшәкать кенә ич.

— Элеватор азыкка нинди гарантия бирә соң! — дип, сорауга сорау белән җавап кайтарды Чигвинцев.— Элеватор тавык асрамый, чебеш үстерми, әзерләгән азыгын үзендә ашатмый. Ә миңа тавыкларның үрчүе, артымы, ите, каурый-мамыгы кирәк. Җиңел юлдан бару мәшәкатьсез, әлбәттә. Дөресен әйтим, ул азыкны дуңгызлар да ашамый. Ә без чебеш үстерәбез, че-беш! Элеватор азыгына ышанып итсак, алар кырыла башласа! Чигвинцевның якасыннан эләктереп алачаклар бит, һичшиксез, алачаклар. «Әһә, син теге чакта дәүләтнең күпме акчасын туздырдың — зур фабрика салдырдың, колачны киң җәеп эшләргә вәгъдә бирдең түгелме!! Кайда ул вәгъдәләрең, иптәш Чигвинцев! Алдадың!..» Шулай дисәләр — кая барасың!

Бу сөйләшү яхшырак аңлашылсын өчен, «Красный ключ» ирешкән уңышларга күз салырга кирәк. Кош караучылар җитмешенче елда 31 миллион 189 мең данә йомырка, 343 тонна тавык ите җитештергән. 1975 елда йомырка 80 миллион данә алынган: 2,6 тапкыр артык! Кошчылар үзләренең бишьеллык планнарын дүрт елда үтәп чыкты: 188 миллион 300 мең йомырка җитештерергә сүз биргәннәр иде, ике йөз алтмыш миллион данәдән күбрәк алдылар. Тавык ите дә 1860 тонна урынына 2545 тонна җитештерелде. Фабрика унынчы бишьеллыкка шундый биеклектән атлап керде һәм ел саен 90—100 миллион данә йомырка алырга вәгъдә итте. Бу инде — әйткән сүзендә торучы коллектив!

Кошчылык фермаларында эш сыйфатын, кешеләрнең осталыгын һәм талантын билгели торган бизмән бер генә: ул — һәр центнер ит, мең данә йомырка җитештерү өчен тотылган азык күләме. Терлек һәм кош-корт алдына азыкны юмарт кулдан мул итеп салу өчен әллә ни зур акыл кирәкми. Азыкны азрак бир, ит, сөт, йомырканы күбрәк ал — менә кайда осталык, уңганлык, эш итә белү сере!..

«Красный ключ»та моны беләләр. Монда мең данә йомырка җитештерү өчен елга 1,7 центнер бөртек (күз алдына китерергә, исәпләргә уңайрак булсын өчен, биредә барлык төр азыклар бөртеккә күчереп исәпләнә) тотыла.

Ә РСФСРның «Птицепром» фабрикаларында исә шул хәтле үк йомырка җитештерү өчен бөртек «Красный ключ»тагыдан кырык килограммга артыграк тотыла. Димәк, елга сиксән миллион данә йомырка җитештерүче уңган бу коллектив утыз мең тоннадан күбрәк бөртекне янга калдыра.

Тагын бер санга күз салу урынлы булыр: фабрикада бер данә йомырканың үзкыйммәте 3,7 тиен, ә дәүләткә сату бәясе — тугыз тиен. Тиеннәрдән сумнар җыела: «Красный ключ» узган бишьеллыкта унике миллион сум саф табыш алды. Шуннан соң инде: «Тавык — кош түгел, тавык асрау — эш түгел» дип әйтеп кара!!

Сер түгел, кайберәүләр төрттереп тә куйгалый: «Красный ключ» кошчыларының эше җиңел, аларга табигать үзе дә булыша, янәсе. Сүз юк, җир уңдырышлы бу якларда. Игенчегә тагын ни кирәк! 1975 елда хәтәр корылык булды. Республикада бөртеклеләр уңышы уртача 8,6 центнер алынса, «Красный ключ»та утызар центнер җыйдылар.

Фабрикадагы тавыклар да бу төбәктә «иң уңганнардан» санала: читлекләрдә утыралар, бөртек чүплиләр һәм, сүз берләшкәндәй, елына 230—235 йомырка салалар. «Красный ключ»ның бал кортлары да тырыш, мондыйларны кайлардан гына табып китерделәр икән дип уйларлык. Фабриканың дүрт умарталыгындагы һәр

умартадан ким дигәндә икешәр пот бал алына. Бу җәһәттән дә «Красный ключ»ны мактыйлар, умартачыларына премия-бүләкләр ява.

«Боларның эше нишләп бармасын — бөтенесе заводтагы шикелле корылган бит» дигән сүзләрне дә ишетергә туры килә. Чыннан да, директор кабинетында телевизор тора, анда фабриканың теләсә кайсы почмагын күрергә мөмкин. Төймәгә бастың исә — рәхим ит, тавыклар ни ашый, сулары бармы — бөтенесе күз алдында.

Хәзер Татарстанда унбишләп кошчылык фабрикасы эшли. Кошчылык производствосын концентрацияләү дәвам иттерелә. Иске фабрикалар үзгәртеп корыла, яңалары бүгенге көн таләпләренә яраклы итеп салына. Һәр фабрика кимендә 200 мең тавыкны бер урында тотуга исәп итеп төзелә. Татарстандагы кошчылык хуҗалыклары якын арада дәүләткә ел саен ярты миллиард данә йомырка, 14 мең тонна кош ите бирәчәк. 1985 елда исә йомырканы 750 миллион данә, кош итен 42 мең тонна җитештерү күздә тотыла.

Бер түбә астында 250 мең тавык асрарлык зур фабриканы, республикада беренче булып, «Красный ключ»та төзеделәр. Кечкенә фермаларга караганда зур фабрикаларның экономик яктан күп мәртәбә нәтиҗәлерәк, файдалырак булуы да шунда расланды.

Моңарчы кошчылык биналары егерме мең тавык сыярлык итеп төзелә иде. Әгәр барына бер зур корпус салып куйсаң! Биналарны гадәттәгечә салу өчен 2 миллион 600 мең сум акча кирәк. Бер генә корпус төзесәң — миллион сумга арзангарак төшә. Өч миллионның берсен янга калдыру аз түгел бит!

Чигвинцевның фикере энә күзеннән үткәрелде дисәк тә хаталану булмас. Башта аның тәкъдимен трестта өйрәнделәр, аннары республиканың Министрлар Советы карады. КПСС өлкә комитетында да тикшерелде бу мәсьәлә. Ниһаять, Россия Федерациясенең авыл хуҗалыгы министрлыгы һәм СССР Госстроеның коллегияләренә куелды. Яңалык һәр җирдә хупланды, чөнки отыш булачагы ярылып ята иде.

Безнеңчә, Чигвинцев һәм аның кулы астында эшләүче кешеләрнең төп сыйфаты да шунда, алар зур идеяләр белән ялкынланып, олы ниятләрен башкаларга сөйләп кенә калмыйлар, бәлки шуларны тормышка ашыру өчен җиң сызганып эшкә тотыналар.

Бу предприятиедә эшнең куелышын һәм барышын күрсәткән гыйбрәтле саннарны мин шулай бик төпченеп куен дәфтәремә теркәп йөргәндә, Чигвинцев миңа:

— Тыйнаграк булыйк, безнең уңышларны бик мактамыйк! — дип куймасынмы.

Менә сиңа кирәк булса! Дөресен әйткәндә, мин аптырабрак калдым. «Красный ключ» ирешкән биеклекләр куплэрнең төшенә дә керми, алар турында әле хыялланырга гына мөмкин. Ә директор «бик мактамыйк!» дип торсын. Ни өчен! Шуны аңламый торуыма гаҗәпләнгәндәй, Чигвинцев төшендерергә керешге:

— Әлбәттә, без ирешкән уңышлар кайберәүләр өчен һавадагы торна әле. Тик үзебез өчен дә бик зурдан дип уйламыйм. Бездә булган барлык мөмкинлекләрне күз алдына тотып уйласаң, кулдагы күкшел генә алар. Кешеләребез, һичшиксез, әйбәт, тырышлар. Эш өчен ялкынланып йөрүчеләр. Һәркайсы үз урынында алдынгы. Тамара Андриянова, Нюра Зотина, Валя Сочкова, Мария Прохорова һәр тавыктан ике йөз иллешәр йомырка ала. Ә тулаем фабрика буенча әлегә ике йөз утыз алтыда туктадык. Азык әйбәт булганда, ике йөз иллене уртача алуыбыз да ихтимал. Бу да чик түгел. Тавыктан елга өч йөз йомырка алырга кирәк. Без хәзер көнгә илле тонна бөртек ашатабыз, сыйфатын яхшыртканда — аның утыз тоннасы да җитәр дип уйлыйм. Күрәсез, нинди экономия!.. Моңа ил күләмендә ирешсәк — кая барып баса!

Мин бер хикмәткә төшенә алмый озак йөрдем: шулай да комбиазык хәзерләү филиалы фабрикага бик кирәкме икән соң! Чүп өстенә чүмәлә дигәндәй, мең шөгыльгә тагын зур мәшәкать ич ул. Шуңа күпме өстәмә акча тотыла. Әйтик, фабрикада йомырканың мең данәсе утыз җиде сумга төшә, шуның тугыз тәңкәсе азыкны өстәмә эшкәртүгә китә. Аннары бит, кош караучылар, дөресен әйткәндә, башкалар эшләргә тиешле эшне башкара.

Башыңа төшсә, башмакчы булырсың, дигәннәр. Азыкны тиешле кондициягә җиткерү өчен, ул үзендә комбиазык заводының филиалын ачарга мәҗбүр. Бер фабрикада гына андый хәл булса, язып торасы да юк, аерым очрак, дияр идең. Тавык асраучы бик күп предприятиеләргә хас күренеш шул бу. Татарстанда гына түгел, бөтен ил күләмендә. Элеваторлар һәм комбиазык заводлары һәркайда бер үк төрле азык болгатып чыгаралар.

«Статистика бөтенесен белә» дигән сүз бар. Бу очракта әлеге раслау хаклыктан ерак тора. Иң ышанычлы саналган белешмәләрдән дә комбиазык җитештерүче элеваторлар һәм заводлар белән кошчылык фабрикалары арасындагы каршылыкны раслый торган мәгълүматны таба алмыйсың.

Бездә бу бәлагә шул хәтле күнегеп җителде ки, кошчылык фабрикалары штатында лаборантлар билгеләү каралган. Йомырка җитештерәсе предприятиеләрне салганда ук азык цехларын төзүне күздә тоталар һәм зур-зур чыгымнар тотып аларны корып та куялар. Аннары ни лаборантлар, ни әлеге азык цехлары мөстә-

кыйль эш башкармый, бары тик азык заводлары болгаткан боткага төрле өстәмәләр, витаминнар кушып, аны кондициягә җиткерү белән шөгыльләнәләр. Моңа күпме чыгымнар тотыла, меңләгән кешенең хезмәте салына. Әмма эш анда гына да түгел. Кошчылык фабрикасындагы азык цехларын күз алдына китерик. Аларда берниндн машина юк, эш коралы — чиләк тә көрәк. Ә төп корпусларда автоматлар эшли, телевизион идарә аппаратлары куелган.

«Красный ключ» һәм башка кошчылык фабрикаларында азыкны яхшырту өчен гаҗәп күп көч сарыф ителә. Бөтенесе кул көче белән башкарыла. Азык заводларында исә шул ук эшне күп тапкыр җиңелрәк башкарырга, азрак чимал тотып, әйбәтрәк нәтиҗәгә ирешергә мөмкин, чөнки аларда производство процессларын механикалаштырырга, автоматлаштырырга була. Поливитамин табу авыр, аны юнәтү өчен Чигвинцевның үткенлеге дә кирәк ди, әмма чуерташ, кабырчык нише өстәмәләр әзләп йөрисе юк лабаса. Идел, Кама, Вятка елгалары, Кара һәм башка диңгезләрдән аларны кирәк кадәр алырга була. Шуны уйлыйсың да, азык заводларында эшләүчеләргә әйтәсе килә: «Нишләп әле сез үзегез башкарасы эшне бүтәннәр иңенә саласыз, туганкайлар! Хезмәт бурычларыгызны әйбәт үтәмисез бит, намусыгыз йокымсырап ятамы әллә!»

«Красный ключ» директоры Чигвинцевка бу фикеремне әйткәч, ул сорау белән җавап бирде:

— Элеватор кешеләренең намусы уянганын көтсәк, кая барып җитәрбез, ә!.. Безнең инкубатордан көн саен меңләгән чебеш чыга. Ашатырга, җылытырга, назларга кирәк аларны. Элеватордан сыйфатлы азык биргәннәрен көтеп ят! Һәр чебиге көн саен егерме бер грамм азык кирәк. Протеинлы, витаминлы булсын!.. Алары юк икән — чебеш үсми. Үссә дә йөз сиксәненче көнне үк йомырка салмый, бер ел көттерә. Ә аны барыбер ашатасың. Менә шундый арифметика бездә: азык әзерләү өчен елына ике йөз дә утыз мең сум тотабыз, ә табыш — ике-өч миллион! Кайсы яхшырак!..

Әлбәттә, табыш алу әйбәтрәк, анысы бәхәссез. Ләкин хикмәт шунда, кошчылык фабрикасы бу керемне әлеге азык расходларын тотмыйча гына да ала ала. Арбитражга мөрәҗәгать итеп, тиешле документларны тапшырсалар һәм элеваторның сыйфатсыз азык бирүен дәлилләсәләр, «Красный ключ»ка бу акчаны кайтарачаклар. Ул бит директорның шәхси капиталы түгел, бөтен коллектив табышы, дәүләт акчасы. Директор теләсә-теләмәсә дә, табышның ике йөз утыз мең сумга кимүе производствоны үстерүгә җибәрелә торган фондны кыскартуга китерә. Былтыр, мәсәлән, фабрика бер торак йортны төзеп бетерә алмады, менә шунда бу акча бик ярап торыр иде. Премиягә диган өстәмә өлеш тә шунда — былтыр аны да кырык алтышар сумга кимрәк бирделәргә туры килгән.

— Безнең бүтән чарабыз юк. Элеватор бу мәсьәләне бик гади хәл итә: азыкны озата да, акчасын күчертеп ала. Калганы өчен кайгырмый. Фабрикада ул азыкны ашатып файда алалармы, юкмы — монысында хәсрәтләре-гамьнәре сизелми.

— Арбитраж ни өчен!— дип сорадым мин, һаман бирешергә теләмичә.— Хезмәттәшлек мөнәсәбәтләре шундый йомшак икән, партнерларның берсе икенчесенең экономик мәнфәгатьләрен оныта икән,— хуҗалык итү мөнәсәбәтләренең хокук нормалары бар бит әле. Бу очракта юридик каналлардан файдаланырга кирәк, минемчә. Эш итә белү үзеннән-үзе генә килми, җаваплы кешеләрдә бу сыйфатны тәрбияләргә дә кирәк. Бу хакта партиябезнең XXV съездында болай диелгән иде: «Договор йөкләмәләрен бозуларына һәм начар сыйфатлы продукция җитештерүләренә дә карамастан, ваемсызларның алдынгы булып йөрүләренә мөмкинлек бирә торган бөтен юлларны ябарга кирәк, план һәм договор дисциплинасын бозган өчен кагтый һәм ныклы санкцияләр белән бергә, материаль һәм мораль стимуллаштыру системасы тәгәл хәрәкәт итәргә тиеш». Нигә, мәсәлән, шундый тәртипне урнаштырмаска: комбиазык индустриясе предприятиеләре үз гаепләре аркасында башкалар тоткан чыгымнарны процент белән түләсеннәр, ә яхшы эшләгәннәренә партнерлары алган табыштан да өлеш чыга торган булсын.

— Ярый, синеңчә дә булсын.— Чигвинцев минем белән килешкәндәй күренде.— Без, үзебезнең юридик хокукыбыздан файдаланып, элеваторга арбитраж кусәге белән тондырдык та ди. Ә Закиров безгә кусәкнең икенче башын төшерәчәк. Ничекме! Фонд белән! Андый хәлне ишеткәнең юкмы! Квартал башлана, ә азык алу өчен нарядлар Мәскәүдә йөри: Госснабта: министрлыкта, Главкада... Анда тоткарланып торырлык урыннар бар, аллага шөкер. Әмма чебешләргә моны аңлатып булмый. «Түзегез, сарыкайларым, пипелдәмәгез!» дия алмыйсың. Юк, без элеваторга барабыз: «Коткар, зинһар!» Ә аның капкасында ат башы чаклы йозак и вәссәләм! «Хакыбыз юк, дәүләт фондын рәсми кәгазьсез җибәрә алмыйбыз», диләр анда. Алар хаклы да. Менә шул чакларда инде үзең этәч булып кычкырып дәрәҗәгә җитәсең. Әгәр Чигвинцев көннәрдән бер көнне: «Җитте! Чебешләргә, тавыкларга азыкны тиешенчә әзерләп китерсеннәр, мин башкача кыл да кыймылдатмыйм!» — дип белдерсә, ни әйтерсең! Директорга үпкәләрлек юк. Бөтенесен үз өстеннән төшерү өчен, эшлекле кыяфәт белән, кабинетындагы телевизор төймәләренә шалт та шолт басып та утырса, төрле оешмаларга белешмәләр, хатлар язарга керешсә, хәбәр итсә...

Мин Чигвинцевны «кыздырырга» тырыштым: директор урынында булсам, моны болай калдырмас идем, янәсе. Арбитраж ярдәмендә партнерларның арт сабагын укытыр идем... Төгәллеккә өйрәнсеннәр, эшне җиренә җиткереп үти белергә вакыт. Күпме, ничә ел түзәргә була! Әллә кайчаннан килә бит инде бу.

Күпне күргән, тәҗрибәле Чигвинцев, «дөньяга син балаларча садә карыйсың, егет» дигәндәй кыяфәт белән аңлата миңа:

— Мине юлдан яздырырга азапланма. Җитлеккән иждивинец итмәкче буласың. Барып чыкмас. Кыенлыклар өчен гаепләне читтән эзләү — буш, мәгънәсез эш. Һәр урында проблемалар булган, бар һәм булачак. Алар бетсә, тормыш та сүнәр иде. Мин бит бүген эшлим. Бү-ге-ен!.. Димәк, хәзер үк нидер булдырырга тиешмен. Эшем өчен кешеләр алдында кызарырга туры килмәсен. Үз намусым алдында да...

— Тагын нәрсәне бүген үк эшләргә телисең!— дип сорадым мин, җавап сүзендә берәр фәлсәфи гомумиләштерү ишетергә өметләнеп. Аның холкы шундый инде — сүзләре уйланган, үлчәнгән, тирән мәгънәле булыр.

Гәптәшем беравык сүзсез торды, ни әйтәсен уйлады, ахрысы, аннары мин бөтенләй көтмәгән җавапны бирде:

— Хәзер үк нәрсә эшләр идемме!.. Аминокислоталар табар идем: цистеин, аргинин, метионин... Шуларны тапсам, иллә дә шәп буласы! Тавыкларга азыкны азрак бирәсең, ә продукция күбрәк алына. Йомырканың бер данәсе дүрт тиенгә төшми, өч тиен генә була. Сиксән миллион тиен отыш бит! Юк, начар түгел!..

*

* *

Промышленность үзәге буларак, Түбән Кама шәһәренең һәм андагы нефть химиясе производствосы комплексының ничек барлыкка килүе, үсеше, аларның авыл хуҗалыгына таләпләре мәгълүм. Шул таләпләрне үтәү йөзеннән авыллар ни башкара, аларда нинди үзгәрешләр бара — шуңа күз салыйк.

Түбән Кама районы территориаль-административ яктан алтмышынчы елларда формалашты. 1977 елда районның авыл хуҗалыгы җирләре 86 мең гектардан 82 933 гектарга калды — шәһәр һәм промышленность комплекслары шактый мәйданны кисеп алдылар. Иң мөһиме шунда — сөрү җирләре кимеде. Шуннан инде һәр гектарның, һәр басуның кадере ничек күтәрелүен чамаларга була. Элек иген үскән кырлар киңлегендә яңа шәһәр калыкты. Ул, бер яктан, эшчеләр өчен азык-төлекне һаман күбрәк сорый, икенче яктан, авыл кешеләрен үзенә тартып, эшче көчләрне ала тора.

Бу тирәдәге авылларда хуҗалык итүчеләргә бер генә юл кала: индустриаль яктан үскән каланың ихтыяҗларын ничек тә канәгатьләндерергә кирәк. Димәк, авылда производствоны үстерүнең яңа оештыру формаларын эзләү һәм табу, агрономик һәм зоотехник ысулларның иң нәтиҗәлеләрен файдалану таләп ителә.

Соңгы ике дистә ел эчендә район колхозлары һәм совхозларында булган экономик үзгәрешләргә күз салсак, менә нинди хәл күрәбез: җитмешенче елда, сөрү җирләренең кимүенә дә карамастан, бөртекле ашлык җитештерү 50 608 тоннага җитте, ягъни 1960 ел белән чагыштырганда, 10 788 тоннага артык булды. Район хуҗалыклары алтмышынчы елда 9 913 тонна сөт алган булсалар, җитмеш җиденче елда 23 810 тонна җитештерделәр. Арту 2,3 тапкыр, димәк! Ит җитештерү тармагында да үсеш бар — унҗиде ел эчендә ул 2 595 тән 5 193 тоннага җиткән. Ә авыл хуҗалыгында эшләүчеләр саны кимеде бит. Әйтик, унҗиде ел элек район территориясендәге колхоз һәм совхозларда 6 171 кеше эшләгән булса, җитмеш җиденче елда 5 412 кеше генә кала. Эшләүчеләр саны кимеп тә продукция җитештерүне ике-өч тапкыр арттыруга ирешелгән икән — бу инде игътибарга лаек казаныш. Яңа үр ничек яуланган соң! «Статистика» дигән нәрсәнең бүтән параграфына күз салыйк. Кешеләрдәге энтузиазм, дәрт һәм осталыкның күтәрелүе монда бик әһәмиятле, әлбәттә, ләкин боларны нииндидер саннар белән аңлатып, сөйләп бирә алмыйсың. Мөгаен, моны авыл хуҗалыгына тотылган капитал салымнарны чагылдырган саннардан да яхшырак төшендерүче табылмас. Соңгы егерме елда районның авыл хуҗалыгы производствосын үстерүгә тотылган акча һаман арта барган. Зур комплекслар — ит, сөт, йомырка җитештерү фабрикалары төзелә, ясалма яңгыр белән үлән-печән үстерелә торган көтүлекләр булдырыла, алардан җәенә өч-дүрт тапкыр уңыш алына. Колхозлар һәм совхозлар яңа машиналар, куәтле техника белән тәэмин ителә. Һәр авылда торак йортлар, клуб һәм кибетләр, мәктәпләр, ясләләр һәм балалар бакчалары салына. Районда яхшы юллар булдыруга игътибар итәләр. Район советы башкарма комитетының тынгысыз председателе Александр Васильевич Тимофеев безгә бөтен бетон тасмаларны, яңа күперләрне тикмәгә генә күрсәтеп йөрми... Боларның барысы да район хуҗалыгын тәшкил иткән тоташ чылбырның буыннары. Шуларның ныклыгын раслаучы саннар мондый: алтмышынчы елда район авыл хуҗалыгын үстерүгә 1 миллион 452 мең сум тотылган, ә ун елдан — бу суммага караганда ике ярым тапкыр күбрәк: 3 миллион 477 мең 200 сум. Җитмеш җиденче елда бирелгән сумманы күз алдына китерүе дә кыен: 19 миллион 906 мең! Үсеш 14 тапкырдан артыграк!

Ә шул ук вакыт эчендә продуктлар — ит, ашлык, сөт, яшелчә җитештерү күләмен билгеләүче сан андый ук зур һәм тәэсирле түгел. Хикмәт нәрсәдә! Сәбәпләре бармы моның, булса — кайсылары объектив та кайсылары субъектив! Әллә Кончыгышның акыл ияләре бик борынгы заманда ук: «Бер ашлык басуында уңышны күтәрүгә караганда җиде яуда җиңеп чыгу җиңелрәк», дигән фикер һаман да хакмы!

Гомумиләштерүләр ясау өчен бер район киңлекләре генә җитми, әлбәттә. Нәтиҗәләрне бер район мисалында гына түгел, бәлки шуңа охшаш хәлләрне бөтен өлкәдән, республикадан, административ-экономик регионнан туплап өйрәнергә һәм фәнни җирлеккә таянып ясарга кирәк. Без дә карашыбызны һәм индустриаль, һәм аграр булган Кама аръягына, бөтен республика киңлекләренә төбик.

Совет властенең юбилее уңае белән Казанда чыгарылган «Татарстан АССРның халык хуҗалыгы 60 елда» дигән статистик җыентыктан күренгәнчә, Октябрьдан соңгы алтмыш ел эчендә республикадагы эре промышленностьның барлык тармакларында продукция җитештерү 1913 ел белән чагыштырганда 655 тапкырга арткан. Хикмәт биредә сан ягыннан үсештә генә дә түгел. Иң мөһиме — экономикада сыйфат үзгәрешләре, промышленностьта булган яңарышлар. Заманында юкә чабаталары белән дан тоткан яклар бит бу. Казан губернасы Россия базарларына чабатаны ташып кына торган — аны бездә елына ике миллион ярым пар үргәннәр. Моннан тыш, Казан сабын кайнаткан, шәмнәр койган, тире иләү осталары әзерләгән тиреләрне сата алган. Хәзергесен кара син Татарстанның: девон катламнарыннан «кара алтын» суырта, самолетлар ясый, компрессорлар, вертолетлар, математик исәпләү машиналары һәм катлаулы аппаратлар җитештерә. Җир асты хәзинәләреннән углеводородлы чималны эшкәртү җирлегендә яңа гигантлар — нефть химиясе индустриясе туды.

Әмма авылның борын-борыннан килгән вазифалары — әллә ни үзгәрмәде — ул һаман азык-төлек җитештерүче, промышленностька чимал бирүче һәм эшче куллар үстерүче, индустриаль үзәкләрне тәэмин итүче база булып кала бирде.

1926 елда халык санын алу үткәрелгән иде, шуның мәгълүматларына караганда, ул чакта Татарстан халкының 10 проценты —253 мең 800 кеше—шәһәрләрдә, уннан тугыз өлеше—2 миллион 307 мең кеше—авылда яшәгән. Күпме халык иген иккән, мал караган, умарта асраган... 1977 ел саннары инде бөтенләй икенче күренеш турында сөйли: республикабыз шәһәрләрендә 2 миллион 900 кеше яши, ә авылда — 1 миллион 279 мең 900.

Октябрьдан соңгы елларда Татарстанның традицион промышленность үзәкләре — республика башкаласы Казан, революциягә кадәр үк Россиядә билгеле булган Алабуга, Бөгелмә, Чистай, Тәтеш — бик нык үсеп киттеләр. Кама аръягында яңа калалар — нефтьле Әлмәт, Лениногорск, нефтехимия үзәге Түбән Кама, автомобильле Чаллы күтәрелде. Киләсе, егерме беренче гасыр башында, шушы 2,5 мең квадрат километр мәйданда барлыкка килгән зур территориаль комплекста халык саны бер миллионнан артып китәчәк. Бу факт бер җәһәттән бик үзенчәлекле: халык санының аерым төбәктә болай тиз үсеп китүе производствоны концентрацияләү дәрәҗәсе югары булуны аңлата. Тегe яки бу өлкәнең экономик потенциалы, аның илдәге җитештерү көчләрен үстерүдәге әһәмияте нәкъ менә шул дәрәҗә белән билгеләнә дә инде.

Яңа индустриаль үзәкләрнең барлыкка килүе һәм үсүе, үз чиратында, гаҗәп күп төрле проблемалар тудыра. Болар — экономик, социаль, идарә итү, архитектура, эстетик, әхлак проблемалары. Мәсьәләләрнең иң четереклесе — гаҗәп тиз үсеп киткән индустриаль үзәкләрне азык-төлек белән тәэмин итү. Ашамлыкларны җиде диңгез артыннан ташып булмый бит. Анда да артыгын әзерләп куймаганнар. Ә индустриаль үсеш юлына баскан үзәкләр күп, алар бер Кама аръягында гына түгел. Башка урыннарда да шундый ук зур комплекслар сафка баса һәм алар да: «Кешеләрнең азык-төлеккә ихтыяҗын ничек канәгатьләндерергә!» дигән проблеманы тудыра. Моны хәл итү юлларын эзләгәндә, шушы ук җирләрдә ашлыкны күбрәк үстерергә, итне һәм сөтне күбрәк җитештерергә, елга-буаларда балыкны күбрәк үрчетергә һәм промышленность ысулы белән азык-төлек әзерләргә кирәк дигән фикергә кайтып калабыз. Һәр шәһәр тирәсендә халыкны тукландырып торырлык база булырга тиеш, бу — кешелек дөньясының яшәү практикасы белән расланган хакыйкать.

Моның хакында бер риваять бар, аны язучы Генрих Волков үзенең китабына да керткән. Шушы гаҗәеп акыллы риваятьтә ничәмә-ничә буыннарның зирәклеге ярылып ята. Ул хәзерге заман белән дә аваздаш. Анда сүз хуҗалык итү зирәклеге, төрле мөмкинлекләрдән иң яхшысын сайлап алу турында бара. Экономистлар теле белән әйткәндә, комплекслы планлаштыру хакында... Бу урында аны нәкъ шушы җәһәттән искә төшереп үтү урынлы. Ничек диләр әле: әкият булса да — хикмәтле, ә хикмәте — гыйбрәтле.

Борынгы грек архитекторы Динокрит үз эшендә бик талантлы һәм сокландыргыч оста булган. Бервакыт аның башына яңа шәһәр кору уе төшкән. Бу фикерен белдерергә, рөхсәт алырга дип, архитектор бөек полководец Александр Македонский гаскәрләре артыннан киткән. Бөтен дөньяны яулап алырга җыенган гаскәр башлыгының тәхете каршына килеп басу җиңелдән булмаганга, күрәсең, Динокрит үз

максатына зур хәйләләр белән генә ирешкән: өс киемен салып ташлаган, башына яшел яфраклар ураган, җилкәсенә арыслан тиресе ябынган. Кулында кистән ди моның. Шул кыяфәттән бу гаскәр башының чатыры урнашкан үргә күтәрелә икән... Шулай сәер киенгән кешене күреп ала да Александр Македонский аны үз янына чакыртып китерә, сораша башлый: кем син, янәсе, бу тирәләрдә нишләп йөрисең!

— Мин — Динократ,— ди әлеге сәер кеше.— Македониядән үзем, архитектор булам. Сиңа үземнең бик зур проектларымны күрсәтергә җөрьәт итәм, хөкемдар. Алар — синең бөтен дөньяга таралган бөек даныңа лаек эшләр, алар синең нур сирпеп күз салуыңны көтәләр. Мин Афон тавын үзгәртергә, аны баһадир ирнең сыны итеп корырга нияt кылдым. Баһадир сул кулында бик зур шәһәрне, ә уңында таулардан агып төшкән барлык суларны сыйдырырлык зур касә — дәрьяны тотып торачак.

Гаҗәеп зур проект турындагы фикер Александр Македонскийны сокландыра, ләкин аның тышкы ялтыравы гаскәр башының акылын томалый алмый. Полководец шундук сораша башлый. Динократ шәһәр саласы урында иген үстерерлек җирләр бармы! Яңа калада яшәячәк кешеләрне туклandырырга кирәк булачак бит. Иген чәчәрлек җирләр юк, ризыкны шәһәр халкына читтән ташып торырга туры киләчәк икән. Моны белгәч, Александр Македонский архитекторның мәһабәт проектын болай бәяли:

«Динократ, проектыңның композициясенә караган өлешенә сүзем юк, ул — соклангыч! Әмма яшәү өчен шундый җайсыз тау-таш арасына кешеләрне китереп утырткан хөкемдарга ни әйтерләр! Аның башына, һичшиксез, нәгъләт һәм каргыш явар. Яңа туган баланы күкрәк сөтеннән башка яшәтеп, үстереп, гомер баскычлары буйлап мендереп булмаган кебек үк, тирә-юньдә кырлары булмаган, ул кырлардан өзлексез чишмә булып ризык килеп тормаган бер шәһәр дә үсә алмый, тукланү әйберләре муллыгыннан һәм халыкны яшәтү өчен кирәкле шул муллык чыганакларыннан башка адәм нәселе яшәйми. Шуңа күрә дә, проектыңны, яхшы нияt буларак, ни дәрәҗәдә хупласам, урын сайлавыңны шул дәрәҗәдә кире кагам»[1].

Татарстанда төзелгән яңа шәһәрләргә урын сайлау мәсьәләсендә бәхәс була алмый. Кама аръягында индустриаль үзәкләр булдыру өчен урынны кешеләр түгел, табигать үзе әзерләп куйган: монда ул җир асты хәзинәләрендә зур байлыклар саклаган, монда ул ике бөек елганы — Идел белән Каманы кушылдырган. Алар — менә дигән табигый су юллары. Яр буйларында халык тыгыз утырган авыллар һәм шәһәрләр. Бирелә дәүләтебезнең зур акча тотып, зур-зур индустриаль комплекслар салуга нәкъ менә шушы уңай шартлар юл ярды. Бөтен хикмәт — икмәктә, дигәндәй, мәсьәлә бу төбәктә кырларның ашлыкка юмартлыгын арттыруга кайтып кала. Авыл хуҗалыгы мондый зур индустриаль күтәрелешне тәэмин итәргә әзер булганмы — төп сорау шул.

Кем — ничектер, ә мин статистик белешмәләр караштырып, саннар белән серләшеп утырырга яратам. Менә хәзер дә күңел шуңа тартыла.

Октябрьдан соңгы алтмыш ел эчендә Татарстан билгән җир мәйданы артмады да, кимемәде дә. Шул ук 68 мең квадрат километр — илебез территориясенең ярты процентыннан да кимрәк. Әмма шушы территориядәге иген кырларында агротехник үзгәрешләр зур булды. Барыннан да элек, чәчү җирләре күбәйде, аларның гомуми мәйданы бер миллион ике йөз җитмеш биш мең гектарга артты, кысыр яткан басулар калмады. Дөрес, әлеге миллионнан арткан гектарларның бары 46 меңендә генә ашлык үстерелә, калганы азык базасын ныгытуга, техник культураларга бирелде. Бу мәйданның биштән бер өлешендә кукуруз игелә. Татарстанда моңарчы булмаган культура — шикәр чөгендере үстерелә башлады, сугарулы көтүлекләр барлыкка килде, бәрәңге чәчүлекләре артты.

1913 елда бер миллион биш мең җиде йөз тонна уңыш җыеп алынган җирләрдән 1976 елда Татарстан бу якларда моңарчы күрелмәгән уңыш җыйды — игенчеләр дүрт миллион ике йөз унҗиде мең ике йөз тонна ашлык җыйды.

Терлекчелектә баш саны да арткан. Колхоз-совхозларда һәм индивидуаль хуҗалыкларда мөгезле эре терлекләр 609 мең баштан 1 миллион 544 меңгә, дуңгызлар 224 меңнән 1 миллион 47 меңгә җитте. Сарыклар һәм кәҗәләрнең баш саны 200 меңгә арткан. Сугышка кадәрге 1940 ел белән чагыштырганда — статистик мәгълүматлар шул чордан алынган — республикада ит җитештерү, тере үлчәүдә, 79,7 мең тоннадан 326,6 мең тоннага, сөт — 373,2 мең тоннадан 1 миллион 253 мең тоннага җиткән, йомырка җитештерү 188,6 миллион данәдән 811,9 миллионга арткан.

Еллар төрлечә килсә дә, иген уңышы һәм терлекчелек продуктлары җитештерүнең график сызыгы даими — ул туктаусыз үсешне күрсәтә, өскә күтәрелә. Шулай да индустриаль биеклекләр янында (1913 ел белән чагыштырганда 655 тапкырга арткан дидек) бу үр шактый тәбәнәк күренә.

Авыл хуҗалыгын үстерү, азык-төлек җитештерүне арттыру проблемалары һәрвакыт бөтен совет халкының һәм партиябезнең игътибар үзәгендә булды. Тугызынчы бишьеллыкта моңа юнәлтелгән средство сигезенче бишьеллыкта үзләштерелгән

[1] Г. Волков. «Социология науки», М., 1968, 249 бит.

суммадан шактый зур — 129 миллиард сум булуын искә төшерү дә җитә. Ә 1975—1980 елларда авыл хуҗалыгына капитал салымнар 171,7 миллиард сум итеп билгеләнгән.

Яңа промышленность комплекслары янәшәсендә калкып чыккан шәһәрләр һәм поселокларны төзү темпларының азык-төлек җитештерү производствосы күләменә һәм характерына туры килерлек булуы бик мөһим.

Сугыштан соңгы елларда, академик Губкинның «Идел, Урал зонасында «кара алтын» хәзинәләре ята» дигән зирәк сүзләре раслана башлагач, нефть эзләүчеләр җир асты горизонтларының тирән катламнарына төшеп җиттеләр. Совет экономика фәне хуҗалыкны идарә итүнең зур тәҗрибәсен туплады, якындагы бурычларны һәм киләчәктә хәл ителәсе стратегик проблемаларны алдан билгеләү теориясен булдырды.

ГОЭЛРО — беренче адым иде. Аннары беренче бишьеллыкның индустриаль төзелешләре күтәрелде, алар яңадан-яңа төбәкләрнең үсешенә этәргеч бирде. Шул җирлектә аерым республика һәм өлкәләрдә җитештерү көчләре ныгыды, ишәйде. Ниһаять, Урал, Кузбасс, Себер һәм Ерак Көнчыгыштагы җир асты байлыкларыннан файдалана башларга чират җитте. Бу регионнар әле сугыш вакытында ук Совет дәүләтенең көче һәм куәте бетмәс-төкәнмәс булуын раслады, алар безнең гаскәрләргә дөньяны кол итәргә җыенган фашизм хәшәрәтен җиңү өчен кирәк булганның барысын да җитештереп торды һәм, бер үк вакытта, совет экономика фәненең зирәклеген дә күрсәтте. Бу фән халык хуҗалыгын үстерүгә юнәлтелгән яңа программаларны эшләү юлларын ачык һәм төгәл билгели алды, илнең индустриаль үсеш перспективаларын аерым предприятиеләр төзүдә түгел, бәлки эре промышленность комплекслары, бөтен-бөтен тармакларны булдыруда күрде.

Совет экономика фәненең күренекле вәкиле Николай Николаевич Колосовский — ГОЭЛРО, Урал-Кузнецк комплексы планнарын, илебезнең җитештерүче көчләрен ул елларда әле үзләштерелергә өлгермәгән Көнчыгыш районнарга күчерү схемасын төзүдә катнашкан зур белгеч — үзенең бу турыдагы теоретик фикерен болай белдерде: «Эре экономик хуҗалыкларны комплекслы итеп төзегәндә, бөтен көч һәм капиталны төгәл билгеләнгән территориядә концентрацияләү шартларын үтәү зарури.

Сайлап алынган территориядә төп промышленностьны, энергетика һәм транспорт корылмаларын гына түгел, а в ы л  х у җ а л ы г ы н  д а (ассызык — безнеке М. З.) үстерергә кирәк... Мөмкин кадәр... чимал һәм энергия резервлары... кул астында булсын...»

«Экономик районлаштыру һәм халык хуҗалыгын үстерү» дигән зур хезмәтендә ул, зирәк карашын киләчәккә төбәп, проблемаларны кыю күтәреп, илебез киңлекләрен бер бөтен һәм хәрәкәттәге тере организм итеп күз алдына китерә. Галим илне егерме алты өлкәгә — зур экономик регионнарга бүлә, аларның һәркайсына, икүләм бурычлардан чыгып, аерым программа һәм үзенчәлекле үсеш юнәлешләре билгели. Капма-каршы фикерләрнең үзара кисешүе, төрле принципларның һәм аргументларның бәрелешүе фән үсеше өчен зарур нәрсәләр. Табигый ки, Н. Колосовскийның хезмәтен тәнкыйть итүчеләр, аны хәтта тетеп ташлаучылар да табыла... Ә ул үз эшен дәвам иттерә. Комиссияләрдә катнаша, бер өлкәдән икенчесенә командировкаларга йөри,бетмәс-төкәнмәс оптимизм рухы белән ялкынланып, көрәшче һәм гражданин буларак, үзенең фәнни карашларын һәм концепцияләрен яклый.

Илебез сугыш яраларын төзәтте, фашист яулары җимергән авылларны, калаларны торгызды. Тыныч җиргә бөтенләй башка чор — лазерлар, атом төше, телевидение һәм космик дәвере килде. Үзе иҗат иткән программалардан күбесенең тормышка ашырылуын Колосовский күрергә өлгерә алмады, аның эшен совет кешеләренең яңа буыннары дәвам иттерә.

Колосовский программасында Кама буендагы бу индустриаль «мәйданчык» атап әйтелмәгән. Әлеге җир — меңнәрчә квадрат километр мәйдан — ил картасында кеченә бер нокта, күз иңләмәс киңлектә бәләкәй бер «түтәл» генә. Әмма галим аның үзенчәлеген, ролен аңлаган, алдан күргән, бу урынны «Урал белән Үзәк арасындагы индустриаль күперчек» дип атаган.

Регионның әһәмиятен билгеләгәндә, галим үз заманында ныгып урнашкан карашларга каршы төшә. Аның фикерләре әле киләчәктә дә озак еллар буена актуаль булып калыр, чорга авазлаш яңгырар. Киләчәкне алдан күргән кеше белән сөйләшү ялыктырмый — Колосовскийның китабын ачабыз: «Индустриаль Үзәк белән Урал арасындагы — Идел, Кама, Вятка һәм Ветлуга елгалары буендагы территория — Госпланның 1923 елгы проектында дөрес бәяләнмәгән,— дип яза галим, ул чорда китерелгән дәлилләргә һәм аргументларга каршы төшеп.— Бу территория, Урал белән Үзәкне тоташтыручы буын буларак, су ресурслары белән яхшы тәэмин ителгән... Анда нефть чыгаруны арттыру бик әһәмияле һәм шулай булачак та... Тагын да ераграк перспективада гидроузеллар төзү... Урта Идел буеның характеристикасын кискен үзгәртәчәк... Шулай итеп, район үзендә машина төзелеше белән нефть химиясе профильләрен берләштергән катлаулы промышленность комплексын үстерү өчен алшартлар ала. Промышленность комплексы интенсив авыл хуҗалыгы белән

бәйләнештә булачак. Ә тагын да ераграк киләчәктә бу районда промышленностьны һәм авыл хуҗалыгын специальләштерү көчәячәк, монысы электр күп тотыла торган производство һәм игенчелектә суландырудан файдалану һәм техник культуралар җитештерүнең үсешенә бәйле...»

Бу юллар язылганга ничә дистә ел үткән инде. Вакыт галимнең сүзләрен раслады. Әлеге регионда җитештерү көчләренең үсеше нәкъ ул сурәтләгән юлдан бара. Хәзер инде безнең күз алдында Идел һәм Кама гидростанцияләренең каскадлары, иң яхшы җиһазлар куелган нефть промыселларыбыз, баһадир КамАЗ, нефть химиясе гигантлары, уннарча яңа поселоклар һәм шәһәрләребез бар. Хәзер инде Кама аръягындагы комплексны төзү тәгәлләнеп килә, аның перспективадагы гомуми күренеше ачык шәйләнә башлады.

Барлыкка килгән яңа экономик үзәкләрнең һәркайсы индустриаль державабызның бөек гигантлары арасында беренче дәрәҗәдәге йолдызлар итеп санарлык булып чыкты. Табигый ки, мондый гигантларның ихтыяҗы да зур һәм алар янында ышанычлы ярдәмче производство объектлары — заводлар, комбинатлар, базалар төзелде. Индустриаль регионның нәкъ үзәгендә, Зәй елгасында, Европада иң зурлардан саналган ГРЭС салынды. Баһадир станция ул — аның еллык энергетик куәте 2 миллион 400 мең киловатт. Түбән Камада, автомобиль төзүчеләр шәһәренә әверелгән Чаллыда җылылык электр станцияләре сафка басты. Монда салынган гидростанцияләрнең агрегатлары да эшли башлагач, Татарстан җиренең Кама буйларындагы кечкенә генә мәйданның энергия куәте Себердәге баһадирлар — Усть-Илим, Саян-Шуша гидростанцияләренең егәрлеге белән тиңләшерлек булачак.

Киләчәктәге перспективаларны алдан күреп эшләнгән комплекслы программаның булмавы аркасында, җитештерү көчләренең шулай тиз үсеше бүгенгенең бик күп хәлләрен, иртәгә туачак проблемаларны өйрәнү кадәресен арткарак калдырып торды. Яңа мәйданнар үзләштерү, аларда зур территориаль-производство комплекслары төзү барышында дистәләрчә идарәләр һәм ведомстволар үз тармакларын чикләп торган коймә артыннан еракка карый алмады, тормышта җитлегеп килгән проблемаларның барысын да бер бөтен итеп күз алдына китермәде. Нәтиҗәдә, элек-электән игенчелек белән шөгыльләнгән районнар шулкадәр үскән яңа промышленность үзәкләрен авыл хуҗалыгы продуктлары белән тәэмин итә алырмы, юкмы! — дигән сорау индустриаль үсеш программасында бөтенләй каралмаган булып чыкты. Дөрес, бу төбәк азык-төлекне аз җитештерми, ите-мае, йомыркасы, бәрәңгесе һәм башка продуктлар аның үзенә дә җитә, читкә чыгарырга да арта. Ләкин индустриаль үсешнең колачы шундый киң булып чыкты ки — төбәкнең үзендә генә җитештерелгән ашамлык продуктлар бу регионда тупланган эшчеләр ихтыяҗын канәгатьләндерергә инде җитми башлады.

Бирредә ил экономикасының ничек үсүе, промышленность үзәкләренең гадәттә ничек оештырылуы, яңа поселокларның һәм шәһәрләрнең ничек күтәрелүе тарихын искә төшереп узу урынлы булыр. Промышленность, шәһәр, эшче һәр вакыт авылга карап яши, кресьянның калада яшәүчеләр табынына кайчак, нинди ризыкны күпме бирә алырын төгәл исәпли. Бу элек-электән шулай. Россия җирләренең байлыгын беренче булып үзләштерергә керешкән өлгер эшкуар Строгановлар, Демидовлар заманында, мәсәлән, патша хөкүмәте заводларга, рудникларга меңләгән авылларны беркеткән. Руда казучылар, тау эшчеләре, корал ясау осталары үзләре дә җир эшкәртүдән аерылмаган: мал-туар да асраган, тавык-кош та тоткан... Октябрь революциясенә кадәрге чорда, 1917 елда, Уралдагы рудник һәм заводларда эшләүчеләрнең җитмеш процентта артыграк өлеше җирле булган. Беренче бишьеллыклар башланган чакта Донбасс шахтерларының яртысыннан күбрәге җир белән арасы өзмәгән. Мәскәү өлкәсендәге эшчеләрнең 22 проценты шулай ук авыл хуҗалыгы белән дә шөгыльләнгән.

Вакыт үтү белән, илебез экономикасын, халык хуҗалыгын үстерү максатлары һәм характеры эшче белән крестьян арасындагы хезмәтнең табигый бүленешенә китерә. Завод конвейеры, төрле оешма һәм учреждениеләр шәһәр кешесенең төп эш урынына әверелә. Җир белән шөгыльләнү мәшәкатьләре — түтәл, бакча үстерү, кош-корт, мал-туар карау — барысы да икенчел булып кала. Бу хезмәт белән бераүләр гаилә бюджетына өстәмә булдыру өчен шөгыльләнә, икенчеләре — саф һава сулап, җан рәхәте алу өчен мавыга, шулар белән кеше үз күңелен күп буыннарга тоташтырган тамырларны саклап яши.

Ил өстенә афәт булып төшкән авыр сугыш елларында совет кешеләре соңгы сыныкларын да, үзләре капмыйча, карлы-бозлы окопларда яткан, гитлерчы дивизияләрне җимереп Көнбатышка һөҗүмгә барган сугышчыларга җибәрделәр. Шундый авыр чакта шәһәр янындагы җир кишәрлекләре, шәхси хуҗалыкларда асралган сыерлар, кәҗәләр, йорт куяннары һәм кош-корт күпме гомерләрне саклап калды... Бу — ил хакына, явыз дошманны җиңү хакына барган аяусыз көрәшнең аерылгысыз өлеше иде.

Сугыштан соңгы елларда да шәһәр кешеләренең бакчалар үстерүе, кечкенә генә хуҗалыкта мал-туар асравы файдасызга булмады һәм берни белән дә чикләнмәде. Алтмышынчы елларда гына бу мәсьәләгә кырын караш ташлаучылар булып алды. Алар, нигәдер, шәхси хуҗалыклардан ил табынына күпме азык-төлек өстәлүен онытып җибәрделәр. Нәкъ шул чакта инде: «Һәр гаилә карамагындагы кечкенә

ярдәмче хуҗалыклардан баш тартырга кирәк, алар белән мавыгуның экономик нәтиҗәсе күзгә күренми», дигән фикерләр һаман ешрак һәм торган саен кагтыйрак әйтелә башлады. Мондый ялгыш карашның «нәтиҗәсе» тиз күренде: шәһәр, поселок кешеләре генә түгел, авылда яшәүчеләрнең дә күбесе ит, сөт, йомырка, май, яшелчә, җиләк-җимешне дәүләт яки кооператив кибетләреннән, колхоз һәм совхозлардан сатып алырга тиеш булдылар. Колхозчы, эшче, интеллигенция гаиләләрендәге ярдәмче хуҗалыкларда терлек асрау кимеде. Колхоз һәм совхозларда терлекчелек продукциясе җитештерүнең артуы гына моны каплый алмады һәм илнең азык-төлек ресурслары көтелгәннән бик күпкә аз булып чыкты. Мәсәлән, 1977 елның 1 январена илдә сыерлар саны колхозларда һәм совхозларда, 1940 елның шул ук вакытына караганда, 14 миллион 94 башка артты, ләкин шәхси хуҗалыкларда 7 миллион 619 башка кимеде. Шулай итеп, гомуми үсеш 6 миллион 475 мең баш кына булды. Шул ук чорда шәхси хуҗалыкларда дуңгызлар — 5 миллион 330 мең, сарыклар — 9 миллион 262 мең, кәҗәләр 4 миллион 572 мең башка кимеде. Мондый хәлнең сәбәбен авылда яшәүчеләр азая, ә шәһәрдә торучылар арта, анда хәзер сугыш алды елларындагыча, халыкның өчтән бере түгел, ә алтмыш проценттан күбрәге яши, дип кенә аңлатырга мөмкин түгел. Монда бүтән сәбәпләр дә бар. Әйтик, хәзер авыл җирендә дә һәр йортта сыер асрамыйлар, өч, биш, ун хуҗалыкка бер сыер туры килә торган урыннар да аз түгел. Авылда да продуктларны магазиннан, ашханәдән, рестораннан алуга күнегә башладылар.

Азык-төлек ресурсларының еллык балансын исәпкә алучы экономистлар белә: бер сыердан елына 108 килограмм ит, ике ярым тонна сөт, дуңгыздан 83 килограмм ит алуны планлаштырырга мөмкин. Әгәр ил күләмендә шәхси хуҗалыклардагы терлекләр саны сугыш алды елларындагы дәрәҗәдә сакланса, без ел саен халык табынына өстәмә рәвештә 800 мең тонна сыер ите, 450 мең тонна дуңгыз ите, 150 мең тонна чамасы сарык ите куя алыр идек, сөт тә 19 миллион 47 мең тоннага артыграк булыр иде.

Авыл хуҗалыгы производствосының бүгенге үсеше нинди генә булмасын, аграр конвейер ничек кенә төгәл эшләмәсен — әлеге зур югалтуларны башка участокларда эшне яхшырту исәбенә генә әле тиз каплау мөмкин түгел шикелле.

Шәһәр кешеләрен генә түгел, авылда яшәүчеләрне дә үз бакчаларында казынудан, үз хуҗалыкларында мал-туар, кош-корт асрау мәшәкатьләреннән коткарырга кирәк дигән ялгыш нигезгә корылган агымнарга каршы төшеп, партиябез тагын бер кат, илнең җитештерү көчләрен үстерүнең хәзерге торышында хуҗалыкны алып баруда иҗтимагый хезмәт һәм конкуренция индивидуаль алымнар белән дә бәйләргә кирәк, дип күрсәтте. Яңа производство мөнәсәбәтләрен формалаштыру барышында тоткарлану да, теге яки бу тармакта объектив хәлдән алга сикереп узарга маташу да уңышка китерми.

1977 елның 7 октябрендә кабул ителгән яңа Конституциябездә: «Дәүләт, колхоз һәм совхозлар гражданнарга ярдәмче хуҗалык алып баруда булышлык итәләр», дигән сүзләр язылган. КПСС Үзәк Комитетының илебез аграр политикасын перспективада билгеләнгән июль Пленумында (1978 ел) Л. И. Брежнев: «Без колхозчыларның, эшчеләрнең, хезмәткәрләрнең үз хуҗалыклары турында кайгыртырга тиешбез..., промышленность предприятиеләренең ярдәмче хуҗалыклары да азык-төлек белән тәэмин итүне яхшыртуда файдалы роль уйнарга тиешләр», дип күрсәтте. Совет власте урнаштырылганнан бирле авыл хуҗалыгын үстерүгә 385 миллиард сум акча салынган, шуның 277 миллиарды, ягъни дүрттән бере чамасы, соңгы унике елда бирелгән. Дәүләт тарафыннан үткәрелгән чаралар нәтиҗәсез калмый, билгеле. Ләкин иҗтимагый сектор уңышларына гына өметләнеп яши торгач, «үз хуҗалыгыбыз» дигән нәрсәне оныта да башладык бугай. Бакчачылык, терлек, кош-корт асрау белән мавыгу кимеде. Әлбәттә, эштән соң чыгып сыерга печән салу, тавыкларга җим сибүгә караганда телевизор янында утыру, китап уку рәхәтрәк. Аратада азык сорап сыерың мөгерәми, йортыңда үрдәкләр бакылдамый, күркәләр кабарынып йөрми. «Гастрономда бүген ни бар икән!» дип кенә борчыласы... Җырда әйтелгәнчә, «ял итә-итә-итә» рәхәт кичерү, вакытны әрәмгә уздыру һәр очракта да сәламәтлеккә файдалы, гомерне озайта, кәефне күтәрә һәм эшкә яңа дәрт тудыра дип уйлау хаталану булыр иде.

Элегрәк — ул чаклар әле безнең буын хәтерендә — йортлары бер катлы гына булган һәр шәһәрчектә, завод поселогында терлек тоталар, ул мал-туар шактый зур көтү булып җыела торган иде. Производствода эшләүчеләр сөт-каймак алыр өчен һәр көнне кич белән кибеткә йөгерми — алар күпчелек хуҗалыкның үзендә була. Ит хәстәре дә шулай ук: кышка әзерлек турында сүз чыкканда, һәр йортта бозау, унлап каз яки алты-җиде потлык дуңгыз телгә алына иде.

Ә ул чактагы базар!..

Теләсә нинди нәзберек кешене дә канәгатьләндерерлек азык-төлек сатыла, муллыкта аптырап калырлык. Ак алъяпкыч бәйләгән, алмадай алсу битле хатын-кызлар, рәтләргә тезелеп, сөт сатып тора, каймактан авыз итәргә чакыра. Сөтнең теләсә ниндиен сайла — кичкесе, кайнатылганы, яңа савылганы, күбекләнеп торганы... Кирәк икән — атланмай да бар. Сап-сары йомрылар — тәмпе ис бөркеп тора. Аһ-ух килеп ит чабучылар эшли, кулларында балталар уйнап тора. Бирәүгә итнең

йомшагын чабалар — кәтлиткә, пилмәнгә дип сорый апаең, икенчеләре сөякләрәк төшен сайлый — монысы, билгеле инде, татар салмасына, я булмаса русның кәбестәле ашына...

Хәзер хәл башкачарак. Индустриаль яктан үскән Кама аръягының яшь калаларында һәм поселокларында, промышленность үсү белән үзгәргән, яңарган шәһәрләрдә терлек көтүенең нинди булуын да онытсылар инде. Производствода эшләүчеләр арасыннан үз хуҗалыгында терлек асраучы гаиләне көндез чыра яндырып эзләргә кирәк! Сыерларны, бүтән терлек затын телевизор йотты, автомобильләр ялмады! Шәһәр базарлары, элекке шикелле, гөрләп тормый, андагы товарлар да бүтән. Җиләк-җимеш өлгергән, урманда гөмбә җитешкән чакларда шәһәр кешеләре базарга күмәк файдаланудагы бакчаларда үстерелгән кура җиләге, кара карлыган, кара миләш, алма китерәләр, укроп, кишер, чөгендер, кервн һәм торма саталар. Базар өстәлләренә кәрзиннәр тезелә, аларда — Кама буе урманнарында үскән гөрәҗдәләр, кызыл түбәтәйле усак гөмбәләре, сары гөмбә, нарат гөмбәләре... Елның башка фасылларында шәһәр базарларында еракта, көньяк кояшы астында үскән җиләк-җимеш мактый-мактый сатыла... Ит, тавык-казлар базарга ихтыяҗны канәгатьләндерер күләмдә чыкмый. Моны аңлатырга да мөмкин: алырга теләүчеләр күбәйде: ә сатарга китерүчеләр аз.

Моторын дистәләгән ат көченә гөжләтеп торучы машиналар — төрле «Москвич», «Запорожец», «Жигули»лар һәркайда җитәрлек. Түбән Кама шәһәрендә, мәсәлән, 1978 елның 1 январена өч мең гаиләдә җиңел автомобиль бар иде. Ә терлек асраучы гаиләләр юк. Шәһәр кешеләре барысы да магазин, ашханә, ресторан аша гына туклана. Мондый шартларда, табигый ки, сәүдә ничек итеп артып, дәүләт фондларыннан продуктлар белән тәэмин итү ничек кенә яхшырып тормасын, азык-төлек проблемасы ахырынача хәл ителә алмый. 1977 елда Түбән Камада, мәсәлән, һәр кешегә 45 килограмм ит — ил күләмендәге уртача саннан 12 килограммга ким сатылган.

Индустриаль Кама аръягы, гомумән, тиз үсеп барган шәһәрләр өчен уртак булган проблема — читтән килгән кешеләрне яхшылап урнаштыру, аларның кире китүен булдырмас өчен кирәкле бөтен шартларны булдыру. Белгечләргә мохтаҗлык зур, төзүчеләр җитешми, шин заводына эшчеләр кирәк. Яңа шәһәргә килүче яшь белгечләр дә аз түгел, ләкин килгәннәрнең барысы да төпләнеп калмый. Шәһәр, гигант иләк шикелле, күп меңләгән кешеләрне үзе аркылы үткәреп кенә тора, берәүләр килә, икенчеләре китеп бара.

Яңа урыннарны үзләштерү чорында миграция — котылгысыз һәм үзенең характеры белән прогрессив күренеш. Яшьләр күченеп килмәсә, яңа промышленность үзәкләрен кем төзер дә аларда кем эшләр! Әмма бу мәсьәләдә бер «ләкин» бар. Түбән Кама да, төбәкнең башка шәһәрләре дә — нәкъ менә шундый, яңа үзләштерелә торган урыннар, аларның тизрәк үзләштерелүен бөтен ил көтә. Хәл шундый, бу шәһәрләрдән бер кешенең, бер гаиләнең генә кире китүе дә кызганыч, хәтта — бәла. Китүчеләрнең кайберләре, төп сәбәпләрнең берсе итеп, шәһәрдә туклану продуктларына кытлык булуын күрсәтте. Аңлашыла ки, азык-төлек белән тәэмин итү мәсьәләсе миграциягә дә тәэсир итә.

Билгеле, традицияләрнең барысын да прогрессив дип әйтергә ярамый, кайберләре, хәтта файдалы һәм кирәкле булсалар да, заман үтү белән яраксызга чыгалар. Әйтик, элекке промышленность үзәкләрендә яшәгән кешеләрнең тормыш итүен, аларның үз хуҗалыклары булуын үрнәк итеп алу хәзер урынсыз. Бертуган Демидовларның Уралдагы заводларында һәм башка хуҗаларның предприятиеләрендә эшләүчеләрне ул чактагы ревизия исемлекләрендә крестьяннар итеп язганнар, шуның белән аларны кисәтеп тә куйганнар: «Заводта эшләү сезне гаиләгез өчен көндәлек икмәк табу хәсрәтеннән коткармый, үз көнегезне үзегез күрегез». янәсе. Хәзерге заман инженеры һәм эшчесе — катлаулы аппаратлар, автоматик системалар белән идарә итүче кешеләр — эштән кайтуга көрәк-сәнәккә тотынсын, кулга чиләк алып, сыер саварга ашыксын дигән сүз түгел бу. Шәһәр кешесен безнең чорда болай күз алдына китерү сабыйларча беркатлылык булыр иде. Шәһәр төзүнең өр-яңа тенденцияләре һәм казанышлары нигезендә салынган калалар һәм поселокларны иске такталардан укмаштырылган абзар, лапас һәм лабазлар чолганышында күрү, шулардан сыер мөгрәвен, сарык бәэлдәвен, тавык кыткылдавын ишетеп тору да бик сәер булыр иде. Юк, заманасы бүтән, җырлары бүтән хәзер!

Әмма халыкны тукландыру җиңел генә эш түгел бит. Илебездә җитештерелә торган итнең һәм сөтнең — утыз ике, бәрәңгенең — алтмыш дүрт проценты, яшелчәнең өчтән бер өлеше әле «шәхси хуҗалык» секторыннан алына, моны исәптән төшерергә ярамый. Ниндидер сәбәпләр белән бу пропорция кайда да булса бозыла икән, ризыкларны «оешмаган» рәвештә җитештерүчеләр кими һәм иҗтимагый җитештерү секторының үсеше әлеге бушлыкны тутыра алмый башлый, үзеннән-үзе проблема барлыкка килә. Промышленность үзәкләрендә тиз арада тупланган халыкны азык-төлек белән ничек тәэмин итәргә! дигән четерекле сорау шулай туа.

Кызганычка каршы, Татарстандагы Кама аръягы кебек зур индустриаль регионны үзләштерү шундый табигый рәвештә барлыкка килә торган проблемаларны тиешенчә өйрәнү һәм тикшерү белән бәйләнештә бармады. Масштабы һәм характеры ягыннан бик зур һәм гаҗәеп тирән булган экономик һәм социаль программаны тормышка ашыру чорында нефтьчеләр, энергетиклар, машина төзүчеләр, нефтехимиклар, башка бик күп төрле ведомстволар — һәркайсы мәсьәләнең үзенә кагылган производство өлешен генә күрде, азык-төлек проблемаларының катлаулана баруын күрмәмешкә салышты, ә иң дөресе, бу йөкне башкалар җилкәсенә салырга тырышты. Ә башкалар — колхоз һәм совхоз кырларында, фермаларда, җиләк-җимеш һәм яшелчә бакчаларында эшләүчеләр — сан ягыннан һаман азая барды. Чөнки барча производстволар да эшче көчләрне авылдан алды. Кичә иген иккән, мал асраган, бакчалар үстергән кешеләр, борын-борыннан килгән авыл хезмәтен ташлап, эшче хезмәткәр булып киттеләр.

Үткән елның язында очерк язучы авторлар белән очрашуга Татарстан АССР Госпланы председателе Владимир Васильевич Ермаков килде. Очеркистлар — бүгенге көн проблемалары белән аеруча кызыксына, шуларны яза торган халык — республиканың планлаштыру органы җитәкчесенә сорауларны яудырып кына торды. Алар арасында, безнеңчә, бик җитди һәм катлаулы булган мондый сорау да бар иде: «Республика шәһәрләрендә һәм авылларында хезмәт ресурслары балансы нинди, бу өлкәдә киләчәк перспективалар ничегрәк күренә!» Перспективалар менә нинди икән. 1978 елда республикадагы халыкның күпчелеге — 2 миллион 162 мең кеше — шәһәрләрдә, эшчеләр поселокларында тора, 1 миллион 246 меңе авыл җирләрендә яши. Киләчәктә демографик үзгәрешләр көтелә. 1991 елда Татарстанда халык саны 4 миллионга якынлашачак, шәһәрләрдә яшәүчеләр чама белән 900 мең кешегә артачак, ә авыл җирләрендә ярты миллионга кимиячәк — нибары 372 мең кеше яшәячәк.

Бу уңайдан тагын бер хәлне игътибарга алырга кирәк. Хәзерге авылда бит игенчеләр, терлекчеләр, бакчачылар — үз хезмәтләре белән башкаларны да туендырып торучы кешеләр генә яшәми. Укытучылар, төзүчеләр, тегүче, итекче, авыл хуҗалыгы продукциясен эшкәртүче профессия ияләре дә шул ук исәпкә кертелә.

Әлеге саннар серле йомгак түгел. Җитәрлек кызыксыну, төпчену, өйрәнү булганда, алар — инде бик күптән ачыласы мәгълүмат. Әмма индустриаль үсеш барышында моңа игътибар ителмәде. Инде әйтелгәнчә, һәр ведомство, үз тармагы мәшәкатьләрен генә кичереп, тирә-юньгә күз салмады, яңа предприятиеләрдә эшләүчеләрне азык-төлек белән тәэмин итү мәсьәләсе бер заман бик җитди проблемага әверeләсен алдан күрә алмады. Әгәр шуңа игътибар ителсә, проблеманы булдырмау чаралары үз вакытында күрелер һәм төбәктәге колхоз базарларына, кибетләргә төрле яктан агылып торган муллык чишмәләре саекмас иде.

«Кызганычка каршы» дигән сүз бар, аны төрле мәгънәдә кулланырга мөмкин. Ул исәп-хисапларның төгәлсезлеген дә, очраклы ялгышуны да бер ук төрле итеп аңлата, ләкин хәлне берничек тә җиңеләйтә алмый. Кызганычка каршы, тик нефтьчеләр генә, билгеле чамада, хәлне дөрес аңладылар. Үзләре яши торган шәһәр һәм поселокларда азык-төлек балансын исәпләгәндә, алар шәхси секторда ит, сөт җитештерү кимиячәген күздә тотты һәм ярдәмче хуҗалыклар булдырды. Промыселларда эшләүчеләрне түтәл арасында казынудан һәм мал-туар асраудан коткарып, өстәмә продукт җитештерү ягын оешкан төстә кайгыртты. Дәүләт фондларыннан тыш, аларның үз запаслары да бар иде. Түбән Кама шәһәре һәм андагы нефтехимия комбинаты да үзендә 130 мең кеше яши торган зур каланы тудырган предприятие — министрның без югарыда телгә алган приказы килеп җиткәнче ук инде берничә теплица булдырды, алардан яшелчә, помидор, кыяр алды. Ләкин нефтьчеләрнең продукция ассортименты аларныкыннан баерак иде. Үз карамакларындагы совхозда үстерелгән яшелчәләрдән тыш, нефтьчеләр хәтта аерым фермада бияләр асрауны оештырдылар һәм безнең көннәрдә инде сирәк күренә торган эчемлек — кымыз әзерләргә керештеләр, 800 баш сыер алып, сөт комплексы төзеделәр, куәтле кошчылык фабрикасы кордылар, дуңгыз симертүне башлап җибәрделәр. Ләкин, дөресен әйтик, санап үтелгән объектларда җитештерелгән продукция — зур табынга бик кечкенә бер өстәмә генә: 1976 елда нефтьчеләр үзләре җитештергән ит — дәүләттән алынганның биш проценты, сөтнең уннан бер өлеше, яшелчә илле процент булды...

Бик тиз үскән индустриаль үзәкләрне азык-төлек белән тәэмин итүнең җитди, эшлекле һәм уйланылган яхшы үрнәге КамАЗ белән бергә барлыкка килде. Ул элеккедән бөтенләй аерылып торган принципларга корылган, авыл хуҗалыгы производствосында иҗтимагый форманы үстерү юнәлешендә баруны күздә тота. Кама буенда автомобиль төзү гиганты корыла башлауның икенче елында ук инде РСФСР Министрлар Советы индустриаль Кама аръягы төбәгендә аграр конвейер булдыру программасын эшләде.

Хәзер барлык индустриаль гигантларның да аграр комплекслары инде билгеләнгән, республикабыздагы уникe административ район территориясендә специальләштерелгән 34 совхоз оештырыла. Автомобиль ясаучылар, химиклар, нефтьчеләр, энергетиклар, төзүчеләр табынына ризыкны шулар бирәчәк. Авыл хуҗалыгын үстерү өчен гадәти каналлар буенча бирелә торган средстволарга өстәмә рәвештә

тагын 200 миллион сум — Татарстанда авыл хуҗалыгын үстерүгә 1955—1965 елларда бирелгән кадәр — акча тотылачак. Азык-төлекне читтән мөмкин кадәр азрак кертеп, урында күбрәк һәм күбрәк җитештерергә — мәсьәлә шулай куела. Унынчы бишьеллык ахырына кадәр ит һәм сөт җитештерүне — 4, бәрәңгене — 8, яшелчәне 33,5 тапкыр арттыру бурычы тора алда. Уен эш түгел!

«Күбрәк!» дип әйтүләре җиңел дә, моңа ирешүләре — ай-һай четерекле! Авыл хуҗалыгы производствосын киң күләмдә һәм тамырдан үзгәртеп корырга кирәк. Бу исә кешеләрнең шөгыльләрен алмаштыруга китерәчәк. Шөгыль үзгәртү — кешенең үзен үзгәртү. Крестьян хезмәтенең асылы үзгәрми, әлбәттә. Ул — үз хезмәте белән кешеләрне, дөньяны тук итеп яшәтү. Ләкин философлар инде күптән искәртеп куйган: тарихи чорлар бер-береннән нәрсә җитештерелү белән түгел, ә кешеләрнең нинди шартларда, ничек эшләве, ягъни производствоның характеры белән аерылып тора.

Азык-төлек җитештерүне арттыру авыл хуҗалыгында эшләүче кешеләр санын ишәйтү хисабына булмаячак. Производствоны интенсивлаштыру ,аны өр-яңа техника белән коралландыру, хезмәт күп куела торган тармаклардан саналган терлекчелекне промышленность нигезенә кору, терлек азыгын һәм яшелчәләрне кирәк чакта яңгыр яудырып үстерү — алга таба илтәсе, югары темплар белән эшләү мөмкинлеге булдырасы юл әнә шундый. Элек ун, егерме, йөз кеше башкарган хезмәтне техника һәм автоматика ярдәмендә берәү үти алачак!

Иң мөһиме шул, бу җитди һәм катлаулы программа тирәнтен өйрәнелеп, башланган эшкә тәэсир итәрдәй факторларны күздә тотып төзелгән. Аграр шәһәрчекләр индустриаль үзәкләрдән шактый ерак урнашсалар да, аларда яшәүче һәм эшләүче кешеләр өчен көнкүреш, социаль һәм культура шартлары промышленность эшчеләренеке шикелле үк булачак. Совхозларда 120 мең квадрат метр квартиралар, 18 мәктәп, 25 балалар бакчасы һәм ясле, 29 клуб төзү күздә тотыла. Аграр конвейер программасында шул максатларга 35 миллион сум — барлык сумманың 18 проценты — бирелә. Яңа эш — яңа принциплар, киң колач! Шуларны уйлыйсың да, туган илебезнең бөек патриоты Дмитрий Иванович Менделеевның хыял һәм өмет белән әйткән сүзләре искә төшә: «Киләчәк гасыр Россияне яңа хәлдә — авыл белән завод-фабрика хезмәтенең нормаль бәйләнешенә ирешкән ил буларак күрер. Үзем ул чоргача яши алмам, әмма бу сүзләр иртәме-соңмы акланырга тиеш», дигән ул.

Хәзерге темплар тизлеген искә алсаң, җиде-ун ел вакыт кыска ара түгел. Һәрхәлдә, артка борылып, шул чорда башкарылган эшләрне барларга, нидән башладык та, нәрсәгә ирештек дип, уйланырга инде мөмкин. Аграр программаны тормышка ашыруда үсеш зур, ул күзгә күренеп тора. Аны хәтта «штурм белән сикереш» дип әйтергә дә ярый. Төбәкнең промышленность гигантларын тәэмин итүче колхозларын һәм совхозларын үстерүгә беренче алты елда 387 миллион сумнан күбрәк акча тотылды. Моның нәтиҗәсе дә күз алдында: тугызынчы бишьеллыкта авыл җирләреннән шәһәр табынына продуктлар күбрәк килә башлады. Яшелчә — 2,8 тапкырга, сөт — 48 процентка, ит — 45 процентка, йомырка — 2,3 тапкырга артты... Нефтьчеләр иң якын арада ирешелергә тиешле бурыч итеп ит җитештерүне биш тапкыр арттыруны куйдылар.

Башланган эшнең колачы һаман киңәя бара, аны хәрәкәткә китерүче пружинаның кысылган һәм үзенә салынган көч арта барган саен зур программаны тормышка ашыруны тизләтә, аңа ныграк тәэсир итә.

Күтәреләсе үрләрнең күбесе әле «киләчәктә» булса да, ирешелгән кадәресе дә марксистик философиянең бер кагыйдәсен — кырыс табигатьнең тискәрелегенә яки игелегенә дә карамастан җирнең уңдырышлыгын хезмәт һәм капитал салу белән күтәрергә мөмкин дигән положениесен практикада раслый. Ә бу исә, үз чиратында, Кама аръягындагы киңлекләрне үзләштерүдә катнашучыларның аграр тактикасын һәм стратегиясен билгели. Ничәмә-ничә еллар буена игътибарга алынмый килгән икенчел факторлар да төгәл исәпләнә, реаль шартлар тәгаен билгеләнә.

Моның мәгънәсе тирән, әһәмияте зур. Вакыты-вакыты белән эшне, әлеге дә баягы, «нульдән» башларга туры килгәләсә дә, без барыбер прогресс баскычларыннан өскә таба үрлибез. Әйтик, Чигвинцев яңа производствода үз хезмәтен, артка кайтып, «Әлифба»дан башлый, әмма аның адымнары ныклы, ышанычлы. Ул инде яңа шартларда эшли, кечкенә-кечкенә фермалар түгел, зур промышленность комплексының ярдәмче конвейерын оештыра. Бурычы да тәгаен билгеләнгән: көн саен ике тонна тавык ите, бер тонна үрдәк ите, елга алты мең дуңгыз түшкәсе, миллион йомырка җитештерү.

Илледән узган кешегә яңа эшкә тотыну — бер яктан, җиңел дә, чөнки күп нәрсә таныш, тәҗрибә тупланган, ә икенче яктан уйласаң, — кыен һәм катлаулы да. Яңа эшкә керешеп китү — яңадан туу шикеллерәк бит ул, үз-үзеңне үзгәртергә, кабат үсәргә кирәк була. Чигвинцевның эшләре ничек барыр! Казанышлары артырмы, әллә үкенечләре күбрәк булырмы! Үз җилкәсенә яңа хезмәтнең элеккесенә караганда да авыррак, зуррак йөгән салгач, кеше нинди хисләр кичерә икән: канәгатьләнүме, кыюсызлыкмы, ниндидер чая адым ясарга әзерлекме! Соңгысына, гадәттә, үз-үзләренә нык ышанган кешеләр генә сәләтле була, шул изге хис аларны канатландыра, киләчәккә ашкындырып тора.

Күптәнге танышым булганга, аның белән очрашуларның берсендә мин Чигвинцевтан:

— Яңа эштә, үзең әйтмешли, «нульдән» башлап җибәрү ничек соң, Григорий Никифорович!— дип сорадым.— Производствосы да элекке эшләгәнегез кебек түгел, анда сез — төп производство җитәкчесе идегез, ә монда, ни дисәң дә — ярдәмче предприятие...

— Төп производство, ярдәмче предприятие, имеш...— Чигвинцев көлемсерәп җавап бирде.— Минемчә, бернинди аерма юк монда. Үз эшеңә ничек карыйсың бит, иң әһәмиятлесе шул. Ничек дигән әле шагыйрь: «Яу өчен дә, хезмәт өчен дә медаль коела бер үк металлдан!» Шундый хәл. Комбинатта СССР Министрлар Советының премиясен химияне үстергән өчен алдылар, ә безгә шундый ук хөрмәт тавыклар асрый белгән өчен күрсәтелде.

— Шулай да «нульдән» башлыйсыз бит, Григорий Никифорович. Иң зур эшләрегез һаман киләчәктә, планнарда, проектта...

— Министр биргән биш миллион сумны «нуль» дисеңмени! — Үз карашларында нык торучан Чигвинцев бушка сүз көрәштерүне яратмый. Аның әйткән сүзе — атылган ук. Бәхәстә үзләрен шулай хис итүче кешеләр, минемчә, тормышта ни эзләгәннәрен, кая атлауларын яхшы беләләр, алай гына түгел, алар үз максатларына ирешүнең ачык юлларын да күрәләр. Директор сүзен дәвам итте:— Мондый капитал белән теләсә нинди эшкә керешергә мөмкин. «Башлармын да, ярты юлда ташларга туры килер» дип борчыласы юк. Ике мең гектар җир, элекке колхозларның хуҗалык корылмалары, умарталар урнаштыру өчен урман, Кама суы, аның күлләре — балыкчылар бригадасы өчен хәйран шәп урыннар!.. Болар барысы да «нуль» дисеңме!! Аннары бит, минем идеяне якладылар, фикерне! Мораль яктан хупладылар — материаль яктан аны тормышка ашыру өчен нигез бу. Элекке тәҗрибәне дә чутка сал. Хезмәттә, эзләнүләрдә тупланган бит ул. Ялгышулар, хаталанулар булмаган дисеңме әллә миндә! «Красный ключ»та миңа бүләк тә, премия генә бирделәр дип уйлыйсыңмы! Кет шайтаннан иман! Күпме шелтә, кисәтү чәпәделәр — сөйләп бетергесез. Алары да маяклар бит, юл күрсәткечләр. Шуларны хәтерләп барсаң, адашмыйсың, сизгәрәк абынасың. Бүгенге эшебезнең нигезен күрәсеңме — нинди! Юк, «нуль» түгел бу, киң колач белән башланып киткән зур эш. Минемчә, уңышлы булырга тиеш. Хәер, эшләп карыйк — күрербез...

Әйе, Чигвинцев: «Исән булсак — күрербез» димәде, «эшләп карыйк», диде. Гомеренең һәр көнен башкарылган эш белән үлчәүче уңган кешеләр үз тормышларын хезмәттән тыш күз алдына да китерә алмыйлар, моны теләмиләр дә, күрәсең.

Рафаэль Мостафин

# КАЛӘМ ОЧЫНДА — КамАЗ

Партиябезнең XXV съезды алдыннан дөньяның бик күп илләрен урап чыккан, хәзер инде тарихи истәлеккә әверелгән бер рәсем бар: яңа гына төп конвейердан төшкән, үзенең мәһабәтлелеге белән күзнең явын алырлык «КамАЗ» машинасы сурәтләнгән анда. Рәсемнән шофер егет Валерий Перетолчинның елмайган йөзе балкый. Сүз уңаеннан «КамАЗ» машиналары колоннасының съезд ачылу көненә Мәскәүгә нәкъ менә шушы егет җитәкчелегендә килеп җитүен дә әйтеп узасы килә.

Бүген исә Чаллыда эшләнгән меңнәрчә машиналар илебез юлларын иңли. Әмма «КамАЗ» машина маркасы гынамы соң? Юк, ул аңа караганда киңрәк һәм тирәнрәк мәгънәле төшенчә. Магнитка, Днепрогэс, Братск исемнәре кебек тиз арада телгә кереп китте, миллионнарча кешеләр күңелен яулап алды КамАЗ. Бу сүздә чорыбыз сулышы чагыла, исемен атауга күз алдына хезмәт дәрте кайнап торган гаять зур төзелеш мәйданнары килеп баса. Ә иң мөһиме — анда эшләүче, иҗат итүче батырлыклар үренә омтыла торган кеше булып төсмерләнә. Бу чыннан да шулай, мәшһүр Кама елгасы буйларында бүгенге көн батырлары эшли.

КамАЗда олы җиңү яуланды — аның беренче чираты сафка басты. Хәзер инде кайбер нәтиҗәләр дә ясарга мөмкин. Бу бөек төзелеш турында язылган әдәби әсәрләрне тагын бер тапкыр күздән кичергәч, КамАЗ әдәбиятка нәрсә бирде һәм, үз чиратында, каләм ияләре аны ни белән баеттылар соң, дигән сорау куясы килә.

Бу җәһәттән КамАЗ парткомының элеккеге секретаре А. Родыгинның «Новый мир» редакциясенә язган хатыннан бер өзек китереп үтик. «Көндәлек мәшәкатьләр белән тарихның нәкъ менә синең эш урыныңда, синең кул көчең белән ясалуын, иптәшләреңнең һәм үзеңнең бөек эшләрдә катнашуыңны аңлап җиткермисең, — ди ул, хаклы рәвештә. — Сездә басылып чыккан материаллар нәкъ менә илһамланып эшләүче хезмәт кешеләренең матурлыгын тоярга, үз көчебезнең бөеклеген күрергә ярдәм иттеләр»[1].

Миңа шундый ук фикерне Чаллы шәһәр партия комитеты секретаре Рәис Беляевтән дә ишетергә туры килгәне бар. Аның бу хакта бик мәгънәле итеп: «Бездә язучы, журналистларның җанлы, дәртле һәм илһамландыргыч сүзенә ихтыяҗ, әйтик, материаль-техник тәэмин итүгә булган ихтыяҗдан һич ким түгел», — дип әйтүе онытылмаслык булып хәтердә калган.

Әлбәттә, КамАЗ темасын үзләштерү эше баштан ук планлы рәвештә оештырылды. Чаллыда «Социалистик Татарстан», «Советская Татария», «Социалистическая индустрия» газеталарының, «Казан утлары» һәм «Новый мир» журналларының даими

---

[1] «Набережные Челны» җыентыгы, 2 нче басма. «Известия», 1976, 333 бит.

эшләүче постлары булдырылды. Каләм осталары башкарган эшнең җимеше буларак, Мәскәүдә «Яр Чаллы» дип исемләнгән ике җыентык дөнья күрде. Татарстан китап нәшрияты исә КамАЗның үзенә бер төрле әдәби-документаль елъязмасын чыгарып килә. Киң катлау укучылар аның инде дүрт томын — «Камадагы батыр», «Батыр адымы», «Батыр биеклек яулый» һәм «Батырны сынау» китапларын бик җылы кабул иттеләр. Шулай ук үзәк нәшриятлар да шактый зур эш алып баралар. Бу җәһәттән бигрәк тә «Молодая гвардия», «Советская Россия» нәшриятларын мактап телгә аласы килә. Аларда бөек төзелешкә багышланган китаплар чыгару матур традициягә әйләнде.

Күрүебезчә, эшләнгән кадәресе аз түгел. Димәк, киң планда сөйләшерлек, тәнкыйть күзлегеннән карап фикер йөртерлек һәм күпмедер дәрәҗәдә нәтиҗә ясарлык җирлек бар.

Яңа темаларны үзләштерүдә иң алгы сызыктан баручы, юл күрсәтеп килүче жанрлардан берсе, әлбәттә, очерк. Моның шулай икәнлеген Волга-Дон, Братск, Куйбышев ГЭСлары төзелеше мисалы белән дә расларга була. КамАЗ темасын яктыртуда да бу закончалык аеруча ачык чагылды.

Башлангыч чорда, төзелеш яңа җәелә башлаган бер вакытта очеркчы иптәшләрнең күпчелеге саннар күрсәтү белән мавыгып алды. КамАЗны нинди төзелешләр белән генә чагыштырмый калдылар икән! Саннар турыдан-туры да күрсәтелде, нинди дә булса берәр җитәкчедән дә әйттерелде. Мисалга А. Приставкинның «Алексей Болдырев белән уткәрелгән көн», «Алексей Болдырев белән уткәрелгән тагын бер көн», М. Ганинаның «Таныш диспетчерлар» дип исемләнгән очеркларын китерергә мөмкин. Хәер, бу ысулның отышлы ягы да юк түгел иде. Ул шунда ук төзелеш тормышына үтеп керергә, аның ритмын һәм сулышын тоярга мөмкинлек бирде. Ләкин монда сурәтләүнең төп объекты — төзүчеләр үзләре читтә кала иде.

Әлбәттә, шундый характердагы очерклар да кирәк иде. Әмма бу әле аз. Коры информация белән генә ерак китеп булмый. КамАЗ турында язылган очеркларның тагын бер кимчелекле ягын күрсәтеп үтәргә мөмкин. Ул да булса — әһәмияте аз булган һәр нәрсәне бик тәфсилләп тасвирлау, кирәгеннән артык хискә бирелү, игътибарны очраклы вакыйгага юнәлдерү. Хәлбуки, КамАЗда өйрәнерлек, сокланырлык чын олы эшләр аз түгел. Очраклы һәр күренешкә сокланасың икән, бу инде бернинди дә чамага сыймый. Болай эшләү тормышны җиңеләйтеп аңлатуга, аны ал төсләрдә сурәтләүгә китерә.

Сүз дә юк, булачак шәһәр яки завод нигезен беренче булып казу, аңа беренче кирпечне салу—мактаулы эш. Беренчеләрнең исемен тарихта калдыру да бик әйбәт. Әмма алга шундый сорау килеп баса: язучыларның роле аларга «мәдхия җырлау» белән генә чикләнергә тиеш мени? Очеркларда шулай ук «беренче» дигән сүз белән бергә яңгыравыклы, купшы «романтика», «энтузиазм», «авырлыклар» дигән тәгъбирләр дә бик еш очрый. Һәрхәлдә, бу жанрда менә мондыйрак төрдәге «авырлыклар» — вагоннардагы кышкы салкынлык, суга чират тору, кибет һәм ашханәләр җитмәү, көзге яңгырлар, юлсызлык кебек вакытлыча кыенлыклар зур урын алмаска тиеш иде сыман.

Очеркчылар тора-бара «романтика» белән мавыгуның артык кыйммәткә төшүен, коры энтузиазм белән әллә ни эш майтарып булмавын аңлый башладылар. Төзелешкә багышланган материалларда хәзер әһәмияте аз булган вакыйгаларны тасвирлаудан проблемалылыкка, «романтика» томаныннан — аек анализлауга күчеш сизелә.

Мисалга «Новый мир» журналының актив каләм ияләреннән берсе Екатерина Лопатина очеркларын китерергә мөмкин. Автор аларда башлыча тик бер теманы — КамАЗның шәһәр яны зонасын төзү проблемасын күтәреп чыкты. Анатолий Злобин белән Анатолий Приставкин исә гаять зур төзелешкә җитәкчелек итү мәсьәләсен җентекләп өйрәнәләр, җитәкче хезмәтенең төрле аспектларын ачып бирәләр. Иң мөһиме, хәзер очерк жанрында зур әһәмияткә ия булган проблемалар күтәреп чыгу гадәткә керә. Шундыйлардан Леонид Жуховицкийның «Атнакич саен учак» дип исемләнгән китабын[1] аерым атап күрсәтәсе килә. Автор укучы игътибарын бер генә

[1] Л. Жуховицкий. Костер по четвергам. М., «Советская Россия» нәшрияты, 1976.

проблемага — КамАЗда кадрларның эштән китүе мәсьәләсенә юнәлдерә. Дөресен әйтергә кирәк, язучы үз алдына куйган бурычны уңышлы башкарып чыккан. Очерк мавыктыргыч әдәби әсәр кебек, яратып укыла. Чын очерк нәкъ менә шулай булырга тиештер дә.

70 нче еллар герое... Ниндирәк кеше ул? Үзеннән элекке буыннардан кайсы ягы белән аерылып тора? Аның рухи дөньясы нинди? Аны төзелешкә килергә нәрсә мәҗбүр иткән? Прозаик Г. Паушкин «Чаллы туфрагында» дип исемләнгән очерклар сериясендә нәкъ менә шушы сорауларга җавап бирергә омтыла. Очеркчы М. Ганина («Яңгырлы көздә», «Таныш диспетчерлар»), В. Семин («Тормыш кору»), М. Зариповны («Еракта — еракка») шундый ук сораулар борчый. Хәер, Чаллыдагы гомуми күренешне күреп алу әллә ни кыен да түгел. Мисалга В. Костровтан бер өзек китерик: «Смена төгәлләнү белән, асфальт буйлап КамАЗның җаны — кешеләр агыла». Әмма бөтен хикмәт тә шул кешеләрнең җанына, рухына үтеп керүдән, аны ачык һәм образлы итеп тасвирлый белүдән гыйбарәт. Бу инде «бүгенге көн героен аңлавы кыен» дип үз-үзеңне аклап фәлсәфә сатуга караганда күпкә катлаулырак.

Замандашыбыз портреты сурәтләнгән очерклардан Ю. Полухинның «Үтеп булмаслык ярлар» дип исемләнгән шактый күләмле китабына («Советская Россия, 1976) аерым тукталып үтәсе килә. Аңа, «Новый мир» журналында шактый уңай фикерләр әйтелүгә карамастан, бүтәнчәрәк бәя дә бирергә мөмкин. Әсәрнең төп герое итеп монтажчылар бригадиры Социалистик Хезмәт Герое А. Б. Новолодский алынган. Китапта мондый характерны сурәтләүгә кирәкле бөтен нәрсә бар кебек. Автор үз героен егерме ел чамасы якыннан белә. Ул аны хезмәттә генә түгел, ә көндәлек тормышта, гаилә шартларында да һәрьяклап күрсәтергә тырышкан. Үз героеның һәр эше, хәрәкәте һәм һәр сүзе «факт дөреслегенә» туры килә. Әмма шул «факт дөреслеген» характер дөреслегенә кадәр күтәрә алсаң иде икән! Кызганычка каршы, автор, гаять бай һәм кызыклы материал туплауга карамастан, художестволы гомумиләштерү дәрәҗәсенә күтәрелә алмаган. Югыйсә, очеркны «повесть» дип атау үзе генә дә күп нәрсә йөкли бит.

Шагыйрьләр дә очеркчылар белән янәшә, бер сафта бардылар. Бүген КамАЗга багышлап бер генә булса да шигырь язмаган татар шагыйре калдымы икән, әйтүе кыен. Коллектив авторларның шушы темага багышланган «Җиде җил үзәне», «Хыялым шәһәре» дип исемләнгән шигъри китаплары басылды. КамАЗ төзелеше турындагы коллектив җыентыкларның берсе дә диярлек шигъри әсәрләрдән башка дөнья күргәне юк.

Тирән эмоциональ көчкә ия булган шигъри сүз КамАЗ яшьләрендә югары романтик рух, дәртле хезмәт пафосы, максатка омтылыш тудырды. Бүген илебезнең бер генә зур төзелешен дә интеллектуаль һәм шигъри атмосферадан башка күз алдына китерүе кыен. Сүз уңаеннан укучы игътибарын гадәти, шул ук вакытта кызыклы бер фактка юнәлдерәсе килә — Чаллы урамнарында яраткан шигырь юлларын плакат һәм лозунг итеп язып элүне күпләп очратырга була. ВЛКСМның Чаллы шәһәр, ә хәзер өлкә комитеты секретаре Ф. Газизуллин сүзләре белән әйткәндә, шигърият үзенең тойгыларга тәэсир итү көче белән гадәти күргәзмә агитация формаларыннан күпкә өстен тора.

Әмма чынбарлык рифмага салынган әсәрләр арасында «буш юлларның» башка жанрларга караганда күбрәк булуын раслый. Чаллыдан бер таныш инженер начар очеркларга үтергеч итеп менә мондыйрак бәя биргән иде: «Аларда коры саннардан һәм төче сокланудан башка берни юк». Кайбер шигырьләрдә, әгәр аларны шигырь дип әйтергә яраса, саннар зур урын алмаса да, төчелек — буа буарлык.

Мисал өчен Феликс Чуевның «Чаллы» дип исемләнгән шигъри репортажына мөрәҗәгать итик[1]. Автор күзгә бәрелгән фактлар белән генә эш итә, шагыйрьне төзелешнең колачы һәм масштаблары таңга калдыра. Әсәрдә күпләргә мәгълүм информация рифмалы юлларга гына салынган. Барысы да шома, көйле кебек. Тик бер генә нәрсә җитешми — анда КамАЗ төзүчеләрнең җаны, рухы юк.

---

[1] КамАЗ, «Молодая гвардия», 1974.

Әйе, мондый шигырьләрдә бүгенге заман техникасына шундый зур урын бирелә ки, аларның «шавы һәм гөрелтесе» җанлы кешеләр авазын бөтенләй диярлек күмеп китә. Бүгенге герой күңеленә үтеп керүгә караганда, В. Костров язганча, «КамАЗның бетон тәненә, тимер сөякләренә» мәдхия җырлау, әлбәттә, күпкә җиңелрәк. Ә менә А. Гаврилов барысын да уздырган. Шигырь сөючеләр аның: «Килер бер көн — автомобиль чабар көпчәкләрен зыр-зыр әйләндереп», дигән юлларын укыгач бик тә «сөенерләр» инде[1].

Хәер, кемгә дә сер түгел: кайбер авторлар теманың актуальлеге һәм әһәмияте шигъри «гөнаһларны» яшереп кала дигәнрәк караштa торалар. Бәлки кайбер редактор һәм нәширләр дә алар ягындадыр. Әмма чын укучының күзенә «төтен җибәреп» булмый. Ул акны карадан бик әйбәт аера. Кайчакта хәтта танылган шагыйрьләр язганны укыйсың да гаҗәпкә каласың: аларның таланты, үзенчәлеге кая киткән соң? Бу нидән килә? Безнең кайбер шагыйрь дусларыбыз күпчелек очракта «килдем, күрдем... яздым» принцибы белән генә эш итмиме? Бу фикерне, мәсәлән, Виктор Боковның «Чаллы» дип исемләнгән шигыре («Известия» газетасы, 2 октябрь, 1977) белән дә дәлилләргә мөмкин. Авторны шәһәрнең «электр нурларына чумып утыруы» гаҗәпкә калдыра. Бүген илебезнең иң ерак почмакларында да Ильич утлары балкуын күздә тотсак, «электр нурлары» КамАЗ өчен характерлы деталь була аламы соң? дигән урынлы сорау туа. Кыскасы, бөтен шигырь шундыйрак «ачышлардан» тора. Дөресен әйтик, бөек төзелешкә багышланган әдәби бакчаны мондый төр шигырьләр һич бизәми.

Хәер, Чулманнар ярларыннан ташып аккан чакта күбекләр калыкмый калмый. Әмма ул ничаклы тиз барлыкка килсә, шулай ук тиз юкка да чыга. КамАЗ да шигъри «күбекләр» генә тудырып калмады, дәверләр буе сакланырлык әһәмиятле, җегәрле шигъри әсәрләр дә иҗат ителде. Танылган каләм остасы Сибгат Хәкимнең «Дәверләр капкасы» һәм яшь шагыйрь Рөстәм Мингалимовның «Күз карасы» поэмалары нәкъ менә шундыйлардан санала ала.

«Дәверләр капкасы» поэмасының башында ук шагыйрь һәртөрле шаукымлы модаларны — «КамАЗ белән бары намаз гына рифмалашмый калган» модаларны кабул итә алмавын белдерә. Аны төзелешкә бөтенләй башка максат алып килә. Әдип замандашларын үз күзе белән күреп, аларның күңеленә үтеп керергә, халкыбызның үткәнен, бүгенгесен, киләчәген бөек төзелеш призмасы аша аңларга тели. Поэмада бердәм сюжетның юклыгы, әсәрнең аерым бәйләмнәрдән торуы да бәлки әнә шуннан киләдер. Ләкин әсәрне туган җир турында уйланулар бер төенгә бәйли, бөтен итә. Туган җир темасы әсәрнең буеннан-буена кызыл җеп булып сузылып килә. Менә поэмадан бер өзек:

**Терелде күк Чаллы туфрагы,**
**Гасырларның данлы туфрагы:**
**Чаллы, чалгы, печән өсте чагы,**
**Арышларның, камышларның шавы..**

**Анда кинәт пәйда булды бары, —**
**Пугачевның ярды быргылары,**
**Уйнады күк, яшен ул чак даны**
**Гражданнар сугышы уч-аклары**
**Янды ярда, җирнең күп зары,**
**Күп болганган Болгар туфрагы...**

Шагыйрь һәммәсен фәлсәфи күзлектән үткәрә. Төзелеш кайсыдыр ягы белән авторга Курск янындагы Дуганы хәтерләтә. Ул монда Ржевта кичергәннәрен янә бер тапкыр күңеле аша үткәрә. Әйе, шагыйрь өчен истәлекле бу исемнәр, сугыш урыннары КамАЗ белән турыдан-туры бәйләнгән. Чөнки яу кырында әдип үзе һәм меңнәрчә башка сугышчылар куркып калсалар, бүгенге төзелешләр дә булмас иде. С. Хәким камазлылар күзенә туры карап, аларны сынарга тели. Хәзерге буын Ватаныбызның бәйсезлеге өчен корбаннарга барырга әзерме? Авторның шагыйрь Муса Җәлилгә мөрәҗәгать итүе дә аңлашыла. Дәверләр бәйләнеше — биредә төп тема

[1] КамАЗ, 1974, җыентык, 129 бит.

менә шул. Бу — халыкның үткәне, революция, Ленин декретлары, беренче бишьеллыклар белән бәйләнеш. Бу — иртәгесе көн белән бәйләнеш. Чөнки Чаллы киләчәк буыннар өчен төзелә. Автор бүгенге шук малайлар йөзендә киләчәк Тукай һәм Җәлилләрне чалымлый.

Р. Мингалимовның «Күз карасы» поэмасы да формасы белән гадәти түгел, әсәр аерым өзекләрдән тора кебек. Әмма аларны шагыйрьнең кайнап торган эчке дәрте бер кысага бәйли. Шагыйрь өчен КамАЗ — барыннан да бигрәк хакыйкатьне бәяләү критерие. Автор хәзерге дөнья, кеше һәм үсешебез юллары турындагы карашын шул хакыйкать аша ачып бирә. Поэтик дәреслеккә таянып, Р. Мингалимов замандашыбыз рухын бөтен тулылыгы белән күрсәтергә омтыла.

Боларга янә татар шагыйрьләре Р. Харисов, М. Газизов, С. Шәрипова, Р. Гәрәй, рус шагыйрьләре М. Львов, В. Костров, Н. Беляев һ. б.ларның истә калырлык, кызыклы шигъри бәйләмнәрен өстәргә кирәк.

КамАЗның үзендә яшәүче шагыйрьләр турында да берничә сүз әйтеп узыйк. Мәсәлән, Василий Росляков «Беренче очрашу» дигән очеркында, яшь камазлылар рухын аңларга теләп, менә мондыйрак сорау куя: «Кемнәр алар, нәрсә хакында уйланалар, үзләрен ничегрәк аңлыйлар? Үзләренә, үз эшләренә, безгә — өлкәннәргә, кешелеккә, мәхәббәткә, гаделлеккә карата нинди мөнәсәбәттә торалар?» В. Росляковка бүгенге геройны аңлау өчен КамАЗда яшәүче шагыйрьләр ярдәмгә килә. Чөнки аларның бөтен иҗаты бүгенге кеше рухына багышланган бит. Эшче шагыйрьләр иҗатына бәлки профессиональлек, җитлеккәнлек һәм үз-үзеңә ышаныч та җитеп бетми торгандыр. Әмма шуңа карамастан, аларда җанлы йөрәк тибешен, хисләр сафлыгын тоясың. Бу шагыйрьләр дөньяны үзләренчә аңлыйлар. Шунлыктан алар иҗатына үзәк һәм җирле матбугат битләрендә киң урын бирелә, әсәрләре аерым җыентыклар булып чыга.

РСФСР Язучылар союзының моннан ике ел элек Казанда үткәрелгән киңәйтелгән утырышында чыгыш ясаучылар бөтенесе диярлек бертавыштан шундый фикер әйттеләр. Соңгы елларда Татарстан куәтле нефть химиясе һәм машина төзелеше державасына әверелү белән беррәттән, бөтен совет әдәбиятын эшчеләр сыйныфы турында язылган байтак күләмле әсәрләр белән баетты. КамАЗ төзүчеләре турында иҗат ителгән Б. Камаловның «Урамнар киңәя», Ә. Баяновның «Ут һәм Су», М. Хәсәновның «Кама таңнары», М. Хәбибуллинның «Тау белән тау очрашмаса да...» дигән повесть һәм романнарын күрсәтергә мөмкин. Язылу осталыгы дәрәҗәсе белән дә, стиль үзенчәлекләре белән дә бер-береннән шактый нык аерылып торган бу әсәрләргә хас уртак бер сыйфатны күрмәү мөмкин түгел — ул бүгенге замандашыбыз характерын бөтен тулылыгы белән күрсәтергә, КамАЗ төзүчеләренең рухын, интеллектуаль һәм әхлакый дөньясын ачып бирергә омтылудан гыйбарәт.

Югарыда телгә алынган әсәрләр исемлегенә шулай ук Красноярск язучысы Роман Солнцевның «Яшел калкулыкта кызыл ат» повестен өстәргә кирәк[1]. Кайбер кытыршы урыннары булуга карамастан, әсәрнең бик талантлы язылуын әйтеп узасы килә.

Күренекле татар прозаигы Б. Камаловның «Урамнар киңәя» исемле повестеның үзәгендә тәрбиягә авыр бирелүче үсмер егет Яфиз язмышы сурәтләнә. Егет буйга озын булып үсүе белән генә түгел, ә йөгәнсезлеге һәм үзен бик иркен тотуы белән дә башкалардан аерылып тора. Аңа әле уналты да тулмаган. Әмма ул инде укуны ташлап, тәмәке тартырга һәм бераз «төшергәләргә» өйрәнгән. Өлкәннәр кисәтү ясаса, ул бик шапылдап, «челт» итеп теш арасыннан гына төкереп куя. Язучы безгә аның нигә шундый бозык юлга басуын да тәфсилләп аңлатып бирә. Баксаң, Яфиз әтисез үскән, җитмәсә, укытучылар да аңа битарафлык күрсәткән, урам үзенең тискәре йогынтысын ясаган икән. Менә Яфиз КамАЗга килә һәм хезмәт коллективында кабат тәрбияләү процессы башлана. Хәер, беренче карашка нәкъ шулай булырга тиештер дә кебек, әмма тормышта гел генә алай булмый. Язучы үз алдына куйган бурычны үтә берьяклы гына хәл итә. Әсәрдәге геройларның эшләре, уй-фикерләре, хәтта

---

[1] Р. Солнцев. Красная лошадь на зеленых холмах. М., «Молодая гвардия», 1977.

тормыш юллары тик бер нәрсәгә — егетне дөрес юлга бастыруга буйсындырылган. Үз гомерен аямыйча, коралллы бандит белән бәрелешкә кергән механизатор Вәдут, аның хатыны, Яфизны укырга үгетләүче укытучы Рәйхан, егетне үзенең шәхси җаваплылыгында монтажчылар коллективына эшкә алган бригадир Григорий Прохорович, кара тир түгеп тапкан икмәкнең кадерен белүче Морзахан карт — һәммәсе Яфизга ничек тә булса уңай йогынты ясау, аны ничек тә кеше итү максаты белән генә яшиләр кебек.

Шушы урында укучы әсәр белән кызыксынуын югалта. Чөнки аңа вакыйганың ни белән бетәчәге болай да көн кебек ачык. Димәк, язучы корган патрон «ядрәсез» булып чыккан түгелме? Туган телебезнең егерен белүче, психологик детальләр белән эш итүче тәҗрибәле каләм иясе Б. Камалов ник шундый пешеп җитмәгән калач биргән? Хикмәт бәлки ашыгудадыр? Чыннан да, бик мөһим һәм актуаль темага беренчеләрдән булып тотыну гына әсәрне уңышлы итми икән шул.

Ә менә Роман Солнцевның «Яшел калкулыкта кызыл ат» повесте сюжет тукымасы белән Б. Камалов әсәренә шактый якын тора. Бу повестьта да сүз үсмер егет турында бара. Унҗиде яшьлек Алмаз Шаһидуллин КамАЗга килеп, шулай ук эшчеләр коллективында хезмәт чыныгуы уза. Әмма бу очракта әсәрне йотлыгып укыйсың. Чөнки төп герой үзенең гадәти авыл малае булуы, оялчанлыгы, сафлыгы, һәрнәрсәгә соклана белүе белән шунда ук күңелеңне яулап ала. Ул ат караучы булгангамы, үлеп ат ярата. Кайчак аптырап, югалып та калгалый. Ләкин тормыш каршында алай ук көчсез дә түгел. Автор бөек төзелешкә нәкъ менә шушы егет күзләре белән карый. Алмаз өчен монда һәммәсе яңа, бөтенесе кызык һәм үзгә. Шуңа да ул дөньяны романтик төсләрдә кабул итә.

Ләкин тормыш ал төсләрдән генә тормый икән. Ул акрынлап кырыс яклары белән дә ачыла. Егетнең КамАЗ турында беренче тәэсире шундый: ниндидер юньсез бәндәләр бер атны дагалары белән тимер челтәргә эретеп ябыштырып киткәннәр. Ә мескен хайван, ничаклы гына чәбәләнсә дә, койрыгын болгап, тимер тозактан һич ычкынып китә алмый. Әлеге күренешнең үзенә бер төрле символик мәгънәсе дә бар. Бала чакның гүзәл хыялы — яшел калкулыктагы кызыл атка хәзер куәтле техника арасында, төзелеш барган урында ялларын уйнатып, иркенләп чабып йөрергә туры килмәс. Әмма монда язучы беркатлы рәвештә шәһәр белән авылны, цивилизация белән табигатьне каршы куйган икән дип уйларга ярамый. Ялгышулар, хаталар, күңел бизүләр аркылы узып, каршылыклы мәхәббәт утында янып, чын дуслык ярдәмендә Алмаз чыныга, ир-егеткә хас сыйфатлар ала. Язучы үз каһарманының язмышын җиңеләйтеп күрсәтми, аның юлыннан киртәләрне алырга ашыкмый. Шуңа да Алмазның чын кешеләр белән танышудан, олы төзелештән үзенә уңай сабак алуы укучыны ышандыра. Әдәби әсәрнең көче дә нәкъ менә шундадыр. Композицион характердагы аерым кимчелекләргә булуга карамастан, «Яшел калкулыкта кызыл ат» повесте — Р. Солнцевның бәхәссез уңышы.

Мөсәгыйть Хәбибуллинның «Тау белән тау очрашмаса да...»[1] дип исемләнгән повестенда да төп игътибар эшче кеше характеры формалашу проблемасына юнәлдерелә, бу процесста коллективның роле күрсәтелә. Гомумән алганда, әсәр шоферлар тормышыннан алып язылган. Әсәрдә үзенчәлекле характерлар тасвирлана, сюжет кискен бәрелеш һәм конфликтлар белән бергә үрелеп бара.

Төп геройларның берсе шофер Ислам Байтимеров — тәвәккәл, һәр очракта уңышка ирешүчән кеше. Шуңа хатын-кызлар да аңа кырын күз белән карамыйлар. Егеткә һәр нәрсә җиңел бирелә. Әллә ни тырышлык та куймыйча, ул дусты Зөлфәт Янаевның сөйгән кызын үзенә карата. һәм эштә дә аны үзеннән күпкә артта калдыра. Ни дисәң дә, Ислам — шофер, ә аның стихиясе — тизлек. Ул юллардан аргамактай җилдереп кенә уза. Моннан тыш, «файдалы рейска» чыгу өчен ул кемгә «күз кысарга» кирәклеген дә яхшы белә. Бөтен хикмәт хәйләли белүдә: йөкне азрак аласың, аның каравы тонна-километрларда күбрәк отасың. Ислам әнә шундый принцип белән эш итә.

Ә Зөлфәт Янаевка килгәндә, ул Исламның нәкъ киресе. Автор аны сабыр, кыюсыз, намуслы кеше итеп сурәтли. Егет сөйгәнен һич кенә оныта алмый газап чигә. Йөк төягәндә сәгатьләр буе чиратта торырга да риза ул, чөнки характеры шундый.

---

[1] Әсәр Мәскәүнең «Современник» нәшриятында «Сәгъди» исеме белән чыкты.

Ничаклы тырышлык куеп та, Зөлфәт кенене бер норма бирә алмаганда, Ислам инде ике-өч рейс ясарга өлгергән була. Повестьта болар һәммәсе бөтен нечкәлеге белән, җентекләп язылган. Ләкин кызыклы характерлар бирүенә, ышандырырлык тормыштан конфликтлар тудыруына карамастан, М. Хәбибуллин ситуацияне нәкъ Б. Камаловча хәл итә. КамАЗга ашыгыч йөк алып кайтучы Ислам машинасы белән Кама бозы астына китә. Гел уңышсызлыкка дучар булучан Зөлфәт исә, бозлы суга чумып, аны үлем тырнагыннан коткарып кала. Бөтенесе бик әйбәт тәгәлләнә. Көндәшләр янә дуслашалар.

Шундый ук схемалылык күренекле драматург А. Сафроновның «Гигантлар» пьесасында да[1] сизелә. Автор әсәрдә ике аерылгысыз дус — производство алдынгылары Сергей Мартынов белән Степан Горобецны партиядән чыгару вакыйгасын сурәтли. Монда да геройлар язмышы өчен укучы борчылмый. Чөнки аларның язмышын хәл итүдә турыдан-туры завод директоры һәм партиянең шәһәр комитеты секретаре катнаша. Бу әсәрдә дә финал бәхетле тәгәлләнә. Геройлар, әлбәттә, партиядә калдырылалар. Игътибарны пьесаның тагын бер ягына юнәлдерәсе килә. Автор монда җитәкчеләр образын җанлы кеше итеп бирә алмаган. Укучы аларны фәкать ниндидер бер функция үтәүче кешеләр итеп кенә күз алдына бастыра. М. Хәбибуллин повестенда да автохуҗалык директоры Сәгъди образы бирелгән. Аның шәхси тормышы да җентекләп сурәтләнгән. Әмма шуңа карамастан, без бу геройны чын җитәкче итеп һич тә күз алдына китерә алмыйбыз.

Шундый ук шелтә сүзләрен татар язучысы, «Кама таңнары» романы авторы Мәхмүт Хәсәнов адресына да әйтергә мөмкин. Әсәр «КамАЗның мие» булган ЭВМ машиналарына хезмәт күрсәтүче һәм төзелешкә автоматлаштырылган идарә итү системасын кертү өчен көрәшүче инженерлар тормышына багышланган. Ләкин, дөресен әйтик, романда фән-техника прогрессының иң соңгы казанышларын күрсәтү тышкы «бизәк» ролен генә үти. Әсәрнең төп эчтәлеге геройларның профессиясе, аларның төп хезмәте белән һич тә бәйләнмәгән. Мәсәлән, төп герой Имам Котдусов сөяркәсенең серле шартларда дөнья куюы, аның яшь тол хатын белән мавыгуы; әсәрнең икенче герое Вагыйз Гайнановны гаепсезгә рәнҗетү һәм аны аклау тарихы; табигать кочагында күңел ачу, балык тотулар; берничә урында аннан-моннан сурәтләнгән «производство тормышы» югарыда әйтелгән фикерне бик ачык раслый. Мондый вакыйгаларны КамАЗда гына түгел, һәр җирдә теләгән хәтле очратырга мөмкин. Автор иң мөһимен — үз героеның рухын, интеллектуаль дөньясын ачып бирә алмаган. Мәгълүм булганча, профессия кешенең характерына, зәвыгына, эчке дөньясына йогынты ясый. Ә М. Хәсәнов әсәрендә профессия тик тышкы билге итеп кенә бирелгән. Язучы Әхсән Баяновның «Ут һәм Су» романында да төп геройлар итеп урта буын төзүче-инженерлар, атап әйткәндә, Фәиз Насыйбуллин белән Борис Филинов образлары алынган. М. Хәсәнов романыннан аермалы буларак, бу әсәрдә профессия геройларының характеры һәм рухи йөзе формалашуда шактый зур роль уйный, күп яктан аларның үз-үзләрен тотышы, мөнәсәбәтен билгели. Кыскасы, автор замандашларыбызның җанлы, истә калырлык образларын тудыра алган. Фәиз Насыйбуллин һәм Борис Филинов ике типтагы характер булу белән генә түгел, бәлки һәркайсының дөньяга үз карашы булу белән дә бер-берләреннән нык аерылып торалар. Бу аерма аларның үз-үзләрен тотышында да ачык чагыла. Мәсәлән, Фәиз әсәрдә бөтен эшне намус белән үз җилкәсендә тартып баручы чын энтузиаст итеп сурәтләнә. Борисның аны ярым чынлап, ярым шаяртып «герой» дип атавы да тикмәгә генә түгел. Фәиз көне-төне эштә кайный, утырышлар үткәрә, прораблар белән әйткәләшә, төзелеш өчен цемент һәм башка кытлык материаллар артыннан чабып йөри. Уртак эш өчен үзен дә, бүтәннәрне дә кызганмый. Ә аның дусты Борис Филинов исә бөтенләй башка яссылыктагы образ итеп тасвирланган. Ул тормыштан мөмкин кадәр күбрәк каерып алырга омтылучы, вак җанлы, эгоист кеше буларак күз алдына килеп баса. Борис җитәкче булырга да омтылмый — ни дисәң дә, болай яшәве күпкә тынычрак. Эшкә дә ул вакытында килеп, нәкъ вакытында китәр. Эш көне тәгәлләнү белән бөтен дөнья мәшәкатьләрен башыннан чыгарып ташлар. Шәхси «Волга»сына утырып, чираттагы «мәхәббәт кошы» белән табигать кочагына ашыгыр. Беренче карашка автор персонажларның беренчесен йөз проценты белән тик уңай, ә икенчесен гел тискәре яктан

[1] «Москва» журналы, № 2, 1976.

гына тасвирлый кебек. Ләкин әсәрдә вакыйгалар үсеше барышында бу гадәти схема җимерелә. «Энтузиаст» Фәизнең китап укырга да, махсус әдәбиятны күзәтеп барырга да, шәхси тормышын кайгыртырга да вакыты калмый. Ул эшендә ышанычлы рәвештә һәм тиз арада югары күтәрелә һәм шул ук вакытта белгеч буларак үз квалификациясен югалта бара. Ә «үзен генә яратучы» Борис — дөресен әйтик, талантлы инженер. Ул гади башкаручы гына түгел, бәлки иҗади кеше. Чынлыкта, Борис хезмәтне фәнни оештыруны хуп күрә. Аның фикеренчә, инженер тәүлек буе чабып йөрергә түгел, үз эше белән шөгыльләнергә тиеш.

Кызганычка каршы, Ә. Баяновка гадәти булмаган бу конфликтны ахырынача чишеп бетерергә иҗади кыюлык җитмәгән. Автор «уңай герой» Фәизне күтәрергә, ә «тискәре персонаж» Борисны фаш итәргә ашыга кебек. Хәлбуки, күп яктан бер-берсенә охшамаган, шул ук вакытта нәрсәдәдер бер-берсен тулыландыручы бу ике герой конфликтында бүгенге чорның кайбер үзенчәлекле сыйфатлары чагылган.

Зур эшләр генә җитди проблемалар, олы характерлар тудыра. Мәсәлән, КамАЗны берни белән дә исәпләшмичә, акча һәм көчне дә, техника һәм кешене дә кызганмыйча төзергә мөмкин. Шул ук вакытта максатка иң кулай юл, дәүләт чыгымнарын мөмкин чаклы киметү юлы белән ирешергә була. «Дәвам» һәм «Диалоглар» пьесалары авторы Диас Вәлиевне нәкъ менә шушы проблемалар дулкынландыра. Драматургның әсәрләре хакында үзәк һәм җирле матбугатта күп язылды, аларның уңай яклары һәм аерым кимчелекләре җентекләп анализланды. Д. Вәлиевнең төп уңышы үзе тудырган характерларның тормышчанлыгында һәм яңалыгында. Ә бу характерда производство һәм әхлак проблемалары бергә үрелеп килә, һәм алар әсәрләрнең тыгыз тукымасын тәшкил итәләр.

КамАЗ төзелешенә багышланган әсәрләр яңа теманы үзләштерү процессының җиңел генә бармавын ачык раслыйлар. Әмма ни генә булмасын, әдәбиятыбыз олы тема каршында каушап, югалып калмады. Алда телгә алынган әсәрләр арасында башкалар күзенә туры карап әйтерлек казанышларыбыз да юк түгел. Димәк, бу тема күп милләтле совет әдәбияты үсешенең баганалы юлында тора.

Кама автомобиль комплексының илебез экономикасына нинди зур йогынты ясаганлыгы бераүгә дә сер түгел. Ә менә «КамАЗ темасы» гомуми әдәби процесска ниндирәк тәэсир ясады соң? Югарыда әйтеп үтелгәнчә, бу тема, татар әдәбиятында мөһим урын алу белән берраттән, илебездәге башка милләт язучыларының игътибарын да үзенә җәлеп итте.

Хәер, бөтен совет әдәбиятының үсеш адымнары чорыбызның бөек төзелешләрен үзләштерүгә барып тоташа. Мисалга В. Катаевның «Вакыт, алга!», М. Шагинянның «Гидроцентраль», Л. Леоновның «Соть», И. Эренбургның «Икенче көн», В. Кетлинскаяның «Батырлык» кебек романнарын китерү дә җитә торгандыр. Алар һәммәсе беренче бишьеллыкларның атаклы төзелешләре уңае белән дөньяга килделәр. Шуннан соң — кырыгынчы, илленче, алтмышынчы елларда да нәкъ шулай булды.

Бу әсәрләрнең әһәмияте нинди дә булса зур төзелешне тасвирлау белән генә чикләнми, аларда социалистик яшәү рәвешенең, совет кешесе характерының социаль һәм әхлакый чор рухын, заман сулышын ачык тоясың. Алар, тормышыбызның күләгәле якларын яшереп калдырмыйча, яңа җәмгыятькә һәм яңа кешегә хас югары романтик омтылышын, күңел шатлыгын, гүзәллекне аңлау хисен укучы йөрәгенә илтеп җиткерәләр. Иң мөһиме шул — нәкъ менә коммунизм өчен көрәшнең алгы сызыгында замандашыбызга хас иҗади сәләт, илнең хуҗасы булу хисе, төзүче таланты һәм яңаны кору кебек сыйфатлар ачык чагыла.

КамАЗ — бүгенге әдәбиятыбызның бик күп проблемалары да хәл ителә торган урын ул, һәм без монда хәзерге чынбарлык куйган дулкынландыргыч сорауларга җавап табабыз.

## Илдар Низамов

# ПУБЛИЦИСТИКАГА— КЫЮЛЫК ҺӘМ ОСТАЛЫК

Публицистиканы ачыграк төшенер өчен төрле чагыштырулар эзләп караган бар. Әйтик, ул йөрәк тибешен бик төгәл сызып бара торган кардиограмманы хәтерләтә. Публицистика халкыбызның, илебезнең, чорыбызның йөрәк тибешен, сулышын язып бара. Үткәннәрне күз алдына китерер өчен юкка гына элекке газета, журналларга ябышып ятмыйбыз. Бүгенге иҗат очкыннарыбыз да тарих елъязмасына җуелмас эзләр булып уелып кала. Без аларга әле торып-торып кире кайтачакбыз, балаларыбыз, оныкларыбыз да шулардан безнең бүген ничек яшәгәнебезне күрәчәк. Бу хәл публицистларны, бер яктан, горурландырып торса, икенче яктан, алардан үз эшләрендә ифрат җаваплы булуны таләп итә.

Ләкин әлеге чагыштыруның җитди кимчелеге бар: ул бер генә яклы. Публицистикага классик чагыштыруны гасыр башында ук әле Владимир Ильич Ленин тапкан. Вакытлы матбугатны ул төзелеш белән бергә уралып менгән басмаларга тиңли (В. И. Ленин. Әсәрләр. 4 нче басмадан тәрҗемә, 5 том, 11 бит).

Димәк, публицистика чорыбыз сулышын теркәп кенә бармый, ә бәлки җәмгыятьнең зур эшләрендә турыдан-туры катнаша, коммунистлар партиясенең җитәкчелек һәм оештыру эшчәнлегендә тугры ярдәмчесе, тәэсирле коралы булып тора. Публицист халкыбыз, илебез йөрәк тибешен язып кына бармый, аның нык, ышанычлы тибүенә үзенең иҗат ялкыны белән тәэсир дә итә.

1977 ел. Бөек Октябрьның 60 еллык бәйрәме елында илебезнең яңа төп законы — СССР Конституциясе кабул ителде. Аның проектын тикшерүдә катнашканда 140 миллионнан күбрәк совет халкы кулына каләм алды. Чын мәгънәсендә бөтен халык ташкынына әверелгән бу хәрәкәттән язучылар читтә кала алыр идемени?! Алар Совет властеның 60 ел яшәү дәверендә илебез, республикабыз ирешкән казанышларны данладылар, гыйбрәтле мисаллар, кызыклы чагыштырулар белән бүгенге тормышыбызны тасвирладылар.

Гариф Ахуновның, мәсәлән, «Илебез маршрутлары» («Социалистик Татарстан», 1 январь, 1977 ел), «Хыял һәм чынбарлык» («Социалистик Татарстан», 18 август, 1977 ел), «Дәверләр документы» («Казан утлары», 1977 ел, № 11), «Халыклар дуслыгы кодрәте» («Советская Россия» нәшрияты 1977 елда басып чыгарган «Горизонтлар» китабы) һәм башка публицистик мәкаләләре хәтердә калган.

Публицистикада автор үзе, аның позициясе ярылып ята. Алай гына да түгел, ул актив, көчле позиция. Димәк, сүзнең үтемле, тәэсирле булуы синең тормышта, эштә ничек яшәвеңә дә нык бәйле. Халык һәм ил язмышы, аның олы эшләре хәл ителгән вакыйгаларда үзләре турыдан-туры катнашкан язучыларыбызның әсәрләре аеруча кызыксынып укыла. М. Әмирнең «Без бәләкәй чакларда» повестеның («Казан утлары», 6, 7 саннар, 1977 ел) йотылып укылуы да анда халык тарихының иң гыйбрәтле, иң истәлекле вакыйгалары язучының үз язмышы аркылы сурәтләнүенә бәйле.

Г. Бәшировның «Без үткән юллар» («Социалистик Татарстан», 23 октябрь 1977 ел), Р. Ишморатның «Рәхмәт сиңа, язмышым» («Социалистик Татарстан, 25 сентябрь, 1977 ел) дигән истәлекләре дә безне шундый хискә баеталар.

Аларның эмоциональ тәэсир көче бай тарихи мәгълүмат бирүдә генә түгел, әлбәттә. Биредә публицистик осталык та җитди роль уйный. Шуны уйласаң, янә теория өчен дә ярап куярлык кайбер нәтиҗәләр чыга, публицистиканың яңа үзенчәлекләре төсмерләнә. М. Әмир, мәсәлән, үзенең сүзләре белән әйтсәк, «Кичә турында бүген яза», ягъни хатирә-истәлекләрен бүгенге тормышыбыз, алда торган бурычлар биеклегеннән бәяли, бүгенге кешеләрне уйлап яза. Әйтик, туган тел, әни, җыр турындагы шигърият белән өртелгән кичерешләр дә, Казан, КамАЗ турындагы яки әдәп кагыйдәләренә бәйләнешле уйлары да, бүгенге көннең актуаль проблемалары булганлыктан, заманча яңгырыйлар, укучыларның һәр төрле катламында кызыксыну уяталар.

Язу алымына килгәндә дә, сырлап, бизәкләп язарга тырышмыйча, автор бик дөрес эшләгән. Ул үзе үк: «Мотлак образлар теле булсын дип тормадым, ачыктан-ачык публицистика алымына мөрәҗәгать иттем», — ди. Өстәп шуны гына әйтәсе килә, бу юнәлеш — татар әдәбияты өчен сыналган, традицион юнәлеш. Г. Тукайдан, Г. Ибраһимов, М. Гафурилардан килә ул.

Тагын шунысы бар, идеология фронты активисты буларак язучының осталыгы истәлекләрен нәкъ вакытында чыгару, көн кадагына суга белү белән дә билгеләнә. М. Садри, мәсәлән, Вахитов исемендәге химия комбинатыннан репортаж язды («Социалистик Татарстан», 5 ноябрь, 1977 ел). Хикмәт өлкән язучының бүгенге комбинатны, аның кешеләрен үзе моннан күп еллар элек, шунда эшләгән вакытлар белән оста чагыштырып, гыйбрәтле сөземтәләр чыгаруында һәм шул хакта укучыларга нәкъ менә юбилей көннәрендә сөйләп бирүендә.

Бөек Октябрь революциясе, гражданнар сугышы, Бөек Ватан сугышы — мәңгелек темалар. Алар әле яңадан-яңа яшь публицистларга рухи азык, илһам бирер. Ләкин бу юнәлештә эшләве кыенлашканнан-кыенлаша бара. Архивларда эзләнү, берәмтекләп истәлекләр җыю күп вакыт, физик көч, зур сабырлык, өстәмә белем сорый. Шуңа күрә дә моңа алынган яшьләр күп түгел. Аларга аеруча игътибарлы булырга, хезмәтләренә гадел бәя бирергә тиешбез.

Әлбәттә, һәр язучы шагыйрь була алмаган кебек, публицист булу да һәркемгә насыйп түгел. Инде үзеңдә шундый сәләт барлыгын сизәсең икән, алдыңа максатның зурын куярга һәм аңа ирешү өчен бөтен көчеңне бирергә тиешсең. «Мин һәлак булып калган героем өчен сөйлим, — ди Шамил Рәкыйпов. — Аның эзләреннән йөреп, мин ил гиздем. Аны күргән, белгән кешеләр белән гәп кордым. Аны хыялымда тереләттем. Башкача булмый. Шулай итмәсәм, сүзгә саран каһарманнар мәңге дәшмәячәкләр». Менә шундый изге, олы максат язучыны осталыкка омтылдыра. Аның «Рейхстагка беренче адымнар» («Татарстан яшьләре», ноябрь-декабрь, 1977 ел), «Һәйкәлләр янында» («Яшь ленинчы», 2—27 апрель, 1977 ел), «Днепр ярында таллар бар» («Казан утлары», 1978 ел, 5 сан) очерклары — шушы иҗади омтылуның җимешләре.

Публицистиканың иң төп үзенчәлеге, Мариэтта Шагинян сүзләре белән әйтсәк, «факттан фикер чыгару». Публицистиканың бурычы портрет тасвирлау, вакыйга сөйләү, ягъни факт санау түгел, ә бәлки фактлардан акылга, хискә тәэсир итәрлек фикер-проблема кузгату. Шунсыз публицистика була алмый. Алдынгылыкны мактыймы ул, әллә кимчелекне яманлыймы, публицистик чыгыш һәр вакыт укучыны уйланырга, дулкынланырга этәргән фикер чыганагы булырга тиеш.

Бәйрәм, тантана уңаеннан язылган материалларга да шул ук таләп. Бүтәнчә мөмкин дә түгел, чөнки В. И. Ленин, партия безне, революцион бәйрәмнәр алдагы көнгә хезмәт итә, дип өйрәтә. Халыкка әйтер сүзе булган язучы газета-журнал биргән мөмкинлекне андый вакытта да урынлы файдаланыр, күптән мәгълүм фикерләрне чәчәкле-чуклы сүзләргә төреп кенә яңартырга маташмас, һәр вакыйганы үзенчә күрә белеп, яңача тасвирлый алыр. Шушы җәһәттән Б. Камаловның «Совет кешесе» («Социалистик Татарстан», 9 апрель, 1977 ел), Г. Минскийның «Хакыбыз-хокукыбыз» («Татарстан яшьләре», 13 август, 1977 ел), Ә. Баяновның «Туган җирем — горурлыгым» («Советская Татария», 7 август, 1977 ел) мәкаләләре хәтердә калган. Аларда

күпне кочакларга тырышып таркалу юк, бәлки, исемнәреннән үк күренгәнчә, аерым бер мәсьәлә тирәсендә конкрет сүз йөртелә.

Ф. М. Достоевский: «Һәр тәнкыйтьче публицист булырга тиеш, шул мәгънәдә публицист: һәр тәнкыйтьченең бурычы үзенең нык ышанычын (иманын) булдыруда гына түгел, ә бәлки шул иманын үткәзә белүдән дә тора» [1], дигән. Талантлы язучы кулыннан төшкәндә юбилей, туган көн уңаеннан язылган гади мәкалә-рецензия дә татлы җимеш булып җитлегеп, өлгереп төшә. С. Хәкимнең шагыйрь М. Львов турындагы мәкаләсен («Социалистик Татарстан», 4 январь, 1977 ел), әдипнең үз шигырьләрен укыган кебек онытылып, ләззәтләнеп укыйсың, авыр юлда салкын чишмә очрап, шуннан бер кушуч су эчеп җибәргәндәй буласың. «Фикер уйнасын... Львов үз хисләренең агыш формасын тапты. Минем юка боз катлавы астында үзенә юл эзләгән суны күзәтеп торганым бар. Башта азаплана кебек... Аннан уйнап-гөрләп ага башлый, тавышы иртә, артыннан калмый йөгерәсе килә. Чоңгылга ашыккан ерганак...»

Биредә публицистика белән шигърият аерып ала алмаслык хәлдә кушылган. Гомумән, публицистика шундый аралашучан жанр ки, ул бүтән иҗади алымнарның иң яхшы сыйфатларын үзләштерүгә бер дә каршы түгел. Әйтик, фәнни стильнең конкретлыгын, кырыслыгын алып, цитата һәм төрле документларны образ биеклегенә күтәрә алган кебек, матур әдәбият стиленең дә үзенә ятыш, кулай сыйфатларын бик иркен куллана.

Публицистик ялкын белән өртелгән әдәби тәнкыйтьнең тәэсир мөмкинлекләре ифрат зур. М. Мәһдиевнең «Галимҗан Ибраһимов әсәрләрендәге образларның прототиплары» («Казан утлары», 1977 ел, 1 сан), «Иван Бунин һәм татар фольклоры» («Советская Татария, 23 январь, 1977 ел), Р. Мостафинның М. Җәлил эзләреннән яңа табышлары («Казан утлары», 1977 ел, 2 сан; «Ялкын», 1977 ел, 8 сан), Х. Сарьянның «Уеңны уйдырып сал» китабындагы (Татарстан китап нәшрияты, 1977 ел) туган тел турындагы мәкаләләре укучыларга әдәбияттан, тарихтан төрле бай мәгълүмат биреп кенә калмый, бәлки чын сәнгать әсәренең үзе кебек үк тәрбия чарасы буларак та төрле яклап йогынты ясый.

Тик мондый чыгышлар әле бик аз. Яңа спектакльләргә рецензияләрнең фәнни яктан да сай булып, публицистикадан да ерак торулары борчылу тудыра. Кайбер яшь язучылар аларны уенчык мылтыктан борчак аткан кебек кенә ыргытып торалар. Ә. Гаффаровның телевизион спектакльгә язган рецензиясен («Социалистик Татарстан», 25 июнь, 1977 ел) кызыксынып укый башлыйсың: тормышыбыздагы, сәнгатебездәге бу яңа күренеш ничек бәяләнә икән, күңелне борчыган кайбер якларын төзәтер өчен автор ниләр тәкъдим итә икән? Тик өмет акланмый: «телевизор экраны ясалмалылыкны яратмый, купшылык, төчелек монда чит нәрсә. Иң кирәклесе — тормышчан кичерешләр, детальләр дөреслеге», кебек әүвәлге театр рецензияләрендә үк тапталып беткән штампларның, яңа квартирга ияреп килгән иске-москы кебек, монда да тагылып керүе җанны гына әрнетә.

Ә бит өйрәнергә бер дә ерак барасы юк. С. Хәкимнең «Камай чишмәсенең суы җырлата» очеркы («Социалистик Татарстан», 27 август, 1977 ел) бер карагандә нибары җыр турында гына кебек, әмма аны укыганда үзеңнән-үзең публицистика турында тирәнрәк уйларга бирeләсең. Кайбер йомгаклар ясала. Әйтик, публицистик гомумиләштерү мәсьәләсе. С. Хәким очеркы шундый көчкә ия ки, Вафирә Гыйззәтуллина йөзендә без барлык артистларыбызны уйлый башлыйбыз. Талантлы җырчыбыз өчен, бөтен сәнгатебез өчен горурлык хисе туа. Авторның җыр сәнгате һәм артистларыбыз турында Вафирәгә кушылып уйлануы барыбызның да борчылуы, уйлануы булып әверелә.

Бу — чын осталык, публицистикада зур казаныш. Моңа ирешер өчен язучыга нык кына каршылыкны җиңәргә кирәк. Уйлап карагыз: бер якта — публицистика чынбарлыкта булган факт белән, анда да әле кабатланмаган, яңа факт белән эш итәргә тиеш, әмма икенче якта — ул факт «шаккатаризм», сенсация дә булмыйча, безнең та-

[1] Краткая литературная энциклопедия. 6 том, 74 бит.

бигый яшәешебезнең уртак күренеше, типик факт, вакыйга дип кабул ителерлек булырга тиеш. Җиңеп кара син шундый каршылыкны! Әмма җиңәргә кирәк. Һәм моның матур үрнәкләре үзебездә үк булуы безне сөендерә.

Публицистика үзенең сәләтен, асыл сыйфатларын көннең төп темаларын яктыртканда гына тулысынча ача. Эшче, колхозчыдан, галим, инженердан башка, аларның хезмәт казанышларыннан башка иҗтимагый яшәеш юк. Төп тема дигәнебез менә шулар. Алардан башка әдәбиятның да, публицистиканың да булуы мөмкин түгел. Завод-фабрикаларда, ферма-кырларда, фәнни лабораторияләрдә, төзелешләрдә бүген иҗади, тынгысыз хезмәт шавы. Совет халкы унынчы бишьеллыкның яңа кыяларын яулый.

1978 ел да тарихка кереп калырлык вакыйгаларга бай булды. РСФСР Конституциясе, Татарстан АССР Конституциясе кабул ителде. КПСС Үзәк Комитетының июль Пленумы «СССР авыл хуҗалыгын тагын да үстерү турында» карар кабул итте. Аны тамәлгә ашыру өчен республикабызда да киң колачлы эшләр бара.

Язучының урыны — алгы сафларда. Иҗади оешма җитәкчеләренең бөтен союз киңәшмәсендә Г. Марков болай дигән иде: «Халыкның күтәренке рух белән яшәве, массаларның политик һәм хезмәт активлыгы безнең күп милләтле әдәбиятыбызны шифалы чишмәдәй сугарды һәм сугарачак. Без халыкның практик эшләренә тагын да якынаерга, халык тормышының төп агымнарына тагын да тирәнгәрәк керергә тиешбез. Совет кешеләренең батырлыгы язучыларны үзенә җәлеп итми кала алмый. Шундый шартларда һәр язучылар оешмасы, һәр журнал һәм газета алдында инициатива өчен, иҗат, эзләнү өчен бетмәс-төкәнмәс мөмкинлекләр ачыла. Бу эшкә һәрбер язучыны тарту, халык белән аралашуның барлык плацдармнарына чыгу, унынчы бишьеллыкның чын шагыйрьләре булу бик тә әһәмиятле».

Партиябез халык алдына куйган чиратагы яңа җитди бурычлар публицистика турында да тирәнтен уйланырга, аның торышына, бурычларына яңача, таләпчәнрәк карауга этәрә.

Иҗади борчылу, уйлануларның нәтиҗәсе буларак, язучыларның авыл темасына багышланган публицистикасы шактый җанлана төште. Г. Ахуновның Куйбышев районыннан язган «Икмәк» циклы, С. Хәким, Роб. Әхмәтҗанов, М. Хәсәнов, Ф. Шәфигуллиннарның соңгы язмалары шул хакта сөйли. Ләкин болар әле беренче адымнар гына. Кызганычка каршы, аларның барысына да хас, һәм, гомумән, тулаем публицистикабызга хас бер кимчелек бар — аларда аерым хуҗалыкларның, аерым геройларның казанышларына, күрсәткечләренә мөкиббән кителә дә, публицистиканың төп асыл сыйфатларыннан берсе — гомумиләштерү, типиклаштыру онытыла. Хәлбуки, Владимир Ильич Ленин моңа аеруча әһәмият биргән: ул «Крестьян хуҗалыкларын дифференцияләү мәсьәләсенә карата» дигән китап авторы Борис Книповичка язган хатында: «Саннар рәте артында вакыты-вакыты белән күздән **типлар**, хуҗалыкларның иҗтимагый-экономик **типлары** төшеп калмыймы. Статистика материалларының үзенчәлек көче бик нык булганга, моның куркынычы бик зур. «Саннар рәте» мавыктыра. Авторга мин бу куркынычны исәпкә алырга киңәш итәр идем...» — ди. (Н. К. Крупская. Ленин — редактор и организатор печати. М., Гослитиздат, 1956, 19 бит.)

Безгә хәзер публицистика, бигрәк тә аның катлаулырак, саллырак жанры — очерклар белән җитдирәк эш итәргә вакыттыр.

Бүгенге очеркларны анализларга керешкәч, аларның бер-берсеннән нык үзгә ике төркемгә аерылуын күрәсең, беришләре кеше турында, икенчеләре язучыны борчыган мәсьәлә турында. Бер жанр дип тамгаланган сәнгать әсәрләренең эчтәлекләре ягыннан шулай аерылуы сәер хәл, тормышта бит кешеләр үзенә, проблемалар үзенә аерым яшәмиләр, алар аерылгысыз. Димәк, бүгенге очеркистикада ниндидер ясалмалык барлыкка килгән. Моны ачыклап китәргә кирәк.

Очерк ул — бүген иҗтимагый әһәмиятле булган чын факт, вакыйганы кеше характерына бәйләп, җәмәгать фикере тудырырлык итеп, әдәби һәм публицистик чаралар белән хикәяләү. Димәк, ул повесть, хикәядән документаль фактлар һәм чын персонажларга нигезләнүе белән генә аерыла. Безнең фикеребезчә, повесть, хикәя

белән бер рәткә куеласы очеркны портрет очерк, проблемалы очерк, тагын әллә нинди очерк дип классификацияләү ким дигәндә җавапсызлык белән янәшә тора.

Әгәр очеркны чын әдәби жанр дип санийсың икән, анда тормышның реаль чагылырга тиешлеген танымый кала алмыйсың. Шулай булгач, анда кешеләр аерым, проблемалар аерым яши алмый. Язмада шулай килеп чыга икән, димәк, ул әле очерк дәрәҗәсенә җитмәгән.

Шулай да без портрет язмаларны игътибарсыз калдырмыйк. Аларны укыгач, республиканың төрле төбәкләрендә, хуҗалыкның төрле тармакларында эшләүче алдынгы кешеләребезнең эш алымнары, яшәү рәвешләре күңелдә әйбәт эз калдыра. Я. Винецкий, Б. Камалов, К. Тимбикова, Җ. Рәхимов, Х. Хәйруллин, Ә. Маликов, Ф. Яруллиннар бу юнәлештә активлык күрсәттеләр. Тулаем алганда, мондый язмалар күптән мәгълүм калыплар хәлендә торсалар да, бу язучыларның иҗаты шул хәлдән чыгу юлларын эзләүләре белән игътибарга лаек. Ф. Яруллин, мәсәлән, моңарчы язылмаган профессия кешеләрен тәкъдим итте. Б. Камалов язмаларында, геройларны бөтен яклап тасвирларга омтылудан котылып, аеруча характерлы бер генә ягына тукталу күренде. К. Тимбикова исә, киресенчә, портретларны киңрәк планда язуда үзен сынады, Ә. Маликов үз геройларының эчке кичерешләрен калкурак бирергә омтылды.

Ләкин портрет язмаларның күпчелегеннән, чыннан да, ясалмалылык бөркелеп тора. Бу аларга тормышчанлык, әйтер идем, документальлек җитмәүдән килә. Документальлек ул геройның чын исемен атап, адресын күрсәтүдә генә түгел. Әсәрнең барлык кузәнәкләре дә тормышчан булырга тиеш. Ә без тормыш дөреслегенә еш кына хилафлык китерәбез. Мисаллармы?

Персонажларыбызның телен алыгыз, тормышта алар шулай сөйләшәләрмени?!

Язмаларыбызның финалын алыгыз, ал да гөл булып бетмәгәне бармы? Ә бит тормышта геройларыбыз безнең арттан хәл ителеп бетмәгән эшләре, борчу-мәшәкатьләре белән калалар.

Геройларыбызга сокланып, төчеләнү дә ясалмалылык түгелмени?!

Дөрес, композитор Прокофьевның: «Мин сокланам һәм шуны кешеләргә сөйләргә телим», дигән сүзе бар. Чын сәнгать әсәре соклanудан, хәтта аптыраудан, шуны башкалар да сокланырлык, аптырарлык итеп язудан туа. Ләкин моның өчен бөтен кеше дә соклана торган фактның табылуы мотлак. «Кара, иске чикмәнгә исе киткән», димәсеннәр.

Ясалмалыкның иң төп сәбәбе — геройларны конфликттан, проблемадан аеру. Дөрес, язучыларыбыз яшәп килгән кимчелекләрне ачуда, аларны бетерү өчен барган көрәштә катнашмый дип булмый, тәнкыйть чыгышлары матбугатта күренгәли. Аларны тикшерә-анализлый китсәк, мондыйрак күренешкә тап булырбыз: язмаларның күпчелеге әхлак-тәрбия темаларына карый, тормыштагы гыйбрәтле хәлләргә таянып, үгет-нәсихәт бирелә. Бу яктан «Азат хатын» журналы актив. Д. Зөбәерованың мәкаләләре проблеманы кискен, таләпчән куюы белән характерлы. М. Маликова исә күңел кылларын тибрәтергә тырышып, нечкәртеп яза. Бу аның Р. Уразманова белән язган «Котлы булсын туегыз» дигән китабында (Татарстан китап нәшрияты, 1977 ел) туй проблемаларын кузгатуда да күренде.

Кешеләр язмышына бәйле кискен конфликтларга язучы күбрәк хезмәт кайнаган, көн бурычлары хәл ителгән җаваплы участокларда — завод-фабрикаларда, колхоз-совхозларда, удар төзелешләрдә юлыга. Тик бездә әле тормыш эчендә кайнап, бөтен җәмәгатьчелек игътибарына күтәреп чыккан проблемалар бик аз. Тәнкыйть материалларының күпчелегенә акыл сату, барыбызга да күптән мәгълүм фактлар белән, яисә бүтән халык, илләрдән алынган мисаллар белән гомумән сүз куерту хас.

Бу мәкаләмне мин «Публицистикага — кыюлык һәм осталык» дип атадым. Димәк, шушы сыйфатлар җитми. Чыннан да шулай. Кыюлык җитмәүгә бер генә мисал китерим. СССР Конституциясе проектын тикшерү барышында Ә. Еникинең «Иске белән яңа» дигән мәкаләсе басылып чыкты («Социалистик Татарстан», 6 август, 1977 ел). Автор Казан шәһәрен яңартканда истәлекле урыннарны сакларга өнди. Мәсьәләне

конкрет тормышка ашыруга килгәндә инде язучы бик пассив. Минә аның агышы: бу йортларны сүтәләр инде, әмма аларны фоторәсемгә яисә фототасмага төшереп алу булдымы икән, юкмы икән? Моның өчен җаваплы берәр оешма бармы икән, әллә уйлаган кеше дә юкмы икән?

Бу, чыннан да, кыюсызлык, тешсезлек. Шундый сораулар борчый икән, ачыклыйсы килә икән, язучының бөтен халыкка билгеле абруе бар, кесәдә олы мандаты — язучылар союзы биргән билеты бар, ул иң югары җитәкчегә кадәр менеп җитеп, тикшерә, мәсьәләнең очына чыга ала. «По городам и весям» дигән китабы өчен Дәүләт премиясенә лаек булган Владимир Чивилихин болай ди: «Минем бурычым укучы алдына негатив фактларны өеп куеп, аңа үземнең кырылган кәефемне көчләп тагу һәм аны өметсезлектә калдырудан тормый. Кешеләр арасында күптән инде өлгереп килгән конкрет тәкъдимнәр әйтергә телим...»

Бурычны нәкъ менә шулай кую, ягъни мәсьәләне кузгатып кына калмыйча, аны җиренә җиткерү кирәк. Җентекләбрәк караганда, моның өчен мөмкинлекләр язмаларның үзләрендә үк ялтырап-ялтырап киткәнен күрәсең. К. Тимбикованың «Кара юрга»очеркында, мәсәлән, («Казан утлары», 1977 ел, 2 сан) колхоз председателе үзенең көндәлек мәшәкатьләре арасында бүгенге техникага ныграк игътибар бирә. Аның инде бу хакта кайбер күзәтүләре, фикерләре дә бар, шуларны уртаклашырга университет галимнәренә дә мөрәҗәгать итә. Кыскасы, язмада заман рухына туры килгән, күпләрне кызыксындырган, аннан да бигрәк, әле язучылар кулы тимәгән, «фән-техника революциясе чорында колхоз председателе» дигән проблема бөреләнгән.

Х. Хәйруллинның «Бригадир Зөфәр» (Казан утлары», 1977 ел, 10 сан), Ә. Маликовның «Мәйдан тоту» («Казан утлары», 1977 ел, 9 сан) һәм башка язмаларда да мондый «бөреләр» күренә. Тик аларны чәчәк, җимеш итәр өчен очеркистларга портретлык чиреннән котылырга, моның өчен трамвай юлыннан төшеп, бормалы-бормалы үз юлларын салырга кирәк.

Шулай кирәк икәнен иптәшләр үзләре дә белә. Ә. Маликов 1975 елда ук әле: «Очерк жанрына бүгенге көннең актуаль проблемаларын күтәрү миссиясе йөкләтелгән» — дип язган иде, нефтьчеләр тормышындагы җитди-җитди проблемаларны санап күрсәткән иде. («Социалистик Татарстан», 19 сентябрь, 1975 ел) «Социалистик Татарстан» оештырган «түгәрәк өстәл» янында Аяз Гыйләҗев тә: «Безнең публицистлар авылдагы проблемаларны корыч каләм белән ачып салу урынына, күбрәк өстә яткан күренешләр белән мавыгалар кимчелекләрне майлы канат белән генә сыйпап узалар. Күбесенең үз проблемасы, үз карашы юк» («Социалистик Татарстан», 13 август, 1970 ел), — дип сөйләде.

Кирәк икәнен беләбез, кайнарланып-кайнарланып сөйлибез, ә менә үзебез төпкә җигелеп күтәрергә ашыкмыйбыз. «Казан утлары» журналының узган елгы алты санын тикшергән җыелышта очерклар турында сөйләгән Җәмит Рәхимов болай дигән иде: «... байтак кына танылган язучыларыбызның очерк жанрына вак эш, икенчел эш, талантсызлар шөгыле диебрәк карауларын әйтмичә булмый. Болай диярга тулы нигез бар. Русның һәм башка милләтләрнең Марков, Сартаков, Залыгин, Кожевников, Лагунов, Шесталов, Рытхэу кебек язучылары нәфис публицистика өлкәсендә җиң сызганып эшләгән бер заманда ни өчен соң безнең прозаны җилкәләрендә алып бара торган язучыларыбыз очеркка кырын карыйлар икән? Габдрахман Әпсәләмов, Фатих Хөсни, Мирсәй Әмир, Афзал Шамов кебек аксакалларга тел тидермик, аларга инде колхоз һәм совхозларга, олы төзелешләргә чыгып йөрүе кыендыр. Соң нигә Нурихан, Фәттах, Аяз Гыйләҗев, Әхсән Баянов, Рафаил Төхфәтуллин, Вакыйф Нуруллин, Мөсәгыйть Хәбибуллин һ. б. талантлы прозаикларга, менә болай язалар аны, егетләр, дип елына бер-икешәр очерк бирмәскә?!» («Социалистик Татарстан», 11 октябрь, 1973 ел).

Әлбәттә, бу юнәлештә каләмнәрен сынап караган язучы публицистларыбыз юк түгел. Г. Бәширов, С. Хәким, Э. Касыймов, Җ. Рәхимов, Равил Вәлиев, журналистлардан М. Рафиков һәм башкалар проблемалы публицистикада шактый актив эшлиләр. 1977 елда Татарстан китап нәшриятында Ш. Бикчуринның «Алтын җирдә ятмый» исемле бөтен бер очерклар җыентыгы басылып чыкты. «Социалистик Татарстан» газетасында язган рецензиясендә Ф. Әгъзәмов очеркларны сәнгатьчә оста

язылганнар, шуңа күрә дә алар озын гомерлеләр, дип югары бәяләде. («Социалистик Татарстан», 21 август, 1977 ел). Аның белән тулысынча килешеп, бер генә фикер өстисе килә: очеркны озын гомерле иткән төп шартларның янә берсе — аның тимерне кызуында сугып мөһим эшләр, вакыйгалар турында нәкъ үз көнендә, үз сәгатендә язылуында.

Гомумән алганда, публицистиканың гомере кыска. Мин аны яктырткыч ракета гомеренә тиңләр идем — балкып ала да сүнә. Әмма шушы бер мизгел эчендә ул кешеләрне айнытып җибәрә, алга өнди, хәрәкәткә китерә, барасы юлларын яктыртып калдыра. Нәкъ кирәкле минутта кабынган ракета яктысын кешеләр озак еллар үткәч тә искә төшерәләр.

Уңышлы әсәрләрне санаганда, мин ике әсәрне аерып калдырдым: Г. Бәшировның «Сөендек матур яши» («Социалистик Татарстан», 4 август, 1977 ел) һәм М. Зариповның «Моңлы Казан, нурлы Казан» («Казан утлары», 1977 ел, 12 сан) очеркларын. Бүгенге очерклар шундый булырга тиеш диясем килә. Аларда чорның актуаль проблемалары авторның үз катнашында, аның актив уй-хисләре аркылы фәлсәфи тирәнлек белән, кешеләр язмышыннан аерылгысыз рәвештә, сәнгатьчә ачыла. Аларда без аерым геройларның гына түгел, ә бөтен бер коллективларның, аерым проблемаларны гына түгел, ә бөтен бер проблемалар комплексын хәл иткәндә образ дәрәҗәсенә үсүен күрәбез. Әмма аңа карап очеркның аңлаешлылыгына зыян килми. Бүгенге укучының яшәү рәвеше, белеме, интеллекты нәкъ шуны таләп итә дә.

Өстәвенә, бу ике язучы мисалында публицистикабыз үсешенең ике төп юнәлеше дә төсмерләнә кебек. Беренчедән, Г. Бәширов, Ғ. Әпсәләмов, М. Әмир, С. Хәким, Г. Ахунов, Б. Камалов, Ш. Бикчурин кебек язучыларыбыз роман-повесть язып ятканда да тормыштан бер көнгә дә аерылмаслар, публицистиканы алга җилдерүче ракетаның ышанычлы бер буыны булырлар — моңа шикләнмәскә мөмкин. Узган ел мин Ленинградта Мариэтта Шагинян белән очрашу шатлыгын кичердем. Ул моннан илле ел элек Ленинград тукучылары турында очерклар язган булган. Хәзер совет тукучыларының бүгенге казанышлары белән кызыксынып, ул шулар эзеннән яңа сәяхәткә чыккан. Туксан яшьлек язучыбызның үзенең гомерлек жанры очеркка тугры булып калуы сокландыра. 1977 елда аның «Очерки разных лет» исемле китабы басылып чыкты. Дулкынланмыйча укуы мөмкин түгел. Китапка кереш сүзендә Мариэтта Сергиевна болай яза: «Очеркистларыбызның күпчелеге, минем кебек үк яңа социалистик җәмгыять төзүнең һәм аның материаль базасын булдыруның барлык этапларында турыдан-туры катнаштылар. Безнең очерклар буенча матбугатта ведомство җитәкчеләре чыгыш ясадылар, министрлыкларның коллегияләрен җыйдылар, инде кабул ителгән карарлар кире кагылды». Их, еллар үткәч, без дә менә шулай дип яза алсак икән!

Публицистиканы үстерүнең икенче юнәлеше — аның үз солдатлары булырга тиеш. Марсель Зарипов кебек. Ни әйтсәң дә, роман, повесть язучы кеше очеркны үзенең төп эше арасында гына яза. И. Газиның «очерк ул разведка» дигәне менә шуларга кагыла. Төп әсәрен язарга тотынгач, алар үзләренең разведчик икәнен онытып торалар, һәм моның өчен аларны гаепләп тә булмый.

Ләкин, тулаем алганда, әдәбиятта разведканың бер генә минутка да онытылып торырга хакы юк. Олы армияләрдә махсус разведка подразделениеләре була. Рус совет әдәбиятының андый разведчиклары Овечкин, Атаров, Радов, Аграновскийларны бөтен дөнья белә.

Аянычка каршы, бездә публицистларның менә шундый отрядын тәрбияләү эше моңарчы җайга салынмаган иде. Язучылар союзы идарәсенең публицистика һәм очерк секциясен оештырып җибәрүе мактауга лаек. Секция алдында хәзер зур, җаваплы бурычлар тора. Аның эшенә тәҗрибәле язучыларны тартырга кирәк. Ә яшь очеркистларны тырышып эзләргә, табарга, үстерергә, ә булганнарының кадерен белергә кирәк.

Ниһаять, публицистиканың үз тәнкыйтенә дә кыюрак һәм остарак булырга вакыттыр. Аның нигезе салынган, стенасын өярлек белгечләре дә бар. Әйтик, Ф. Әгъзәмовның публицистикага шактый өлеш керткән «Яшәү көче» дигән китабы чыкты

(Татарстан китап нәшрияты, 1977 ел). Р. Мостафинның «Сүз ялкыны йөрәктән генә» («Социалистик Татарстан», 12 июнь, 1977 ел), Б. Камаловның «Очеркларыбыз турында» («Социалистик Татарстан», 22 декабрь, 1977 ел), Җ. Рәхимовның «Публицистикага — киң колач» («Социалистик Татарстан», 11 октябрь, 1978 ел) чыгышлары басылды. Гәрчә теориягә бик үк тирән төшмәсәләр дә, бүгенге публицистикага үз вакытында күзәтү ясарга тырышулары белән бу хезмәтләр әһәмиятле булдылар.

Ләкин публицистиканың өлгереп җиткән күп кенә мәсьәләләре әле теориядән дә, агымдагы тәнкыйтьтән дә читтә кала килә. Очерк — үсештә, дибез икән, аның тенденцияләрен ачыклап бару бик мөһим. Соңгы ике елда гына да Г. Ахуновның очерк-репортажын, Ш. Рәкыйповның очерк-сценариен, М. Хөсәеннең очерк-памфлетын укыдык. Х. Зарипов очерк-диалоглар язуда үзен сыный. Димәк, форма турында да да уртага салып сөйләшергә вакыт җиткән; публицистиканың тел-стиль үзенчәлекләре дә тәмам ачыклауны көтә; радио-телевидение публицистикасына килсәк, үзе бер чытырман.

Публицистика алдына куелган таләпләр — заман таләпләре ул. В. И. Ленинның публицистикага биргән билгеләмәсе бүген дә үз көчендә. Тик без ул билгеләмәнең башта-ы өлешен ешрак кабатлыйбыз, публицистика ул — тарих язу дибез. Ә юлбашчының төп фикере билгеләмәнең азаккы өлешендә. «Аны шундый итеп язарга тиешбез,— ди В. И. Ленин,— безнең тарих язмабыз анда, вакыйгалар барган җирдә, хәрәкәттә турыдан-туры катнашучыларга һәм герой-пролетарийларга хәл кадәренчә ярдәм итәрлек булсын, шундый итеп язарга тиешбез ки, ул хәрәкәтнең киңәюенә, көрәшнең аз көч түгеп, иң зур һәм иң нык нәтиҗәләр бирерлек чараларын, алымнарын һәм методларын аңлы рәвештә сайлап алырга ярдәм итсен». (В. И. Ленин. Әсәрләр, 4 басмадан тәрҗемә, 8 том, 88 бит.)

Бүген дә публицистика коммунизм төзү бурычларын хәл итүдә партиягә, халыкка нәкъ менә шулай булышырга тиеш. Публицистика — әдәбиятның киләчәге. Ул бүген чәчәк ата икән, аның иртәгәсе җимешләре — хикәя, повесть, роман, поэмалар.

Рафаэль Хәкимов

# ӘДӘБИЯТЫБЫЗДА ИНТЕРНАЦИОНАЛИЗМ ИДЕЯЛӘРЕ

Социаль чынбарлык һәм тормыш-көнкүрештәге уртаклыклар элек-электән Россиядә яшәүче төрле милләт вәкилләренең, бигрәк тә рус һәм татар халыкларының рухи омтылышлары уртаклыгына нигез булып килгән. Әйтик, Степан Разин һәм Емельян Пугачев кул астында башка милләт крестьяннары белән бергә татарлар да сугыша. Аларның теләк һәм омтылышлары халык җырларында, бәетләрдә чагылыш таба.

> Пугачев патшаны күрсә идең,
> Алларыннан буй бөгеп узса идең.
> Аргамак менеп, дан тотып,
> Җаек яуларында йөрсә идең,

— диелә «Пугачев турында»гы җырда.

Ике яшь йөрәкнең бер-берсенә мәхәббәте турындагы җырлар һәм бәетләр аеруча тәэсирле, дулкынландыргыч булулары белән аерылып торалар. «Хәернисә бәете»ндә, мәсәлән, татар егетенең рус кызы Марусяга (аңа Хәерниса дип яңа исем кушалар) булган мәхәббәте сурәтләнә.

Бәеттә әйтелгәнчә, егет һәм кызның фаҗигалы язмышы өчен кайгырып (алар кавыша алмый!), кешеләр кайнар күз яшьләрен түгәләр.

Мондый әсәрләр халык аңында акрынлап интернационализм яралгылары барлыкка килүгә нигез була. Халыклар дуслыгы мәсьәләләре, рус культурасы һәм рус телен өйрәнүнең кирәклеге турында XIX йөз татар мәгърифәтчеләре дә ачыктан-ачык белдерәләр.

Татар халкының интернационалистик аңы үсешендәге яңа чор пролетар хәрәкәт, Идел буенда яшәүче халыклар арасында киң эш җәелдергән большевиклар эшчәнлеге белән аерылгысыз бәйләнгән. РСДРПның Казан комитеты җитәкчелегендә Хөсәен Ямашев, Гафур Колахметов, Мулланур Вахитов шикелле күренекле революционер-большевиклар үсеп чыга. Алар әдәби хәрәкәткә якын торалар һәм Г. Тукай, Г. Камал, Ф. Әмирхан, М. Гафури, Г. Ибраһимов кебек язучыларның идея үсешенә уңай йогынты ясыйлар.

1905 елгы Беренче рус революциясе татар халкының барлык катламнарын хәрәкәткә китерә. Татар телендә күп санлы газета-журналлар чыга башлый, театр барлыкка килә, халыкның культура үсеше өчен яңа шартлар туа. Пролетар интернационализм идеяләре аның иң түбән, артта калган катламнарына да үтеп керә. Россия халыклары көрәшенең интернациональләшү перспективасыннан курыккан татар буржуазиясе бө-

тен көчен куеп милләтчелек идеяләрен пропагандалый, революциядән котылу юлын шуннан эзли. Бу болганчык дулкын алдынгы карашлы кайбер язучыларга да тәэсир итә — реакция елларында М. Гафури, мәсәлән, мөселман бердәмлеге һәм төрек милләте идеяләре белән сугарылган шигырь яза. Ләкин революция елларында инде ул әсәрләрендә азатлык байрагын шатланып алкышлый. Вакытлы ялгышлыкларыннан арынуга аңа большевиклар ярдәмгә килә.

Г. Тукай үз иҗатында милләтчеләрне аеруча аяусыз камчылый. Ф. Әмирхан да алардан ачы көлә. Алдынгы карашлы әдипләр татар милләтенең киләчәк язмышын, гомумән, тар милләтчелек һәм исламчылык кысалары белән чикләмиләр. Реакциянең котырынуына да карамастан, ул елларда рус һәм дөнья әдәбияты белән кызыксыну тагын да көчәя бара. Язучылар, милләтчеләргә капма-каршы буларак, халыклар дуслыгы идеяләрен яклап чыгалар. «Олуг юбилей мөнәсәбәте белән халык өмидләре» шигырендә Г. Тукай:

**— Һич бетәрме тарихи бу бергәлек! —**
**Без туган бер җепкә бергә теркәлеп,**

— дип яза.

Әмма милли чикләнгәнлеккә каршы көрәш гаять авыр шартларда бара һәм ул кешеләрнең аңы формалашуында да ачык гәүдәләнә. Моның чагылышын без матур әдәбиятта да күрәбез. Ф. Әмирханның 1911 елда язылган «Хәят» повестенда сәүдәгәр гаиләсендә туып-үскән татар кызы һәм рус студенты Михаилның бер-берсенә гыйшкы тасвирлана. Ихлас хисләр белән янган Михаил үзенең хатында Хәяткә болай дип яза: «Сез, бәлки, мине рус булганга күрә үзегезгә муафыйк күрмәссез, ләкин, дусксэм, сөю дигән нәрсә милләт аермаларын белми торган көчле нәрсә икән ул. Мин аны татып белдем. Минем бәхетем хәзер сезнең кулда, шуңа күрә мин сездән бер хөкем көтәм». Әмма Хәят «тормышны ике төрлегә аера: мөселман тормышы — монысы үзләренекечә булырга тиешле; рус тормышы — монысы Мясниковларныкыча булырга кирәк дип ышана иде... Аларның бер-берсенә кушылып, үрелеп китүләреннән курка, икесен йөрәгенең ике почмагына яшереп, араларына калын бер пәрдә корып куя». Патриархаль традицияләрдә тәрбияләнгән кыз үзенең күңелендә туган якты хисләр өчен көрәшергә көч таба алмый; дини хорафатларга һәм гасырлар буена сакланып килгән йолаларга буйсынып, бөтенләй таныш булмаган кешегә тормышка чыгарга мәҗбүр була.

Октябрь революциясе халыклар дуслыгының ныгуы өчен бөтен шартларны тудырды. Милләтләр арасындагы яңа мөнәсәбәтләр, пролетар интернационализм рухы революцион көрәш һәм гражданнар сугышы утында чыныкты. Шуның белән бергә тан татар әдәбияты төрле төркемнәргә бүленү чоры кичерде. Ачуларына чыдаша алмаган милләтчеләр, азатлык татар әдәбиятына файда түгел, зарар китерде, дип расларга маташтылар. «Болак арты республикасы» һәм «Башкортстан автономиясе» дип аталган нәрсәләр уңышсызлыкка очраганнан соң аларның кайберләре «Идел — Урал штатлары»н яклап көрәшү өчен Берлинга, Варшава, Париж, Әнкара һәм Истамбулга сыздылар.

Язучыларның күпчелеге исә социализмны яклап халык белән бер сафтан атлады. Мәсәлән, Г. Ибраһимов Бөтенроссия Үзәк Башкарма Комитеты члены итеп сайлана һәм Үзәк Мөселман комиссариаты председателе урынбасары итеп билгеләнә. Аның турыдан-туры катнашында милләтчеләргә каршы күп кенә чаралар уздырыла. Вакытлы матбугат битләрендә, шул җөмләдән «Чулпан» газетасында, ул әледән-әле чыгышлар да ясап килә.

Кызыл Армия күп санлы яшь язучылар өчен менә дигән интернационализм мәктәбе булды. Шамил Усманов, Мәхмүд Максуд, Афзал Шамов, Кави Нәҗми, Муса Җәлил, Фәтхи Бурнаш һәм башкалар әдәбиятка турыдан-туры, төрле милләт хезмәт ияләре белән иңгә-иң көрәшкән утлы яу кырыннан килделәр. Революция һәм гражданнар сугышы татар совет әдәбиятының төп темасына әверелде.

Әмма НЭП чорында Татарстанда милләтчелек элементлары активлаша, вак буржуазия яңадан баш калкыта. Шуңа күрә дә алдынгы карашлы әдипләрнең әсәрләрендә милләтчелек идеяләре кискен рәвештә кире кагыла. «Җавап» пьесасында Г. Кутуй, гражданнар сугышы герое коммунист Нургали Хановны үтереп, аның документларын үзләштергән кулак малаен сурәтли. Ул партия оешмасы секретаре булып ала, эчке

контрреволюция — кулак Хисамый, аның иярчене Дәүли, буржуаз милләтче Сәйфуллин һәм Каһиров белән элемтәгә керә. Дошман явыз һәм көчле. Ул үч алырга, үткәнне кире кайтарырга омтыла. Ләкин эшче-комсомолец, үз тормышын куркыныч астына куеп, аларны фаш итә.

Бу чорда, бетүгә хөкем ителгән күренеш буларак, милләтчелек бигрәк тә сатирик образларда киң чагылыш таба. К. Тинчуринның «Җилкәнсезләр» комедиясендә милләтче Батырхан тамашачы алдында көлкегә кала. Ш. Камалның «Таң атканда» романында бөтен Россияне революция ялкыны чолгап алган бер вакытта социалистик идеяләрнең зарары турында туктаусыз сафсата сатучы милләтче «эшлекленәр»нең чын йөзләре фаш ителә. «Шәмсетдин бай» повестенда Ш. Усманов милләтче ак эмигрантларның тормышка ашмаслык хыялларыннан көлә.

Әмма бу көрәштә классик мираска һәм «юлаучылар», «эчке эмигрантлар» дип аталган язучылар өстенә анархистларча ташлану кебек суллык күренешләре дә булды. Г. Камал, Ш. Камал, Ф. Әмирхан, һ. Такташ, Ф. Бурнаш нигезсез ээрлекләүләргә дучар ителделәр. Ф. Бурнашның иҗаты, мәсәлән, реакцион иҗат, ә ул үзе эре буржуазия хезмәтчесе дип характерланды. Вульгар социологлар, әсәрләрендә буржуаз-милләтчелек идеологиясенең «типик сыйфатларын» чокып табарга тырышып, Г. Тукай иҗатын кире кагарга маташтылар. Күп кенә язучылар һәм культура эшлекленәре милли культураларның кичекмәстән «кушылу»ын таләп иттеләр. Алар пролеткультчыларның «милли чикләнгәнлек»не тиз арада ерып чыгарга һәм тулысынча сыйнфый нигездә экстерриториаль культура төзергә дигән карашларын чагылдырдылар. Бу ялгыш тенденцияләрдән арынырга Ленин хезмәтләрен өйрәнү һәм М. Горькийның татар язучылары белән булган әңгәмәсе ярдәм итте. Үткәндәге әдәбиятның казанышларын тану, татар культурасының гомумсовет культурасында тоткан урынын ачык билгеләү бай милли традицияләрнең прогрессив элементларын саклап калырга мөмкинлек бирде.

Шуның белән бергә утызынчы елларда татар язучыларының тормышны күзаллау дәрәҗәсе үсте, күп милләтле совет әдәбияты белән танышлыклары, элемтәләре ныгыды һәм тирәнәйде. 1929 елның җәендә Татарстан язучылары Горький инициативасы белән Дагстан, Әзербәйҗан, Грузия һәм Украина буйлап сәяхәт оештыралар. Анда Ш. Камал, һ. Такташ, К. Тинчурин, Г. Кутуй, К. Нәҗми, М. Әмир һәм башка язучылар катнаша. Бу сәяхәт татар язучыларына интернациональ элемтәләрне ныгытырга, илдә барган үзгәрешләрне тирәнрәк аңларга ярдәм итә.

Утызынчы елларда татар язучылары, узган көннәрнең истәлекле вакыйгаларына яңадан борылып кайтып, гражданнар сугышы темасын яктыртуны дәвам иттерәләр. Т. Гыйззәт «Бишбүләк» драмасын, Г. Бәширов «Сиваш» повестен яза. Китап битләрендә инде поход юлларыннан төрле милләт сугышчылары кулга-кул тотынышып атлыйлар.

Г. Бәширов укучыларны Казанда оешкан һәм үзе аның гади солдаты булып хезмәт иткән унбишенче Инза дивизиясе сугышчылары белән таныштыра. Әсәрдә без яшь сугышчы Шәмси, аның тәҗрибәле өлкән иптәше Вәлитов, рота командиры Пахомов, политрук Исмаев, украинлы Перебейнос, белорус Басило, чуваш Митька, руслар Данилов, Борисов һәм башкалар белән очрашабыз. Алар барысы да 1920 елның салкын көзендә, кыска вакытлы привалга туктаган араларда шакраеп каткан арыш икмәген бөкәнгә куеп, балта белән вата-вата ашаганда бары тик бер генә нәрсә — кышка кадәр ничек тә Врангельны дөмектерү турында уйлыйлар. Авыр сугышлар һәм поход юллары, коралдаш дусларны югалту кайгылары, җиңүнең якынлыгын тою шатлыгы кешеләрне чыныктыра, аларда теләктәшлек, бердәмлек хисләрен тудыра һәм ныгыта.

Ш. Усмановның «Легион юлы» әсәрендә интернациональ полкларның данлы көрәше тасвирлана. Аклар белән ике арада булып узган аяусыз сугышлар, чигенү газаплары һәм ерак Төркестанда чиксез авырлыклар бәрабәренә ирешелгән җиңү — әсәрдә болар бернинди купшы бизәкләрсез, ялган романтик буяуларсыз күрсәтелгән. Әсәрнең төп герое — татар, рус, венгр һәм немец ирекленәреннән торган революцион масса. Аның составында төрекләр, әфганнар, казакълар, башкортлар, үзбәкләр һәм башка милләт вәкилләре дә бар. Алар өчен бернинди кургаш яңгыры да, казакларның еракка ата торган пушкалары да, Тургай даласының җиргә төкрек төшмәслек салкыннары да куркыныч түгел.

Халыкара теләктәшлек хисләре татар шигыренә дә үтеп керә. Баш калкытып килгән фашизмга каршы көрәш темасына мөрәҗәгать итү аңа аеруча көчле яңгыраш бирә. Бу тема Ә. Исхакның «Батырның үлеме», Г. Хуҗиевның «Хасан күле», Ф. Кәримнең «Аникин» поэмаларында чагыла. Ф. Кәрим ике дус — чик сакчылары Галим белән Михаил Аникин, аларның ил чиген үтеп кергән дошманга каршы ничек сугышулары турында сөйли.

Интернационализм идеяләре һәм рухы белән өртелгән әсәрләргә мисал итеп Г. Кутуйның «Тапшырылмаган хатлар» повестен китерергә мөмкин. Аның төп геройлары: Галия, Искәндәр, Вәли — болар бөтенесе дә бер милләт кешеләре. Әмма әсәрдә Галиянең иптәш кызы Лиза турында телгә алынып үтелә, партоешма секретаре Николаев күз алдыбызга килеп баса, пионерка А. И. Мойкина, революционерка Ольга Делевская һәм 1920 елда Одесса шәһәрендә аклар тарафыннан үтерелгән Д. Любарская хатлары китерелә. Галия совет кешеләре мәнфәгатьләре белән яши, аның уйлары һәм тормышы шул еллардагы күпчелек хатын-кызлар өчен типик күренеш. Совет халкының бердәмлегә Галиянең Ватан турында уйлануларында үзенең ачык гәүдәләнешен таба. Радио аша Шуберт симфониясен тыңлаганда ул туган иленә мөрәҗәгать итеп болай ди: «Шатлыклы туган илем! Шуберт, Бетховен шикелле композиторларның иң тирән моңнарын ерак авылларга ишеттерүең өчен сиңа җылы рәхмәт яусын».

Татар язучыларының әсәрләрендә интернационализмның көннән-көн көчләрәк гәүдәләнүе гадәти күренешкә әйләнә, ә милләтчелек кизәнешләре узган заман күренеше булып кала. Хәзер инде игътибар үзәгендә милләтләрнең үзара якынаюы, төрле культураларның бер-берләренә йогынтысы, халыкара хезмәттәшлек көчәюе тора.

Бөек Ватан сугышы исә халыклар дуслыгы мәсьәләсен көн тәртибенә аеруча кискен итеп куйды. Бу чорда әдәбият Ватанга бирелгәнлек хисен тагын да көчәйтә торган, барлык совет кешеләрендә җиңүгә булган ышанычны арттыра, дошманга карата тирән үч һәм нәфрәт тойгысы тәрбияли торган куәтле көчкә әверелде. Барлык совет халкы белән бергә язучылар да кулларына корал һәм каләм тотып изге сугышка күтәрелделәр. «Без — руслар, украинлылар, татарлар, белоруслар — корыч таулар тезмәсе булып, сине якларга килдек», — дип язды Г. Кутуй «Без — сталинградчылар!» нәсерендә.

Бу елларда интернациональлек дигән төшенчәнең мәгънәсе киңәя һәм тирәнәя. Иң беренче чиратта Ватан темасы яңача яңгырый башлый. «Мин үз илемнең борынгы Иделен, тын Донын, якты Арагвасын, шигъри Дим буйларын сагынам» — дип яза әсәрләренең берсендә Г. Кутуй.

М. Җәлилнең кайгы-әрнүләре, көенү-ачынулары, өмет-хыяллары да киң туган илгә юнәлгән. Ул барлык көчен төрле легионнар оештырып, совет әсирләрен милли нигездә бер-берсенә каршы куярга маташкан гитлерчыларны фаш итүгә бирә, иҗатын интернационализм рухы белән сугара.

Рәхим Саттар Берлинда чыгып килгән «Идел — Урал» редакциясенең әдәби хезмәткәре буларак, газетаны зыянсыз, төссез, хәтта немец пропагандасы өчен зарарлы органга әверелдерүгә булышты. «Булачак» «Идел — Урал» дәүләтенең «булачак» президенты Шәфи Алмаз Р. Саттар һәм А. Алиш өстеннән язган доносында болай ди: «Бу елның мартында большевиклар немецларга әсир төшкән татар милләтеннән булган Кызыл Армия сугышчыларына Россияне сакларга чакырып мөрәҗәгать иттеләр. Алар аны уртак Ватан дип атыйлар. Бу чакыруда татар шагыйре Тукайның руслар белән татарлар бердәмлеген мактап җырлаган шигыре искә алына. Нәкъ шушы вакытта Саттаров «Идел — Урал» газетасы өчен мәкалә язды. Анда ул рус һәм татар халыкларының бердәмлеге, мәнфәгатьләр уртаклыгы идеясен чагылдырды һәм әлеге шигырьне хәрефкә хәреф саклап калдырды...»

Җәлилчеләр иң каты цензура шартларында, гитлерчыларның үз өнендә дә интернационализмга тугрылыклы калдылар. Әлбәттә, бу союзга каршы чыкканда газета кинаяләп сөйләргә мәҗбүр иде. Шәфи Алмаз А. Алишның төрле милләт хәрби әсирләрен «уртак дошман»га каршы берләшергә чакырган мәкаләсен искә алмый. Газетаны укучылар исә мәкаләдә нинди дошман күздә тотылганлыкны бик яхшы аңлыйлар.

Фашистлар тылында әдәбият көчле коралга әверелә. Ул кешеләрне рухландыра һәм берләштерә. Җәлилнең камерадаш иптәше Андре Тиммерманска багышланган «Бүләгем» шигырендә мондый юллар бар:

**Үзем үлсәм, исмем, җырым үлмәс,**
**Ул яңгырар илнең кырында,**
**Сөйләп илгә тоткын күңелләрдә**
**Чәчәк аткан дуслык турында.**

Халыкларның бердәм көрәшен, һаман үсә, ныгый барган дуслыгын данлау сугыштан соңгы елларда да бөтен көченә яңгыравын дәвам итте. Моны раслау өчен Г. Әпсәләмовның «Ак төннәр» повестен, «Алтын йолдыз» романын, Ә. Еники повестьларын, С. Хәкимнең «Курск дугасы» поэмасын санап узу да җитә. Аларда халыкларның уртак көрәше темасы белән бергә, интернационализм идеяләре киң яктыртылган. Мәсәлән, Г. Әпсәләмовның «Мәңгелек кеше» романында немец антифашистларының калку образлары бирелгән. Фашизмга булган нәфрәт патриот сугышчыларны немецлар арасында да дусны дошманнан аера белергә өйрәтте. Фашизм тәмам җиңелгәнчегә кадәр үк совет кешеләре Гете һәм Бетховен, Шиллер һәм Гейне, Маркс һәм Тельман Германиясе дә барлыгын хәтердән чыгармады. 1943 елның азагында Моабит төрмәсендә М. Җәлил:

**Борыгыз муйнын комсыз карчыганың,**
**Кояш чыксын Алман җиренә.**
**Күтәрелсен Тельман трибунага,**
**Маркс, Гейне кайтсын иленә,**

— дип язды.

Бу мәсьәлә җиңү якынлашкан көннәрдә, Германиянең киләчәге проблемасы алга куелгач бөтен тулылыгы белән күтәрелде. Г. Әпсәләмовның «Мәңгелек кеше» романында совет, немец, чех, француз һәм башка милләт антифашистларының Бухенвальдтагы көрәше тасвирлана. Әсәрнең төп герое подполковник Бакый Назыймов, әсирлектән качарга омтылулары барып чыкмагач, концлагерьдагы «Рус хәрби-политик үзәге» белән элемтәгә керә. Бакыйның дусты, подполье заданиесе буенча лагерьдагы балаларның тормышын яхшыртуга, хәтта аларны укытуны оештыруга ирешкән Задонов, «Рус үзәге»нең җитәкчесе Симагин һәм башка совет кешеләренең образлары белән янәшәдә немец антифашистларының үзәк персонажлары Ганс, Отто, Бруно, чех Йозеф, «Интернациональ үзәк» җитәкчесе Вальтер образлары гәүдәләндерелгән. Тыгыз элемтәдә бергә эшләү, пролетар бердәмлек концлагерьда восстаниенең җиңүенә китерә.

Бер кешелек камерада алты ел утырган тарих укытучысы карт Ганс образы аеруча дулкынландыргыч итеп сурәтләнгән. Ул Бухенвальдка килеп эләгә. Анда кайчандыр ябалдашын киң җәеп үскән карт имән төбендә Гете үзенең «Фауст»ын язган, Шиллер иҗат иткән, Бах һәм Листның тылсымлы көйләре яңгыраган. Концлагерьга кергәндә Ганс пышылдап кына әйтә: «О, изге җирләр! О, Шиллер һәм Гете ватаны! Үләр алдыннан бу почмакны күрүемә мин шатмын!» Ватаны, халкы өчен әрнү хисе аның йөрәген телгәли. Ул һәр вакыт совет кешеләре белән дуслыкны яклап чыга, алар яңа Германия өчен көрәшүчеләрнең булуын белми калырлар дип ачыргалана. Аның Бакыйга төбәп әйткән соңгы сүзләре дә шул хакта: «Хуш, дустым. Әгәр исән калсаң, онытма: нацизм һәм немец халкы — бер үк нәрсә түгел...» Немец антифашистлары белән бердәмлек символы буларак, немец эшчеләр сыйныфы юлбашчысы Э. Тельман үлеме уңае белән Бухенвальдта тоткыннарның матәм митингысы уздырыла.

Марс Шабаевның «Җирән Конрад» поэмасы немец теле укытучысы, «чын немец» турында. Балалар аны фашист, «Җирән бүре» дип йөртәләр. Аннары ул «Җирән Конрад»ка, ә соңрак Конрадка әйләнә. Немецка балаларның ышанычын яулау бик авыр була.

Миллилекне һәм интернациональлекне берләштерү мисалы буларак Г. Әпсәләмовның «Газинур» романы да игътибарга лаек. Газинур образы милли сыйфатлар белән бизәп бирелгән. Алар аның үзенчәлекле сөйләмендә, мәзәкләрендә, үз-үзен тотышында, Бөгелмә ягындагы туган авылын сагынуларында күренә. Шул ук вакытта Га-

зинур образы барлык совет кешеләренә аңлаешлы образ, аның батыр йөрәге барлык совет кешеләренең уй-фикерләренә авараздаш тибә. Татар егете рус солдаты ясаган батырлыкны кабатлый. Бу образда һәм әлеге батырлыкта төрле милләт кешеләренең уртак асылы чагыла. Романда Газинур шәхесенең калыплануы совет чынбарлыгының тирәнәя барган интернациональләшүе нәтиҗәсе буларак күз алдына килеп баса.

Сугыштан соңгы елларда интернационализмны киң тарихи материалда күрсәткән зур күләмле байтак әсәрләр дөнья күрде. К. Нәҗминең «Язгы җилләр» романы, И. Газиның «Онытылмас еллар» трилогиясе, А. Расихның «Дустым Мансур» повесте Казан губернасындагы татарларның һәм русларның революцион көрәшен тасвирлый. «Язгы җилләр»нең прологында Сәүбән әйткән сүзләр бик мөһим: Рус мужигы булды ни дә, ди ул, татар булды ни, аерма юк. Икесенә дә җир кирәк. К. Нәҗми, элек томана булган кешеләрдә аң уянуын һәм үсүен, революцион көрәштә интернациональ бердәмлекнең массалар тереге булып әверелүен күрсәтә.

К. Нәҗми романы идеясен И. Газиның «Онытылмас еллар» трилогиясе тагын да тирәнәйтеп сурәтләде. Аның төп темасы — крестьяннарның социалистик революциягә килүе. Коммунист Якубның, авыл ярлысы Миңнулланың, яшүсмер Хәлимнең һәм башкаларның язмышы киң социаль-политик планда күрсәтелгән. Әсәрдә ике дус чекистның — крестьян егете Гыйльметдин белән анархистларга хас холыклы Федюшкин образлары зур урын алып тора. Гыйльметдин русча көч-хәл белән генә аңлаша. Ул хәтта Федюшкинның исемен дә Анатолий дип түгел, Тула дип йөртә. Әмма дуслык тел һәм милли киртәләрне белми, уртак дошманга каршы көчләрне тупларга кирәккәндә, максатлар бер булганда күңелләр бердәмлеге җиңә. Аларны бары тик бандит пулясы гына аера.

Трилогиянең икенче кисәгендә автор милләтчеләрдән Дәүләтъяров, Курманаев, Халит Җамали образларын бирә. Дәүләтъяров Керенский һәм акчехлар белән бергә булган, ә хәзер автономия биргән большевиклар ярдәме белән, коммунистлар партиясе исеменнән, руслар һәм татарлар арасында ызгыш политикасын уздырырга маташа. Ләкин аның бу мәкерле уйларын тормыш үзе кире кага. И. Гази күләмле материалда кешеләрнең «үз» мөселманнары арасындагы дошманнарны һәм руслар арасындагы дусларны аерырга өйрәнүләрен күрсәтә. Гади халыкның азык-төлек комиссары буларак авылларда тәртип урнаштырган, кулаклар белән рәхимсез эш иткән Федюшкинга карата булган мөнәсәбәте бу яктан бик характерлы. Аны татар авылларында үз туганнарыдай күреп каршы алалар, озатканда җылы саубуллашалар.

Шулай итеп, сугыштан соңгы елларда татар матур әдәбиятында милләтчелек белән интернациональлек арасындагы көрәш аерым күренешләрдә генә чагылмыйча, социаль проблемаларның киң спектрында яңа, тагын да тирәнрәк гәүдәләнеш тапты.

Сугыштан соң, бөтен илебездәге шикелле үк, Татарстан тормышында да зур үзгәрешләр булды. Яңа нефть ятмалары ачылды, Казанда һәм Кама буенда эре промышленность предприятиеләре үсеп чыкты. Машина төзелеше, металл эшкәртү һәм нефть-газ чыгару алга китте.

Русларның һәм татарларның шул яңа тармакларда иңгә-иң торып эшләүләре байтак әсәрләрдә чагылыш тапты. Моны барыннан да элек Г. Әпсәләмовның «Сүнмәс утлар», Ш. Бикчуринның «Каты токым» романнарына, С. Хәкимнең «Үрләр аша» поэмасы, Д. Вәлиев драмаларына карата әйтергә кирәк. Шунысы характерлы, бу әсәрләрдә татарлар һәм руслар социаль мәгънәдә бертөрле итеп, тигез итеп күрсәтеләләр. Егерменче елларда татарлар башлыча кара эшчеләр иде, соңрак милли кадрлар үсеп чыккач, әдәбиятта аларның образлары барлыкка килде. Ш. Камал иҗатында инженер Габбас Галин, Г. Кутуйның «Тапшырылмаган хатлар»ында врач Галия һәм башкалар нәк шундыйлар. Сугыштан соңгы елларда исә бу күренеш гадәти хәлгә әйләнә. «Сүнмәс утлар» романын укыганда җитәкчеләрнең, инженерларның һәм гади эшчеләрнең нинди милләттән булуларын бөтенләй онытабыз, безне аларның производство, социаль һәм шәхси проблемалары дулкынландыра. Әлбәттә, моңа карап романның милли үзенчәлеге юкка чыкмый, автор татарларга хас сыйфатларны тулы сурәтли, әмма әсәрдә интернационализм рухы сулыш торган һавабыз кебек үк даими яши.

Соңгы еллар әдәбиятында геройларның милли «составы» киңәя бара. Элекке еллардагы әсәрләрдә, кагыйдә буларак, татарлар һәм руслар, сирәк кенә якын күршеләребездән башкортлар, чувашлар, марилар, удмуртлар һәм мордвалар күренгәли

иде. Нефть ятмаларын үзләштерү, эре промышленность предприятиеләре кору республикабызга Советлар Союзының барлык почмакларыннан төрле милләт вәкилләре килүгә сәбәп булды. Бу хәл, билгеле, әдәбиятта да чагылмый калмады. Ш. Бикчуринның «Каты токым» романы шуның күркәм дәлиле. Романның баш өлешендә укучылар нефть эзләүчеләрнең ашыгыч кына тупланган бригадасы белән танышалар. Бригададагы кешеләрнең күбесе нефть эзләүдә үзләрен вакытлы кешеләр дип саный. Берсе — Тин Тиныч — яраткан кызы Валяны эзләп килгән. Икенче бер персонаж — тәҗрибәле бораулаучы Саакян бригадада характерлар чуарлыгын күреп хафалана һәм кире китәргә ниятли. Ускенбаев, калымлык акча җыйгач та, далага ычкыну турында уйлый. Мотгәрәй һаман югалып тора, Кадермәт тирә-юньдәгеләргә җанвардай карый.

Мондый уйлардан соң Зөбәеров үзе дә Ибраһим-задә янына китү турында уйлап куя. Ләкин күпчелек эшчеләр каты тау токымнарыннан да ныграк булып чыгалар. Язтургайда яңа, бердәм тупланган интернациональ бригада барлыкка килә. Авырлыклар кешеләрне чыныктыра, үз көчләренә ышанырга өйрәтә.

Совет әдәбиятында интернационализм, төрле милләт кешеләренең бердәмлеге, хыяллары, идеаллары һәр вакыт Ленин образы белән бәйләп бирелә килде. Егерменче еллар уртасыннан башлап Ленин образы, партия һәм халык бердәмлеге темасы татар әдәбиятында үзәк урыннарның берсен ныклап ала. 1924 елда Г. Кутуй «Биш минутка дөнья туктады» дигән шигырен яза. «Октябрь» әдәби берләшмәсе «Ленин» дигән җыентык бастырып чыгара. Әмма бу елларның иң күренекле әсәре һ. Такташның «Гасырлар һәм минутлар» поэмасы булды. Башлангычны дәвам итеп, утызынчы-кырыгынчы елларда Г. Хуҗиев — «Ильич», Ш. Маннур — «Аның рәсеме», Ә. Исхак — «Ленин йорты» һәм «Мавзолей янында» дигән шигырьләрен иҗат итә. Юлбашчыга багышланган әсәрләр сугыштан соңгы чорда да әледән-әле языла тора. Ленин образына шагыйрьләр генә түгел, прозаиклар һәм драматурглар да мөрәҗәгать итә.

Татар поэзиясенең аксакалларыннан Х. Туфан Ленинга күп кенә әсәрләрен багышлый. Бу теманы ачуга шагыйрь С. Хәким дә зур өлеш кертте. Аның «Күңелем Ленин белән сөйләшә», «Баһавиның моңы», «Кукушкино авылы крестьяннарының Ленинга хаты», «Язгыз, җир уллары», «Ленин фәрманы белән» һ. б. әсәрләре бөек юлбашчыга багышланып язылган.

Юлбашчы образының язучыларыбыз иҗатында тирән һәм күпкырлы чагылыш табуы татар әдәбиятында халыкара хезмәттәшлек, теләктәшлек һәм интернационализм идеяләренең тантана итүен раслаган гыйбрәтле һәм якты мисал булып тора.

## КИТАП КҮЗӘТҮ

# СҮЗДӘН ҺӘЙКӘЛ

Караштырып кына багыйм да иркенрәк вакытта җентекләп укып чыгармын әле, дип кенә кулга алган идем, кырык эшне ташлап кырык якка дигәндәй, бер сулыш белән укып чыктым бу китапны. Әйе, бер сулыш белән. Ә бит укучыда баштан ук кызыксыну уяту — авторның беренче максатына ирешүе дигән сүз. Әмма беренче тәэсир эзсез-юлсыз гына да югалырга мөмкин. Шамил Рәкыйповның Татарстан китап нәшриятында узган ел басылып чыккан «Геройлар үлмиләр» исемле документаль проза әсәрләре җыентыгындагы геройлар, аларның данлы да, катлаулы да, әрнеткеч тә булган язмышлары хәтергә тирән сеңеп кала, искә төшкән саен дулкынландыра, күңелдә туган халкың, аның үзенә лаеклы вәкилләре өчен горурлык хисе кузгата.

Әсәрләрнең үзенә тарту көче нәрсәдә соң? Беренче нәүбәттә — аларның темасында, геройларында. Сугыш темасы, сугыш каһарманнары даны — алар һәр вакыт изге булып калачак. Безнең бүгенге тыныч тормышыбыз хакына җаннарын фида кылган, иҗат өчен яратылып та, матур хыяллары өзелгән, мәхәббәтләренә кырау төшкән чәчкә кебек яшь егет һәм кызларның язмышы, илебез азатлыгы өчен көрәштә үзләренең иң гүзәл сыйфатлары ачылып киткән азамат ирләрнең язмышы безнең күңелләребезне һәркайчан җәлеп итәчәк. Чөнки бүгенге бөек эшләребездә аларның да өлеше бар. «Бу баһадирларның,— дип яза автор кереш мәкаләсендә,— һәркайсының тормышы, сугышчан юлы матур җырга тиң! Алар алдында без, 9 нчы Майны ел саен шаулатып-гөрләтеп бәйрәм итүчеләр, һәммәбез бурычлы». Сугыш каһарманнарына карата үзеңне гел бурычлы итеп тою аларга багышланган әсәрләрне тартымлы итә.

Әлбәттә хикмәт темада гына түгел. Шул ук сугыш темасына, аның каһарманнарына багышланган, әмма донесение һәм рапортларга, бүләкләү кәгазьләренә теркәлгән кырыс вакыйга һәм фактларны «җанландырырга», «әдәби итәргә» маташудан узмаган, батырны «ура» кычкыртып, шарт-шарт аттырып (нәкъ урамда малайларның сугыш уены уйнаганы кебек), рәхимсез сугышның тышкы күренешләрен теркәүдән ары китмәгән, яисә конкрет баһадирлар, аеруча вафат булганнары турында (алар ризасызлык белдерә алмыйлар ич!) тузга язмаганнарны тасвирлаган, фантазия-уйланманы эшкә җиккән булып төрле сентиментлар белән тутырылган кысыр хәсрәт язмаларны укыганда күңел бөтерелеп-бөтерелеп рәнҗи бит. Андый язмаларның авторларына: «Булышма, изге «темага тыкшынма...»— диясе килә.

Димәк, Ш. Рәкыйпов әсәрләренең үзенә тарту көче темада гына түгел, ә тирәнрәк катлауларда. Иң тәү шунысы — автор моңарчы без белмәгән яңа геройлар яисә безгә электән күпмедер билгеле булган каһарманнарның яңа яклары, яңа сыйфатлары белән таныштыра. Ш. Рәкыйпов туктаусыз эзләнә, архивларда казына, ерак сәфәрләрдән кайтып керми, илнең төрле почмакларындагы төрле кешеләр белән язышa. Язучы-журналист бик тә изге эш белән мәшгуль. Бөек Ватан сугышында каһарманлык күрсәткән милләттәшләребезнең, республикабызда туып-үскән бүтән милләт вәкилләренең язмышлары белән кызыксынып яшәве, моны иҗат кыйбласы итүе өчен аңа рәхмәт сүзләре аз әйтелмәде, моннан соң да әйтелер. Чыннан да, тәкъдир ителерлек эш. Барлык совет кешеләренең ихтыярын чагылдырып, үзе дә Бөек Ватан сугышы каһарманы Л. И. Брежнев: «...бүген, сугыштан соң күп еллар үткәч, без бик күп санлы эшләр арасында сугыш юлларын үткән кешеләрне һәр вакыт исебездә тотарга тиешбез»,— дип, тагын бер кат без — исәннәрнең — изге бурычын хәтердә яңартты.

«Беркем дә онытылмасын, бернәрсә дә

онытылмасын!» Бу девизны эшкә ашырыр өчен кул кушырып утырырга түгел, ә хәрәкәт итәргә, эзләнергә, тәпченергә кирәк. Баксаң, яу кырында кеше ышанмаслык гайрәтлекләр күрсәтеп тә тыныч тормышта җай гына, тыйнак кына яшәп һәм эшләп ятучы каһарманнар яшь икән арабызда. Шулай тыйнак кына яшәп тыйнак кына дөнья куйганнары да байтак икән. «Чирәм җир» исемле китабында Л. И. Брежнев шундыйларның берсе — Даниил Нестеренко дигән геройның фаҗигале язмышын тасвирлап күңелләрне тетрәткән иде. Хәтерегездәдер, батып үлгән бу тракторчыны судан чыгаргач, иптәшләре аның кесәсеннән, Советлар Союзы Герое таныклыгы табып алалар. Ә бу фаҗигага кадәр совхоз эшчеләре үзләре белән янәшәдә Герой эшләгәнен һәм яшәгәнен белмәгәннәр бит. Әйе, геройлар тыныч тормышта күзгә бәрелеп тормыйлар, тыйнак булалар.

Ш. Рәкыйповның «Кайту» исемле әсәре герое, Актаныш егете Хәсән Заманов шул ук Нестеренколар токымыннан түгелмени! Киевны азат итү өчен барган бәрелешләрдә зур батырлык күрсәткән бу егет. Каты яраланган, аны үлгән дип уйлаганнар. Әмма ул мең бәла белән исән калган. Уралдагы шәһәрләрнең берсенә кайтып, бер аяксыз килеш, шахтада эшләп йөргән, алдынгы эшче булып танылган, 1951 елда салкын тидереп дөнья куйган. Үзенә Герой исеме бирелгәнлекне белмичә китеп барган. Сугышка хәтле Харьков трактор заводында тыйнак кына хезмәт иткән, үзенең һөнәрен намус белән үтәгән, сугыш кырында да батырлыкны гадәти эш үтәгән кебек кенә башкарган, сугыштан соң да күзгә бәрелеп тормыйча гына яшәгән. Геройлык эшләгәнен исбат итәр өчен бармакка бармак та сукмаган. Ш. Рәкыйпов үз героеның менә шушы тыйнаклык сыйфатын әдәби чаралар белән дә, публицистика чаралары белән дә матур итеп тасвирлап биргән, шушы төп сыйфатын үзәккә алып мөлаем һәм тимер ихтыярлы кеше образын тудырган. Тыйнак кешеләр көчле ихтыярга ия булалар икән шул. Әсәрне укыганда әлеге каһарманның үзе исән чагында тиешенчә тәкъдир ителмәвенә автор белән бергә әрнисең дә. Кешеләргә: тыйнакларга игътибарлырак булыйк, алардагы әлеге сыйфатны хөрмәтли белик! — дип оран саласы килә.

«Мәңге сакларга!» очеркы да безгә яңа герой ача. Бу геройга нәкъ менә Замановның сыйфатлары, хәтта аның моңсу язмышы да хас кебек. Рейхстаг стеналарына исемфамилияләрен уеп язган миллаттәшләребез хакында укыганыбыз бар. Ә менә Рейхстаг түбәсенә җиңү байрагы кадаганы турында ишеткән юк иде. Гәрчә андый каһарманыбыз да булган икән, Башкортстанда туып үсеп врач булырга хыялланып йөргән, әмма каһәр төшкән сугыш тарафыннан шул изге хыяллары челпәрәмә китерелгән Гази Заһитов исемле тыйнак егетебез булган икән. 30 апрельдә яралы килеш Рейхстаг түбәсенә беренче Җиңү байрагын кадый ул һәм шушы батырлыгы өчен аңа Советлар Союзы Герое исеме бирелергә тиеш дип кәгазь языла. Әмма ни сәбәпледер бу югары исем аңа бирелмичә кала. Алай гына да түгел, Г. Заһитов һәм аның сугышчан дусларының әлеге фидакарьлеге әлегә кадәр тиешенчә яктыртылмаган да. Ш. Рәкыйпов әнә шушы сер йомгагын чишә. Ул без — укучыларны да үзе белән «ияртеп» йөртә, төрле документлар, Газиның дусларының истәлекләре белән таныштыра, бүләкләү кәгазендәге фактны тәфсилләп бирә. Бу очеркында автор геройның эчке рухын ачудан битәр әлеге фактны ачыклауга төп игътибарын юнәлтә. Табигый хәл. Сүз бит тарихи факт хакында бара. Әмма операцияне тасвирлау барышында аны башкаручыларның, беренче чиратта Гази Заһитовның асыл сыйфатларын да саран шәрехләр белән булса да күрсәтеп бирә. Гази үз теләге белән рейхстагны штурмлаучылар сафына баса, коммунистның урыны алгы сызыкта булырга тиеш, дип уйлый ул. Сугышчан бурычны үтәгәндә каты яралана: дошман пулясы аның партбилетын үтәли тишеп чыга. Аны Кызыл Йолдыз ордены белән бүләклиләр. Госпитальдә дәваланып туган ягына кайткач, җиң сызганып эшкә керешә Гази. Авыл советы председателе, киң профильле механизатор, иң алдынгы тракторчы һәм комбайнчы. Кызганычка каршы, ул 1953 елда автомобиль һәлакәтенә эләгеп вафат була. Авылдашлары аның да герой икәнлеген белмиләр. Гази, аучыларга хас булганча, атнага ике сүз әйтә торган йомыкый, юаш, түземле, сабыр холыклы булган. Автор болай ди: «Табигый матурлык беркайчан да бәясен җуймаган кебек, тыйнак батырлык та адәм балаларын үзеннән читкә этәрми. Халыкның мактанычы булган чын батырның каһарманлыгы үз иленә кайчан әйләнеп кайтса да соңламый диләр. Хак сүзләр болар».

Китап безгә электән таныш булган кайбер каһарманнарның да яңа сыйфатларын

ача, дидек. Бу җәһәттән киносценарий рәвешендә язылган «Һәйкәлләр янында» исемле әсәр характерлы, аның үзәгендә — атаклы генерал, Советлар Союзы Герое Гани Сафиуллин. Бу легендар каһарманның сугышчан тормыш юлы шактый яхшы билгеле — аның турында укыган да бар, истәлекләре белән дә таныш. Әмма Ш. Рәкыйпов әлеге әсәре белән командирның образын тагын да тулыландырган, дөресрәге, аның мөлаем образын иҗат иткән. Ул безнең алга чын гуманист һәм интернационалист булып килеп баса. Ординарецы Сидор Новгородцевның оригиналь хикәяте аша без Г. Сафиуллинның фронттагы батырлыкларын солдат күзлеге аша хәтердән уздырабыз, солдатның аңа мөнәсәбәте аша генералның ифрат дәрәҗәдә кешелекле булганлыгын ачык итеп тоемлыйбыз. Моңа тагын Советлар Союзы Герое Нәҗип Нугаевның тасвирлаулары өстәлә. Батыр украин каһарманы Петр Гончаров һәм бигрәк тә үзбәк егете, Советлар Союзы Герое, Болгариянең Халык Герое Зыямәт Хусановка мөнәсәбәтендә генералның гуманлыгы, халыклар дуслыгы хисенең канына сеңгән булуы калку итеп гәүдәләнә (әсәрдә шулай ук татар Нәҗип Нугаев белән украин Петр Гончаровның туганлыгы күңелне күзгатырлык итеп тасвир кылынган). Үзенең частенда хезмәт итүче үзбәк егете З. Хусанов безнең илдә һәм Болгариядә фантазия җитмәслек батырлыклар эшли. Ике тапкыр үлде дип исәпләнә. Әмма корычтан коелган егетне үлем алмый: исән калып туган илгә кайта. Ләкин геройның намусына яла ягыла. Концлагерьдан качкач, немецлар үз архивларына мәкер, хәйлә тулы кәгазьләр язып калдырган булалар. З. Хусанов Герой исеменнән мәхрүм ителә. Кара көннәр башлана. Шул чак аңа Г. Сафиуллин ярдәм кулы суза. Инде авыру булуына карамастан, ерак сәфәргә чыга, төрле оешмаларга хатлар яза. Нәтиҗәдә Герой исеменә төшкән тап алып ташлана. Автор бу эпизодларны күңелне тетрәндерерлек итеп тасвир итә алган.

Әсәрләрне, аларның геройларын күңелгә якын иткән тагын бер сәбәп бар. Ш. Рәкыйпов үз персонажларының язмышларын шомартып күрсәтми, ул әлеге язмышларның чоңгыллы урыннарын әйләнеп узмый. Нәтиҗәдә, каһарманнар үз язмышлы, индивидуаль төсмерле тере кешеләр булып алга килеп басалар. Алыгыз шул ук З. Хусанов фаҗигасын, янсә «Мәтрүшкәләр һаман хуш исле» очеркы герое, атаклы партизан Николай Орлов-Гатауллаңың ифрат катлаулы язмышына игътибар итегез, «Хәрәкәттә — бәрәкәт» очеркы герое Сәлим Айткуловны хәтергә төшерегез. Сугыш кебек дәһшәттә дә кешеләр кеше булып калалар: бер-берсен яратышалар, дус итешәләр, шул ук вакытта бер-берсенә мөнәсәбәттә каршылыклар да чыгып тора. Әмма барыбер ахыр чиктә гаделлек, безнең тормышыбызда тыныч вакытта ук ныклап урнашкан нормалар җиңә.

Документаль әсәрләрдәге һәр геройның үз шәхси дөньясы бар. Әнә шул дөньяга да күз ташлап, автор аның гаять бай һәм эмоциональ икәнен ача. Бу уңайдан «Сөю дәвам итә» исемле әсәр аеруча хәтердә кала. Солдат көндәлеге рәвешендә иҗат ителгән әсәрнең герое Вилдан Хабиевның искиткеч батырлыгы һәм үзәкләрне өзгеч яшьлек мәхәббәте турында ул. Чын мәгънәсендә оптимистик трагедия. Челпәрәмә китерелгән өметләр дә, яшьлек хатасы аркасында туган гомерлек вөҗдан газабы, шашынып көнләшү хисләре... һәммәсе дә бар монда. Кирәк бит: бер үк Миләүшәне яраткан ике егет (берсе — ханымның элекке сөйгәне, икенчесе — ире) яу кырында очрашалар. Бер-берсен чын мәгънәсендә дошман күргән бу кешеләр, үлем якадан алгач булса да, бер-берсен аңлашалар, бер-берсен гафу итешәләр. Икесенең дә күңелен биләгән олы мәхәббәт хакына!

Җыентыкта тагын да әле үзенчәлекле язмышлар бар. Ничек кенә үзгә язмышлы, үзгә холыклы булмасыннар, бу батырларны берләштергән чыганак бер үк: туган илгә, азат илгә бирелгәнлек, аны ярату, аның өчен җанны фида кылырга әзер булу, хак эш өчен көрәшкәнне аңлау, үзара мөнәсәбәтләрдә кешелеклелек, туганлык, ярдәмләшү, тыйнаклык, хезмәт сөючәнлек, дошманга көйдергеч нәфрәт хисе... Аларның бу сыйфатлары советча яшәү җирлегендә тәрбияләнгән. Әлеге сыйфатлар тыныч хезмәт елларында тамырланып үсеп килгәннәр дә авыр сынау мизгелләрендә гөлт итеп тышка бәреп чыкканнар һәм каһарманлык дигән гүзәл рухи бөеклеккә әверелгәннәр. Ш. Рәкыйпов үзенең әсәрләрендә әнә шундый идеяне үткәрә.

Җыентыкның тарту көче, ниһаять, шунда, автор һәр әсәренә оригиналь әдәби форма тапкан. Кайсына гына мөрәҗәгать итмә, һәрберенең жанры, сюжеты, композициясе, тел-стиль чараларының үзенчәлеге турында сөйләргә мөмкин. Автор документаль про-

заның мөмкинлекләре киң икәнлекне исбат итәргә тырыша.

Әмма бер мәсьәләдә автор белән принципиаль бәхәскә керәсе килә. Сүз такт һәм документаль төгәллек хакында, тормыш дөреслеге белән автор уйланмасы нисбәте турында бара. Бәхәссез, әдәби документаль проза әсәре язу — иң кыен иҗат төре. Төп хикмәт шунда, документализм дигән метод авторның фантазиясен чикли. Ләкин бу — документаль әдәбиятта уйланмага урын юк дигән сүз түгел. Ансыз гомумән иҗат була алмый. Документаль әдәбиятта художество алымнары белән бергә публицистика алымнары да ярдәмгә килә. Документаль әдәбият, сурәт әдәбияты булу белән бергә, логик формаларда әйтеп бирелә торган фикер әдәбияты да ул. Документаль прозаның шушы хасиятеннән уңышлы файдаланган очракта автор иҗади уңышка ирешә. Моның бер мисалы «Һәйкәлләр янында» исемле сценарий. Оригиналь алым. Автор, вакыйгалар һәм характерлар логикасына каршы килмичә, үзенең иҗат фантазиясен эшкә җиккән, шартлылык алымнарын кыю кулланган. Художестволы сурәтләүгә табигый рәвештә авторның публицистик уйланулары, чигенешләре, фикерләре килеп керә. Язучы гоман да итә («Әгәр мин кино төшерүче булсам...»), геройларның монологларын һәм диалогларын да бирә. Әмма без белеп-сизеп торабыз: ул шартлылык кысаларында эш итә. Шуңа күрә укучы тормыш дөреслегенә каршы килү хисе кичерми.

Әмма аерым әсәрләрендә автор чама хисен онытып җибәрә. Замановка багышланган очеркта, мәсәлән, шәфкать туташы Тамара бар. Бик мөлаем, бик кешелекле образ. Геройның үлемне, каты авыруны җиңүендә аның роле гаять зур. Ләкин ул ханымның Замановка булган интим мөнәсәбәтләрен, мәхәббәтен әсәргә кертү нигә кирәкте? Очеркны җанлы, психологик итү өченме? Ә бит Замановның тормыш иптәше, балалары, дуслары, якташлары бар. Турысын әйтергә кирәк, бу очракта авторга такт, чама хисе җитеп бетмәгән. «Сөю дәвам итә» дигән әсәрдә дә шул ук хәл. Геройның яшьлек хатасын, Миләүшә белән булган иң нечкә интим мөнәсәбәтләрен тәфсилләү (хәтта дөреслеккә туры килгән очракта да), минемчә, шулай ук такт җитмәүнең бер чагылышы.

Бу әсәрдә автор эмоциональ тәэсир итү көче ягыннан бик тә үтемле булган тагын бер алым — солдат көндәлеге алымын куллана. Ләкин андый «көндәлек» тормышта булганмы, бар икән — ул әдәби яктан шулай камил эшләнгән булганмы (чын язучы кулы әллә каян сизелеп тора) — ышануы кыен. Геройның эчке дөньясын, бу дөньяның драматизмын ачу өчен кулай алым булса да, ул бу очракта документаль әдәбиятның төп таләбенә каршы килә. Минемчә, фактлар төгәллеге, тормыш дөреслеге мондый төр әдәбиятта бозылмас закон булырга тиеш. Аннары бит сүз объективлык принцибы турында гына түгел, ә каһарманнар алдындагы җаваплылык турында да бара. Реаль кешеләр хакындагы әсәрләрдә фактлар дөреслегенә бернинди хилафлык килергә тиеш түгелдер кебек. Моннан «язучы — фактлар колы» дигән хата нәтиҗә ясалмасын, алай түгеллекне авторның инде телгә алынган «Һәйкәлләр янында» дигән һәм башка әсәрләре раслап тора.

Китапның ахырында гаҗәеп бер документ китерелгән. Ул — Татарстанда туып үскән, яшәгән һәм эшләгән, һәм Татарстаннан читтә туган, милләте татар булган Советлар Союзы Геройларының исемлеге. Ул исемлектә һәр геройның исем-фамилиясе, туган елы, урыны, милләте, Герой исеме бирелү турындагы Указның датасы күрсәтелгән. Күңелдә горурлык хисе уята торган бик кирәкле исемлек!

Җыеп әйткәндә, Ш. Рәкыйпов, үзенең эзләнүләрен дәвам иттереп, иҗат кыйбласына тугрылык саклаган хәлдә, тәрбияви көче зур булган файдалы, мавыктыргыч китап иҗат иткән. Ул совет кешесенең рухи гүзәллегенә дан җырлый, аңа сүздән һәйкәл торгыза. Нәтиҗәдә, Бөек Ватан сугышы каһарманнары мәңнәр аңында үзләренең икенче гомерләрен башлыйлар. Совет кешесенең гүзәллегенә соклану белән бергә, кешенең асылына ук каршы килә торган рәхимсез сугышка карата күңелдә бунт кузгата бу китап. Уйлар ирексездән бүгенге көннең фаҗигале вакыйгаларына килеп тоташа. Бүген дә дөнья тыныч түгел, Океан артыннан да, Көнбатыштан да, Көнчыгыштан да янау авазлары яңгырап китә, корал чыңлавы ишетелеп тора. Алар барысы да социализм дөньясына каршы юнәлтелгән. Мондый шартларда аталарыбызның туган илгә бирелгәнлеге, каһарманлыгы, дошманга нәфрәте яшь буыннарның характерында төпкелләнеп тамырланырга тиеш. Шамил Рәкыйповның әсәрләре әнә шул изге эшкә хезмәт итә.

**ФЛОРИД ӘГЪЗӘМОВ.**

# ЯШЕРЕН КАССА

Мәгъсүм Насыйбуллин — җиде китап авторы. Аларда тасвирланган вакыйгалар бер-берсе белән органик мөнәсәбәттә булып, үзара үрелеп баралар.

Дөреслекне бернинди таш капчыкка бикләп тә булмый. Асфальтны тишеп дөньяга чыккан үлән кебек, ул, богауларны өзеп, киң дөньяга чыга. Әлбәттә, дөреслек өчен түземле рәвештә, акыл белән, кыю көрәшергә кирәк. Бу сыйфатлар табигать тарафыннан һәркемгә тигез бирелмәгән. Берәү, әйтик, гомер буе үзенең кырын эшен каплар өчен көрәшә. Кеше алдында ал да гөл, матур сүзләрне сибә генә. Андыйларны фаш итү җиңел түгел. Әмма кырын эш кырык елдан соң да беленә. Дөреслек тантана итә. Тик менә аңа чаклы кырын эш эшләүче кайбер саф йөрәкле кешеләрне дә сазга батырып өлгерә. Бу очракта аңа башка саф йөрәкле кешеләр кул суза. Бер кеше — бөтен кеше, бөтен кеше — бер кеше өчен яшәгән социалистик җәмгыятьтә бу — канунлашкан күренеш. Ил мәнфәгате белән яшәүче саф күңелле, гадел, бай рухлы кешеләр миллионнар. Кырын эшне кырык ел таш капчыкта яшәтә торган заманнар үткән. Чөнки бездә гадел совет суды бар.

М. Насыйбуллинның һәр әсәрендә бу идея кызыл җеп булып сузыла. Ул үзе — юстиция өлкән советнигы. Тикшерү һәм суд органнарында эшләүчеләр турында яза. Аларның хезмәте социалистик җәмгыять милкенә кул сузучы, кеше кесәсе исәбенә яшәргә тырышучы әрәмтамак, бүгенге матур тормышны сөткә тамган деґет кебек ямьсезләп торучылар белән рәхимсез көрәш алып баруга бәйләнгән.

Язучының әсәрләрендә әледән-әле бүгенге «культуралы караклар» белән дә очрашабыз. «Яшерен касса»[1]да да шулай. Яшь сатучы Хәят Солтанова эшли торган кибеткә яңа гына мичтән чыккан җылы көмәч китерелә. Кибет эче икмәк хуш исе белән тула. Кабарып пешкән, тәмле көмәчне кешеләргә тәкъдим итүе нинди күңелле! Шулай уйлый Хәят. Ләкин ул акчасын банкка тапшыра алмаган, яшерен кассага салып куйган. Икенче көн эшкә килсә, 810 сум акчадан җилләр искән. Томанлы Күл районы эчке эшләр бүлеге тикшерүчесе капитан Моталлап, прокурор санкциясе булмый торып, Хәятне кулга ала. Укучы Моталлап яклы, акчаны Солтанова үзе үзләштергән дип уйлый. Тикшерә башлагач, вакыйга һаман куера бара, төенләнә, аны чишү дә авырлаша. Хәяткә карата алтынчы магазин директоры Шәмсениса Габбасова, районның сәүдә оешмасы башлыгы Мөхәммәт Сөбхангулов һәм башкаларның үз карашлары бар. Берәүләр аңа ышана, икенчеләре — юк. Шулай итеп, акчаны кем үзләштерү мәсьәләсе табышмакка әйләнә. Җепнең очын табу һаман кыенлаша бара. Ярдәмгә республика прокуратурасының өлкән тикшерүчесе Гайнан Ибраһимов чакырыла. Тикшерүчеләр райком белән дә бәйләнештә. Район прокуроры Мөнип тә, җәмәгатьчелек тә читтә калмый.

Һәркем күңелендә сакланып килгән бер сер, хис-тойгы, күчерелмә мәгънәдә әйтсәк, үзенә генә билгеле «яшерен касса» була. Дөрес, уй-хисләрне һаман бикләп кенә яшәү дә мөмкин түгел. Эчке әрнү, күңел тетрәнүе үзе үк сине ачылырга мәҗбүр итә. Әгәр ачыла алмый иза чигәсең икән, синең күңел сандыгыңны башкалар җимерә.

Бу әсәрдә дә шулай. Вакыйгалар барышында кешеләрнең эчке дөньясы, рухи халәте, чынбарлыкка мөнәсәбәте ачыклана. Хәят тә сөттән ак, судан пакь түгел икән. Үзләштерү нияте белән булмаса да, акчаны яшерен кассада тоту — үзе үк сәүдә тәртибен бозу. Бервакыт кешегә сатыласы ак онны да капчыклап алган әле ул. Бу фактлар эштә ал да гөл булып күренгән, беренчелек дилбегәсен кулына нык урап тоткан магазин мөдире Габбасовага яшь сатучы Хәятне гаепләү өчен җитә кебек. Әмма... мәсьәлә катлаулырак — акчаны Габбасова үзе үзләштергән икән. Хәят эшен тикшерергә килгән Гайнан Ибраһимов магазин мөдиренең бик күп кырын эшләрен, шул исәптән, яшерен кассасын да ача. Хәят аклана, Шәмсениса кулга алына. Аның белән яшерен мөнәсәбәткә кергән капитан Моталлап та җәзага тартыла.

Үз вакытында М. Насыйбуллинга тикшерүчеләр тормышын күп яклырак яктыртырга, алар арасындагы капма-каршылыкларны тирәнрәк итеп күрсәтергә киңәш ителгән иде. Дөрес, бу мәсьәләгә язучы һәр әсәрендә игътибар итә. Ул башта республиканың күренекле юстиция кешеләре турында очерк-

[1] М. Насыйбуллин. Яшерен касса. Казан, Татарстан китап нәшрияты, 1978.

лар да язды, аларда кеше язмышы сагында торучыларның иң гүзәл сыйфатларын чагылдырырга тырышты. Повестьларында да ил, халык мәнфәгате белән яшәүчеләрне, гадел кешеләрне беренче планга куя. Бу әсәрдә дә республика прокуратурасы тикшерүчесе Гайнан Ибраһимов, прокурор Мөнип, шәһәр прокуратурасы тикшерүчесе Марат, райсоюз башлыгы Мөхәммәт Сөбхангулов, Хәятнең ире Идрис — барысы да күңелдә матур тәэсир калдыра. Суд органнарында эшләүчеләрнең иң мөкатдәс бурычы кеше язмышы өчен көрәшү — М. Насыйбуллин шушы миссияне аңлап эш итә. Моның өчен гадел юстиция кешеләренә үз араларындагы йомшак җаннарга һәм социалистик җәмгыять милкенә кул сузучыларга каршы көрәшергә кирәк була. Бу әсәрдә без шуның бер үрнәген күрәбез. Якты идеаллы Гайнан тикшерү процессында капитан Моталлапның кара эшләрен фаш итә. Изге күңелле кеше булса да, Сөбхангуловның эштә принципиальлек күрсәтмәве ачыклана. Гайнанның матур рухи дөньясы шәһәр прокуратурасы тикшерүчесе Маратның да күңеленә якты нур булып керә.

Гайнан — хезмәт сөючән, кешелекле, изге күңелле оста тикшерүче. Исле гөл янында иссез гөл дә хуш исләнә дигән кебек, хезмәттәшләре аннан фәһем, үрнәк алып яши. Укучылар күңелендә дә ул тирән эз калдыра.

Кешене бәладән коткару өчен утка-суга керергә әзер торучы тикшерүчеләр язучының башка әсәрләрендә дә бар иде. Ул әлеге һөнәрнең гаять житди, авыр, җаваплы икәнлеген яшерми. Шуның белән бергә аның романтикасын да күрсәтергә тырыша. Яшьләр, М. Насыйбуллин әсәрләрен укыгач, караклар арасындагы маҗаралар белән түгел, ул каракларны төрле маҗаралы юллар аша тозакка эләктерүче тикшерүчеләр белән кызыксына. Авторга яшьләрдән килгән хатлар да моның шулай икәнлеген раслап тора. Менә Башкортстанның Яңавыл районыннан килгән хат: «Кулга аттестат алганга биш ел үтеп китте. Төрле җирдә эшләп карадым, ләкин һаман яраткан һөнәремне таба алганым юк иде. Ансыз яшәү бик кыен икән. Ә бит мәктәптә начар укымадым. Мәгъсүм абый! Менә хәзер сез күземне ачтыгыз. Рәхмәт! Бер иптәшнең тәкъдим итүе буенча өч китабыгызны укып чыктым. «Их, шул кешеләр кебек булырга иде»,— дигән уй тудырды алар. Минем дә гаделсезлеккә каршы көрәшәсем килә. Юрист булган кешегә бу өлкәдә мөмкинлекләр зур икән».

Мондый хатлар алу язучы өчен күңелле хәл, билгеле. Алар авторның әсәрдән-әсәргә үсә килүе хакында сөйли. «Яшерен касса»да тел-сурәтләү чаралары юристларның хезмәтенә, яшәү рухына бәйле рәвештә туа. Мәгъсүмнең әдәбиятта моңарчы аз яктыртылган тема өстендә шулай армыйталмый эшләве шатлыклы хәл.

Сүз азагында юристларның үзара мөнәсәбәтләрен тагын да сәнгатьчәрәк чагылдырырга кирәк дигән фикерне кабатлап әйтәсе килә. Тормышның үзе кебек катлаулы, тирән һәм кызыклы итеп эшен башкару өчен юристның оста педагог, психолог булуы зарури. Шушы сыйфатларны үзенә туплamаган тикшерүченең кеше йөрәгенә юл табуы мөмкин түгел. Язучының киләчәк әсәрләрендә бу мәсьәләләр игътибар үзәгенә ныграк алынсын иде.

Автор туган тел мөмкинлекләрен, егәрлеген дә тулырак файдаланырга тиеш. Ничек кенә булмасын, укучы М. Насыйбуллинның кешеләр язмышын киң чагылдырган һәр яңа әсәрен түземсезлек белән көтеп ала.

**СУФИЯН ПОВАРИСОВ.**

*«Казан утлары»нда чыккан «Чын сөю бармы?» исемле повесть турында укучылардан байтак кына хатлар килде. Аларның кайберләре үзләре үк хикәя булырлык. Шуларның берничәсен, артык «кыркымый гына», «геройлар»ның исемнәрен дә үзгәртми генә, редакция карамагына тәкъдим итәсе килә. Чын сөю бармы? Бу — мәңгелек сорау, мәңгелек бәхәс бит. Шуңа күрә, әгәр мин хат авторларының иң нечкә, иң яшерен серләрен үз исемнәре белән игълан иткән булсам, укучыларым мине гафу итсеннәр. Ул хикәяләрдәге «аромат»ны саклау өчен, башкача булдыра алмадым.*

*АВТОР*

## Кызыл яр авылыннан хат

Хөрмәтле дус Шәйхи!

Бүген «Казан утлары» журналының өченче санын алдым. «Нәрсәләр бар икән?» — дип актарсам — синең повесть. «Бу ни турыда икән?» — дип укый башлаган идем, укып та чыктым.

Хискә, уйга, шигърияткә бай — мавыктыргыч.

Үткән көзен, Казанда, телефонда сөйләшкәндә «Мин әле үземне прозачы дип саный алмыйм...» дигән идең. Алдыйсың. Кара, нинди матур хикәя язгансың. Сөендем.

Синең ул повесть миңа гына түгел, башкаларга да ошаган.

Пермь өлкәсе, Барда авылында минем белән профтехникумда укыган Гайшә ханым белән хат алышабыз. Үткән хатында: «Ш. Маннурның повестен бик яратып укыдым, инде ахырын көтәм», дигән иде. Бүген миңа тагын аңардан хат бар.

«... «Казан утлары»ның дүртенче саны килде. Ш. Маннур повестеның ахырын укып чыктым. Бик ошады. Ул кызык яза бит. Халык мәкальләрен дә бик урынлы куллана. Көләрдәй җирләре дә, җыларлык урыннары да бар», дигән...

Ихтирам белән, И. Сәләхов.

## Лениногорскидан хат

Хөрмәтле редакция!

Күптән түгел генә «Казан утлары» журналында Шәйхи Маннурның «Чын сөю бармы?» дигән лирик повесте басылган иде. Мин бу повестьны кызыксынып укып чыктым. Бу повесть миңа бик ошады. Шуның өчен мин Шәйхи абый Маннурга киләчәк тормышында шатлыклар, эшендә зур уңышлар теләп, һәм якынлашып килүче 9 нчы май — Җиңү бәйрәме белән котлап калам.

Хат ахырында минем шуны әйтәсем килә. Миңа хәзер унсигезенче яшь, яшьлегемнең иң матур чоры. Яшьләрнең кызлар белән йөри торган чагы... Ләкин мин, кызлар белән йөрү, алар белән танышуга шул кадәр «кыргый» ки, кызларны күрсәм, күз алларым караңгыланып кала. Ә менә Шәйхи абыйның повестен укыгач, бөтенләй әллә ни эшләдем.

Рәхмәт сезгә, Шәйхи абый. Киләчәктә дә шундый повестьлар бастыруыгызны теләп, проф. тех. училище укучысы — сварщик Хәмит Бикбаев.

## Башкортстаннан хат

Кадерле редакция!

Шәйхи Маннурның «Чын сөю бармы?» дигән повестен укыгач мин чынлап та сөюнең бар икәненә ышандым. Зәйтүнә бәхетле булган. Сөйгән, сөелгән кыз ул. Ә мин 19 яшем тулса да, бер егет белән дә дус булып йөргәнем юк. Дөрес, бер егет миңа ошый иде. Тик ул минем белән бер дә сөйләшкәне юк. Ул әле дә мин укыган техникумда укый. Кыска гына вакыт эчендә күп кызлар белән йөрде инде. Бозылып бетәр инде ул. Ә Шәйхи абыйга чын күңелемнән рәхмәт әйтәм мин. Ул минем күңелемдә киләчәккә дәрт уятты, башымдагы кара болытлар таралып, азаеп калды. Чирем дә онытылып, шат күңелле бер кызга әйләндем мин. Үземнең киләчәгемне төрлечә күз алдына китерәм. Канатланып очам уйлар диңгезендә, яңадан туган кеше кебек. Ә элек мин киләчәгем турында уйлый алмый идем. Үләрмен дә онытылырмын, үземне искә алырдай берни дә эшли алмам ди идем. Зур рәхмәт сезгә.

Сәлам белән Лена.

## Түбәннән хат

Хөрмәтле Шәйхи Маннур дускай!

«Чын сөю бармы?» әсәреңне укыдым, әсәр бик әйбәт язылган. Татар сүзләренә бик бай син, туган! Әсәреңне укый башласам, укып бетермичә туктала алмыйм. Әсәр үзенә тартып тора — «укы-укы, тагын да кызыграк», — дип тора.

Шәйхи туган! Тагын бер әйбәт әсәр язарга хәлең житәрме? Синең озак яшәвеңне телим мин! Тагын яңа язылган әсәрләреңне күрәсем, укыйсым килә!

Карт укытучы Т. Гарифуллин.

## Уфадан хат

Хөрмәтле Маннур дус!

3 нче санда чыккан үкенечле язмышлар хакындагы хикәяләрең күңелгә нык тәэсир итәрлек дәрәҗәдә тирән итеп язылганнар. Укыган кадәресе миңа бик ошады. 4 нче санны көтәм. Эшеңә караганда син әле егетләр кебек булырга тиеш!

Яңа иҗади шатлыклар теләп калам!

Максуд Сөндекле.

## Чын сөю уты сүнми ул

Чыннан да, чын сөю бармы? Бар! Булмаганда Шәйхи аганың бу әсәренә әдәбият мәйданында урын да булмас иде.

Әсәрнең «Ике дус»тагы Гөлбәдрия белән Гафар мәхәббәте, «Сыйнфый дошман»дагы Зәйтүнә — Баязит арасында, «Матурның да матуры»нда Назикә белән Ихсан арасында, «Барыбер сүнми»дәге Зөлхиҗә белән Гәрәй дуслыгы, ялкынлы якынлык, бер-берсен үз итеп, карашларның тәңгәл килеше, нечкә нәзакәтле гыйшык хисләренең бөрелеп үсеше, мәхәббәтнең илаһи көченнән куәт алып, дәрт белән яшәү һәркем өчен уртак булуы мөмкин.

Яшьлектә беркем дә сөю утларында янмыйча калмый. Шуның өчен берәүләр Гөлбәдрия — Гафар, Рәмзия — Мөслим, икенчеләр Зәйтүнә — Баязит, Таһир — Зөһрә, Назикә — Ихсан, Мәдинә — Әбүзәр, Зөлхиҗә — Гәрәйләр мәхәббәтенең үз язмышында чагылышы итеп кабул итә, охшашлыкларын күңелендәге хәтер көзгесендә күрә ала.

Минем үземә Назикә образы ошады. Назикә, ирдән «колак кагуы»на карамастан, Ихсанны зәзрлекләми, Ихсанның яңа гаиләсенә тыкшынмый, үз улы Айдарны «әтиле малай» рухында тәрбияли. Ихсан өчен дөнья куласасы әйләнүдән туктап кала язган чакта, аңа ярдәм кулын суза, Айдарына — атасын таба, Ихсанның ике баласына ана була, агач аяклы Ихсанга — чын терәк, иптәш булырга үзендә көч таба, үткәннәргә һич нинди үпкә тотмый. Менә шуңа да бит Назикә — чын инсан, баш хәрефле кеше, матурның да матуры!

Әсәрдәге Зөлхиҗә белән Баязит язмышы тетрәткеч. Мәхәббәтнеке шул инде — сөйдерә, көйдерә башлата, төпсез упкыннарга, чоңгылларга, әҗәл ястыгына башыңны ташлата.

Ике җанның күңелендә гыйшык ярысыннан бөреләнеп, үсеп чыккан ярату хисләре бер-берсенә үрелә-үрелә баралар да, тормыштагы киртәләр, таулар юлларны аера. Шул килеш юлда да чын сөю, саф сөю булып кала бирә.

Китабының изге сәхифәсенә чын сөю булып язылган икән, шул ук сәхифәгә икенче мәхәббәтнең язылышы мөмкин түгел. Чын сөю — кеше күңеленең мәңгелек иярчене ул.

Х. Арсланов.

# Ташкенттан хат

Хөрмәтле «Казан утлары!»

Ш. Маннурның «Чын сөю бармы?» дигән лирик повестен көннәр-төннәр укып, җанга рәхәтлек алдым, яңадан яшьлекне искә төшердем.

Ф. Әмирханның «Габделбасыйр гыйшкы» искә төшеп, Ш. Маннурның повесте артыгы белән хәзерге «Габделбасыйр гыйшкы» дип әйтмәкчемен.

Бу повестьта автор табигать дөньясының матурлыгын, халкыбызның гореф-гадәтен, аның шаулы вакытларын, тарихи тәрәккыятен бөртекләп яза алган. Гомумән, ничек итеп мактасам да мактап бетерерлек түгел. Сөйләшкәндә сөйләнми торган сүзләрне дә матур итеп теркәгән, белмәгән сүзләрне өйрәткән.

Моңарчы шундый оста телен кайда яшереп торган. Гади итеп язылган «Чын сөю бармы?» лирик повесте халкым тормышын оста итеп сурәтләгән.

Ш. Маннурны кочаклап, дусларча «хакыйкать, тел бистәсе икән» дип әйтәсем килә... Ш. Маннурның бу повестен «Мең дә бер кичә» хикәясенә тиңләп, «Ике мең дә җиде кичә», дип әйтәсем килә. Картаймыйча, киләчәктә шундый матур лирик повестьларын яңадан кат-кат укыйсым килә.

Гарәф.

# ЕЛМАЕП ТА, КӨЛЕП ТӘ...

Вахит Монасыйпов

## ИСЕМЕ БУЛСЫН СӘҮДӘГӘР

### Бер агай хикәяте



Менә шулай, агай-эне... Булдырып булмады шул. Тоттылар да шудырдылар мине сәүдә челтәреннән... Кая, бир әле берне, көйрәтик булмаса... Җанга сихәте тимәсме...

Башта мине алма сату эшенә җиктеләр. Прәме урамда. Өеп куйдылар як-ягыма алма тулы әрҗәләр. Дөресен әйтим, алманың сыйфаты теге ни... Кайсын гына алып карама — тишек тә тошык, ярык та йорык, һәрберсендә диярлек теге ни... корт-кырмыска гөжли... Торам шулай алма сатып, алма турында җыр көйләп:

**Алма зирәк, алма зирәк,**
**Алып ашарга кирәк...**

Менә минем каршыма мөлаем генә йөзле бер әби килеп туктады.

— Улым, — ди, — картым бүлнистә ята, шуңа күчтәнәчкә дип, бер-ике кадак алма илтмәкче идем, сайлап бир әле матурракларын...

— Әбекәем, матурым, күз нурым! — дим аңа. — Юк матурларны каян сайлап бирим ди мин сиңа?! Күреп торасың ич: бернинди ата-анасы юк алмаларның. Тыштан гына ялтыраган ул, ә эчендә аның теге ни... гөҗ-гөҗ...

Мин бер зуррак алманы алып, әбинең колак төбендә тотып тордым:

— Ишетәсеңме?.. Керт-керт кимерә, азгын җан!.. Алма, әбекәй, син минем алманы. Картың соңыннан колак итеңне чәйнәп интектерер.

— И, ходаем, — дип уфтана әби, — нишлим соң инде...

— Аптырагансың! — мәйтәм. — Әнә, күрәмсең, урамның аръягында өем-өем әрҗәләр... Күрсәң, шул: анда да алма саталар. Шәп алмалар, менә дигәннәр, берсеннән-берсе матур... Минекеләр белән чагыштырырлыкмы соң! Бар син, әбекәй, шунда, чират-мират дип торма, бәреп кер, туп-туры әйт сатучысына: «Вахитов җибәрде!» диген. Әхири кеше ул минем, күрше. Һәр кич домино сугабыз ишегалдында...

Әби рәхмәтләрен укый-укый китеп барды. Аның каравы, бактың исә, безнең кибет мөдире читтән генә, астыртын рәвештә минем үгетнәсихәтне тыңлап торган икән. Җилләнеп килеп җитте дә бу минем янымга, әйтә салды:

— Кичен летучка! Сөйләшәсе сүзләр бар!..

Летучка дигәне мине тиргәр өчен, кызган табага бастыру өчен

җыелган-чакырылган булып чыкты. Ярыйсы гына тетелеп чыктым мин мөдир кабинетыннан.

— Син, иптәш Вахитов, — диде мөдир, — сәүдә планын сознательный өзәсең, коллективны премияләрдән колак кактырырга җыенасың, ахры, — ди.

Янәсе, андый үгет-нәсихәт белән, көт тә тор, барлык сатып алучыларны, ягъни покупательларны, биздереп бетерергә можешь. Янәсе, без үстергән алма түгел, нindиен бирәләр, сыйфаты нинди — анда эшең булмасын, сатуыңны бел! Мактап-мактап сат! Иначе какой син сәүдәгәр!..

Кыскасы, алма бүлегеннән алдылар да мине, концентрат бүлегенә күчерделәр. Теге ни инде ул... Такта чәй формасында эшләнгән концентратлар. Ягъни төрледән төрле боткалар... Дөгенеке, тарынык, кара бодайдан да бар һәм башкалар.

Беләсездер инде, һәркайсының пакет кәгазенә цифр-саннар ташка басылган, ягъни мәсәлән индекслары бар. Кайчанга чаклы, күпме срок сакларга була әнә шул боткаларны.

Кызыксынам, карыйм һәм ни күзем белән күрим: әлеге боткаларның барысының да диярлек саклау-сату сроклары әллә кайчан узып киткән. Боткалар, димәк, яраксыз булып чыга?! Уйлап-уйлап тордым да, шундый нәтиҗәгә килдем: «Юк, мәйтәм, боларны һич тә сатарга ярамый, мин, понимаешь, сәүдә челтәренә кеше алдарга дип кермәгән, намусым кушмый!..»

Сатып алучыларга турыдан-туры әйтә тордым:

— Алмагыз... Ризык түгел бу. Күрмисезмени: сроклары чыккан, биш былтыр инде... Эчегез-ниегез, аш казаныгыз богырдый башласа, миңа үк йөгереп киләчәксез, минем якага килеп ябышачаксыз бит, дим...

Бактың исә, мөдир тагын тыңлап торган икән, җәһәт кенә килеп җитте дә яныма, әйтә салды кырыс кына:

— Летучка бүген! Ишетсен колагың!..

Сизенәсездер, тагын бик каты эләкте миңа. Ай-һай пешекләде, мин сиңа әйтим, очынып-ярсынып, акылдан шашкан шөпшә шикелле талады...

Кыскасы, концентрат бүлегеннән дә шудырдылар мине. Соңгы тапкыр кисәтеп, конфет сатарга куйдылар. Башта ярыйсы гына барды минем эш, әмма бер көн тагы бәлагә юлыктым бит. Ниндидер бер адәм прилавка янына килде дә жалу кенәгәсен сорады. Аны-моны уйлап тормастан, тоттым да бирдем кенәгәне. Нинди кеше булгандыр ул, корреспондентмы, әллә берәр контролермы, кенәгәне җентекләп карап чыкты да, бернинди язу-сызусыз кире сузды. Һәм... бу юлы инде мөдирнең үз туксаны барысыннан да яманрак булып чыкты.

— Юк, иптәш Вахитов! — диде ул, кистереп һәм каршы сүз әйтергә урын калдырмыйча. — Сәүдә системасында сез очраклы кеше!.. Башыгыз бармы сезнең, юкмы, кем инде көпә-көндез әллә кемгә, сораган бер кешегә жалу кенәгәсен чыгарып тоттыра ди, ә? Җитте! Саруларым кайный! Сал халатыңны! Бер минут та тоталмыйм сине эштә! Туйдырдың чистый!..

...Менә шулай, агай-эне... Булдырып булмады шул. Әле җитмәсә, хезмәт кенәгәмә «профессиональ яктан яраксыз» дигән язу чәпәп чыгарды мөдир. Янәсе, сәүдә челтәрендә минем ише кеше бер кайчан да эшләргә тиеш түгел һәм правасы да юк эшләргә!..

... Кая, бир әле берне... Көйрәтик булмаса... Җәрәхәтле күңелгә сихәте тимәсме... Тьфү! Ничек тартасың син мондый әшәкене?!. Кит! Кит! Бердәнбер газиз үпкәмне черетеп таркатырга баш ике түгел минем!.. Лутче бер-ике тәмле алма алып ашарга. Тишек-тошыклысын түгел — иң матурын, иң татлысын! Беләм мин: кайда, кемнең, нинди алма сатканын!..

Хәйдәр Басыйров

# БОЛЬНИЦАГА ЭЛӘКТЕМ

## Юмореска



Бер якшәмбедә мунча кереп чыккач, сыра эчәргә туры килде. Иртән торуга тамак шешеп чыккан, күкрәкне дә кыса. Әллә ни зыян юкъюгын, шулай да врачларга күренергә кирәк, белеп булмый дөнья хәлен, көчәеп китмәгәе.

Регистрация тәрәзәсе янында ике дистәгә якын кеше бар. Чиратка мин дә бастым.

— Нихәл, кордаш?..

Борылып карасам, күрше авылның Әсгать. Апаларга кунакка барганда, үзебезне ашка алалар иде.

— Авырып киттеңме әллә?

— Зыянлы түгел, мунча чыккач, салкын сыра эчкән идем, шул ярамаган, ахрысы.

— Шулай шул, сак йөрергә кирәк.

Безнең сүз шунда бүленде. Каршыбызда, ике кулын сузып, бергә өч ел солдат шулпасы чөмергән дустым Хәмит тора иде. Улын күрсәтергә амбулаториягә килгән. Хәл-әхвәл сорашкач:

— Агарынып киткәнсең, температураң да бар бугай, — дип, маңгайдан тотып карады.

Аның тыштан өшеп кергән кулы миңа боздай тоелды. Салкын кулга җылы маңгай, әлбәттә, кайнар кебек иде.

— Да, пожалуй, 39 градуслап бардыр, әй...

Регистрациядән үтеп, чиратымны җиткереп, врачны көтеп, аңа күренеп, бюллетень алып чыкканчы, тагын да берничә таныш-белеш очрады. Барысы да кызгандылар, киңәшләр бирделәр.

Больницадан кайтып, дарулар эчеп, бераз ял итәргә яттым. Берике сәгать черем иттеме-юкмы, ишек шакыдылар. Кайнага белән хатыны икән.

— Авырып больницага барган, дигәннәр иде, хәлеңне белеп кайтыйк, дидек. Ярый әле, больницага салмаганнар.

— Юк, зыянлы түгел, менә дару эчтем әле, шундук әйбәтләнеп китте.

Хатын ял йортында иде, кунакларга чәй куя башладым. Чәйне эчеп бетерүгә, ах-ух килеп, ике улы белән туган апам килеп керде.

— Әсгать үзеңне күреп кайткан. Больницада дигәч, котыбыз очты. Бердәнбер ир туганыбыз бит, авырый күрмә инде.

Боларны чәй эчерүгә сеңелкәш белән кияве, бажа белән хатыны, төпчек җиңгәчәй белән кызы килеп керделәр. Алар да кемнәндер ишеткәннәр, белгәннәр. Иң зур сумканы өстерәп, магазинга чыгып чаптым. Төшкә ябылган булып чыкты, бераздан тагын бардым. Алары булгач, базарга иткә төштем, гөнаһ шомлыгына каршы, акчаны аз алганмын, анысын да ике рәт урадым. Иң ахырдан тагын бер сумка аракы алып кайттым. Соңгы мәртәбә баскычтан күтәрелгәндә, тез буыннарым калтырый иде инде. Әмма үзем турында уйларга вакыт юк, килгән кешене хөрмәт итә белергә кирәк. Казан тутырып аш салдым, табын әзерли башладым.

Ә кунакларның кайсы шахмат уйный, кайсы кәрт суга. Отылган беренә рюмка тутырып аракы тоттыралар.

Мәҗлес ахырында халык исереште. Бажаны, кулбашка салып, өенә илтеп куйдым. Сеңелкәшләр күрше авылдан иде, иртә таңнан эшкә, диләр. Аптырагач, аларны унбиш чакрым җиргә мотоцикл белән илтә киттем. Кайтканда, яңгыр явып, өс-баш лычма су булды. Теш-тешкә тими кайтып кердем. Тик ятарга вакыт юк, ярты төнгә кадәр савыт-саба җыештырдым.

Ә иртәгесен мине, чыннан да, больницага салдылар. Агай-эне хәл белергә тагын килде.

— Теге көнне бик матур идең, нишләп болай булды икән? — дип, барысы да аптырашып утырдылар.

## Фагыйль Сабиров

# ТАПШЫРУ

### Хикәя



Мине редактор үзенә чакыртып алды:

— Үзебезнең район газетасын гына укыйсың, тапшыруларны кызыграк итү өчен бөтен фантазияңне җик, хәзергә эшеңнән канәгать түгел, — диде.

Мин, үз бүлмәмә чыккач, газетабыздагы исемлектән иң күп сөт савучыны эзләп таптым. «Алга» колхозыннан Н. Камалова иде ул. Күпме шалтыратып сорасам да, ни зоотехникны, ни ферма мөдирен табып бирә алмадылар. Шулай да хисапчы кыздан белештем: Камалованың исеме Нәсимә икән.

«Алга» колхозына ничек барып чыгарга дип уйланып утырганда, район культура йортында эшләүче Рәшит исемле дустым исемә төште. Аның «Иж» мотоциклы бар иде. Бәлки дуслык хакына илтеп куяр.

— Ә нигә барып йөрергә? Нужа чигеп йөрмичә дә бөтен район таң калырлык радиотапшыру эшлибез,— дип, ярты сүздән туктатты мине Рәшит дустым. — Аннан соң, монда минем ачылмаган талантым чәчәк атарга җае да чыгып тора, — дип, үзенең планын сөйләргә кереште.

Тапшыру болай башланырга тиеш иде:

Ф а р с и н (*мин үзем ягъни):* Мин «Алга» колхозының сөтчелек

фермаларына якынлашканда кызарып таң атып килә иде. Авылның тынычлыгын бозып, беренче әтәч тавышы ишетелде. *(Рәшит бу вакытта сузып-сузып әтәч булып кычкыра.)* Бу беренче әтәчкә авылның барлык әтәчләре кушылды.

Рәшит *(микрофоннан ераклаша-ераклаша тагын әтәч булып кычкыра).* Ки-кри-күк, ки-кри-күк...

Фарсин. Таң атып килгәндә фермада кеше булуга ышанып җитмичә, шунда йөрүче каравылчы карт белән исәнләштем.— Бабай, исәнме.

Рәшит *(калын тавыш белән бабай булып сөйли).* Аллага шөкер, улым, аллага шөкер. Кая юл тоттың әле әче таңнан?

Фарсин. Бабай, районның җирле радиотапшыру редакциясеннән килдем менә. Сезнең ферманың алдынгы савучысы Нәсимә апа Камалова турында радиодан сөйләргә булдык.

Рәшит. Бик мәслихәт, бик дөрес эшлисез. Күз алдымда үсте, яшьли терлекчелектә эшли башлады. Һай, аның сауган сөтләрен исәпләсәң, авыл уртасындагы түгәрәк күл мөлдерәп тулыр...

Фарсин. Бабай, аны каян эзләп табарга соң, кайсы урамда торуын әйтеп җибәрә алмассыңмы?

Рәшит. Балакаем, күптән сыерлары янында инде ул...

Ферма эченәрәк үткәч, Рәшит нәсел үгезе булып үкерде. Нәсимә апа булып миңа эш тәҗрибәсе турында сөйләде. Аның сыерлары булып мөгрәде.

Ахырдан Нәсимә апа: «Яле, иркәм, әйтче дөресен», — дип җырлый-җырлый, мине озатып калырга тиеш иде.

Терлекчеләргә багышланган тапшыру җомга көнне яңгырады. Ә дүшәмбе эшкә баргач, мине редактор үз кабинетына чакыртып алды.

— Молодец, булдырдың! — диде ул, сүзләрен теш арасыннан гына чыгарып. — Менә, хөрмәтлем, кәгазь.

— Нәрсәгә ул?

— Гариза яз, үз теләгем белән эштән китәм дип... Без монда шундый карарга килдек.

Нишлисең, берхәл итеп булмый. Иртәгесен үк гариза язып редакторга кердем. Тик бу юлы ул елмаеп, ачык чырай белән каршы алды.

— Кая йөрисең? Сиңа монда хат бар менә...

«Хөрмәтле редакция! Терлекчеләргә багышланган тапшыруларда мине мактап сөйләгән Фарсин иптәшкә район газетасы аша рәхмәтемне белдерәм. Ул минем күземне ачты. Әйе, заманында алдынгы савучы, чынлап та, мин идем. Хәзер үзем өйрәткән яшьләр алда бара. Хәзер Нәфисә Камалова беренче урында. Ләкин мин 15 яшьтән савучы булып эшләп зур тәҗрибә туплаган кеше. Әле үземдә яшьләр белән ярышырлык бетмәс-төкәнмәс көч сизәм. Шуңа күрә сеңелем Нәфисә Камалованы ярышка чакырам. Фарсин иптәш, ышанычыгызны акларммын, беренчелек минеке булыр.

Сәлам белән Нәсимә апаң».

Редактор гаризамны ертып ыргытты да:

— Бар, эшеңне дәвам ит, — диде. Чыгып планны ачып карасам, үзара ярышучы коллективлар турында тапшыру оештырырга тиешмен икән. Магнитофонымны астым да «Алга» колхозына киттем. Хәзер миңа Рәшитнең артистлыгы да, мотоциклы да кирәк түгел иде.

## В. И. ЛЕНИНГА БАГЫШЛАНГАН ФЕСТИВАЛЬ

Республикабызда ел саен В. И. Ленинның туган көненә багышлап әдәбият һәм сәнгать фестивале үткәрү күркәм традициягә әверелде.

Юлбашчының юбилеена багышланган сәнгать бәйрәме быел 10 апрельдә Казан дәүләт консерваториясенең актлар залында симфоник концерт белән башланып китте. Анда Бөтенсоюз һәм Бөтенроссия конкурслары лауреаты — Г. Тукай исемендәге татар дәүләт филармониясенең симфоник оркестры В. И. Ленин яраткан музыкаль әсәрләрне — Гетеның «Эгмонт» трагедиясенә Бетховен иҗат иткән увертюра, Чайковскийның патетик симфониясе һәм Гендельның орган концертын башкарды.

Фестивальдә республикабызның иң танылган музыкаль коллективлары, күренекле җырчылар һәм композиторлар катнашты. Шулай ук илебезнең төрле республикаларыннан һәм өлкәләреннән килгән сәнгать осталары — Мәскәү филармониясенең камера оркестры, Латвия ССРның академик хоры, Кабарда-Балкариянең «Кабардинка» ансамбле, Мәскәү эстрада артистлары һәм башка иҗат коллективлары чыгыш ясады.

Әдәбият һәм сәнгать бәйрәме көннәрендә Казанның Актерлар йортында башкалабыз хезмәт ияләре зур кызыксыну белән КПСС Үзәк Комитетының Генеральный секретаре, СССР Верховный Советы Президиумы Председателе Л. И. Брежневның «Кече җир», «Яңарыш» һәм «Чирәм җир» әсәрләре буенча эшләнгән «Илгә турылыклы йөрәк» дигән әдәби-музыкаль композиция карадылар.

Фестиваль көннәрендә Г. Камал исемендәге Ленин орденлы татар дәүләт академия театрының танылган сәхнә осталарыннан СССРның халык артисты Шәүкәт Биктимеров һәм РСФСРның халык артисты Габдулла Шамуков Казан тамашачылары белән очрашуларда булдылар. Алар икесе дә — татар театры сәхнәсендә Ленин образын иҗат иткән артистлар. Очрашулар вакытында Ш. Биктимеров һәм Г. Шамуков тамашачыларга Ильич образын татар сәхнәсендә гәүдәләндерү өчен ничек эшләүләре турында сөйләделәр.

В. И. Качалов исемендәге зур драма театрында «Ленин образы безнең театр сәхнәсендә» дигән темага фотокүргәзмә оештырылды. Театр артистлары завод, фабрика, төзелешләрдә һәм профессиональ-техник училищеларда очрашулар үткәрделәр.

В. И. Ленинга багышланган әдәбият һәм сәнгать фестивале республикабызның башка шәһәрләрендә дә тантаналы бәйрәм төсендә үтте һәм 29 апрельдә Казанның Спорт сараенда Татарстан сәнгать осталарының зур концерты белән тәмамланды.

## ТУКАЙ БӘЙРӘМНӘРЕ

Халкыбызның сөекле шагыйре Габдулла Тукайның тууына 93 ел тулу алдыннан Арча районының Яңа Кырлай авылында мемориаль музей ачылды. Бу зур вакыйгага багышланган тантананы ТАССР культура министры урынбасары М. Т. Низамиев ача. Шагыйрьнең җырларында зурланган Кырлай авылының соңгы елларда танымаслык булып үзгәрүен, яңаруын искәреп, министр урынбасары Яңа Кырлайда Габдулла Тукайга мемориаль музей ачылуның татар әдәбияты һәм сәнгате өчен олы бәйрәм, тарихи күренеш булуын әйтә.

Трибунада Татарстан Язучылар союзы идарәсе председателе, СССР Верховный Советы депутаты Гариф Ахунов.

— Тукай музее илебез халыкларының хокукларын алтын хәрефләр белән язган СССРның Төп Законы — яңа Конституция нигезендә СССР Верховный Советына беренче сайлаулардан соң, аның беренче сессиясеннән соң ачыла,— диде ул.— В. И. Ленинның тууына 109 ел тулган көннәрдә, бөек юлбашчыбызга багышланган әдәбият-сәнгать фестивале көннәрендә ачыла. Бөтен прогрессив кешелек дөньясы бердәм рәвештә халыкара балалар елын уздырган дәвердә ачыла. Һәм ул шулай булып тарихка да кереп калачак.

Мемориаль музейны ачу тантанасында КПССның Арча райкомы секретаре М. Л. Гайнетдинов, Яңа Кырлай урта мәктәбенең татар теле һәм әдәбияты укытучысы Гомәр Яруллин, «Тукай — Кырлай» совхозының сыер савучысы Зәкия Шакирова, Татарстан АССР Дәүләт музее директоры Л. Г. Вәлиева иптәшләр чыгыш ясады.

Иң истәлекле минут: ТАССР Министрлар Советы Председателе урынбасары М. Х. Хәсәнов, тантанага килүчеләрне республикабызның культура тормышында булган бу зур вакыйгага уңае белән котлап, ишектәге алсу тасманы кисә.

Мемориаль музейны ачу тантанасында КПСС өлкә комитетының культура бүлеге мөдире М. М. Мусин катнашты.

* * *

Шул ук көнне Яңа Кырлай авылы культура йортында Г. Тукайның туган көненә багышланган зур әдәби кичә булды. Анда республикабызның күренекле әдәбият һәм сәнгать эшлеклеләре катнашты.

* * *

26 апрельдә халык шагыйре Габдулла Тукайның туган көненә багышланган Шигырь бәйрәме Казанда булды. Анда катнашкан әдәбият һәм сәнгать эшлеклеләре В. И. Ленинның Ирек мәйданындагы һәйкәленә чәчәкләр куйдылар. Аннары А. С. Пушкин, А. М. Горький, Габдулла Тукай һәм Муса Җәлил һәйкәлләренә чәчәкләр салынды.

Шул ук көнне М. Җәлил исемендәге татар дәүләт опера һәм балет театры янындагы Г. Тукай һәйкәле алдында шигъри митинг булды. Аны Татарстан Язучылар союзы идарәсе председателе Г. Ахунов ачты.

Беренче сүз республиканың Г. Тукай исемендәге Дәүләт премиясенә быел лаек булган яңа лауреатларга — драматург Туфан Миңнуллин һәм М. Җәлил исемендәге татар дәүләт опера һәм балет театры солисты Ренат Ибраһимовка бирелде. Алар илебездәге барлык халыкларның әдәбиятын һәм сәнгатен үстерү турында даими кайгыртып торучы коммунистлар партиясенә һәм Совет хөкүмәтенә ихлас күңелдән рәхмәт белдерделәр.

Шигъри митингта шагыйрьләрдән Сибгат Хәким, Әхмәт Исхак, Мөхәммәт Садри, Равил Фәйзуллин, Шәүкәт Галиев, Роберт Әхмәтҗанов, Гөлшат Зәйнашева, Мәхмүт Хөсәен, Лидия Григорьева, Галимҗан Латыйп, Ренат Харис, Радиф Гатауллин, Мөдәррис Әгъләмов, Зөлфәт, Шамил Маннапов һәм башкалар шигъриятебезнең мәңге сүнмәс йолдызы — Тукайга багышланган шигырьләрен укыдылар.

Митингта КПСС өлкә комитетының культура бүлеге мөдире М. М. Мусин, ТАССР Министрлар Советы Председателе урынбасары М. Х. Хәсәнов иптәшләр катнашты.

Кич белән Шигырь бәйрәме В. И. Ульянов-Ленин исемендәге Казан дәүләт университетының Актлар залында дәвам итте.

Шундый ук кичәләр һәм шигырь бәйрәмнәре Чаллы, Әлмәт, Түбән Кама һәм республикабызның башка шәһәрләрендә язучыларның актив катнашы белән тантаналы төстә үтте.

## 65 ЕЛ ЭЛЕК ЯЗЫЛГАН ШИГЫРЬ
## МӘРХҮМ ТУКАЕВКА

**(2 апрель мөнәсәбәте илә)**

И, Тукаев, син Тукаев! Шагыйрь идең би мәсәл[1],
Бигрәк иртә, бик вакытсыз, алды сине бу әҗәл.
Сине безгә биргән икән, бер гомерсез җан кылып.
Ни чара? Без бичарага булса шул тәкъдир әзәл[2].
Гомре кыска улачагың күп сүзендә вар (бар) иде,
Әллә синга мәгълүм иде барчага мәҗһүл әҗәл[3].
Шул гомерсез гомрең ичрә[4] кичә, көндез туктамый (би мәләл[5].)
Сайрадың тик милләтем дип, алмадың һичбер бәдәл[6].
Алмадың да, сормадың да[7], тәмгы, өмед кылмадың[8],
Шуның өчен гани шаның[9], бакый намың би хәләл[10].
Шуның өчен үлмәдең дип, әйтә сине милләтең,
Үлмәдең, тик милләткә мәңгелек булдың мәсәл[11].

**1914 ел, 28 март.**

Бу шигырьне редакциягә татар әдәбияты укытучысы пенсионер **Вәли ага Хаҗиев** тапшырды. Ул аны «Әльислах» газеталары эченнән кульъязма килеш тапкан. Шигырь авторы үз имзасын **Ибраһим бин Гыйсмәти әл-борындыкый** дип куйган.

---

[1] Тиңдәшсез шагыйрь идең. [2] Мәңгелек язмыш.
[3] Кешеләргә билгеле булмаган үлем вакыты.
[4] Кыска гомерең эчендә. [5] Армый-талмый бик күп эшләдең.
[6] Эшләгәнең өчен хезмәт хакы да алмадың.
[7] Сорамадың да. [8] Кешедән өмет итмәдең, сорамадың.
[9] Бөек дәрәҗәң. [10] Исемең мәңгегә дан булып калачак.
[11] Мәңгелек үрнәк булдың.

## ТӨРЛЕ ЯКТА, ТӨРЛЕ ТЕЛЛӘРДӘ

Филология фәннәре докторы Әбрар Кәримуллин туплаган мәгълүматларга караганда, Г. Тукай әсәрләре **рус телендә**, 1920 елдан алып хәзерге көнгә кадәр аерым китап булып 36 басмада чыгарылган, аларның гомуми тиражы 2 миллион данәгә җитә яза. Шулар арасында бер тапкыр ике томлыгы, 14 тапкыр Сайланма әсәрләре һәм 19 тапкыр балалар өчен китаплары нәшер ителгән.

Рус теленә тәрҗемә аркылы Тукай әсәрләре илебезнең барлык халыклары арасында тарала. Аерым китап булып һәм вакытлы матбугат битләрендә чыгарылганнары белән исәпләгәндә, Совет власте елларында Тукай әсәрләре 26 телдә басылган.

Тукай шигырьләре чит ил халыклары телләренә дә тәрҗемә ителә.

1969 елда Мәскәүнең «Мир» нәшрияты Гаяз Ишмөхәммәтов тәрҗемәсендә «Шүрәле» әкият-поэмасын гарәп телендә, 1977 елда «Прогресс» нәшрияты «Европа поэзиясе» сериясендәге сайланма әсәрләр җыентыгында Г. Тукайның берничә шигырен инглиз, немец, француз телләрендә бастырып чыгарды. Лондон университеты каршындагы Шәрык институты җәмгыятенең Гыйльми язмаларында Бензинг тәрҗемәсендә «Шүрәле» инглиз телендә басылган. Румыниянең венгр автономияле өлкәсендә

чыгарылган татар әдәбияты җыентыгында Тукай шигырьләре венгр теленә тәрҗемә итеп урнаштырылган. ГДРда һәм ГФРда чыккан әдәби антологияләрдә Тукай шигырьләреннән үрнәкләр бирелгән.

Румыния татарлары өчен чыгарылган уку китапларында Тукайның «Исемдә калганнар»ы һәм аерым шигырьләре басылган. Хельсинкида Финляндия татарлары өчен дә Тукайның җыентыгы чыгарылган.

Китап булып басылу ягыннан Г. Тукай әсәрләре революциягә хәтле дә, революциядән соң да татар язучылары арасында беренче урында тора. 1917 елдан алып аның әсәрләре туган телебездә 103 тапкыр аерым китап булып басылып чыккан. Алар арасында ике дүрт томлык, 18 сайланмалар һәм балалар өчен 56 басма бар. Боларның гомуми тиражы 1,5 миллионга җитә.

*
* *

Мәскәүдә әдәбиятчыларның А. Фадеев исемендәге Үзәк йортында ТАССРның атказанган сәнгать эшлеклесе рәссам Фәйзрахман Әминовның күргәзмәсе булды. Аны РСФСР Культура министрлыгы, РСФСР Художниклар союзы һәм аның Ленинград оешмасы, әдәбиятчыларның Үзәк йорты оештырган иде.

Күргәзмәгә художникның бөек татар шагыйре Г. Тукай әсәрләре нигезендә иҗат ителгән рәсемнәре куелды.

## БӨТЕНСОЮЗ КИҢӘШМӘСЕНДӘ

СССР Язучылар союзы идарәсе Мәскәүдә әдәбиятчыларның А. Фадеев исемендәге Үзәк йортында республика, край, өлкә язучылар союзлары җитәкчеләренең, партия оешмалары секретарьларының һәм әдәби басмалар редакторларының Бөтенсоюз киңәшмәсен үткәрде. Анда КПСС Үзәк Комитетының 1978 елгы июль һәм ноябрь Пленумнары һәм иптәш Л. И. Брежневның чыгышларында бирелгән нәтиҗәләр һәм киңәшләр яктылыгында совет әдәбиятының бурычлары турында җитди һәм эшлекле сөйләшү булды. Киңәшмәдә Татарстан Язучылар союзыннан партия оешмасы секретаре Туфан Миңнуллин, «Казан утлары» журналының баш редакторы урынбасары Әхсән Баянов, «Идел» альманахы редакторы Мансур Вәлиев катнашты.

## ПОЭЗИЯ СЕКЦИЯСЕНДӘ

Шагыйрьләр секциясенең чираттагы утырышында СССР Фәннәр академиясенең Г. Ибраһимов исемендәге тел, әдәбият һәм тарих институты галимнәре дә катнашты. Филология фәннәре докторы профессор П. Г. Нигъмәтуллинаның «Хәзерге татар шагыйрьләре иҗаты мисалында дөнья моделе һәм эстетик идеал» дигән докладын шагыйрьләр һәм әдәбият белгечләре зур кызыксыну белән тыңлады. Докладчы фәнни тикшеренүләренә нигез итеп шагыйрьләрдән И. Юзеев, Р. Фәйзуллин һәм Р. Гатауллин иҗатларын алган.

Секция утырышында катнашучылардан өлкән шагыйрь Х. Туфан, филология фәннәре докторы Н. Юзиев, филология фәннәре кандидаты М. Бакиров, шагыйрьләрдән Г. Рәхим, Ш. Маннапов һәм башкалар, фикер алышуларда чыгыш ясап, галимнең бу тикшеренүләре яңача, кызыклы һәм бик әһәмиятле булуын әйттеләр, татар поэзиясен бу юнәлештә өйрәнүдә докладчыга уңышлар теләделәр.

## ТЕОРЕТИК СЕМИНАРНЫҢ ЙОМГАКЛАУ ДӘРЕСЕ

Татарстан Язучылар союзы каршындагы даими эшләп килүче теоретик семинарның йомгаклау дәресе булды. «Фәнни-техник революция чорында әдәбият-сәнгать өлкәсендә идеологик көрәш» дигән темага докладларны «Идел» альманахы редакторы М. Вәлиев, «Казан утлары» журналы редакциясенең тәнкыйть бүлеге редакторы Р. Мөхәммәдиев, «Азат хатын» журналы редакциясенең бүлек редакторы Р. Юсупова, шагыйрь М. Галиев сөйләделәр. Фикер алышуларда Татарстан Язучылар союзы идарәсе председателе Г. Ахунов, партбюро секретаре Т. Миңнуллин, язучылардан К. Тимбикова, В. Ихсанова, Р. Мостафин һәм башка иптәшләр катнашты.

## ИСТӘЛЕКЛЕ ОЧРАШУ

Апрель аенда РСФСРның М. Горький исемендәге һәм республиканың Г. Тукай исемендәге Дәүләт премияләре лауреаты шагыйрь Сибгат ага Хәким белән Татарстан комсомолының М. Җәлил исемендәге премиясе лауреаты Илдар Юзеев Минзәлә педагогия училищесында һәм районның Хуҗамәт, Кузкәй авылларында поэзия сөючеләр белән очраштылар. Район газетасы редакциясе каршында оештырылган «Бөреләр» әдәби берләшмәсенең беренче утырышында катнашып, яшь һәм башлап язучыларның әсәрләренә карата фикерләрен әйттеләр, киңәшләр бирделәр.

Күренекле шагыйрьләрнең Алабуга педагогия институтында студентлар һәм укытучылар белән очрашуы да истәлекле булды. Әдипләр татар әдәбияты һәм поэзиясенең бүгенге уңышлары турында сөйләде, кичәдә катнашучыларның сорауларына җаваплар бирде һәм шигырьләрен укыдылар.

## ТАТАРСТАН КОМСОМОЛЫНЫҢ 60 ЕЛЛЫГЫНА

### «ИҖАТ ДЕСАНТЫ»

Апрель башында Бөтенсоюз удар комсомол төзелешләре барган Чаллы һәм Түбән Кама шәһәрләренә республикабызның бер төркем иҗат яшьләре сәяхәт итеп кайтты. «Әдәбият һәм сәнгать десанты» дип исемләнгән бу бәйрәм республикабызның иҗат союзлары һәм ВЛКСМның Татарстан өлкә комитеты тарафыннан оештырылды. Анда шагыйрьләрдән Равил Фәйзуллин, Рәдиф Гатауллин, Равил Вәлиев, Роберт Миңнуллин, артистлардан Алла Фадеичева, Илдар Хәйруллин, Валерий Минаев, композитор Рәшит Абдуллин, «Саз» халык ансамбле

һәм башкалар катнашты. Иҗат яшьләре КамАЗ цехларында, Түбән Камадагы шин заводында, профессиональ-техник училищеларда һәм мәктәпләрдә чыгыш ясадылар. «Татарстан яшьләре» газетасы «иҗат десантында» катнашкан шагыйрьләрнең яңа әсәрләрен махсус сәхифә итеп чыгарды.

### СТУДЕНТЛАР ТЕАТРЫ

Ленин орденлы Мәскәү дәүләт энергетика институтының Казан филиалында укучы татар студентлары оештырган драма театры республика комсомолының 60 еллыгына Татарстанның атказанган сәнгать эшлеклесе Туфан Миңнуллинның «Ак тәүбә, кара тәүбә» комедиясенең премьерасын күрсәтте. Студентлар тормышын чагылдырган бу әсәрне сәхнәгә Әнвәр Әхмәдуллин куйган. Художнигы — ТАССРның атказанган сәнгать эшлеклесе Петр Баландин. Спектакльдә РСФСРның М. Глинка исемендәге Дәүләт премиясе лауреаты, ТАССРның атказанган сәнгать эшлеклесе композитор Фасил Әхмәтов көйләре файдаланылган.

### ШИГЫРЬ КИЧӘСЕ

24 апрельдә Казанның Актерлар йортында яшь шагыйрьләрнең иҗат кичәсе булды. Аны Татарстан телевидениесе, Бөтенроссия театр җәмгыятенең Татарстан бүлеге һәм республика китап сөючеләр җәмгыяте В. И. Ленинга багышланган сәнгать фестивале һәм Татарстан комсомолының 60 еллыгы уңае белән үткәрделәр. Шигырь кичәсендә шагыйрьләрдән Зөлфәт Маликов, Разил Вәлиев, Роберт Миңнуллин катнашты. Аларның чыгышы телевидение буенча тапшырылды.

### ТАТАР КОМПОЗИТОРЛАРЫНЫҢ УҢЫШЫ

РСФСР композиторларының Мәскәүдә 9—13 апрельдә үткәрелгән съездында республикабызның күп кенә музыка осталары катнашты, концерт залларында аларның яңа әсәрләре тыңланды. Мәскәү дәүләт консерваториясенең академик симфоник оркестры СССРның халык артисты, Дәүләт премиясе лауреаты Нәҗип Җиһановның Сигезенче симфониясен башкарды. Съезд алды көннәрендә үк Алмаз Монасыйповның Дүртенче симфониясе яңгырады. Әсәрне Төньяк Осетия филармониясенең симфоник оркестры уйнады һәм аңа композитор үзе дирижерлык итте.

Илебез башкаласының җәмәгатьчелеге татар композиторларының яңа әсәрләрен бик җылы каршылады.

Мәскәүнең Чайковский исемендәге концерт залында СССР Оборона министрлыгының үрнәк оркестры, башка тугандаш халыклар композиторларының әсәрләре белән берр әттән, республика комсомолының М. Җәлил исемендәге премиясе лауреаты Мирсәет Яруллинның «КамАЗчылар маршы»н уйнады.

Съезд көннәрендә Мәскәүнең Композиторлар йортында Рөстәм Яхин, Фасил Әхмәтов, Бату Мулюков романслары яңгырады. Аларны ТАССРның халык артисты Эмиль Җәләлетдинов башкарды.

* * *

Луиза Хәйретдинова — балалар өчен иң актив иҗат итүче композитор. Аның «Мәкерле песи» операсы (либретто авторы — Зөлфәт Маликов) М. Җәлил исемендәге татар дәүләт опера һәм балет театры сәхнәсендә уңышлы бара. Халыкара балалар елы дип игълан ителгән 1979 елны да композитор яңа әсәр — «Һәрвакыт әзер!» дигән пионер кантатасы белән каршылады. Шагыйрьләрдән Роберт Миңнуллин һәм Абдулла Сәләх сүзләренә язылган бу кантата Татарстан композиторларының XVI пленумында уңай бәя алган иде. Күптән түгел генә ул Казан телестудиясенең балалар хоры башкаруында зәңгәр экран аша яңгырады.

### ТЕАТР ЯҢАРА

ТАССР Министрлар Советы карары белән Татар дәүләт республика күчмә театры Татар дәүләт драма һәм комедия театры итеп үзгәртелде. Карарда яңартылган театр өчен бина һәм 300 урынлы тамаша залы булдыру, коллективның эшчәнлеген активлаштыру чаралары билгеләнгән.

## СОЮЗНЫҢ ӘЛМӘТ БҮЛЕГЕНДӘ

### ЗАМАНДАШ ГЕРОЙ — КЕМ УЛ?

Нефть ягы язучыларының январь аенда үткәрелгән чираттагы җыелышы «Татар әдәбиятында заманчалык» дигән темага багышланды. Бүлек җитәкчесе Ә. Маликов докладыннан соң язучылардан Ш. Бикчурин, Р. Төхфәтуллин, С. Сөләйманова, М. Хәсәнов, Җ. Рәхимов үзләренең фикерләре белән уртаклаштылар.

### ОТЧЕТ-САЙЛАУ ҖЫЕЛЫШЫ

Шушы елның 4 апрелендә бүлекнең отчет-сайлау җыелышы булды. Нефть якларында яшәүче әдипләрнең соңгы өч елда иҗат иткән әсәрләре һәм бүлекнең оештыру эшчәнлеге турында докладны аның җитәкчесе Әдип Маликов сөйләде.

Фикер алышуларда язучылардан В. Мальцев, Х. Хәйруллин, К. Булатова, Җ. Рәхимов, М. Хәсәнов, Г. Афзал, Э. Мөэминова, Н. Әхмәдиев, Әлмәт татар драма театры режиссеры Р. Абдуллаев, Татарстан китап нәшриятының баш редакторы В. Нуруллин бүлек эшчәнлегенә уңай бәя бирделәр. Йомгаклау сүзе белән Татарстан Язучылар союзы идарәсе председателе Г. Ахунов чыкты.

Отчет-сайлау җыелышында КПССның Татарстан өлкә комитеты культура бүлеге инструкторы Р. Гарипов, Татарстан Язучылар союзы идарәсе председателе урынбасары Ф. Миңнуллин һәм башка иптәшләр катнашты.

Бүлекнең яңа бюросына Ә. Маликов (җаваплы секретарь), Р. Төхфәтуллин, Ш. Бикчурин, ревизия комиссиясе председателе итеп Г. Афзал сайланды.

# «ВАКЫТ ҺӘМ КЕШЕЛӘР»
# КОНКУРСЫ

Киләсе елда В. И. Ленинның тууына 110, Татарстан Автономияле Совет Социалистик республикасы төзелүгә 60 ел тула. Ленин һәм Татарстан — бу ике исем һәр вакыт бер-берсеннән аерылгысыз. Татарстан җирендә — аның башкаласы булган данлы Казанда яшь студент Володя Ульянов беренче революцион рух, революцион чыгыш чирканчыгы ала. Татарстан АССР төзелү хакындагы тарихи Декретка юлбашчыбыз В. И. Ленин кул куйган.

Шушы ике зур бәйрәмгә багышлап, «Казан утлары» журналы редакциясе «Вакыт һәм кешеләр» дигән рубрика белән В. И. Ленинның Татарстан белән бәйле эшчәнлеге, республикабызның бүгенге вакыйгалары, хезмәт ияләренең бөек казанышы һәм матур тормышы турындагы очеркларга ачык конкурс игълан итә. Аның йомгагы республикабызга 60 яшь тулган көндә ясалачак.

Җиңеп чыккан очерклар өчен түбәндәге бүләкләр билгеләнә:

**Беренче бүләк (берәү) — 150 сум,**
**Икенче бүләк (икәү) — 100 сум,**
**Өченче бүләк (өчәү) — 75 сум күләмендә.**

Конкурста эшче һәм колхозчы хәбәрчеләр, журналистлар һәм язучылар катнашыр дип көтәбез. Иң яхшы очерклар «Казан утлары» журналында урын алачак.

Очеркларны (15 бит күләмендә) «Конкурска» дип җибәрергә.

**Конкурс жюрие.**

## КАДЕРЛЕ УКУЧЫ!

Озак та үтмәс, сезнең кулга журналның 8 нче саны килеп керер. Анда ниләр бар? Кайсы әдипнең нинди әсәре белән танышырга мөмкин булачак? Бу сораулар, әлбәттә, әдәбият сөючене һәр чак кызыксындырып тора. Кыскача гына аңлатып үтик.

Журналның август ае саны соңгы елларда үз тавышын нык ышаныч белән яңгырата башлаган яшь шагыйрь Фәннур Сафинның яңа шигырьләре белән ачыла. Шагыйрьнең укучыга әйтер тирән мәгънәле сүзләре нечкә моңга өртелгән.

Күренекле язучыбыз Атилла Расих романының беренче өлеше сезне катлаулы вакыйгалар эченә алып кереп китәргә өлгергәндер инде. Персонажларның язмышы күңелегездә төрле фикерләр уяткандыр: кайсы белән бәхәскә керергә уйлыйсыздыр, икенчесен якларга чамалап куйгансыздыр. «Сынау» романының 8 нче санда биреләчәк өлеше сезнең башта туган кайбер сорауларны ачыклар, ә икенчеләрен тагын да киеренкерәк хәлгә китерер. Чөнки роман әле бу санда да тәмамланмый.

Укучыга тәкъдим ителә торган икенче проза әсәре Татарстанның 60 еллыгы уңаеннан бирелә. Өлкән әдибебез Гомәр ага Бәширов шактый зур күләмле бу хикәясен «Кара төндә нур чәчеп...» дип исемләгән. Кара төн — патша Россиясе шартларында интегеп яшәгән авыл халкының авыр хәле, нур — халыкның алга, яктылыкка, гаделлеккә омтылышы, изге теләкләре, күркәм гадәтләре.

Гадәттәгечә, журналның бу санында да проза әсәрләре шигырьләр белән аралашып бара. Монда сез Рәдиф Гатауллинның, Харрас Әюповның яңа әсәрләре белән таныша аласыз. «Дуслар җыры» рубрикасында Кырым татарлары шагыйрьләренең иҗат үрнәкләре бирелә.

Язучы Фатих Хөсни журналга «Орлыклар кая төшә?» исемле язмасы белән катнаша, әдәби осталык турындагы уйлануларын тәфсилли.

8 нче сандагы калган язмалар да укучы игътибарын җәлеп итми булмас. Т. Әйдинең «Атомны йөгәнләүче» дип аталган очеркы, Р. Харисовның «Татарстан артистлары Италиядә һәм Мальтада» исемле юлъязмасы, даими рубрикалардагы материаллар һәм әдәбият-сәнгать яңалыклары — барысы да зур кызыксыну тудырыр дип ышанабыз.

Бәясе 50 тиен
Цена 50 коп.

# КАЗАН УТЛАРЫ (ОГНИ КАЗАНИ)

Ежемесячный литературно-художественный и общественно-политический журнал

ОРГАН СОЮЗА ПИСАТЕЛЕЙ ТАТАРИИ

ИНДЕКС 73210